**Габделхабир б. Ярулла б. Валиулла б. Хабибулла б. Габделхамид б. Бик Мухаммад б. Иш Мухаммад (1905-1994).**
Получил образование в медресе Касымия и Мухаммадия. В 1927 г. получил традиционный "указ" на должность имама второй мечети в д. Ямаширма. С 1 июня 1967 г. работал имамом мечети Марджани в Казани. Основное богословское наследие Яруллина представлено в его проповедях.
Библиография: Миннуллин И.Р., Бустанов А.К. Яруллин, Габдельхабир Яруллович // Ислам в Татарстане. Энциклопедический словарь. М.: ИД Медина, 2017. С. 248; Мөбәрәк Ж. Габделхәбир хәзрәт Яруллин турында хатирәләрем. Казан: Иман нәшрияты, 2016; Габделхәбир хәзрәт Яруллин. Җомга вә гает вәгазьләре. Казан: Иман нәшрияты, 2005.
Работа выполнена в рамках профессуры ТАИФ по истории исламских народов в составе России. Набор текста: к.ф.н. Алсу Ахмадулловна Хасавнех.
1967 нче Миляди елларда җомга намазларында сөйләнгән вәгазьләр
Габделхабир Ярулла

1968 нче ел 23 нче февральдә хаҗ кылу (хаҗга бару нияте белән) Казандан киткәнбез

Хөрмәтле хәзрәт!
Бу кульязма вәгазьнең таркау хәлендә булу әһәмиятен югалтуындан төрлечә фикерләнгән уйлар бүгенге көндә бер җыентык китап булу, үзенә бер күркәм сыйфат алуы белән мөһим. Вәгазь-нәсыйхәт тирән гыйбарәт булган ике еллык хатирәне искә алмый мөмкин түгел. Үзенең эчрә күб кенә тарихи истәлекләрне алган белмәгәнләргә дәрес бирү булса, белүчеләрнең йилбәрә онытылганларны искә төшереб яңартучы бу кечкенә түгел, бәлки хәзерге дәвердән тарихларның чын, дөрес булыб, күб көч сарыф кылу, эзләнү, күб тырышлык, дәлилләр берлән нигезләнеб бер көтелгән булуына һичбер шик, шөһбәгә урын калмаган. Киләчәңездә бу илнең олыгъсы – хәзрәт безләргә изге теләк берлән, уңышлыклар теләб, киләчәгемездә зур өметләр, гомерләрегезгә бәрәкат биреб, без мөселманларны шатландырсак иде.
Ихтирам берлән Нәҗиб Фәхретдинов.
Казан. Февральнең 12 сендә, 1975.
Әʿраф, 33 :
الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَٰذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْلَا أَنْ هَدَانَا اللَّهُ
Мәрҗани хәзрәт хакында бар.
Коръәнне хөрмәтләү хакында.
Гайбәт хакында.
Кабер вә үлем хакында бар.
Мал, балалар хакында.
Юмартлык хакында 8нче номерда.
Исраф хакында.
Ният хакында
Хаҗ сәфәре соңында, 6 нчы апрель.
Тагын да сәфәр хакында, 18 апрель.
Мәрҗани хәзрәт хөтбәсе.
Әл-халәл бирә вә әл-хәрам бирә хакында.
Намаз хакында.

Миграҗ хакында бар.
Биш вакыт намазның фарызлыгына Коръән аятьләре белән дәлилләр.
Иң беренче көнне сөйләнгән вәгазь.
Беренче номер.
№1
Мәүлед аенда сөйләнгән вәгазьләр.
1967 нче ел июньдән башлаб.
Әлхәмделилляһи Раббел галямин вәс салавәт вәс сәлам галә рәсүлиһи вә сахбиһил әҗмәгыйн. Хәзрәт Гомәр (радый Аллаһу ганһу. – рг) шул рәвешле риваять кылына: бер вакыт рәсүл (сгс) хозурында утырган вакытта пакь киемле, матур кыяфәтдә бер ир керде. Арабызда бу ирнең кем икәнен бер-берсе белүче юк иде. Юлдан килүче мөсафир адәмгә охшаш иде, ди. Фәкать рәсүлнең бик белгән кешесе кебек рәсүл янына ук килеб утырды, хәтта рәсүлнең кызына караб, кулларын ботларына куеб, әдәб белән утырган. Тик соңында исә:
الايمان عن اخبرني محمد يا
- диб. Фә-кал галәйһис сәлам:
بالقدر وتؤمن الآخر؛ واليوم ورسله وكتبه وملائكته بالله تؤمن أن الإيمان
- диб җаваб бирә. Бу хәдиснең тагын да ахыры бар. Бүгенге сөйләргә теләгән вәгазем пәйгамбәремезнең туган ае мөнәсәбәте белән пәйгамбәрләр иман хакында сөйләмәкче булам.
Аллаһы Тәбарәка вә Тәгалә тарафындан һичбер нәрсәне бер гади ула, шик кабилияте булмаган кеше аркылы өйрәтү мөмкин түгел. Мәсәлән, бер бик надан кешенең югары дәрәҗәдә булган галим вә философ, хаким кеше белән мәҗлесендә ни кадәр утырса да, андан хаким вә файда ала алмый, яки бер бик түбән дәрәҗәле, беркая чыкмаган бер фәкыйрь адәмнең бөек бер хөкүмәт ады янына барса, каушаб калуы бик мөмкин. Бу табигый хәл. Бу ике кеше асылда һәр икәве зәгыйфь, гөнаһлы, шәйтан катышма затлар була торыб, боларның әдәб-тәрбия, гыйлем булмаганлыктан гына бер-берсен аңлаша алмаслар, уйлаб карарга кирәк. Адәм балаларның күпчелеге һәрвакыт шәйтан, нәфес тозагында һәм игътикад вә гамәл җәһәтенчә бозык вә яман хәлдә вә һәрвакыт үзене һәлакәт чыгуда ташларга хәзер торыб, кальбен, күңелен каралык (касавәт) басачанлыкларын, аның күңелендә хаклыкны (мөсаррәфәт) аңларлык ак белем, гакыл булмавы сәбәбле, бер гади адәмнең шундый адәмләр берлән аралашуы мөмкин булмас; шушы дусд – түбәнлекдә вә бозыклыкда булган кеше. Чын пакъ вә һич косурсез – кимчелексез булган, күз күрмәгән вә гакыл ирешмәгән галим, хаким.
Халик (Алла исеме – А.Х.) җөмлә мәхлукатның Раббел галәмин булган бөек бер Зат белән андан нәрсә өйрәнә алсын, нәрсә аңласын, ничек аның хөтбенә тугъры була алсын? Ул зат тарафындан бәндәләрне ирешдерергә тиешле булган әмре вә нәһиләрне, кәма йәнбәгый (гар.: как проистекает, аңлашылганча), аңлатуы мөмкин түгел. Бәс Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Үзе камил хакимияте вә тәдбире буенча бәндәләрнең үз араларындан яхшы табигатле, күркәм холыклы, пакъ калебле вә үзенең рәхмәт тәрбиясе берлә тәрбияләнгән, фазыл вә кирам тәрбия берлә әдәбләнгән вә фәрештәгә йолыгырлык вә андан соң сүз ишетерлек мәртәбәгә ирешкән. Аллаһының сүзене өйрәнерлек вә аңлаб халыкка ирештерерлек вә аңлатырлык булган кадерле вә хөрмәтле бер хатынны сайлаб (рәсүл, бәни пәйгамбәр, илче) кылмышдыр. Тәэкид, ул илче бәндәләренә Алланың юлын ирешдерер. Менә бу илчеләр Алла хөсен китерүче шәригать хөкемләрен, Алла теләген дуста дөрест аңлатучы, Алланы танытучы вә шөкер гыйбадәт рәвешләрене яхшы өйрәтүче

الْمُبِينُ الْبَلَاغُ إِلَّا عَلَيْنَا وَمَا
диб, һәртөрле авылгыларга, җәбер-залимләргә бер үзләре күкрәк киереб каршы торыб һичкемдән курыкмый, Алла боерыкларын бәндәләргә ирештерүче (пәйгамбәр, бәни рәсүл) исеме белән аталган хөрмәтле затлар буладыр. Шушы мөхтәрәм затларның, пәйгамбәрләрнең әүвәлгесе – атамыз Адәм (гс) булыб, иң соңгысы – сәййидел әнбия, әшрафел әнбия, хәтимел мөрсәлин булган безнең пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа (сгс)дер. Шушы ике пәйгамбәр арасында бик күб пәйгамбәрләр килгән. Шушы пәйгамбәрләрнең һәркайсы Алланың хөрмәтле затлары. Болар һәрвакытда гөнаһдан пакъ. Пәйгамбәрлек килгәнче, пәйгамбәрлек килгәч дә һәр урында, һәрвакыт мәгъсумлар диб, иман китерергә
رُسُلِه من أحدٍ بَيْن نُفَرِّق لا
иман китерү, ышану фарыз. Әгәр бер кеше шушы мөэмәнун биһи (ышанырга, иман итәргә) тиешле булган (алты төрле – җиде төрле) нәрсәнең берсенә генә ышанмаса да, мөселман булмый. Яки шушы җиде нәрсәнең берсенә шәйлә тиешле (ай-һай), шулай ук булыр микән диб уйласа, шәйлә билә иман булмый. Чын мөселман булу өчен
الموت بعد والبعث تعالى الله من وشره خيره والقدر الآخر واليوم ورسله وكتبه وملائكته بالله آمنت
мәгънәсен белеб, тел белән әйтү, күңел белән, чын күңелдән ышану – мөэмин-мөселманлыкның иң беренче шарты, мөхтәрәм җәмәгать! Тиздән Мәүледен нәби кичәсе җитә, Аллаһы насыйб итсә, инша Алла.
Шул көндә, вакытда пәйгамбәремез хакында тулырак, ачыграк сөйләргә тырышырмын. Пәйгамбәрнең әхваленә кадәр мөкаддәмә рәвешендә мөэмин биһи булган, ышанырга тиешле булган пәйгамбәрләр хакында беркадәр сөйләргә тиеш күрдем. Сөйләгән вәгазьләремдә беркадәр мөлке хасил иткәнче кимчелекләрем күб булыр, бу хакда сүз дә юк. Имди Аллаһы Тәбарәкә вә хәзрәтләре шушы нәрсәләр хакында иманымызны нык, һәртөрле шәйдә шөбһәләрен, пакъ калеб, чын иман насыйб итеб, мөэмин булыб гомер итәргә насыйб итсен. Ахыры сылуларыбыз да соңгы сәгатьләребездә иманыбызны юлдаш кылыб, кәлимә шәһадәт, кәлимә тайыб белән дөньядан үтеб, әбәди сәгадәтгә ирешергә Аллаһы насыйб итсен. Амин.
Бисмилләһир рәхманир рәхим. Мәүлед аенда сөйләнелгән вәгазь.
Әлһәмделилләһи Раббел галәмин вә салли Аллаһу галә сәййидинә Мөхәммәд вә алиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн.
Мәүледен нәби кичәсен, пәйгамбәрнең туган көнләрен хөрмәт белән искә алуны теләб, мәсҗедемезгә җыелган мөхтәрәм мөселманлар! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтләренең сәламе, рәхмәте, бәрәкате вә мөгъфирәте Аллаһы ризалыгы барчаларыбызга насыйб булсын.
لالعالمين رحمة الا ارسلناك ما و بالله استعيذ
булган аның күрсәтелгән тугъры юлы белән барсак, дөнья Ахирәтдә бәхетле булыб, сәгадәт дарәйнга ирешүебезгә сәбәб булган сәййидел әнбия булган пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа (сгс) нең туган көнләре, туган кичәләре барчаларыбыз өчен мөбарәк булыб, гомер барча дөньяда яшәгән мәртәбездә мөкаддәс, пакъ булган Ислам дине үзренә яшәб, ахыр гомеребездә соңгы сәгатьләребез, соңгы сулуларыбыз да кәлимә шәһадәт, кәлимә таййиб белән яхшы үлемләр (хөсне хатим) белән дөньядан үтеб, җенабее Раббел галәмин хәзрәтләренә ак йөз вә кальбе салим барыб, мөбарәк пәйгамбәребезнең шифагәтенә ирешү барчаларыбызга насыйб булсын (бихөрмәт сәййидел мөрсәлин, бихөрмәт Таһ вә Йасин). Амин.
Аллаһы тарафындан мөкаддәс Ислам диненең шәригать хөкемләрен өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәрләрнең иң соңгысы – Хатимел әнбия булган Мөхәммәд (гс) нең,

кыскача гына булса да, аның тәрҗемә хәлен, башыннан үткән вакыйгаларны дине Исламның заһир булуыны, Ислам диненең ни рәвешле таралуыны һәрбер мөселманга кыскача гына булса да белү тиеш. Рәсүлүлла (сгс) нең хак пәйгамбәр, Ислам диненең хак дин булуын белер өчен ул мөбәрәк затның гадәт вә холыкларны, эшләгән эшләрене белү җитәдер. Адәм балалары Рәсүл (сгс) нең әхвален ни кадәр белсә, иманны вә динне шул кадәр куәтләндерәләр. Затән дини адәмләрнең вә бөек галимләрнең тәрҗемә хәлләрене белү дә адәм балалары өчен иң файдалы; дин, диянәт артуына, фикер вә әхляк төзәлүенә иң зур сәбәбләрнең берседер. Коръән Кәримнең үткәндәге пәйгамбәрләрнең әхвал вә тарихларыны да сөйләб гыйбрәтләнергә кушуы да шундый сәбәбләрдәндер.

Мөхәммәд (гс) гарәбләр арасында иң мөгътәбәр булган Курайш кабиләсендән булыб, нәсеб шәрифе (нәселе) Исмәгыйл, Ибраһим (гс) гә тоташадыр. Ачык мәгълүм бабалары Мөхәммәд бин Габдулла бин Габделмутталиб бин Һашим бин Габделманнаф бин Кусай бин Киляб бин Мурраһ бин Кәгеб бин Лоэай...

Анасы Әминә бинт Вәһәб бин Габдеманнаф бин Зөһрәбин Килябдер. Килябдә ата һәм анасында нәселләре бергә кушыладыр. Рәсүлүллаһ (сгс) тарих Миляди илә 571нче елда 25нче апрельдә Рабигел әүвәлнең 12сендә, дүшәнбе көн таң вакытында дөньяга килде.

Рум императоры Һераклга Рәсүл (гс) нең дине Исламга өндәб җибәргән хаты ирешкәндән соң, рәсүлулла хакында Әбу Суфьяндан сорашуы.

Имам Бохари хәзрәтләре үзенең "Сәхих"ендә Габдулла бин Габбасдан (рг) шушы вакытны сөйли: "Әбу Суфьян курайшләр берлә Шамга сату-алу белән баргач, Рум пасшасы Һеракл Әбу Суфьянны юлдашлары белән үзенә чакырды. Бонлар бардылар: ул вакытда Һеракл Бәйтел мөкаддәсдә иде. Рум патшасы хозурында (Һераклның) Румның иң зурлары җыелган иде. Патша (Һеракл) тәрҗеманны чакыртды. Тәрҗеман аркылы сорады: "Мин пәйгамбәр диб дәгъва кылган кешегә кайсыгызның кардәшлеге якын, артыграк", - диб сорады. Әбу Суфьян: "Мин – иң якын", - диде. Соңра Әбу Суфьянны үзенә якын китереб, юлдашлар артына куярга кушды. Бу кешеләргә тәрҗеман аркылы әйт: мин болардан пәйгамбәрлек кылучы ир хакында сорамакчы булам. Әгәр ялган сөйләсә, тәкзиб кылсынлар. Әбу Суфьян бу вакыйганы сөйләгәндә: валлахи, ялганчы исем чыгудан курыкмасам, бер кадәр ялганларга ниятем бар иде, дигән. Һеракл Әбу Суфьяндан сорашырга керешде. Һеракл: "Ул адәмнең нәсәбе ничек?" Әбу Суфьян: "Ул адәм нәселле нәсәбле кеше".

Әбу Суфьян хакында: Әбу Суфьян курайш кабиләсендән, беренче буыннан, нәселле, рәсүлуллага тоташа. Курайшнең нурларындан, Әбу Җәһелдән кала, дине Исламның иң зур дошманларындан иде. Мәккә фәтех ителгәннең соңындан гына дине Исламны кабул иткән адәмдер.

Һеракл: "Сезнең арагызда бу көнгә кадәр пәйгамбәрлек дәгъвасы кылучы булдымы?" Әбу Суфьян: "Юк". Һеракл: "Ата-бабасындан патша булганы бармы?" Әбу Суфьян: "Юк". Һеракл: "Бу адәмгә халыкның байлары, зурлар кадәрлеләре иярәме, әллә фәкыйрь-зәгыйфләреме?" Әбу Суфьян: "Фәкыйрьләр, зәгыйфләр". Һеракл: "Аңа иярүчеләр арта баралармы, яки кимиләрме?" Суфьян: "Арта баралар". Һеракл: "Диненә ачуланыб кире кайтучылар бармы?" Суфьян: "Юк". Һеракл: "Хәзер сөйләгән сүзендән элек ялган сөйләгәне бар идеме?" Суфьян: "Юк". Һеракл: "Хыянәт-алдау гадәте бар идеме?" Суфьян: "Юк. Байтакдан бирле күрешкәнемез юк. Хәзер ничекдер, белмим", - диде (Әбу Суфьян). "Шушы сүздән башка сүз кыстыра алмадым", - дигән. Һеракл: "Ул адәм нәрсә эшләргә куша?" Суфьян: "Бер Аллага гына гыйбадәт кылыгыз, ширк кылмагыз, ата-бабаларыгыздан начар гадәтләрне куегыз, намаз укыгыз, тугры булыгыз, ата-аналарга

яхшылык кылыгыз”.
Мондан соң Рум патшасы Һеракл тәрҗеман аркылы Әбу Суфьянга түбәндәге сүзләрне сөйләде: мин ул адәмнең нәселе хакында сорагач, пакъ нәселдән диб әйттең. Пәйгамбәрләр һәркайсы нәселле вә нәсәбле була. Бондан элек арагызда пәйгамбәрлек дәгъва кылучы булдымы, – диб сорадым, – юк диб җаваб бирдегез. Әгәр монда да ул пәйгамбәр булса, шуңга ияреб итә дияр идем. Ата-бабаларында да патша булган кеше бармы? – диб, – сез юк дидегез. Әгәр нәселендә патша булса, ата-бабасы мөлкен кайтарырга әле эзли дияр идем. Бу сүзендән элек ялган сөйләгәне бармы? – дим. – Юк, – дидегез, – адәмләргә ялган сөйләмәгән кеше Аллага ялган сөйләмәс, – диде. Кешеләрнең зурлары байлармы иярә? – дидем. – Зәгыйфләр, дидең. Дөрест, әүвәлге пәйгамбәрләргә фәкыйрьләр, зәгыйфләр ияргән башда. Арталармы? Кимиләрме? – дидем. Арталар, - дидең. Дөрест, чын иман һәрвакыт шулай. Дөрест, чын иман бервакытда да үзгәрми. Берәр кеше мөртәд булганы бармы? – дидем. – Юк, – дидегез. Хакыйкый һәрвакыт шулай: бер күңелгә урнашса, һич чыкмый, - диде. Алдаганы бармы? – Юк, - дидегез. Хак пәйгамбәрләр бервакытта да алдамас, - диде. Сезгә ни белән боера дигәч, сез: бер Аллага гыйбадәт кылырга гына, намаз укырга, гыйффәткә беркемгә дә золым итмәскә, урлармаска, кардәшләр хакын , ата-аналар хакын ригаять итәргә, – дидегез. Әгәр әйткән сүзләрең хак булса, бу кеше минем мәмләкәтне мөлкелә, мин бу пәйгамбәр киләсен белә идем. Ләкин сездән булыр диб уйламадым. Әгәр эшемдә аерылыб аңарга юлыксам, ул адәмнең аякларын идәм, – димешдер.
Һиҗрәтдән унөченче ел:
Рәсүл әкрәм хаҗ Мәккә Мөкәрәмәгә барачагын белдерде. Халыклар бу сүзне ишеткәч, һәр тарафдан төркем-төркем Мәдинәгә җыелдылар. Зөль Кагъдәнең егерме бишенче көн. Өйлә газине укыгач, әһле бәйт вә әсхабе кирам белән Мәдинәдән чыгыб Зөль Хәлифә исемле йиргә барды. Иртәсе көн шул йирдә баглаб Өйлә газине укыгач, кырык меңдин артык сәхабә, хаҗилар белән Мәккә Мөкәрәмәгә китделәр. Вә Зөль Хаҗнең дүртенче көн Мәккәгә җиттеләр. Бу һәр тарафдан мөселманлар хаҗгә җыелганлар иде. Гарәфә көн җомга көн улыб, ул Хатимел әнбия йөз меңнән артык хаҗи белән (хаҗел әкбәр) олугъ хаҗны кылдылар. Рәсүл әкрәм гаять моңлы бер хотбә укыды адәмләргә, вәгазь, нәсыйхәт кылды. И, өметләрем мин сезләргә. Шәригать хөкемләрене ирештердем вә үземдән шул ике нәрсә калдырдым.
تركت فيكم امرين لن تضلوا و ان تمسكتم بها كتاب الله و سنة رسوله
Дин хөкемләрене тәмам сөйләгәч, и җәмәгать, «мин ирештердем!» – диде.
Әсхаб җөмләсе бер аваздан: ирештердең, – диб җаваб бирделәр. Рәсүл әкрәм өч мәртәбә “Шаһид бул, йә Рабб” диде. Бу вакыт Икенде җиткән иде. Хәзрәт Билал азан укыды, камат төшерде. Өйлә намазы укылмаган иде, ул өйлә соңындан Икенде гази укылды. Шушы вакыт
اليوم اكملت لكم دينكم و اتممت عليكم نعمتى و رضيت لكم الايلام دينا
(Әл-Ма’идә сүрәсе, 3 аять).
дөньядан үтүенә олугъ ишарә иде. Хәзрәт Әбу Бәкер бу атыны ишеткәч, бик кайгырды, күңеле тулыб елады. Рәсүл әкрам дөньяда озак торачак түгел икәнлеген аңлады. Рәсүл әкрам Гәрәфатдән кузгалыб Мөздәлифә дигән урынга барды. Әхшам укылмаган иде, ул Әхшам соңра Ястү намазыны укыды. Иртә белән Минәгә килеб корбан чалды, сачыны алдырды. Соңра җәмәгатькә караб: “И, җәмәгать! Хаҗ хөкемләрене миндән өйрәнегез, белмим, мондан соң бу урында минем белән күрешемсез”, - диде. Соңра Мәккәгә килеб тәввафыны кылды. Вә Ибн Габбас кулындан Зәмзәм суыны эчде. Хаҗ тәмам булды.

Шундан 23нче июнь, җомга.
Хәзрәт Рәсүл ни кадәр тырышыб, бөтен авырлыкларга сабыр итеб, халыкны дингә өндәсә дә, Мәккә мөшрикләре һаман да җәбер-золымларын арттыра гына бардылар. Шуның өчен хәзрәт Рәсүл хаҗ вакытында читдән килгән гарәбләрне дингә өндәргә керешде. Төрле кабиләләрдән иманга килүчеләр артыб торса да, таяныч булырлык, дингә ярдәм бирерлек зуррак кабиләләрнең иманга килүен көтә иде.
Пәйгамбәрлекдән унберенче елда:
Мәүлед аенда сөйләнгән вәгазь
Мәдинә халкындан алты кешегә очраб, хәзрәт Рәсүл аларны дин Исламга өндәде, аларга Коръән укыды. Мәдинә кешеләре үзләренең күршеләре яһүд галимләрендән “зур бер пәйгамбәр киләчәк, тирә-якка галиб булачак, Торада шулай хәбәр бирелгән” дигән сүзләрне ишеткәнләр иде. Рәсүл Хода боларны дәгъвәт итдекдә бер-берсенә каратдылар да “яһүдләр хәбәр биргән пәйгамбәр шушы булса кирәк. Яһүдләргә кадәр бу динне без кабул итик”, диб бер-бере белән килешеб, Ислам динен кабул итделәр. Хәзрәт Рәсүлгә вә дине Исламга мәхәббәт итеб кайтыб китделәр. Мәдинәгә кайтыб сөйләгәч, Мәдинәдә Ислам диненә керүчеләр күбәйде. Икенче елда тагын да күб кенә кешеләр Рәсүл әкрам хозурына килеб иман китерделәр. Үзләренә Коръән өйрәтер өчен, шәригать хөкемләрен өйрәтер өчен Мөсгаб бин Гөмәйр исемле сәхәбине алыб китделәр. Шушы көндә шул Мәдинәдә Ислам дине бик тизлек белән тарала башлады. Бөтен сүзләре Ислам дине һәм хәзрәт Рәсүл хакында булды. Пәйгамбәрлекдән 13нче елда Мәдинәдән җитмешдән артык ир вә берникадәр хатын-кыз Рәсүл әкрам хозурына килеб итагать итделәр. Хәзрәт Рәсүлгә, дине Исламга зур мәхәббәт күрсәттеләр. Хәзрәт Рәсүл вә дине Ислам өчен җанлары, тәнләре, маллары белән ярдәм итәчәкләренә вәгъдә вә вәһед бирделәр. Рәсүл әкрам вә сәхабәләр Мәдинә шәһәренә күчсәләр, һәммәсе җан-күңелдән шад булачакларын сөйләделәр. Курайш халкы Мәдинә халкының Исламга килүләрен, хәзрәт Рәсүлгә мәхәббәт итүләрен ишетдекән (ишеткәч – А.Х.), тагын да дошманлыкларын артдырдылар.
Шундан соң Рәсүлнең рөхсәте берлә берәм-берәм Мәдинәгә күчә башладылар. Мөшрикләрнең җафаларындан, һөҗүмләрендән куркыб, кичәләрдә качыб яшерен генә хиҗрәт итәләр иде. Фәкать хәзрәт Мәккәдән Мәдинәгә күчәргә теләгендә, коралларын тагыб әүвәл Кәгъбәт Аллаһ фи тәууәф кылыб, шунда булган мөшрикләргә: “Мин бүген Мәккәдән Мәдинәгә күчәм. Кем дә кем балаларын ятим, хатынын тол калдырасы вә ата-аналарын хәсрәткә салырга теләсә, минем артымдан чыкмас”, – диде. Ләкин аның артындан чыгарга берәү дә батырчылык итмәде. Шул рәвешле сәхабәләр бер-бер артлы Хиҗрәт итеб, Мәккәдә Рәсүл әкрам хәзрәт, Әбу Бәкер, Гали вә мөшрикләр тарафындан тоткын ителгән сәхабәләр генә калды. Дин өчен туган, үскән йирләрен, ватанларын ташлаб, Мәдинәгә хиҗрәт иткән сәхабәләргә “мөһаҗирин” (күчүчеләр), дине Исламга, мөһаҗирләргә ярдәм иткән кешеләргә “ансар” (ярдәмчеләр) диерләр, димәкдер.
Ислам диненең Мәдинә шәһәрендә куәт табуы, сәхабәләрнең Мәдинәгә күчүләре, Мәккә мөшрикләрен төшүенә китерде. Мәккә халкының сәүдәгәр булулары Шамга Мәдинә аркылы йөри торган булганлыкдан, Мәдинә шәһәрендә мөселманлар куәтләнсә, Мәдинә аркылы йөрү мөмкин булмаячак. Мөселманлар куәтләнеб, бездән үч алырлар диб, мөшрикләр бик каушаб калдылар. Тиз генә киңәш мәҗлесләре ясаб, төрлечә киңәшләр кырдылар. Әбу Җәһелнең фикере буенча таза, батыр егетләрне сайлаб, бердән һөҗүм итеб, Рәсүл әкрамне үтерергә карар кабул итделәр. “Мөхәммәднең үз урынына калырлык баласы – ир баласы юк, үтерсәк – котылырбыз, Ислам дине бетәр”, – диделәр. Вә берәр кичәне билгеләб, хәзрәт Рәсүлне үтермәк булдылар.

Шул кич хәзрәт Җәбраил килеб Алланың сәламен сөйләде. Һәм Алла тарафыннан Мәккәдән күчәргә изен (рөхсәт – А.Х.) китерде. Рәсүл әкрам үз урынына хәзрәт Галине яткырыб, өйендән чыгыб китте. Саклаучы егетләр нииндидер сәбәбләр гәфләтдә калдылар. Хәзрәт Әбу Бәкергә барыб бергә Мәккәдән китәчәкләрен сөйләде. Хәзрәт Әбу Бәкер пәйгамбәр белән сәфәр итү шәрәфенә ирешү өчен шадлыгындан елады. Һәр икесе Мәккәдән чыгыб, бер тау тишегенә кереб яшеренделәр. Шушы вакытда Камәри ел белән хәзрәт Рәсүл 53 яшендә, Миляди ел белән 51 яшендә иде.

Батыр мөшрик егетләре: "Рәсүлне саклаб төн үткәреб, иртә торыб Рәсүлнең өенә керсәләр, хәзрәт Рәсүл юк, аның урынында хәзрәт Галине күреб абтыраб калдылар. Төрле якка чабышыб, Рәсүлне эзләргә керешделәр. "Һәркем Мөхәммәдне китерсә, йөз дәвә бирәмез", – диб игълан кылдылар. Хак Тәгалә Үзенең хак пәйгамбәрен саклады. Сигез көн юлда уздырыб, сигезенче Рәбигел әүвәлдә Куба исемле авылда дүрт көн торыб, анда бер мәсҗед бина кылды. Исламда иң беренче мәсҗед – шушы Куба мәсҗедедер булыб, Коръәндә Тәүбә сүрәсендә 110 нчы аять шушы хакында әйткән аять икән.

Җомга көн иртә белән 622нче ел 25 нче сентябрьдә Рәбигел әүвәлнең 12нче көнне Мәдинәгә барырга юлга чыгыб, юлда бәни Салим кабиләсендә беренче мәртәбә җомга укыды. Җомгада йөзләб кеше бар иде. Мәдинә халкы хәзрәт Рәсүлнең үзләренә килү хәбәрен ишетеб, гаять дәрәҗәдә шадландылар. Бөтен халыкның телендә хәзрәт Рәсүл булды. Бөтенесенә зур шадлык булыб, зур бәйрәм төсен алды. Балалар сөенеб: "Хәзрәт Рәсүл килде", кәнизәкләр кызлар: "Йә Рәсүлулла, хуш килдегез" диб, гүзәл-гүзәл шигырьләр укыдылар. Һәркайсы Рәсүлнең үз өенә кунак булуын теләделәр. Хәзрәт Рәсүл: "Төянең (дөянең –А.Х.) ихтыярына куегыз, ул кайда барыб чыкса, шунда мәнзилемез булачак", - диб төя ансардан Әбу Әйүбел Ансари дигән кешенең алдына барыб чыкды. Әсгәд бин Зурара дигән кешенең: хәзрәт Рәсүлнең төясе миндә кунак булсын диб, төясен алыб китде. Шушы Рәсүл әкрамның Хиҗрәтендән соң Мәдинәдә вә Мәдинә тирәсендә Ислам тизлек белән тарала башлаб, Ислам динендә булган кешеләр Аллага тынычлаб гыйбадәт итә башлаб, Ислам дипенең таралуына иң мөсәббәб булганлыкдан, бу Хиҗрәт бер мөселманлар тарафындан зур, истәлекле, тарихи вакыйга булганлыкдан, Рабигел әүвәл ае Рәсүлнең туган ае, Мәккәдән Мәдинәгә күчкән ае. Һәм шушы дөньяда Ахирәткә күчкәнлекдән бу ай һәрвакыт без – мөселманлар тарафындан хөрмәт белән искә алынырга тиешле, хөрмәтле айдыр.

Хәзрәт Рәсүлнең туган вә Хиҗрәт кылган, үлгән ае – җөмләмез өчен мөбарәк булыб, мөкаддәс динемез кушкан, мөбарәк пәйгамбәребез кушканча, бөтен гадәтләрне, күркәм холыкларны үзебезгә гадәт итеб, үзара, инсаният галәменә таратырга, начар гадәтләрдән булыб саналган гайбәт, хөсед белән сүз йөртү кебек эшләрдән сакланыб, иттифак, татулык, тынычлык белән гомер итәргә Аллаһы насыйб итсен.

Сабан туе уңае белән:

Мөхтәрәм җәмәгать! Киләсе якшәмбегә ата-бабадан гадәт булыб килгән милли гадәтебез – күңел ачу бәйрәме булыб, шушы халыкара бәйрәмебезне аеклык, тәхәллүф белән үзебезнең бер-беребезгә халык арасындан күңелсез хәлләргә сәбәб – бозык булган гадәтләрдән бик сакланыб уздырырга насыйб булсын.

Ходай хәерле яңгырлар бирсен авыл хезмәтендә.

Рәсүл әкрам (сгс)нең Хиҗрәтендән унынчы елдагы вакыйгалар:

Бу елларда Мәдинәгә атрафдан бик күб илчеләр киләләр, һәркайсы Ислам динене чын күңелдән кабул итеб, кайтыб китәләр иде. Рәсүл әкрам һәр якка әмирләр, вәлиләр йибәрмәкдә иде.

Әлхасыйл Мәккә Мөкәррәмәне фәтех кылгач, курайш тармаклары, кабиләләре – бар да мөселман булганнар кеби, Мәккә, Мәдинә тирәсендәге башка кабиләләр дә төркем-төркем дине Исламга керәләр иде. Адәмләрнең ерак-ерак җирләрдән килеб, дине Исламны кабул итделәр. Бу хакда:
استعيذ بالله اذا جاء نصر الله و الفتح و رايت الناس يدخلون فى دين الله افواجا
сүрәэи хәлиләсе инде. Бу сүрәдә Рәсүлулланың гомере аз калдыгына ишарә бар иде. Бу сүрә укылгач, хәзрәт Габбас Рәсүл әкрамнең гомере аз калганыны аңлаб, күңел тулыб елады. Һәм шушы вакытларда Рәсүл әкрамнең актык хәҗи хәҗҗәтул видагъ вакыйгъ булмышдыр.
Шушы елда Рәсүл әкрам Хаҗ кылу нияте белән Мәккә Мөкәррәмәгә барасын белдерде. Рәсүл әкрамнең бу хәбәрен ишеткәч, һәр тарафдан төркем-төркем Мәдинә шәһәренә җыела башладылар. Зөль Кагъдәнең 25 нче көне Өйлә намазыны укыгач, әһле бәйти (өй җәмәгатьләре) һәм әсхабе кирам белән Мәдинәдән чыгыб, Зөль Хәлифә исемле йиргә барыб, иртә белән шул урында әхрам багълаб, Өйлә намазыны укыгач, кырык меңдән артык хаҗилар белән Мәккә мөкәррәмгә китделәр. Зөль Хиҗҗәнең 4нче көне Мәккә Мөкәррәмәгә җитделәр. Мәккә Мөкәррәмәнең башка тарафларында бик күб хаҗилар җыелган иде. Гарәфә көне җомга көн булыб, ул Хатимел әнбия йөз меңнән артык хаҗи илә (Олугъ хаҗ) Хаҗел әкбәрне үтәделәр. Рәсүл әкрам гаять моңлы бер хөтбә укыды, вәгазь-нәсыйхать кылды. “И, өммәтләрем! Мин сезгә Ислам диннең шәригать хөкемләрен тиешенчә ирештердем вә үземдән соң ике нәрсә калдырдым.
تركت فيكم امرين لن تضلوا و ان تمسكتم بها كتاب الله و سنة رسوله
Моннан соң да, җәмәгать, мин сезгә Алланың динен, шәригать хөкемләрен ирештердемме? - диб сорады. Бөтен сәхабәләр, аптыраб: ирештердең, - диделәр. Шушы вакыт хәзрәт Рәсүл: йә Рабб, шаһид бул! – диб өч мәртәбә әйтте. Вакыт Икенде җиткән иде. Өйлә намазы укылмаган иде. Хәзрәт Билял азан укыды, камәт кылды. Әүвәл Өйлә, соңындан Икенде намазы укыдылар. Шушы вакыт:
اليوم اكملت لكم دينكم و اتممت عليكم نعمتى و رضيت لكم الايلام دينا
аятел Көрси нәзел булды.
Хаҗилар таралды. Рәсүл әкрам Мәдинә мөнәввәрәгә кайтды. Менә бу хаҗ Рәсүл әкрамнең актык хаҗы булыб, һәрбер мөселман өчен тиешле чара булыб, хаҗ – зур вакыйга (хәдисә) булды. Шул көндән соң озак тормый Рәсүл әкрам дөньядан күчә (салла Алла галәйһи вә галә алиһи вә асхабиһи аҗмәгыйн). Инша Алла Рәсүлебезнең вафаты һәм шамаил шәрифәсе хакында сөйләргә насыйб итсен. Рәсүлебезнең өйрәткән мөкаддәс Ислам дине үзе дә күңелләребезне беркетеб, Рәсүлебезнең шифагәтенә ирешү барчаларыбызга насыйб булсын.
Сүрәтел Гыймран:
اللهما يا مقلب القلوب ثبت قلبى على دينك
Амин.
Әгузу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ
(ا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواَي) – Аллага иман. (اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ) – чын курку, хак курку белән куркыгыз.
(لَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَو) – хак мөселман вә хак мөэмин булганыгыз хәлдә генә үлегез.
(اعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًاو) – Алланың җебенә, диненә ябышыгыз. (لَا تَفَرَّقُواو) – аерылышмагыз.
(اذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْو) – Алланың биргән нигъмәтләрене исегезгә төшерегез. (ذْ كُنتُمْ أَعْدَاءًإ) –

Ислам дине килгәнче җаһилият заманында бер-берегезгә дошман идегез, Ислам дине сезнең арагыздагы бу дошманлыкны бетерде, бер-берегезгә кардәш итде, (أَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ) – бер-берегезгә күңелләрегездә өлфәт, мәхәббәт тудырды. (أَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ) – Ислам нигъмәте сәбәбле таңга кердегез ягъни үрелдегез, (إِخْوَانًا) – бер-берегезгә кардәш булыб, (وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ) – ягъни Ислам дине килмәсә, элек тәмугъ чокыры тирәсендә, тәмугъта шешәр идегез, )0557( (فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا) – бәс Аллаһы Тәгалә Ислам дине сәбәбле сүзне тәмугъ чокырындан, газабындан коткарды. (كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ) – ушандак узгандагы хәлләрне искә алган кебек, аятьләрене, галәмәтләрене дә бәян кылырды. (لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ) – шәет ки, (бәлки – А.Х.) сез шушы хәлләрне искә алыб, тугъры юлга күнегерсез. Ягъни Аллаһы кушканча, пәйгамбәр кушканча бер иттифакда, берлекдә, бер сүздә булыб яшәб, аерылмаенча, бер-берегез белән тату булыб, өлфәт, мәхәббәт белән, чын мөселман, хак мөэмин булыб яшәб, Алланың юлына күнелеб, һидаять тавыб, дөнья Ахирәт тәҗәлли булырсыз, ди.

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

– шундый кешеләр кебек булмагы, (فَرَّقُوا وَاخْتَلَفُوا) – бер-берсендән аерылышдылар, ихтиляф кылышдылар. (مِن بَعْدِ مَا جَاءَهُمُ الْبَيِّنَاتُ) – иттифакны, бердәмлекне важиб иткән, фарыз иткән хаклыкны, ачык бәйан иткән дәлилләр, аятьләр килгәннең соңында алар бер-берсендән аерылышдылар. Җәмәгатдән аерылдылар (وَأُولَٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ عَظِيمٌ) – Кыямәт көнендә шушы кешеләр өчен зур газаб бар, ди. (وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَرَسُولَهُ) – Аллага вә Рәсүленә итагать кылыгыз. (وَلَا تَنَازَعُوا) – Бәдер сугышында низагълашкан кебек низагълашмагыз, ди. (وَتَذْهَبَ رِيحُكُمْ) – Дәүләтегез, нигъмәтегез кулыгыздан китәр, ди.

Бу аятьдән ачык аңлашканча, таркау булу, бердәм булмау, иттифаксыз булу арабыздан дәүләтнең, Алланың биргән нигъмәтләренең кулдан китүенә сәбәб була икән. Калә Рәсүлулла (сгс):

عَلَيْكُمْ بِالْجَمَاعَةِ ، وَإِيَّاكُمْ وَالْفُرْقَةَ ، فَإِنَّ الشَّيْطَانَ مَعَ الْوَاحِدِ ، وَهُوَ مِنَ الاثْنَيْنِ أَبْعَدُ ، وَمَنْ أَرَادَ بُحْبُحَةَ الْجَنَّةِ فَعَلَيْهِ بِالْجَمَاعَةِ

Ягъни: һәрвакыт күпчелекдә җәмәгать белән бергә булыгыз, аерылышудан сакланыгыз, ди. Шайтан дөреслекдә ялгыз кеше белән бергә булучы, ди. Ике кеше дә ярар, әгәр яхшы ибтәш белән бергә булсак, ул сине яхшылыкка өндәр. Әгәр бер кеше җәннәтнең уртасында, ягъни җәннәтлек булуны теләсә, әлбәттә җәмәгать белән бергә булсын, арылмасын, ди. Икенче бер хәдисендә:

ثَلاثَةٌ لا تَسْأَلْ عَنْهُمْ : رَجُلٌ فَارَقَ الْجَمَاعَةَ وَعَصَى إِمَامَهُ وَمَاتَ عَاصِيًا ، وَأَمَةٌ أَوْ عَبْدٌ أَبَقَ مِنْ سَيِّدِهِ فَمَاتَ ، أَوِ امْرَأَةٌ غَابَ عَنْهَا زَوْجُهَا ، وَقَدْ كَفَاهَا مُؤْنَةَ الدُّنْيَا فَتَبَرَّجَتْ بَعْدَهُ فَلا تَسْأَلْ عَنْهُمْ

Ягъни: өч төрле кешенең хәле турында сорама. Бу кеше белән элемтә тотма, катнашма дигән сүз була; беренче: бер кеше җәмәгатьдән аерылса, икенче: хөкүмәт эш башында имамларына буйсынмаса, өченче: бер хатын өеннән ире юк вакытда чыгыб йөрсә. Хәлбуки, аның тормыш кирәкләре җитеш иде. Бу хакда, җәмәгать, Рәсүлулланың хәдисләре бик күб, тагын да сәхих булган хәдисләрдән:

إن الله لا يجمع أمتي أو قال أمة محمد صلى الله عليه وسلم على ضلالة ويد الله مع الجماعة ومن شذ شذ إلى النار

Тагын да:

ان امتي لا تجتمع على ضلالة و اذا رأيتم اختلافا فعليكم بالسواد الاعظم
من فرق فليس منا

дигән куркынычлы сүзләр сөйләгән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу сүзләрне, бу мөбәрәк аятьләрне, хәзрәт Рәсүлнең мөбәрәк сүзләрен сөйләүдән максад белән шул һәрвакытда берләшү, иттфикакда булу, күпчелекдән аерылмау – арабызда шушындый күңелсез хәлләрдән ерак булу. Үзебезнең хәлләребезне шушы аятьләр пәйгамбәр сүзләре белән чагышдырыб, үлчәб карасак, безнең

хәлләребез ничек?
Алланың йорты Бәйтулла хөкүмәтебез тарафыннан дини эшләребезнең баш идарәсе – Дининя нәзарәте тарафыннан рөхсәт ителгән бөтен дини мирасларыбыз шушы рөхсәтле кешеләр тарафыннан үтәлергә тиеш булганның соңында без шушы эшләрне Алла кушканча, пәйгамбәр дигәнчә үтибезме? Ләкин, кызганычка каршы, безнең арабызда шушындый таифә, шундый бүлек, шундый адәмләр күренеб тора. Алардан бөтенләй мәсҗедемездән, имамнарыбыздан, мәсҗед хозурнда эшләүче дини хәдимләребездән мөтәвәлият әгъзаларына, хәтта мәәәззиннәргә дә начар күз белән караучылар бар. Ничек дисәгез, бу кешеләр бөтен дини мирасларын, мәсҗеддән башка үткәрәләр: мәйетне дә, никяһны да, исем кушу, һәркайсы кем туры килде, шуны чакырып, бирә торган иганәләрен элек кемнәрнең кесәсенә сала-бирә. Җәмәгать, шуны яхшы аңлагыз! Безнең арабызда хәзер дини ләвзимемезне дөрест итеб үтәрлек кешеләребез бик аз калыб бара. Икенчедән, безнең илебездә фәкыйрь, мохтаҗ, ач, ялангач кешеләр юк. Менә безнең мәсҗеддә яраклашыб рөхсәтле дин хадимләрен чакырмыш бер адәмне (0560) чакырыб, Аллаһы ризалыгы өчен бөтен өмед иткүче әрвахларыбызның рухлары шад булсын диб, биргән сәдакаларыбыз тиешле урынга бирелә, юкмы? Шуны яхшы аңларга кирәк. Менә дини эшләребез бу рәвешле мәсҗеддән рөхсәтле булмаган кешеләребездән дини эшләребезне башкарабыз икән, безне инде бу эш безнең кулыбызга, пәйгамбәребез хәдисенә кабма-каршы булыб, гәрчә тел белән әйтәсе дә юк.
1. Миңа мәсҗед кирәк түгел, андагы адәмләр һәрика (буш сүз сөйләп – А.Х.): мин җәмәгатьдән аерылдым дигән сүз булыб кала. Алла сакласын, “Мән фәррака фәләйсә минна” дигән сүз була.
2. Мәсҗед тарафыннан баргаб, имам булсын, мөэззин булсын, йә булмаса башка кешеләр булсын кирәк, нинди генә мәҗлесдә бирелгән сәдакалар – һәркайсы бер тиене дә югалмый мәсҗедебезгә кайта, шуның белән шушы сәдакалар белән мәсҗедебез, динебез дәвам итә. Инде шушы бирелгән сәдакаларыбыз, хәзрәт Рәсүл заманындагы кебек, бәйел малга бирелгән сәдакалар кебек, һәркайсы сәдака җария булыб, инша Алла, шул рәвешле ителгән иганәләребез сәдакалар сәдака җария булыб зур әҗер-сәвабларга ирешер.
3. Җәмәгать! Бик яхшы уйлаб хәзерге мәсҗедебезнең хөкүмәт тарафыннан рөхсәт бирелеб, шушы ни төрле рәвешдә күңелле, матур булыб дәвам итүе безнең өчен Аллаһы тарафыннан бирелгән зур нигъмәт. Шушы нигъмәтнең кадерен белмәсәк, мәсҗедебезгә шулай салкын карасак, мәсҗедкә булачак иганәне бирәүнең шәхси файдасына (кесәсенә салуны) артык күрсәк, бу һичшиксез көфран нигъмәт булыб, дөнья Ахирәтдә (0561) үкенечкә калуыбызга сәбәб булачак
اعوذ بالله من ذلك الحال
Әстәгыйзу билләһ (сүрә Ибраһим):
وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ
Бик куркынычлы рәвешдә безне шундый эшләрдән тәнбид кыла минһу.
Җәмәгать! Мондый эшләрдән зинһар бик каты сакланыйк. Мин шушы мәхәлләдә яшәгән кеше булганлыгымдан никяһ, мәет күмү эшләрен үтәгән кешеләр арасында шундый адәмләр күргәнем бар. Коръәннең бер генә сүзен дә дөрест укый белми торыб, ничек Алладан курыкмый, пәйгамбәрдән оялмый, Коръән сүзләрен ватыб, никяһ укыб, мәет күмеб, шушы эшләрне үзләренә кәсеб итеб кешеләр бик күбәеб бара. Зинһар, мондый эшләрдән бик сакланыб, гомер буена эшләб, картлык көнләребездә алган пенсияләребезне тиешсез урынга сарыф кылудан Алла сакласын. Шундый эшләрне эшләүче мәсҗедгә килә алмаган мөселман кардәшләребезгә яхшылаб аңлатыйк. Шушы сөйләгән сүзләремне,

вәгаземне яхшылаб уйлаб карыйк.
Югарыда сөйләнгән Коръән аятьләрен, пәйгамбәребезнең мөбәрәк сүзләрен истә тотыб, шуның белән гамәл кылсак
وَتَعَاوَنُوا عَلَى الْبِرِّ وَالتَّقْوَى وَلا تَعَاوَنُوا عَلَى الْإِثْمِ وَالْعُدْوَانِ
Аять кәримәсе буенча гамәл кылган адәмләр җөмләсендән булыб, сәгадәт дарәйнгә ирешүебезгә сәбәб булыр. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте дөньяда вакытда Коръән, сөннәт белән гамәл кылыб, саф мөселман, хак мөэмин булыб дөньядан үтәргә насыйб итсен.
اللهم ارنا الحق حقا وارزقنا اتباعة وارنا الباطل باطلا وارزقنا اجتنابه
Мәүледен нәби киче, дүшәнбе көн кич, сишәнбе көне Алла насыйб итсен.

1967нче елда Казан мәсҗедендә Габделхәбир Ярулла угълы тарафындан сөйләнгән вәгазьләр
2нче номер дәфтәр, 1967 нче ел
1) Кулләкум рагыйн хәдисе;
2) Иман хакында.
Ихлас күңелләребез белән Алланың ризалыгын истәб (теләп – А.Х.), пәйгамбәргә өмет булуны теләб, ерак вә якын җирләрдән җомга гыйбәдәтене үтәргә килгән мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Алланың сәламе, Алланың рәхмәте, Алланың бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын. Тәнләребез, киемләребез пакъ булган шикелле, күңелләребез дә пакъ булыб, Алла Раббел галәмин хозурына ак йөз белән барырга Алла насыйб итсен. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Узган җомгада сөйләгән сүзләремне бәгъзе берәүләр ялгыш вә хата аңлаулары мөмкин, яки үзем дөрест аңлата алмаганмын. Шуның өчен бу җомгада да шул хакда беркадәр сүземне дәвам итдермәк булам. Дикъкать белән тыңларга, аңлашылмаган сүзләр булса, турыдан-туры үзем белән сөйләшергә кирәк.
Калә Рәсүлуллаһ (сгс):
كُلُّكُمْ رَاعٍ وَمَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ فَالْإِمَامُ رَاعٍ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ وَالرَّجُلُ فِي أَهْلِهِ رَاعٍ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ وَالْمَرْأَةُ فِي بَيْتِ زَوْجِهَا رَاعِيَةٌ وَهِيَ مَسْئُولَةٌ عَنْ رَعِيَّتِهَا وَالْخَادِمُ فِي مَالِ سَيِّدِهِ رَاعٍ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ
(كُلُّكُمْ رَاعٍ وَمَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ) – сезнең һәркайсыгыз, һәрберегез көтүче. Сез һәрберегез көтүе хакында соралмыш булырсыз, ди. Җаваб бирәчәксез, ди. (فَالْإِمَامُ رَاعٍ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ). Имам яки хәлифә үз кул астында булганнарга көтүче, ул шушы хакда соралмыш булыр: (وَالرَّجُلُ فِي أَهْلِهِ). Ир булган кеше үзенең гаиләсенә, балаларына көтүче, шуларны караучы, тәрбияләүче, шулардан соралмыш булыр, ди. (وَالْمَرْأَةُ فِي بَيْتِ زَوْجِهَا رَاعِيَةٌ وَهِيَ مَسْئُولَةٌ عَنْ رَعِيَّتِهَا) – Хатын ирнең өендә көтүче, ул шул хакда җаваб бирер, ди. (وَالْخَادِمُ فِي مَالِ سَيِّدِهِ رَاعٍ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ) – хезмәтче хуҗасының малына көтүче, ул шулардан җаваб бирер, ди.
Бу хәдисдә сөйләнгән имам (ир, хатын, хезмәтче) сүзләре мисал өчен генә сөйләнгән. (كُلُّكُمْ رَاعٍ وَمَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ) хөкменә нинди генә эш башында булган кешеләрнең һәрберсе, нинди генә эш өстенә йөкләнгән икән, һәркайсы үзенең эшендән җаваблы булачак. Болай гына да дөньяви эшләрдә вә гомуми эшләрдә гакыллары, гамәлләре, аң вә игътибар кадәр булырлар.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бу хәдисне сөйләүнең теләгем: дин хадимләре, дин хезмәтчеләре, үз арабызда булган күңелсез гадәтләребезне әйтми, күз йомыб (0569) калабыз икән, бу вакытда без һәр ике дөньяда зур җавабка калачакбыз. Дин хадимләренең (хезмәтчеләренең) вазыйфасы тәвазזаглы булу тәкбберлек, риядан саклану, гыйлем белән

гамәл итү, тәхәммелле, сабырлы булу, гафу кылу, әһле очраса гыйлем өйрәтү, хаталарны, кимчелекләрне аңлатыр дәрәҗәдә җөсэарәтле (батыр) булу, Ислам динене, дин хөкемләрен башкаларга ирештерү, тәблигъ итү, халыкларның начар гадәтләрен төзәтергә тырышу, үзараларында һәм ватанга өлфәт, мәхәббәт орлыкларын чәчү, күңелләренә дустлык, туганлык урнаштыру, шадлыкларын-кайгыларын уртаклашу. Шушы эшләр бәрабәренә бернәрсә өмет итмәү, кәнәгатьле булу, комсыз булмау, мөнкәр эшләрне бетерергә тырышу (нәһи ганель мөнкәр), хөерле, яхшы кызыктыру, димләү (әмер бил мәгъруф) кылу; менә шушы эшләр һәркайсы – имамлар, дин хезмәтчеләрнең вазыйфасы. Узган җомгада сөйләгән вәгаземдән төп теләгем: сезне тәкъвалыкка чакырыб, дөнья Ахирәт, сәгадәткә, бәхеткә чакыру.
استعيذ بالله يا ايها الذين آمنوا التقوة الله حق تعالى
И мөэминнәр, Аллага тәкъвалык кылучылардан булыгыз. Чын тәкъвалык йөзендән واعتصم باللهалдындан тәкъвалыкны искә төшерүдән мөслихәт, шул игътисам билләһига сәбәб булган иттифакка вәсилә булган (тоташтыра) торган тәкъвалыкны шарт кылган, ягъни чын тәкъва булсагыз, бер иттифак булыб, Алланың күрсәткән юлында булыгыз, диб. Иттифакка игътисам бихәблилләгә каршы булган хәлләрне искә алыб
وَلَا تَكُونُوا كَالَّذِينَ تَفَرَّقُوا وَاخْتَلَفُوا مِن بَعْدِ مَا جَاءَهُمُ الْبَيِّنَاتُ ۚ وَأُولَٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ عَظِيمٌ
аяте назил булды.
Тәкъвалык нәрсә соң ул? Нидән гыйбарәт? Җаваб “Кәлям Шәриф”дә:
وَسَارِعُوا إِلَىٰ مَغْفِرَةٍ مِّن رَّبِّكُمْ وَجَنَّةٍ عَرْضُهَا السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ أُعِدَّتْ لِلْمُتَّقِينَ
الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ ۗ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ
Ягъни: وَسَارِعُوا إِلَىٰ مَغْفِرَةٍ (مِّن رَّبِّكُمْ) Раббыгыз тарафындан булган ярлыкауга, ярлыкануга ашыгыгыз. “Вә җәннәтин” дәхи шундый күрергә ашыгыгыз. (عرْضُهَا السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ) Ул әҗмахның киңлеге, җирләрнең, күкләрнең (галәм киңлеге) кебидер. (أعِدَّتْ لِلْمُتَّقِينَ) Алладан куркучы тәкъва адәмләр өчен хәзерләнмеш булды, ди. Моның соңында мөттәкыйль тәкъва адәмләр, шул адәмләр диб, (في السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ) байлык хәлендә дә, фәкыйрьлек хәлендә дә тарлык вакытында инфак, әнгам, ихсан кылырлар, Аллаһы юлында сарыф кылырлар. (وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ) Ул тәкъва адәмләр, ачуны тиючеләр кешегә ачу тотмаслар. (وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ) Әүвәл тәкъва кешеләр үзләрен рәнҗеткән кешеләрне дә гафу кылырлар. (وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ) – Аллаһы Тәгалә шушы рәвешле изгелек кылучыларны дуст күрүче, сөючедер, ди.
Һәм хәзрәт Рәсүл әйтә:
سبعة يظلهم الله في ظله يوم لا ظل إلا ظله
(Имам Гадел) – Җиде төрле кеше, Аллаһы Тәгалә аларны Кыямәт көнендә Үзенең рәхмәт күләгәсендән башка күләгәләр урын булмаган көндә, вакытда, Үзенең рәхмәт күләгәсе белән күләгәләндерер:
1) Дөрестлек белән хөкем итүче ишан, дөрестлек белән алыб баручы имам (вә башлык).
2) و شاب نشأ فى عبادة الله Аллаһы гыйбадәтендә үскән егет.
3) رجل قلبه معلق بالمساجد Мәсҗедкә вә җәмәгать намазына мәхәббәт итүче кеше.
4) ورجلان تحابا في الله
5) ورجل دَعَتْهُ امرأة ذاتُ مَنْصِب وجمال، فقال: إني أخافُ الله
6) رجل تصدق بصدقة فأخفاها حتى لا تعلم شماله ما أنفقت يمينه
7) ورجل ذكر الله خاليا ففاضت عيناه
كل نفس ذتئقة الموت
Мөхтәрәм җәмәгать! Бүген, бүген булмаса иртәгә һәркайсыбызга үлем киләчәк. Һәркайсымыз Алла Раббел галәмин хозурына барыб, хисаб бирәчәкмез. Кылган гамәлләребездән (кирәк – яхшы, кирәк – яман) һәркайсының: кирәк – изге җәза, кирәк –

явыз җәзасын күрәчәкбез. Газабланыб табкан малларыбыздан кирәк нинди юллар белән булса да, тәһлил сәдакаларыбыз, мәет озату сәдакалары, үлгәннәребезгә дога кылу нияте белән Аллаһы ризалыгы өчен диб бирелгән сәдакаларыбыз тиешле урынга сарыф кылынса, (мәсҗедкә, дин юлына), Алла кашында мәсэулияткә кылмаска сәбәб булыр диб, сезгә Алланың калямен, пәйгамбәр хәдисләрен сөйләб күрсәтдем. Инде шушы мәетләребезнең шадланасы, Алла разый булсын, диб бирә торган сәдакаларыбыз бер дә әһле булмаган кешеләр тарафындан мәетләребез күмелсә, никяһларыбыз укылса, башка мәҗлесләребез уздырылса, шушы мәҗлесдә бирә торган сәдакаларыбыз бер дә тиеш булмаган кешеләр кесәсенә керсә, бу вакытда мәсэулият үз өстегезгә төшәчәк. Хәзрәт Рәсүлнең

وأن أقول الحق ولو كان مرا ، وأن لا أخاف في الله لومة لائم

хәдисенә бинаэә (таянып – А.Х.), бәлки бәгъзе берәүләргә бу сүзем авыр булыр, ләкин авыр булса да, хаклыкны әйтми кала алмыйм. Бу сүзләрдән теләгем минем комсызланыб үз кесәмә байлык җыю түгел, җенабее Хак мондый начар сыйфатлардан барыбызны сакласын.

اليد العليا خير من اليد السفلى

дигән хәдискә бинаэ, дин юлына әфгал әхсан кылырга насыйб итсен.

استعيذ بالله و ذكر انما انت مذكر

диб, бары мин исегезгә генә төшердем. Тыңлау, тыңламау үз эшегез. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә барчаларымызга тәуфыйк, һидаять биреб, мәхшәр мәйданында рәсвай галим булудан саклаб, хак мөэминләр булыб кубарылырга насыйб итсен.

وافنا مسلمين وألحقتنا بالصالحين

Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.

Киемләремезне, тәнләремезне пакълаб, Алланың йортына мәхәббәт итеб, ихлас күңел белән җомга намазына килгән мөселман кардәшләрем!

Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Сәламе, рәхмәте, бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын. Бүгендән соңда тәнләребезгә сәламәтлек, илләребезгә, җанларыбызга тынычлык биреб, күб елларга кадәр, күб җәмәгать белән бергәләб гыйбадәтләр кылырга, догалар кылышырга Аллаһы насыйб итсен.

Бисмилләһир Рәхманир Рәхим! Габдулла бин Гомәр дигән сәхабәдән риваять:

قال رسول الله صلى الله عليه و سلم:

بُنِيَ الإِسْلامُ عَلَى خَمْسٍ : شَهَادَةِ أَنْ لا إِلَهَ إِلا اللَّهُ ، وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللَّهِ ، وَإِقَامِ الصَّلاةِ ، وَإِيتَاءِ الزَّكَاةِ ، وَصَوْمِ شَهْرِ رَمَضَانَ وَحَجِّ الْبَيْتِ ،

Ягъни Ислам диненең нигезе, бинасы биш нәрсә үзренә бина кылынды, эшләнде. Ул Аллага, Рәсүлуллага ышанмак, биш вакыт намаз укымак, әгәр дә тиешле, зәкят бирмәк, хәле җиткән кешегә гомерендә бер мәртәбә Хаҗ кылмак һәм рамазан аенда раузасын (ураза) тотмак. Дөнья эшләребез белән чагышдырыб караганда, нык, таза җиргә, яхшы фундаментка, яхшы нигезгә вак-төяк җил-давылларга, җиңелчә җир селкенүләргә дә ирек бирмәгән кебек, шушы бишнең иң нык булганы – иманыбыз. Нык булса, нигезебез таза булса, як-яктан исеб торган нәфесемез, шайтанларыбыз тарафындан, җил-давылларындан күңелләребезгә килә торган шик, шөбһә зилзиләләрендән имин булыб исән-сау котылыб, Алла хозурына саф игътикад, пакъ иман белән барыбызга сәбәб булачак, Алла барыбызга насыйб итсен.

Иман нәрсә? Иман лүгатьдә (телдә – А.Х.) мотлак ышану дигән сүз. Әмма шәригатьдә, дин каравында истыйләхенең (гыйбарәнең – А.Х.) мәгънәсе:

التصديق بالقلب بجميع ما جاء به من الله تعالى و النبى صلى الله عليه و سلم والافراد عند عدم المانع حقيقة او حكما

Вә әмма әл-куфр фил лүгаттил инкяр мотлак. Әмма истыйләхи мәгънәсе мөэмин биһи булган каһәрләргә ышанмау булмас, диб әйтү. Сәхабәләр алдында Җәбрәил фәрештә килеб Рәсүл өйрәткән иман:
ان تؤمن بالله و ملائكته و كتبه و رسوله و اليوم الاخر و تؤمن بالقدر خيره و شره
Шушы чын күңелдән ышаныб, иман китерүче – иман була. “Мөэмәнун биһи” – ышанырга тиешле нәрсәләр. Шушы алты төрле нәрсәгә һичшиксез ышансак кына, чын мөэмин булабыз. Шушы нәрсәләрнең берсенә генә ышанмасак, яки шик тотсак, бу иман дөрест булмый. Шик белән иман бергә җыелмый. “Иман шарты”бызда язылган:
آمَنْتُ بِاللهِ ، وملائكته ، وَكُتُبِه ، وَرَسُوْلِه ، وَالْيَوْمِ الْاخِرِ ، وَالْقَدْرِ خَيْرِه وَشَرِّه مِنَ اللهِ تَعَالى ، وَالْبَعْثِ بَعْدَالْمَوْتِ
Һичшиксез, иман китерү минһу шушы иман дигәнемез өч бүлеккә бүленә: иман тәхкыйки, иман истидляли, иман тәклиди.
Иман тәхкыйки шул була: сиңа бөтен дөнья халкы каршылык кылыб, сине иманыңдан яздырырга торсалар, синең күңелеңә тузан кадәр дә шик салырга тырышсалар, син шушы иманыңда сабит буласың. Бу иманның, ышануның иң әгъля, югары дәрәҗәсе. Бу иман пәйгамбәрләрдә хас, адәмләрдә була торган иман. Нитек пәйгамбәрләр бөтен кавеме, туганлары каршы торыб, ни кадәр җәбер-золым иткәнләр, араларындан куганлар, хәтта тәнләрен агач ярган кебек пычкы белән җараганлар. Шулай газабласалар да, иманларында сабит булганлар. Нитек хәзрәт Рәсүл кәфирунләргә: لكم دينكم و لي ديني, диб җаваб бирергә куша Аллаһы Тәбарәкә.
Иман истидляли: дәлилләр белән иман китерү. Һәртөрле мәхлукатьләргә күз салу. Җирдәге, күңелдәге, табигатьдәге булган нәрсәләргә караб, шушылар хакында уйлаб, фикерләб, дөньядагы хәйванларга, һәртөрле чеби, черки, вак хәшәратләргә, төрле төсдәге, төрле зурлыкдагы, төрле тавышдагы кошларга, һәртөрле-төрле үсемлекләргә, төрле рәвешдәге яфрак-үләнләргә, диңгез астларында һәм эссе якларда гына үсә торган зур-зур агачларга күз салыб, уйлаб карасак, һичшиксез, бер Санигъ, Галим булган бер Зат булырга тиеш, – уйларга мәҗбүр булабыз. Бер кеше шушылай уйлаб, дәлилләр белән иман китерә икән, - бу иман кувәтле иман була. Күңеленә шик-шөбһә килми. Шуның Рәсүлуллаһ (сгс) тәфәккер кадәр зур гыйбадәт юк. Әгәр бер кеше йолдызларга караса, андагы гаҗәбләрне күреб, Алланың кодрәтенә, хөкемәтенә гакыллар хәйран калыб:
رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ
укыса, күктәге йолдызлар санынча бу кешегә әҗер вә сәваблар була, дигән. Бу әҗер-сәвабларның күблеге – бу кешенең иманының кувәтле нурына сәбәб булганлыкдан. Менә бу рәвешле Аллаһыны таныб, күзе белән күргән бөтен җир йөзендә булган мәхлукатька күз салыб, һәркайсы гакыл белән яхшылаб уйласа, юк-бар белән генә бу адәмнең иманына шик-шөбһә килми, бу иман – кувәтле иман. Шәйтан шәррендән (явызлыгыннан – А.Х.) хилас табуга, нәҗат табуга сәбәб иде.
Мәңгелек сәгадәткә ирешдерә торган иман. Барчаларымызга хакыйки, истидляли иманга ирешеб, нык, таза, кувәтле иман белән яшәб, шундый иман белән Алла хозурына күчәргә насыб итсен.
Өченнче: иман тәклиди. Бу иман ата-бабага ияреб, вәгазь, нәсыйхәт кылучыларның сүзенә ияреб, һич дәлилсез генә иман китерү. Менә бу иман зәгыйф иман булыб, әлгыйяз билләһ (Алла сакласын – А.Х.), үлем авыруы вакытында шәйтанның иректә булуы мөмкин. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре барчамызны вәсвәс кылучы шәйтан шәррәнә иярү куркынычы булган зәгыйф иманлы булудан сакласын.
Дин һәм иман ялгыз телләрдә генә сөйләнеб кала торган сүз белән генә калырга тиеш түгел. Бәлки адәм баласының күңеленә нык урнашкан “йакыйн”дән, чын ышанудан. Адәм

баласы һәртөрле яхшылык юлларына кызыкдыручы-өндәүче, бөтен начарлыклардан тиарга тартучы (вөҗдан)дан гыйбарәт булса, менә шушындый чын иман адәм баласыны бәла-шөбһә, шиксез гәдаләт, иманәт һәм һәртөрле изгелек юлларына күндерүче. Хыянәт, җәбер-золым, хөсед, исерткеч, зина кебек һәрбер бозыклыкдан тияр. Һәм адәм баласын хәзер дә һәм киләчәкдә, дөньяда һәм Ахирәтдә бәхеткә ирештерер. Шуның өчен Аллаһы тарафындан килгән шәригатьләрнең һәрбере иман мәсъәләсенә бөтен нәрсәгә караганда зур әһәмият, зур игътибар биргәнләр. Чын иман, күңелдә булыб, күңел төзек булмаса, тышкы якдан гына булса, бөтен тормышымызның бозык булуы мөмкин. Бәгъзе берәүләр тышдан гына никадәр суфи күренеб, әстәгъфирулла, кәлимәсен никадәр күб әйтсә дә, үзе һаман бозыклыкны кылыб йөргән кешеләр бар. Шуның чын иман күңелдә булганлыкдан безнең һичберебез берәүнең күңеленә көчләб иман тагырга, иман урнаштыра алмыйбыз. Бары вәгазь-нәсыхәт юлы белән аңлату. Ислам диненең тоткан юлы шушы: "Лә икраһә фид дин" вә
فَمَن شَاءَ فَلْيُؤْمِن وَمَن شَاءَ فَلْيَكْفُرْ ۚ
сүрәтел Кәһф:
ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ ۖ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ
Әгәр дә берәүнең күңеленә чын иман кереб урнаша икән, моны беркем дә көчләб чыгара алмый. Берәүгә никадәр көчләб иманлы итәргә тырышсак да, бу иман тышдан гына булырга мөмкин. Бәлки чын иман күңелдә булырга тиеш. Ислам дине һичбер вакытда көчлек белән каралмады. Рәсүлулла һәрвакыт вәгазь-нәсыйхәт юлы белән дингә әйдәде. Ислам тарихын укыган кешеләргә мәгълүм: Ислам дине тарафындан алынган һәрбер халыкга чын ихтыяр бирелде. Теләсәң – дине Исламга керәсең, теләсәң – үз динеңдә калыб.
Хасыйлел калям (кыскасы – А.Х.), чын иман күңелдә булган бер сыйфат, беркемнең күңеле Алладан башкага мәгълүм түгел. Тышкы кыяфәтенә караб беркемне үзебезчә хөкем итәргә беребезнең дә хакыбыз юк:
إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ
Чын ышанычлы, нык иман: иман хакыйки иннәма истидләли – дәлилле иман һәрнәрсәгә гыйбрәт күзе белән караб, гакылларыбызга салыб, уйлаб карарга кирәк.
تفكروا فى خلق الله و تتفكروا فى ذات الله
хәдисен истә тотыб, хакыйки, истидляли иманга ирешеб, җенабее Раббел галәмин хозурына хакыйки иман вә кальбе сәлим белән күчергә насыйб булсын. (0579)
عن ابو ذريرة راضى الله عنه انه قال: قال رسول الله صلى الله عليه و سلم:
الإِيمَانُ بِضْعٌ وَسَبْعُونَ شُعْبَةً ، أَوْ بِضْعٌ وَسِتُّونَ شُعْبَةً ، أَفْضَلُهَا لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ ، وَأَدْنَاهَا إِمَاطَةُ الأَذَى عَنِ الطَّرِيقِ ، وَالْحَيَاءُ شُعْبَةٌ مِنَ الإِيمَانِ
Кәлям таййиб хакында сүрәэи "Ибраһим":
استعيذ بالله كَلِمَةً طَيِّبَةً كَشَجَرَةٍ طَيِّبَةٍ أَصْلُهَا ثَابِتٌ وَفَرْعُهَا فِي السَّمَاءِ
Ягъни иман: тамырлары җиргә нык бөркетелгән, ботаклары һавага таралган. Тәмле, татлы җимеш бирә торган хөрмә агачы кеби, диб мисал китерә.
Әгәр дөнья тормышында бер йимеш агачы утыртыб, шуны яхшы тәрбияләсәң
وَالَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ أُولَٰئِكَ أَصْحَابُ الْجَنَّةِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ
җөмләсенә кереб, мәңгелек сәгадәткә, бәхеткә ирешәчәкбез. Инде шушы агачны яхшы тәрбия кыла алмый, начар сулар сибеб, җимеш агачыбыз корыган кебек, Алла сакласын, безнең иманыбыз сәбәбле киткән.
استعيذ بالله
بلى من كسب سيئة وأحاطت به خطيئته فأولئك أصحاب النار هم فيها خالدون

Ягъни: аларга ут газабы күб ирешер, чөнки һәркем яман кәсеб итсә, хаталары аны чолгаса, анлар ут әһелләредер. Анда мәңге калачаклардыр. Алланың рәхмәте вә газабы бәндәнең иман вә гамәленә күрә булачакдыр.
Җомга көн. 11нче август. Бисмилләһир рәхманир рәхим
Ихлас күңелләребез белән җомга намазы укырга җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллахи вә бәрәкатуһу!
Мөхтәрәм җыелган җәмәгать! Узган дүшәнбе көн 7нче август көнне Җәмадил әүвәл аеның беренче көне булыб узды. Ай башы хакында узган җомгада әйтелергә тиеш иде. Бу минем тарафымдан булган бер кимчелек, гафу итегез!
Өстебезгә туган җәмадил әүвәл ае җөмләбез өчен мөбарәк булыб, илебезгә тынычлык, тәнләребезгә сәламәтлек биреб, начар эшләрдән тыелыб, Алла разый булырлык яхшы эшләр, яхшы гамәлләр белән уздырырга Алла насыйб итсен. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Узган җомгада иманны, тамырлары җир астына нык урнашкан, ботаклары һавага таралган, тәмле, татлы җимеш бирә торган бер хуш агачка охшаткан, диб сөйләгән идем. Иманның иң әгъля, югары дәрәҗәсе: “Лә иләһа илләллаһ”, диб әйткән идем. Иман хакында хәзрәт Рәсүл шундый сөенечле сүз әйтеб, безне сөендерә:
أَبْشِرُوا ، وَبَشِّرُوا مَنْ وَرَاءَكُمْ ، أَنَّهُ مَنْ شَهِدَ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ صَادِقًا بِهَا ، دَخَلَ الْجَنَّةَ
Ягъни: сезгә сөенечле хәбәр бирәм. Сез һәм үзегезнең артыгызда булганларга сөенеч бирегез, (0581): Аллаһы Тәгалә хәзрәтене чын күңеле белән тәухид итүче кеше, әгәр дә шул тәухиде, ышануы үзренә улса, җәннәт әгъля керәчәктер.
Хәзрәт Рәсүл икенче хәдисендә әйтә:
الإِيمَانُ بِاللَّهِ وَالْعَمَلُ قَرِينَانِ لا يَصْلُحُ وَاحِدٌ مِنْهُمَا إِلا مَعَ صَاحِبِهِ
Ягъни: иман бергә гамәл бер-берендән аерылмый торган иптәшләр, ди.
Намаз уку, ураза тоту белән генә мөселманлык тәмам булмый. Әгәр бер кеше үзен иманның җимешләре, күркәм гадәтләр (حسن الخلق نصف الدين), ди . Ни ригаять кылыб һәр ярдәмле, шәфкатьле булса, һәрвакыт күңелендә башкаларга яхшылык, изгелек итү теләге булса, теле белән, кулы белән кирәк, кем генә рәнҗетүдә бөтен кешелек дөньясына зарар китерә торган дибез дә, каты харам булган, каты тыелган исерткеч эчүдән сакланса, гайбәд, хөсед, һәртөрле фетнәгә сәбәб була торган эшләрдән сакланса, сакланырга тырышса, менә бу кешеләр хакында Коръән газыймдә:
استعيذ بالله وَالَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ أُولَٰئِكَ أَصْحَابُ الْجَنَّةِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ
ди. Ягъни: Аллага иман китергәнең соңында изге гамәлләр кылдылар. Менә шушы кешеләр җәннәт әһеле, җәннәттә мәңге калачаклар, бетмәс-төкәнмәс бәхеткә ирешәчәкләр, ди. Хәзрәт Рәсүл әкрам мөселманлыкны тәгъриф кылыб:
المسلم من سلم مسلم من لسانه و يده
Ягъни: мөселман булган кеше беркемне дә  теле белән дә, кулы белән дә, хәтта зарары тими торган башка мәхлукатларны да рәнҗетмәс, бөтен кешеләр аның җәбер-золымыннан сәламәт, әмин булырлар, ди. Әгәр бер кеше иман кәлимәсен үзендән өзми итеб йөртсә дә, башкаларны теле белән дә, кулы белән дә рәнҗетүдән сакланмаса, ике кеше арасын бозышдырыр, дошманлаштырыр өчен сүз йөртсә, халык шау-шуга, фетнәгә, аерылышуга сәбәб булган эшләргә катнашса, гайбәт, ялган сөйләсә, менә бу кешеләр һәркайсы иманны зәгыйфләтә торган, кылган гамәлләребезнең сәвабын бетерә торган, динебез тарафындан нык тыелган начар гадәтләр булыб, чын иманлы кеше бу эшләрдән бик сакланырга кирәк.
Мөбәрәк пәйгамбәребез тагын да бер хәдисендә әйтә:
وَالَّذِي نَفْسِي بِيَدِهِ لا تَدْخُلُوا الْجَنَّةَ حَتَّى تُؤْمِنُوا ، وَلا تُؤْمِنُوا حَتَّى تَحَابُّوا ، أَوَلا أَدُلُّكُمْ عَلَى شَيْءٍ إِذَا فَعَلْتُمُوهُ تَحَابَبْتُمْ أَفْشُوا السَّلامَ بَيْنَكُمْ

Ягъни: нәфсем – ул Алланың кодрәт кулында булган, Аллаһы хакы өчен итәмен, ди. Чын мөэмин булмаенча җәннәткә кермәссез, ди. Вә мөэмин камил булмасагыз, чын мөэмин булмассыз, ди. Бер-берегезгә өлфәт, мәхәббәт, дустлык, татулык белән карагыз, ди. Шушы эшне, шушы гамәлне кылсагыз, узарагызда өлфәт, мәхәббәтегез артыр, дустлык урнашыр, тынычлык урнашыр, ди.
أَفْشُوا السَّلاَمَ بَيْنَكُمْ
ди. Узара сәламне фаш кылыгыз, ди. Якты чырай белән кычкырыб сәлам биргәнегез соңында күңеллек белән дә бу кешегә чын җаннан яхшылык, изгелек теләүче булырга, Алладан сәламәтлек теләү белән бергә сез минем үземдән дә амин булыгы, минем хакында бик тыныч булыгыз. Мин сезгә һич бер явызлык теләмим. Күңелендә шушындый ният белән бирелгән сәлам-иманны ныгыта торган, дөньяда да татулык, дустлык белән тыныч яшәргә сәбәб булган изге гамәл була. Әгәр узара сәлам бирешеб тә, күңелебездә гөнаһ, хөсед, гайбәт, күңелдә тынычсызлыкка сәбәб була торган явыз ният, бу рәвешле сәлам имандан ераклаштыра торган начар гамәл җөмләсендән булуы мөмкин.
Җенабее Хакк барчабызны бөтен бозык гадәтләрдән пакъ кылыб, күркәм холыклар, яхшы гадәтләр белән гадәтләнергә насыйб итсен.
Кеше нәрсә белән чын мөэмин мөселман була ала.
Пәйгамбәр Ходаның хикмәтле сүзен әйтми калдыру мөмкин түгел. Хәзрәт Рәсүл әйтә:
إِذَا سَرَّتْكَ حَسَنَاتُكَ وَسَاءَتْكَ سَيِّئَاتُكَ فَأَنْتَ مُؤْمِنٌ
Ягъни: һәркайчан сине нинди генә яхшылык-изгелегең шатландырса, яман эшләрең, начарлыкларың сине кайгыртса, син мөэминсең, ди.
Мөхтәрәм мөселманлар! Яхшылаб уйлаб карыйк. Хәзрәт Рәсүлебезнең бу сүзе белән бергә чын иманлы булуның юлын өйрәтә, үзебезне үлчәб карар өчен кулыбызга үлчәү тоттыра. Әгәр Алланың бер бәндәсенә яки бер башка мәхлукына файдаң тисә, аңа нинди дә булса бер яхшылык кылсаң, соңра шул эшкә жаның рәхәтләнсә, андан тәм табса, бу хәл синең иханлы булуыңның билгесе, галәмәте, шулай ук зарарың тиюе, яманлык кылуың сине кайгыртса, шушы начарлык хата эшең жаныңны рәнҗетсә, күңелеңне тырнаса, бу да синең чын мөэмин булуыңа галәмәт билгесе була. Хәзрәт Рәсүл менә бу хәдисе белән дөньяда тору рәхәт, тыныч яшәргә сәбәб булган һәрбер яхшы эшләргә кызыктыра, тарта торган яман, начар эшләргә нәфрәтләндерә, алардан ераклаштыра торган бер сыйфатка гадәт итәргә, һәм адәм баласы шушылай булса гына, чын мөселман була ала.
Менә шушы сыйфат, шушындый куәт безнең шәригатемез кашында “кальбе сәлим” диб тәгъбир кальбенә Алла каршында шушы “кальбе сәлим” генә нәҗат һәм мәңгелек сәгадәткә ирешергә сәбәб була икән. Коръән Кәрим:
استعيذ بالله
يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ
ди. Ягъни: ул көндә мал һәм балалар файда бирмәс, мәгәр Аллага пакъ күңел белән килгән кешегә кальбене, күңеленең дөрестлеге генә файда бирер, ди. Менә Коръән тәгъбирендә “кальбе сәлим” диб аталган мәгънәви куәт әдәби телебездә “пакъ вөждан” саф вөждан диб атала. Шушындый мактаулы сыйфат күңелебездә булса гына иманыбыз камил була икән. (18нче август, җомга).
Бисмилләһ. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем!
Җенабе Раббел галәмин хәзрәте җомга көндә җомга намазларыбызны мөбарәк кылыб, киләчәкдә дә саулык-сәламәтлек, тынычлык белән күп елларга пакъ булган Ислам динебез кушканча яшәргә Алла насыйб итсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Исламның бинасы, нигезе биш нәрсә үзен бина кылынган, төзелгән

дигән идем. Исламның бинасы, нигезенең икенчесе муеныбызга фарыз булган биш вакыт намаз уку. Пәйгамбәребез шушы намаз хакында сөйләгән сүзләре, хәдисләре бик күб (“Әссалават гыймадед дин”). Намаз – диннең терәге, ди. Әгәр берәү намаз укыса, бу кешенең исламы камил булыб, (0586) дине нык була. Әгәр бер кеше, иман әһеле булыб та, намазга ялкаулык кылса, диненең нигезе зәгыйф булыб, әгәр йортның нигезе начар булса, сыйфаты да начар шикелле, шушы Исламның булган биш нәрсә (әркан хамсә) диб әйтелеб, шушы икенче рөкене булган намаз һәркемгә фарыз, гәйн, ягъни үзе үтәргә тиеш. Менә шушы намаз гыйбарәте бу мөселманларга Мәккә вакытда фарыз булган намазның фарызлыгы Коръән Кәрим, бергә сабит булыб, Коръәндә күб урында “акимус салават”, диб кылынган намаз укымаучылар хакында зур тәһдидләр, куркытулар сөйләнгән. Шуның өчен әгәр Аллага ышансак, Кыямәт көненә ышансак, намазга йиңел карарга ярамый: “Әссалават нурель муэмин”. Иң беренче тышкы файдаларын тикшереб карасак, ул намаз укыган кешенең киеме, тәне пакъ булырга тиеш. Әгәр бер кешенең киеме, тәне пакъ булса, ул кешенең сәламәтлегенә зур файда. Әгәр бер кешенең тәне сәламәт булса, ул адәмнең гакылы сәламәт була, дигәннәр хакимләр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Коръәндә:
إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ
– намаз фәхеш вә мөнкәр эшләрдән тыяр диб, әгәр берәү намаз укыб та, мөнкәр вә бозык эшләрдән: гайбәт, хөсед, ялган эшләрдән тыелмаса, бу рәвешле намаз укучының намазы камил намаз булмас. Мондый эшләрдән бик сакланырга кирәк.

Намазны торгызу, үтәү ике төрле диб белән хасыйл була.

Беренче – тышкы әдәбләр, заһири әдәбләр: намазның важибләрен, сөннәтләрен ригаять кылыб уку. Менә бу – намазның тышкы күренеше.

Икенчесе – әдәб батыйнисе (эчке, яшерен – А.Х.): намаз рухи, җани. Хошугъ кальб вә хашийә Алладыр. Ягъни Алла хозурында чын курку белән куркыб, күңелне сындырыб, түбәнлек, тәвәззаглык хәлендә тотудыр.

Кыскасы, бәндә үзенең чын Раббысы, халикы, хуҗасы хозурында торам һәм Аңа мөнаҗәт кылам, бөтен кирәкләремне сорыйм, диб белмәкдер.

Сәхабә салихлар намаз укыганда: Хода хәзрәти, өстемдән Караучы, Күреб торучы. Уң тарафымда җәннәт, сул тарафымда тәмугъ. Үзен сыйрат күпере өстендә торган кебек гыйбадәт кылганлар. Хәзрәт Рәсүлнең хәдисе:

اعوذ بالله أن تعبد الله كأنك تراه فإن لم تكن تراه فإنه يراك و احسب نفسك مع الموت
– үзеңне Алла хозурында итеб хисаб кыл, ягъни намаз укыган вакытда камил хошугъ, ходугъ белән кыл. Намазда үзеңне Алла хозурында торган кебек, бөтен дөнья уйларын күңелеңдән чыгарыб, уңга-сулга күзеңне төшерүдән сакланырга. Кыямәт вакытда рөкугда аяк бармакларыңа кара, сәҗдәдә вакыт борыныңа кара, эттәхыятдә вакыт алдыңа кара. Шушы зур игътибар белән укылырга тиеш.

Хәзрәт Рәсүл: “Йәфәстә тирәдәге патшаларны Ислам диненә өндәргә җибәрергә илчеләр арасында Рум кайсарләренә, Рум патшасына да илчеләр бар”. Рум илчелегеннән, җирендән кайткан илчеләр кайтканын соңында Рум патшасы хозурында күргән гаҗәбләрне сөйләгәндә: патша хозурында шундый сакчы солдатларны күрдек, гаудә әгъзаларында каплаган ялангач солдатлар кылычларын күтәргәнләр, һич кымылдамыйлар, ясаган сүрәт кебек катыб калганлар, хәтта тәнләрен усал чебеннәр тешләб кан чыгаралар. Шул вакытда да һич кымылдамыйлар. Әгәр дә боларның алышынган вакытларын күрсәң, җансыз тора идек, диб сөйләделәр. Шул вакыт хәзрәт рәсүл: “Дөнья патшаларындан бер патша каршында сакчы солдатлар шушылай итагать кылсалар, бөтен дөнья уйларын хәтерләрендән чыгарыб, җансыз нәрсә кебек катыб калсалар”. Инде бер мөселман үзенең

юкдан бар кылган, бөтен хастәләре аның тарафындан гына үтәлергә тиеш, уйлаган Рабел галәмин булган Аллаһы хәзрәтенә хозурына (мөэминнәрнең Мигъраҗе) булган намаз укырга диб, намазга керешә икән, бу кеше бигрәк тә кыймылдамаска, күзен анда-монда йөртмәскә, күңелләребезне хәтта уйларындан бушатыб, намазларыбызны шушы рәвешдә үтәргә тырышсак, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләренең "Мөэмин" сүрәсендәге:
قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ
Намазларын хошугъ белән укыб, Аллаһының газабындан котылыб, мәңгелек сәгадәткә, бәхеткә ирешделәр инде, мөхтәрәм җәмәгать!
Ерак-ерак җирләрдән киләбез, тәнләребезне, киемләребезне пакълыйбыз. Күбчелек олы яшьтәге кешеләр арабызда сәламәтлегебез зәгыйфь кешеләр бар. Шушылай зур мәшәкатьләр белән Аллаһының ризалыгына зур әҗергә ирештерә торган намазларыбызны мөмкин кадәр зур ихлас белән, дөнья уйларыннан, һәртөрле вәсвәсәләрдән сакланырга тырышыб укыган намазларыбыз Аллаһы кашында кабул булыб, һәртөрле куркынычлы хәлләрдән амин булыб, мәңгелекгә ирешергә сәбәб булсын иде.
Шушындый зур өметләр белән укыган намазларыбызны, намаз соңында үзара араларыбызны бозыштыра торган әллә кемләрнең гайбәтен сөйләсәң, ялган сөйләсәк, бу эшләр һәркайсы яхшы гамәлләребезнең сәвабы китә торган, бәлки артыкка китсә, бөтенләй юкка чыгара торган начар гадәтләр. Аллаһы Үзе сакласын. Моның мисалы шуның шикелле: бер кеше никадәр зур газаблар, мәшәкатьләр чигеб иген чәчеб үстерә. Ни кадәр зур өмедләр, файдалар көтеб тора. Инде тәмам өлгереб җитте, бүген-иртәгә урак җыеб алам дигәндә генә, ут төртеб яндырыб, бөтен ашлыгы көл булыб юкка чыгарган шикелле.
Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре барчаларыбызга нәфсебезгә хуҗа булыб, телләребезне вә башка әгъзаларыбызны начарлыклардан тоеб, газабланыб кылган гыйбадәтләребез Аллаһы кашында кабул булыб, мөэмин колларына вәгъдә кылынган әҗер вә сәвабларга ирешергә насыйб булсын.

Дәфтәр "3нче номер"
1967
№3
Сентябрьдән.
1. Намаз хакында.
2. Үлемне искә алу хакында.
3. Күркәм халык турында.

Бисмилләһир Рәхманир Рәхим
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһының мөбарәк йортына, мәсҗедкә саф иман, пакъ күңел белән Алланың рәхмәтендән, фазыйлыныдан өмед итеб, күбчелек белән дөньяви, ахирәви хаҗәтләребезне теләргә, дога кылырга диб җыелган хөрмәтле мөселманлар!
Алланың сәламе, Алланың рәхмәте вә һәр эшләребездә, гомеребездә, тормышыбызда барчаларыбызга насыйб булсын.
Мөхтәрәм мөселман кардәшлрем!
Динебезнең терәге, мөэминнең нуры, дөньяви, ахирәви сәламәт булуыбызның сәбәбе

Аллаһы кашында, гамәлләрнең сөекләреге, артыграгы булган намаз хакында тагын бер кадәр сөйләб үтәкче булам. Кабатлау булса да, безнең арабызда пәйгамбәр сөннәтенә хыйляф, күңелсез гадәтләр күренгәнлекдән, тагын да сөйләб үтсәк, инша Алла, файдадан хали буш булмас.
Калә Рәсүлуллаһ (сгс):
قلوبكم تختلف لا صفوفكم سووا
- Сафларыгызны тигезләгез, күңелләрегез төрлеләнмәсен, арагызда ихтиляф чыкмасын. Сафларыгызны тигезләгез, юкса Аллаһы Тәгалә күңелләрегезгә төрлелек сала, - ди.
Икенче бер хәдисендә:
الصلاة حسن من الصلاة تمام من الصَّلَاةِ إِقَامَةِ مِنْ الصُّفُوفِ تَسْوِيَةَ فَإِنَّ , صُفُوفَكُمْ سَوُّوا
- Сафларның тигезлеге бөтен мәзһәбләр кашында игътибар белән искә алына торган сөннәт гамәл булыб, хәтта Рәсүлуллаһ безне шушы белән әмер кылганлыкдан, шушы гамәлнең хыйляфы эшләнүдә вә гаед булганлыкдан, бәгъзе бер галимләр, важиб диб әйтүчеләр бар икән. Хәзрәт Рәсүл бу хакда бик күп сүзләр сөйләб, шушы сафларны тигезләүгә зур әһәмият биргән. Хәтта гаскәр башлыгы шикелле сафларны үзе тигезли торган булган. Алда торганны арткарак, артдагыны алга тарткан. Тигез тормасагыз, арагызга күңел төрлелеге, фикер вә сүз башкалыгы керер. Хәзрәт Мөхәммәдне Аллаһының рәсүле диб ышанган һәрбер мөселманга аның һәрбер өйрәтүене кабул итү өчен күңелдән һәр эшләребездә аңа ияргә тырышу безгә лязим булган эш.
Рәсүл вә аның сәхабәләре намазга керешүдән элек як-якка караб, сафларны тигезлиләр икән. Әгәр шушы эшкә салкын караучылар, җиңел караучылар булса, гәмалән тигезләгәнләр, сафлар тигезләнмичә тәкбир кылмаганлар. Иң дөрес, иң сәваблысы
الصلوة قامت قد
дигәндә, тәмам сафланыб, тигезләнеб, тәкбир-тәхримгә хәзер булыб тору. Хәзерге вакыт ничекдер, ул вакытларда Мәккә мөкәрәмәдә, Ахшамдан кала, бөтен намазларда мөэззин бөтен халыкка ишеттереб:
الصَّلَاةِ إِقَامَةِ مِنْ الصُّفُوفِ تَسْوِيَةَ فَإِنَّ , صُفُوفَكُمْ سَوُّوا الله رسول قال
- диб әйтәләр икән. Мәдинә мөнәввәрәдә имам тәкбир-тәхримдән элек: тигезләнегез! Алланың рәхмәте булсын, диб әйтү гадәте булган.
Инде мөхтәрәм җәмәгать!
Үзебезне чагышдырыб карыйк: мин үзем утыз биш елдан артык шушы мәсҗеддә җомга укыб, гозерсез җомгадан калмаганлыкдан үзебезнең халкыбыз арасындагы күңелсез гадәтләрне, әдәбсез хәлләрне җик күрдем. Сафларыбыз һичбер вакытда тигез булмый, бер-беребезгә сафларны тигезлик. Алгарак яки арткарак барыгыз, диб әйткән кешеләрне яратмыймыз, дәшми калу гына түгел, хәтта әйткән кешене ачуланамыз. Дөрест, җәмәгать, җомга намазларында халык күб булу сәбәбле, заллар тыгыз була, эссе була, уңайсыз була. Шушы уңайсызлыкларга түзсәк, сабыр итсәк иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре әйтә:
يسرا العسر مع فان
Һәрбер авырлык белән җиңеллек, һәрбер борчулы хәлләрнең ахыры шадлык була.
Шушы гыйбадәт вакытында булган уңайсызлыкларга сабыр итсәң, сабыр, бәла-каза, – кайсы хәсрәткә генә сабыр итү түгел, бәлки начарлыкдан тыелуга сабыр итү, гыйбадәт вакытындагы мәшәкатьләргә сабыр итү. Сабырлык белән үткән намазларыбыз беренче – Аллага гыйбадәт кылу сәвабына ирешсәк, икенчедән – сабыр итүчеләр сәвабына
الصابرين بشر و الصابرين؛ مع الله ان
дигән адәмләр рәтенә кереб, зур әҗер вә сәвабларга ирешербез. Арабызда бер-беребезгә

урын бирешсәк,
لنفسك تحب ما للناس احب
хәдисенә бина (бина: таянып – А.Х.), тагын да пәйгамбәрнең бер сөннәтен үтәгән булырбыз.
Тагын да бер искә алырга тиешле эш булса, ул да – бигрәк тә кыш көннәрендә мәсҗеддә кеше күб булу сәбәбле, һәрвакыт шау-шуларга сәбәб булган форточкаларны ачу-ачмау мәсъәләсе. Мәсҗеддә һәрвакыт саф һава булырга кирәк. Адәм баласының иң беренче сәламәтлегенә кирәк нәрсә - саф һава. Әгәр дә берәүләргә ачык тәрәзә янында утыру зарар бирә икән, ул кеше инде ул якка утырмаска тиеш. Тәрәзәләр ачык булмаса, һава бик начарлана, бик күпләрнең күңелләре әрни, борчый, намазга булган дәртне сүндерә. Тәрәзә янында утырган кеше бөтен җәмәгатьнең теләгенә каршы килеб, тәрәзәне ябса, менә бу кешеләр инде الناس خير – хәйрен нас (яхшы кешеләр – А.Х.) булмый, الناس شر – шәррен нас (явыз кешеләр – А.Х.) булыб, бөтен җыелган җәмәгатьне рәнҗеткән булалар. Менә бу эшләрдән бик сак булырга кирәк. Мәсҗеддә генә түгел, башка урынларда да кеше рәнҗетү – хәрам. Менә бу эшләр һәркайсы намаз безнең түбән киметә торган бәлки ифратка китсә, намазларыбызны бөтенләй читкә китүе мөмкин. Ихлас белән укыган намазны Аллаһы кабул итеб, әҗер вә сәвабларга ирешергә насыйб булсын.
Әбу Һурәйрәдән намаз хакында шундый бер хәдис күчерелә: “Рәсүл мәсҗеддә утырган вакытда сәхрә гарәби кереб намаз укый. Намазын укыб бетергәч, рәсүлуллаһ чакырыб ала да: “Намазыңны кайтар, син намаз укымадың”. Икенче мәртәбәсендә шулай укыгач, хәзрәт рәсүл чакырыб, бу гарәбнең намаз укуның тәртибен өйрәтеб: “Һәркайчан намазга трсаң, түбәнчелек, тәвәззаглык белән тәкбир-тәхрир кыл. Үзеңә авыр булмаслык, җиңел булырдай Коръән аяте укы, рөкуг кыл. Рөкугдан каүмәгә тор тәмам тураеб җиткәнче. Аллага дога кылыб сәҗдә, ике сәҗдә арасында тәмам утырыб җитеб (җәлсә) кылыб Алладан күңелең белән ярыкануыңны телә”, ди.
Бик искә алырга тиешле эшләрдән, җәмәгать! Бик сак булырга тиешле эшләрдән – җәмәгать белән намаз укыганда имамдан да алда рөкугың, сәҗдәң имамдан алда колак кагудан бик сакланырга кирәк. Пәйгамбәребез әйтә: “
أما يخشى الذي يرفع رأسه قبل الإمام أن يحول الله رأسه رأس حمار
- ягъни җәмәгать намазында имамдан тәкбир-тәхрирдә рөкүг мәсҗеддә һәм башка рөкенләрдә имамдан элек башлаган адәмләрнең Кыямәт көнендә ишәк рәвешендә кубарылулар куркылган да, курыккан да хас, ди. Җеназа намазында имамдан элек колак кагулар бәгъзе адәмләрдә күренә, бу эшләрдән бик сакланырга кирәк.
Кайчандыр безне рәсүлуллаһ шатландыра:
فُضِّلْنَا عَلَى النَّاسِ بِثَلَاثٍ: جُعِلَتْ صُفُوفُنَا كَصُفُوفِ الْمَلَائِكَةِ، وَجُعِلَتْ لَنَا الْأَرْضُ كُلُّهَا مَسْجِدًا، وَجُعِلَتْ تُرْبَتُهَا لَنَا طَهُورًا، إِذَا لَمْ نَجِدِ الْمَاءَ
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә хәзрәте безне әшрафел әнбия, афзалел әнбия булган Ахры заман пәйгамбәре өммәтендән итеб яраткан. Безнең шәригатемездә көч җитмәслек эшләр йөкләтелмәгән. Адәм балалары һәрнәрсәне дә белеб бетерә алмыйбыз, килешмәгән, күңелсез гадәтләребезне бер-беребезгә әдәби рәвешдә өйрәткән кешегә һичбер вакытда да ачуланырга ярамый, бәлки, киресенчә – рәхмәт әйтергә генә кирәк. Аллаһы хәзрәте бәндәчелек белән булган хаталарыбызны, кимчелекләребезне гафу итеб, ихласыбыз хөрмәтенә кылган гамәлләребезне кабул итеб, мәңгелек сәгадәткә ирешеб, әҗер вә сәвабларын күрергә насыйб итсен.

1967нче ел, 1 сентябрь, җомга көн.
Бисмилляһир Рәхманир Рәхим
Ихлас көңелләребез белән Аллага гыйбадәт кылыр өчен мәсҗедкә җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булса иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы насыйб итсә, 5нче сентябрь, сишәмбе көн, Җәмадел ахыр аеның беренче көнне булачак җенабе Раббел галәмин хәзрәте өстебезгә туачак айны җөмләбез өчен мөбарәк кылыб, илләребез, җанларыбыз тыныч, тәнләребез сәламәт, шадлык белән күрергә насыйб булсын.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте Коръәндә “Җомга” сүрәсендә әйтә:
قُلْ إِنَّ الْمَوْتَ الَّذِي تَفِرُّونَ مِنْهُ فَإِنَّهُ مُلَاقِيكُمْ ۖ ثُمَّ تُرَدُّونَ إِلَىٰ عَالِمِ الْغَيْبِ وَالشَّهَادَةِ فَيُنَبِّئُكُمْ بِمَا كُنْتُمْ تَعْمَلُونَ.
И, Мөхәммәд. Әйтсен шунда ләин үлем – ул сез андан качасыз. Беркемнең үләсе килми, никадәр генә озак яшәүгә карамасдан, һаман дөньяда яшисе килә. Ләкин никадәр генә үлмәскә тырышсак да, кайчан гына булса да һәркайсыбыз үлемгә бер йолгачакбыз, очрашачакбыз (ثُمَّ تُرَدُّونَ) , күзебез белән күрмәгән пәйгамбәрләр хәбәр биргән Аллаһы хозурына кайтачакбыз. Үзебезнең кылган гамәлләребездән хәбәр бирeләчәксез, ди.
Һәм Коръәндә берничә урында:
كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ
- Һәрбер җан иясе үлем әчесен татыячак. Моңа һәркайсыбыз ышана, бу һәркемгә киләчәк.
Рәсүл Хода шуның өчен:
أكثروا ذكر هازم اللذات
- ягъни һәрбер ләззәтләрне, рәхәтләрне юкка чыгаручы, кисүче нәрсәне – үлемне күб искә алыгыз. Тагын да хәзрәт рәсүл:
استعد للموت قبل نزول الموت
- ягъни үлем килгәнгә кадәр үлем эчүен хәзерләгез, ди.
Үлем өчен хәзерләнү ничек булырга мөмкин? Үлем өчен хәзерләнү һәрвакыт намаз укыб, рәуза (ураза – А.Х.) тотыб, тәсбих тартыб утыру – үлем өчен хәзерләнү диб аңларга мөмкин. Үлемгә хәзерләнү, үлемне искә алу, һәр эшләребездә тугъры, бозык эшләрдән, начар гадәтләрдән саклану, һәр кылган эшләребездән Аллаһы хозурына барыб, хисаб бирәчәк эш кылу – һәркайсы үлем өчен хәзерләнү булачак. Әмма берәү намаз да укыр, “Истигъфар” кәлимәләрен дә укыр, теле белән: һай, үләсе бар диб, үлемне дә һәрвакыт зикер итәр. Үзе гамәли рәвешдә кеше рәнҗетүдән дә тартынмас, кулы белән, яисә теле белән башкаларны рәнҗетер. Менә бу эшләр үлемне искә алу түгел, киресенчә, үлемне оныту, үз-үзеңне алдау. Хәзрәт рәсүл бер хәдисендә әйтә:
قل آمنت بالله ثم استقم
Аллага иман китердем, диб һәр эшдә тугъры бул, алдама, һичвакыт хыянәт кылма, ялган сөйләмә, сүз йөртмә, көнчелек кылма, гайбәт сөйләмә, менә истикамәтле булу шушы рәвешле була икән.
Әгәр бер адәм сау-сәламәт булыб да, өстебезгә бурыч фарыз булган кәсебне куеб, башкаларга йөк булыб, хәлендән килә торыб да башкалар көчендән файдаланыб халәл кәсебне куйса, бу үлем өчен хәзерләнү булмый, бәлки киресенчә, – үлемне оныту була, үлемне искә алмау була.
Инде берәү халәл кәсебне безгә Аллаһы Тәгалә фарыз иткән кеше өстендән файдалану дөрест түгел диб, аның шушындый ният белән кирәк кайда гына булса да, завод-фабрикаларда, колхозда, совхозда халкыма, ватаныма файдалы эшләр, хезмәтләр күрсәтим

диб, шушындый изге ният белән халәл кәсеб итүе Алла кашында үлем әчен хәзерлек булырга мөмкин.
Хәзрәт рәсүлнең:
الْحَلال طَلَبِ فِي مِنْهَا تِسْعَةٌ : أَجْزَاءٍ عَشَرَةُ الْعِبَادَةُ
дигән сүзенә бинаэ (бинаэ – таяныпp А.Х.). Ягъни гыйбадәт – ун кисәк, шуның тугызы – халәлдән кәсеб итү дигән сүзенә караганда, кәсебең эшләргә яше, сәламәтлеге була торыб, фарыз булган кәсебне ташлаб, ялкаулык юлына керү булыб, халәл кәсеб итү нәфел гыйбадәтләрдән күб сәваблы булыб, үлемне искә алу булырга мөмкин.
Хәзрәт рәсүл әйтә:
الْآخِرَةَ تُذَكِّرُكُمُ فَإِنَّهَا الْقُبُورَ زُورُوا
каберләргә зиярәт итегез, зиярәт итү Ахирәтне искә төшерү, үлемне искә төшерү, ди. Каберләрне зиярәт кылудан төб теләк – үлемне искә алу. Зиратларга барыб да, Ахирәтне искә алмасак, Аллаһы хозурына баруны онытсак, монда һич файда юк.
Инде җәмәгать! Хөтбә дә укымас
مسفرون انكم اعلموا الناس ايها
- И, адәмләр, белегез сез, без һәркайсыбыз бу дөньяда мөсафирләр генә.
Бер агач күләгәсендә, күләгәдә утырыб, ял итеб кешеләр шикелле генә:
داخلون الدنيا رباط في و
Мөсафирханәйә кереб, куныб чыккан адәмләр генә.
محشودون العرصات في و
Гөрсат мәйданына кубарылыб, кырылыб барачакмыз.
محاسبون الميزان عند و
Әхкамел хакимин булган Аллаһы кашында бөтен гамәлләребез хисаб кылыначак. Шушы гөрсат мәйданында Мәхшәр көнендә Адәм балалары әйтерләр, ди:
مرقدنا من بعثنا من ويلنا يا قالوا
ягъни ятагъмыздан (яткан урыннан – А.Х.), каберләремездән кем кубарды, кем торгызды, шул вакыт Аллаһы тарафыннан нида кылыныр.
الْمُرْسَلُونَ وَصَدَقَ الرَّحْمَٰنُ وَعَدَ مَا هَٰذَا
Пәйгамбәрләр аркылы сезгә Алла тарафыннан вәгъдә ителгән көн диб әйтерләр, ди. Үлемдән максуд, үлемгә һәркайсыбыз ышанабыз. Иң дикъкать итәргә тиешле нокта, Аллаһы тарафыннан әйтелер:
الْمُجْرِمُونَ أَيُّهَا الْيَوْمَ وَامْتَازُوا
Яхшылар, яманлардан аерылыгыз.
السَّعِيرِ فِي وَفَرِيقٌ الْجَنَّةِ فِي فَرِيقٌ
диб әйтелде.
Һичкайсыбыз белә алмаебыз, шушы көндә кайсы фиркадән вә кайсы сыйныфдан булачагымызны.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре барчаларыбызга дөньяда яхшы юлда йөреб, яманлыклардан тыелырга, мөселман булыб үләргә, салих адәмләр белән бергә булырга насыйб итсен.
مفتونين ولا خزايا غير بالصالحين وألحقنا مسلمين وأحينا مسلمين توفنا اللَّهُمَّ
67нче ел 8нче сентябрь, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Җенабе Раббел галәмин хәзрәте җомга көнебезне, җомга көнендә кылган гыйбадәтләребезне вә башка изгелекләребезне мәкбуль гыйбадәтләр җөмләсендән кылыб,

бүгендән соңда Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызгы саулык-сәламәтлек, тынычлык белән хәерле гомер биреб мөбарәк йортына килеб, гыйбадәт кылырга вә догалар кылышырга Аллаһы насыйб итсен.
Картлар вә мөтәвәллият әгъзалары дога үтенәләр.
2. Әстерхан шәһәре мөселманлары вә имамлары бер мәхәлля картыбыз аркылы безгә сәлам табшыралар. Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Мөхтәрәм җәмәгать! الحمد لله رب العلمين
Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә никадәр хәмде вә шөкранәләр кылсак да, аз булыр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте безне әшрафел мәхлукат булган әдам баласы итеб яраткан. Һәм безгә гакыл нигъмәте биргән. Шушы гакыл аркасында яхшы белән яманны, ак белән караны аерырга ирешкәнмез. Инде зур нигъмәтләр өстенә Аллаһы хәзрәте безгә хак булган, тугры булган Ислам динен, пәйгамбәрләр җибәреб, безгә өйрәткәнләр. Менә шушы биргән кадәрле нигъмәтләренә ни кадәр шөкранә вә шушы Ислам динен безгә түкми-чәчми ирештергән пәйгамбәребезгә ни кадәр салават әйтсәк тә, аз булыр. Менә шушы Алланың хөрмәтле дустлары, Алланың илчеләре безгә дөнья Ахирәт бәхетле, тыныч, рәхәт яшәвебезгә сәбәп.
Һәрбер гали сыйфатларны аермачак аңлатканнар, һәм адәм балаларының дөньяда вакытда ук һәртөрле бәхетсезлекләргә дөнья Ахирәт үкенчек калдыра торган һәртөрле начар гадәтләрдән безне тыйганлар. Менә шушы пәйгамбәрләр өйрәткән яхшы гадәтләр (хөсне әхляк вә мөкаррәм әхляк) әхляк хәмидә диб аталалар.
Җенабе Хак бәндәләрнең үзләренә һәм башкаларга дөньяви һәм ахирәви файда бирерлек гадәтләр, сыйфатлар һәркайсы әхляк хәмидә өндәб һәм үзенә вә башка зарар киләчәк начар, явыз гадәтләрдән (әхлякун зәмим)дән тыелырга кушыб пәйгамбәрләр җибәргән. Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс) шушы хакында бик күб сүзләр сөйләгән.
بعثت لاتمم مكارم الاخلاق
“Мин күркәм халыкларны өйрәтүне тәмамламак өчен җибәрелдем”, - ди.
Тагын да: Күркәм холыкның фазыйләтләре хакында, аның Аллаһы каршында ни дәрәҗәдә зур, сәваблы эш икәнен белдереб,
إن العبد ليبلغ بحسن خلقه درجة الصائم القائم
ягъни күркәм холыклы кеше шул гүзәл холкы сәбәбле көндезләрдә нәфел рәузалары тотыб, кичәләрдә төн йокламый, гыйбадәт кылыб, намаз укыб үткәрүчеләр дәрәҗәсенә ирешә алыр, ягъни шуларга булган әҗер вә сәваблар аларга булыр, ди.
Күркәм холык турында Коръәндә аятьләрдә, зикерләрдә күб әйтелә. Күркәм холык хәзрәт рәсүлнең:
حسن الخلق نصف الدين؛ الخلق حسن من الامان
ди. Менә шушы күркәм холыкның төрләре, санлары бик күб булыб, шулардан: һәркемгә якты чырайлы булу; тәмле телле булу; ата-анага изгелек кылу, аларны хөрмәт итү; картларны, карчыкларны хөрмәт итү; күршеләрең белән тату тору, аларга яхшылык итү; сабырлы булу; юмарт булу; бөтен адәм балаларына, хәтта зарары тими торган бөтен җан иясенә шәфкатьле булу; остазларны, галимләрне, гыйлем әһелләрен хөрмәт итү; гыйлемне сөю; аманәткә хыянәт итмәү; йәрвакыт дөрест сүзле булу, ялган сөйләмәү; гадел булу, һич беркемгә җәбер-золым итмәү вә бөтен кеше хакында хөсне фикерле булу; кешедән көнләшмәү; һәркемгә тәвазыйг, түбәнчелекле булу – тәкәббер күңелле булмау; кешеләрнең гайбәтен сөйләмәү; икейөзле , мөнафик булмау; дуст адәмләрнең, туганларның хәлләрен белү; сүз йөртмәү; ике кеше арасын бозмау; мөмкин кадәр үбкәләшкән адәмләрнең арасын төзәтү, аларны килештерергә тырышу; әдәбле, инсафлы

булу; тәммаглы булмау вә ягъни һич беркемдән һичнәрсә өмед итмәү; яхшылык кына түгел, яманлыкка да яхшылык итү; исрафдан саклану; үч алмаска тырышу; һәр эшдә сабырлык белән итү; һәркемгә өлфәт, мәхәббәт итү; ачык йөз, татлы, тәмле сүз белән күрешү; кычкырыб, кыһ-кыһлаб көлмәү; һәркемгә көчең җиткән кадәр ярдәм итешү; һәрвакытта да пакълеккә ригаять кылу; балаларны әдәбкә, тәртибкә өйрәтү; ялкау булмау, тырыш булу; батыр булу, куркак булмау; хәзрәт рәсүлнең сөннәтләренә гадәт итү, иярү; эшсезлек, ялкаулык, теләнчелекдән саклану; исерткеч эчүдән саклану; гыйффәтле булу, зинадан саклану. Менә шушы сөйләнгән гадәтләр, сыйфатлар – һәркайсы "әхляк хәмидә" җөмләсендән булыб, шушы сыйфатлар, шушы гадәтләрне исендә тотыб, шулар белән гадәтләнерргә тырышса, дөньяда ук халык арасында абруе артыб, дәрәҗәсе күтәрелеб, Аллаһы Раббел галәмин хозурында да зур әҗер вә сәвапларга ирештерә торган дөнья Ахирәт бәхеткә, сәгадәткә сәбәб булган изге гамәлләр булыб, шушыларның киресе, каршы гадәтләр, сыйфатлар – һәркайсы әхляк зәмим (зәмим – начар, порочный А.Х.) пәйгамбәребез, динебез тарафындан каты рәвешдә тыелган начар, кабих гадәтләр булыб, адәм баласын дөнья Ахирәт үкенәчәк, хәсрәткә калдыра торган сүэ (сүэ – начар А.Х.) әгмал булыб – бозык вә начар гадәтләр.
Шушы югарыда әйтелгән гадәтләр, сыйфатлар – һәркайсы хәзрәт рәсүлнең гадәтләре булыб "Нун" сүрәсендә мөбарәк пәйгамбәребез хакында:
عظيم خلق لعلى انك و بالله استعيذ
ягъни син гали, олугъ булган күркәм холык үзрендә син, ди.
Хәзрәт Гайшәдән хәзрәт рәсүлнең Холкы, гадәтләре турында.
Хәзрәт Гайшә ул сораучыга: "Аның холкы Коръән иде. Син Коръән укысаң, "Мөэминун" сүрәсендән:
خَاشِعُونَ صَلَاتِهِمْ فِي هُمْ الَّذِينَ الْمُؤْمِنُونَ أَفْلَحَ قَدْ
ун аять укыб җаваб биргән иде.
Инде киләчәкдә, Аллаһы насыйб итсә, шушы күркәм холык хакында аерым-аерым өйләргә тырышырмыз.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга динебез кушканча, пәйгамбәребез өйрәткәнчә күркәм холыклар белән холыкланыб дөньяда вакытда бөтен адәм балалары белән өлфәт, мәхәббәт, тынычлык белән гомер кичереб Ахирәтдә мәңгелек сәгадәткә ирешүне насыйб итсен.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
14нче сентябрь, җомга көн, 1967 ел.
Җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бохарада укучы шәкертләренең хаты. Мәгълүм итү: Мөхтәрәм җәмагать! Адәм балаларын иң түбән дөньядан югары ашыра торган иң гали, күркәм сыйфатлар белән матурлый, бизи Аллаһы кашында, динебез каршында иң мөкатдәс булган дөнья – Ахирәт. Адәм баласын бәхеткә ирештерә торган нәрсә – гыйлем, белем, галим булу, гыйлем өйрәнү, гыйлемне өйрәтү, гыйлем әһелләрен, гыйлемне сөю: Ислам дине шул кадәр гыйлемгә әһәмият биреб, дөньяның иң беренче сүзе – اقراء сүзе белән башланыб, укы, галим бул, адәм балаларын укырга, язырга, гыйлемгә өндәб башлана:
يَعْلَمُونَ لَا وَالَّذِينَ يَعْلَمُونَ الَّذِينَ يَسْتَوِي هَلْ
النُّورُ وَلَا الظُّلُمَاتُ وَلَا وَالْبَصِيرُ الْأَعْمَى يَسْتَوِي وَمَا
Коръәндә һәм башка аятьләрдә бик күб урында гыйлемне, галимләрне зикер әйтә. Ягъни:

бәлки адәмләр белән, ягъни галимләр белән наданлар тигез булырмы? Һич юк. Һәм сукыр кеше белән күзле адәм бер булырмы? Һич юк. Яктылык белән, нур белән караңгылык һичвакытта да бер булмас. Гакыллы адәм һәрвакытта да караңгылыкта булырга теләмәс, яктылыкка, нурга омтылыр. Һәм пәйгамбәремез бу хакда бик күб хәдисләр сөйләгән:
مسلمة و مسلم كل على فريضة العلم طلب
اللحد الى المهد من العلم اطلبوا
بالصين العلم اطلبوا
Мөхтәрәм җәмәгать! Аңларга тиешле булган, игътибар итәргә тиешле урын – Ислам дине каршында һәртөрле гыйлем кирәк, дин гыйлеме кирәк. Дөнья гыйлеме, һәртөрле фән гыйлемләре һәм фәннең белгечләре, галимләре – һәркайсы мөкаддәс санала, һәркайсы мөхтәрәм вә ихтирам ителергә тиешле. Бу сүземә куәт, дәлил – хәзрәт рәсүлнең:
خرجت وعاء أي من يضرك ولا الحكمة خذ
Сәламәтлеккә вә дөнья тормышында файда бирерлек нинди генә хикмәтле, файдалы сүз барсын, аны алырга тырыш, ул сиңа һичвакытда зарар бирмәс, кирәк кедмән генә ишетдергән дин вә милләт вә аермасына карамасдан, һәркемдән гыйлемне өйрәнергә куша. Икенче бер хәдисендә: “Гыйлемне өйрәнү, гыйльме хикмәт мөэминнең югалткан нәрсәсе кебек”, ди. Ягьни бөтен кешегә караганда аны алырга хаклырак диб, без, мөселманларны гыйлем алырга, өнди.
Дин галимләребез безне дөнья Ахирәт бәхетле булуыбызгы сәбәб булган, яхшы булырга өндәб дөнья Ахирәт үкенчек калдырудай, начар гадәтләрдән тыеб, Ахирәтдә әҗер вә сәвабларга ирештерә торган дин гыйлемнәрен рухани табиблар, фән галимләре өйрәтсәләр, саулыгыбызны саклау юлларын күрсәтеб, һәртөрле авырулардан дәвалаб, инңенерлар, агрономлар, биологлар, педагоглар, астрономнар – һәркайсы халык бәхете өчен, адәм баласының дөньяда рәхәт яшәве өчен тырышучы галимләр булыб:
للناس انفعهم الناس خير
бөтен кешелек дөньясына җиңеллек китерергә тырышучы, һәркем тарафындан ихтирам кылынырга тиешле мөхтәрәм затлар. Менә безнең динебез шулй куша.
Үзебезне бик артык суфига санаб халык файдасы өчен тырышыб хезмәт итүче фән галимләрен тышкы кыяфәтләре белән хөкем итеб, шуларны мәкруһ күрсәк, алар хакында һәртөрле сүэ зөнндә (сүэ зөнндә – начар караштa А.Х.) булсак, бу безнең гыйлемгә дошман булуыбызның галәмәте. Шушындый рәвешдә йөргән адәмләр арасында Алланы чын тану белән таныб, хакыйкый иман әһелләре булырга бик мөмкин, чөнки к\укыган адәмләрнең гакыллары, зиһенләре куәтле була. Алар һәрнәрсәне яхшы аңлыйлар. Чын галим кеше вакытның кадерен яхшы аңлый, сәламәтлеген сакларга тырыша, һәрвакыт уку, язу белән шөгыльләнә. Инде кирәк дин галимләрен, кирәк фән галимләрен яратмаска, мәкруһ күрсәк, аларга күңелләребездә дошманлык сакласак, хәзрәт рәсүлнең :
فَتَهْلِكَ الْخَامِسَةَ تَكُنِ وَلا ، مُحِبًّا أَوْ مُسْتَمِعًا أَوْ مُتَعَلِّمًا أَوْ عَالِمًا اغْدُ
Хәдисенә бинаэ дөнья Ахирәт үкенәчәк калырбыз. Хәзрәт рәсүлнең икенче бер хәдис:
وأحبهم عرفهم لمن طوبى والآخرة الدنيا في أمتك سراج هو فقال العلم صاحب عن جبريل وسلم عليه الله صلى النبي سأل
وأبغضهم معرفتهم أنكر لمن والويل
Җәбраиль (гс) әйтде: алар галимләр, синең өммәтенең якты утлары, якты йолдызлары, дөнья һәм Ахирәтдә (طوبى) ны сөенеч, шул адәмләргә галимләрне таныдылар, белделәр, аларны хөрмәт итделәр, алар күрсәткән якты, дөрест юл белән бардылар.
ابعضهم و انكرهم ويل و
Ни үкенеч, шул адәмләргә, алар галимләрне мәкруһ күрделәр, аларны дошман күрделәр, ди. Галимләрне дуст күрү, аларның гыйлемендән файдалану, кирәк нинди генә милләтдән,

кирәк нинди генә диндән булуына карамастан, алардан гыйлем алу хакында тарих сәхифәләре шаһид: дин беренче көнләрендә, беренче гасырында рәсүл Алла (сгс) мөшрекләр белән булган беренче сугышда әсир алынган (пленный) әсирләрдән, уку-язу белгәнләрендән, һәркайсына ун баләгә уку-язу өйрәтмәс илләрдән башка диндәге галимләрдән шул заманындагы фәннәрдән, телләрдән сабак алулары, укулары, һәркайсы тарих белән сабит.
Гасыр сәгадәтдә, андан соңгы гасырларда яшәгән мөселманлар (Коръәнне) яхшы аңлаганлар:
الدنيا من نصيبك تنس لا و
Аять буенча һәм хәзрәт :
وَ هَذِهِ هَذِهِ مِنْ أَخَذَ مَنْ وَلَكِنْ ، لِلدُّنْيَا الاَخِرَةَ تَرَكَ مَنْ وَلا ، لِلاَخِرَةِ الدُّنْيَا تَرَكَ مَنْ خَيْرُكُمْ لَيْسَ
ягъни сезнең Ахирәте өчен дөньясын, дөньясы өчен Ахирәтен куйганы түгел, бәлки һәр ике дөньядан цлеш алган, ди. Ягъни вакытына урынына, заманына гыйлем һөнәре өйрәнү һәм халәлдән кәсеб итү кеше көчендән файдаланмый, үз кул көче белән көн күрү мөселман булган кешенең беренче бурычы.
Менә мондан мең ел элек яшәгән мөселманлар шушы мөбәрәк сүзләр белән гамәл итеб, бөтен дөньяга остаз булырлык әдәби, мәдәни тормышка ирешкәннәрдер. Мөтәрәккый милләт булыб яшәгәнләр. Чын галим кирәк дин гәләми, кирәк фән бервакытда да файдасыз, кирәкмәгән сүз сөйләмәс. Хәзрәт рәсүлнең:
فسكت فالا الحكمة و الخير قل
Хикмәтле, файдалы сүз булса, сөйләб булмаса, тик торганда сүзе белән гамәл итәрләр. Хәзрәт рәсүлнең тагын да бер мөбарәк сүзе:
مثل جنة كل جنتين تعالى الله أعطاه خطوتين معه مشى أو كلمتين منه سمع أو لقمتين معه أكل أو ساعتين العالم عند جلس من مرتين الدنيا
Чын галим гыйлемнең нәрсә икәнен аңлаган кеше, һичбер вакыт үзен галим диб әйтмәс. Гыйлем – чиксез диңгез ул (عميق بحر), төбсез диңгез. Шуның өчен зур галимләр һәрвакыт гомер буена гыйлем арттыру юлында гомер үткәрәләр.
Исламның зур хаким, философлары һәм хәзерге зур адәмләр, академик, профессорлар үзләренең белгәннәрен башкаларга өйрәтәләр, үзләре һаман үлгәнче белемләрен арттыралар.
Мөхтәрәм җәмәгать! Без хәзер бик бәхетле. Гыйлем, мәгърифәт, мәдәният дәверендә яшимез. Безнең балаларыбызга һәртөрле урта белем, югары белем бирә торган мәктәбләрнең ишекләре барыбызга ачык. Менә шушы зур бәхетнең кадерен белеб, балаларыбызның мәктәбләрдә укуларына шадланыб, кулыбыздан килгән кадәр укытучыларга ярдәм итәргә кирәк. Аларга ничек ярдәм итәргә? Күбрәк балалар хәзерге вакытда дәү әтиләр, дәү әниләр, әбиләр, бабалар кулында була. Сабый балаларыбызны мәктәбкә вакытында барамы? Вакытында кайтамы? Начарлыкларга, начар гадәтләргә өйрәнмиме? Өйгә кайткач дәресен хәзеллиме? Үзендән зурларга һәрвакыт ихтирамлы булырга, һәрвакыт пакьлеккә, чисталыкка өйрәтү, аш алдындан кул юарга, аш артынна кул юарга, барындан бигрәк ана телен оныттырмаска һәм башка яхшылык гадәтләргә өйрәтү, шушы эшләрне өйрәтергә тырышсак, бездән укытучыларга ярдәм итү, икенчедән, әдәбкә, әхлякка өйрәтү булыб, хәзрәт рәсүлнең:
حسن ادب من افضل لولده والد نحل ما
сүзе буенча гамәл иткән булыб, өстебездән беркадәр бурычны төшергән булырбыз.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга галәмгә мәхәббәт итеб, галимләргә

хөрмәт-ихтирам итеб Ахирәтдә пәйгамбәрләр һәм аларның варислары аталган галимләр белән бергә булырга насыйб булсын. Амин. Йә Мөҗиб.

Җомга көн, 22нче сентябрь 1967нче ел.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ихлас күңеләребез белән Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб (истәб – теләп А.Х.), җомга намазына килгән мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Тәбарәкә хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын. Амин. السأیلین مجیب یا
Күбләребез күңелдән белә торган “Кәлам шәригъ”да мөбарәк сүрә бар:
بِالصَّبْرِ وَتَوَاصَوْا بِالْحَقِّ وَتَوَاصَوْا*الصَّالِحَاتِ وَعَمِلُوا آمَنُوا الَّذِينَ إِلَّا خُسْرٍ لَفِي الْإِنسَانَ إِنَّ وَالْعَصْرِ.
Ягъни адәмләрнең хәрәкәтләре вә һәр эшләре вакыйг була торган:
وقت زمان عصر مطلق
Белән Икенде намазы важиб булган, Икенде намазы вакыты белән جاهلیت (Җаһилия) заманында Икенде вакытын мәкруһ күргәнләр, чөнки ул вакытда мөшрикләр үзара җыелышыб кемне гайбәт кылыб, кемне хурлаб утыра торган начар гадәтләре булган. Моның өчен Икенде вакытын яхшырак, күңелле адәмләр бу вакытны яратмаган. Шуның җенабее сезнең начар гадәтләрегездә вакыт заман гаебле түгел, бәлки сез үзегез, ант итеб әйтәмен, ди.
خسر لفی الانسان ان
- ягъни дөрестлекдә һәрбер гакыл балигъ булган кеше, һәркайсы үзенә зарар итүче һәм зарар итеб үкенчек калучы (آمنوا الذین الا) мәгәр шундый кешеләр генә үзләренә зарар итүче түгел. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенә чын күңелләре белән иман китерделәр, изгелек белән явызлык, күркәм сыйфат белән начар сыйфатны, ягъни шушыларны дөрест аера белеб, дөрест игътикад кылдылар, һәр эшләрендә әхкамел хакимин булган Алла хозурына барыб, хисаб бирүне, җаваб бирүне истә тотдылар: الصالحات عملوا و
Болар телләре белән әйтеб кенә калмадылар, бәлки шушы иманларына, игътикадларына мөафикъ рәвешдә бөтен адәм балалары һәм дин Ислам өчен файдалы булган изге гамәлләр кылдылар: بالحق تواصوا و
- һәрвакытда да берсенә хаклык, дөреслек, тугърылыкда булырга, бер-берсен диләштеләр, васыять итешделәр: بالصبر تواصوا و
- Һәр эшләрендә һәрвакытда бер-берсенә сабырлы булырга, сабырсыз булмаска димләшделәр һәм васыять әйтешделәр.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бу сүрәне укудан морад (максат- А.Х.): Ислам динендә иң гали, күркәм сыйфатның, алардан шушы әхляк хәмидәнең берсе булган – сабырлы булуны гадәт итсәк (صالحین سلف) узгандагы изге адәмләребезнең юлы белән барган - булыб дөнья Ахирәт үкенчек калудан котылыб, дөньяда ук бер-беребез белән тау, тыныч яшәб, Ахирәтдә бәхетле булыр идек. Сәлфе салихин сәхабәләр бер-берсе белән очрашканда “Гасыр” сүрәсен укудан морад (һәрвакыт берсен-берсе сабырлык белән хаклыкка өндәү булган)да Кәлам шәригъдә “Бәкарә” сүрәсендә:
الصابرین مع الله ان الصلوة بالصبرو استعیذوا آمنوا الذین ایها یا
диб, Аллага иман китергән бәндәләр, ягъни күркәм кешеләргә, изге гамәлләргә ирешү өчен сабырлык белән, намаз уку белән ярдәм өстәгез, ди. Авырлыкларга сабыр итеб, тәхәммел булыб, күркәм эшләрне хасыйль итәргә булдырырга тырышса, әлбәттә ул сабыр

һәм күркәм тәдбирләре аркасында үзенең теләгән максатына ирешми калмас. Һәм ихлас белән укылган намаз бөтен начар сыйфатлардан ерак калачак диб, намазны зикер кыла: ان الله مع الصابرين – Аллаһы Тәгалә сабыр кылучылар белән бергә.
Сабыр турында һәртөрле авырлыкларга, кайгв-хәсрәтләргә сабыр иткәнләр хакында: و بشر الصابرين – аларга син сөенеч шадландыр.
الذين اذا اصابتهم مصيبة قالوا انا لله و انا اليه راجعون
Ягъни шундый адәмләргә сөенеч бир. Алар, нинди генә борчу, кайгы-хәсрәт ирешсә дә, сабыр итеб: انا لله و انا اليه راجعون
Рәсүл Алланың бервакытда яна торган уты сүнгәч (шушы аятьне укыганда сәхабәләр: йә рәсүлулла, ут сүнү мусыйбәтеме (кайгысымы – А.Х.), Рәсүл Хода һәрбер мөэминне рәнҗетә торган нәрсә – мусыйбәт, димеш.
اولئك عليهم صلوات من ربهم
Менә ул адәмләргә хәбәр итүчеләргә Рабблары тарафында шәфкать булучыдыр. و اولئك هم المهتدون
Менә шушы рәвешле сабырлы булган адәмләр хаклыкка, тугъры юлга күнелгән адәмләр, ди. Бу сыйфатларның киресенчә булу хаклыкдан читкә киткән адәмләр булыб, дөнья Ахирәт үкенчек калулары мөмкин. Бу хакда хәзрә рәсүлнең мөбарәк сүзләрен искә алыйк. Хәзрәт әйтә:
الانات من الله و العجلة من الشيطان
– ягъни һәр эштә тәдбирле, викарлы, сабырлы булу – Алладан, ашыгу – шайтандан.
الصبر عند الصدمة الاوللى
- сабыр – кайгының иң әүвәл килеб бөрелүендә, ягъни кайгы килеб тә сабыр итү – чын сабыр.
Иң беренче кайгы-хәсрәт килгәндә, якаларын ертыб, сакалларын, чәчләрен нух кылыб, тавышланыб елаулардан саклану – менә шушы чын сабыр булыб, Алланың вәгъдә кылган әҗер вә сәваблары шушы адәмләргә булачак. Әмма тавышсыз елау, күзнең яшьләнүе, күңелнең сызлануы бу сабырга хиляф түгел. Хәзрәт рәсүл угълы Ибраһим ...
Инде җәмәгать! Күркәм сыйфат, күркәм гадәт билә казаларга гына сабыр итү түгел, әҗер килгән вакытда үз-үзенә хуҗа булу, үзебезне кулга алу, ачу йоту, тау йоту дигәндер. Хәзрәт рәсүлнең мөбарәк сүзе:
ألا أدلكم على أشدكم؟ أملككم لنفسه عند الغضب
сүзнең иң көчлегез кем икәнен хәбәр бирмиме? – Ачу вакытында үзен тота белер һәм сәлфе салихиндән булган табигатендән мәшһүр фикһадан Гурвәт б. әз-Зәбир хәзрәтләренең бер вакыйгасын әйтеб үтә...
Сабыр – иң гали сыйфатлардан булса да, ничә урында ашыгуны мәмдух санаганлар: беренче хаталык белән генә барадыр булса, тизрәк тәүбә кылу, берәүне рәнҗеткән булсак, тизрәк гафу үтенү, бәхилләшү. Җиткән кызың, яки угълың булса, начар юлларга китү куркынычы булса, тизрәк өйләндерү (никяхландыру) .
Мөхтәрәм җәмәгать! Рәсүлнең:
زِنُوا أَنْفُسَكُمْ قَبْلَ أَنْ تُوزَنُوا
- үзебезне үлчәб карыйк, тикшереб, кайсы шушы мактаулы сыйфатар бездә бармы? Сабыр итү, ачуга хуҗа булу... Бөтен кешеләрне бер үлчәү белән үлчәб булмый. Арабызда шул кадәр күркәм, сабырлы, ни кадәр авыр борчуларны, зур кайгы-хәсрәтләрне Ватан сугышында бер генә түгел, икешәр, өчәр матур, батыр җегетләре, кайтмаган кешеләр булды. Аллаһы Тәбарәкә әҗерен насыйб итсен.
(0620) Гурвәт б. Әз-зәбир б. Әл-Гәввам хәзрәтләре:

Гурвәт б. Әз-зәбир б. Әл-Гәввам хәзрәтләре Мәдинә мөнәввәрәдә җитешкән фукаһәэ сабгәдән бере булыб, мөҗтәһид мотлак иде. Атасы Гашәрә мөбәшәрәдән булыб, анасы хәзрәт Абу Бәкернең кызы Әсма (рг) һәм ата тарафындан әбисе – рәсүлулланың атасы белән бертуган хәзрәт Сафия иде. Ибн әз-Зәбир хәзрәте гаять зәки зирәк, тәкъва, салих, галим адәм булыб, һәм ифрат дәрәҗәдә сабырлы булыб, башына килгән зур кайгы вә борчуларында җиңел генә уздырыб җибәрә булган, бер вакыт, шамидә вакыт аягына бертөрле авыру ирешеб, табиблар һәркайсы кисәргә киңәш биреб, ахырда разый булыб кисдермәк булгач кисү алымыны ачы хисен белдермәс өчен исерткеч эчәргә тәкъдим итсәләр дә: сәламәтлек өмед иткән нәрсәдә Аллаһы харәм иткән нәрсә белән ярдәм истәмәм (теләмәм) һәм һәш җибәрә. Йоклата торган, хисне югалта торган дәва бирик, дигәнләренә каршы: әгъзаларымнан бер әгъзамнең мин сизмәстән югалуыны, юк булуыны сөймим, чөнки мин аның ачысы, сызлавы берә-беренә Аллаһыдан сәваб өмед итәмен, дигән. Тубкына кадәр пычак белән, сөяге пычкы белән кисеб, үзе һаман тәкбир вә тәһлил әйтүендә дәвам иткән. Сөякне кисеб, кайнаб торган зәйтүн маена тыккан шактый вакыт. Һушсыз булыб киселгән аякны кулына алыб, мине аяк үзрендә йөрткән Аллаһы хәзрәте беләдер, мин һичвакыт бу аяк белән генә юлында юлмадым (йөрмәдем – А.Х.), димеш. Һаман шул хәлендә Коръән укыб, (0621) гамәл гыйбадәтенә һич кимчелек китермәгән. Шул ук сәфәрендә тәмам кәмаләткә ирешкән. Мөхәммәд исемле бер угълын ат тибеб үтергән. Шушы кадәр зур хәсрәт-кайгылар күрсә дә, “уф” диеб тә әйтми, һич кемгә шикаять кылмаган. Менә сабырның әгълә дәрәҗәсе.

Аста тагын бер язма (карандаш белән язылган):
Хәдис шәриф:
ذَا آخَى الرَّجُلُ الرَّجُلَ فَلْيَسْأَلْهُ عَنِ اسْمِهِ وَاسْمِ أَبِيهِ وَمِمَّنْ هُوَ ؟ فَإِنَّهُ أَوْصَلُ لِلْمَوَدَّة
اذا آضيت رجلا فسأله عن اسمه و اسم ابيه فان كان عائبا حفظته و ان كان مريضا عدته و ان مات شهدته.
Каба мәсҗеде.

Инде бәгъзе кешеләребез бар, хәтта сафларыбызны тигезлик, яки мәсҗеддән чыкканда кимләребезне алганда, инде башка җирне әйтмим, мәсҗед эчендә дә зәзер кайтып китәргә торган кешеләр бар. Менә бу эшләр һәркайсы, җәмәгать, күңелсез хәлләр, динебез һәм пәйгамбәр тарафындан мәкруһ булган начар гадәтләр. Сабырсызлык хакында адәм баласының башына әллә нинди күңелсез хәлләр була, гаилә белән бозыла, хәтта үзенең тормышын юкка чыгара , үзен-үзе хәраб итә.
Борынгылар әйткәнләр: бер авыр сүзне күтәрмәсәк, күб авыр сүзләр ишетерсең, дигәнләр. Ягъни берәүдән күңелгә авыр бер сүз ишетәсең икән, шул вакыт дәшми калсаң, шуның белән тукталыб бетәргә мөмкин. Каршы әйтсәң, береңдән-берең катырак әйтеб, тәмам йөрәккә кадала торган авыр сүзләрне әйтеб, якын дустларың, балаң, туганнарың белән күңелсез булыб дөньяда ук зур үкенчек калырга мөмкин. Кылыч җәрәхәте төзәлә, тел җәрәхәте төзәлми, дигәнләр.
Мөхтәрәм җәмәгать! Безнең күбебез гомеребезнең ахырына җиткәнебез, бүген бар, иртәгә юк. Калган гомеребез һәрвакыт, һәр урында сабырлы һәм күркәм холыклар белән холыкланыб, үбкәләшкән хәтерен калдырган кешеләребез бәхилләшеб, өлфәт, мәхәббәт, дустлык, татулык гомер итеб, Әхкамель хакимин булган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хозурына ак йөз, камил иман белән барырга насыйб булсын. Амин, йә Мөҗибес саэилин би хөрмәти сәййидель мөрсәлин.

4нче рәкымле дәфтәр.
1967 Милядия
1967 нче ел, 13нче октябрь, җомга көн.
Була алмадым. (Ангина белән авырыб, температурам югары булды).
Шул сәбәб белән 13нче октябрьдә сөйләнәчәк нәрсәләрем 20 нче октябрьдә җомга көн сөйләнде.

1967 нче ел, 27нче сентябрь, көн
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Үзебезнең бәндәчелек бурычымызны үтәр өчен Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенә итәгать кылыб, җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Дөнья Ахирәт сәламәтлек Аллаһының бәрәкате вә рәхмәте барчаларыбызга насыйб булсын. Амин.
Ай башы хакында (Рәҗәб ае) аңлатыб үтәргә.
Мөхтәрәм җәмәгать! Рәсүл (сгс) әйтә:
قل الحق و ان كان مرا لا تخف لو مات لائم
- хак сүзне, ачы булса да, әйт. Төсләтә кылучы ачуланучылар булса да, аларның ачуларындан, шелтә кылуларыннан курыкма, ди. Түбәндә сөйләнәчәк сүзләрем бәлки бәгъзе бер кешеләргә авыр тоелыр, шулай булса да: пәйгамбәребез тыйган, динебез мәзмүм бөтен гакыл ияләре тарафыннан мәнфур булган, нәфрәтләнеб каралтырга, начар гадәтләрне аңлатмасак, әйтмәсәк, Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтләре хозурында мәсъулияткә, җавабка калачакмыз.
Пәйгамбәр Хода өмәтләре өчен шул дәрәҗәдә тырышкан, аларны дөньяда бөтен бәни бәшәр, гакыл ияләре тарафыннан кабул итәрлек гали халыклар күркәм, матур гадәтләргә өндәб, гакыл ияләре тарафыннан мәнфур дөнья бәхетсезлеккә сәбәб була торган адәм баласының дәрәҗәсен, игътибарын югалтырга сәбәб булырдай бөтен начар гадәтләрдән тыйган: менә шушы динебез тыйган, пәйгамбәребез тарафыннан тыелган, арабызда булган начар гадәтләрне сөйләми чара юк.
Калә рәсүлулла (сгс):
عليك بالاياس بِالْيَأْسِ عَمَّا فِي أَيْدِي النَّاسِ فَإِنَّهُ الْغِنَى، وَإِيَّاكَ وَالطَّمَعَ فَإِنَّهُ الْفَقْرُ الْحَاضِرُ، وَصَلِّ صَلَاةَ مُوَدِّعٍ، وَإِيَّاكَ وَمَا تَعْتَذِرُ
مِنْهُ، وَأَحِبَّ لِأَخِيكَ مَا تُحِبُّ لِنَفْسِكَ
Ягъни кешеләр кулында булган нәрсәдән өметсез бул. Башкалардан бернәрсә дә өмет итмә, тамегъ (طمع) кылма, тамегъдан саклан, чөнки тамегъ хәзир булган фәкыйрлекдер.
و صلى صلاتك و انت موضع
Һәр намаз укыганда ахыргы намазым уйлаб укы (күңелдән шушылай уйлау ихлас белән укуга сәбәб була).
وَإِيَّاكَ وَمَا تَعْتَذِرُ مِنْهُ
Соңыннан гафу үтенелрек эшне эшләүдән саклан. Пәйгамбәребезнең кешеләр кулында булган нәрсәне өмет итмә, вә тамегълы булмау башкалардан моңсыз булырга кушуы, дөнья тормышында һәрбер мөселманның һәр җәһәттән өстен булырга тырышырга тиеш икәнлеген белдерә. Хакыйкать хәлдә дөнья тормышында гайрәт итеб тырышу, башкалардан моңсыз булу, кешедән бернәрсә дә өмет итмәү – Исламның рухы, Исламның юлы булыб, сәләф вә сәхабәләр заманында кешеләрнең кул көчләренә күз текәб торучы

берәүнең манланыб тире агызыб яки кул көчене сарыф кылыб табкан икмәгенә яки тиенләрен кул сузучы адәм һич булмаган.
Әсхабе вә сәләф заманында каберлекләрдә, зияратларда сәдака вә нәзер корбан вә сәдака көтеб торучыларның, үзләре түгел, аларны шундый кешеләр булыр диб әйтсәләр, алар һич ышанмаслар иде. Ул вакытдагы мөселманларның һәрбере берәр төрле кәсеб вә һөнәр белән шөгыльләнеб, ризыкларыны үз кул көчләре белән табарлар иде. Балаларын, үзләренең гаиләләрен кеше кулындагы нәрсәне өмет итүдән, кешедән нәрсә булса да бернәрсәне бушка алудан бик нык тыя торган булганнар. Үзләре табкан малларын, эш эшләрлек сәламәтлеге вә бик артык карт булмаган, ялкаулыгы сәбәбле кеше кулына караб, кешедән тартыб алырга торучы кавемсез адәмләргә сәдака биреб, шушы сәдакалары бер-беренә сәваб өмед итү гадәте юк иде. Гасре сәгадәтдән ераклашкан саен, Ислам дине гасре сәгадәтдәге сафлыгындын чыгыб, һәртөрле хөрәфәтләр шаиг була башлаб, зиярәт тирәсендә сәдака җыеб һәм өйдән өйгә Коръән укыб, үзләрен ялкаулыкка салыб йөрүче кешеләр. Болар һәркайсы башкаларга ялкаулыкны үрнәк итеб, динебезне ямьсез итеб күрсәтүче, Аллаһы сөймәгән, пәйгамбәр тыйган начар гадәт белән гадәтләнгән кешеләр. Дөньяда булган бөтен бозыклыкларның вә һәртөрле авыруларнаң сәбәбе (ялкаулык) икәне әхляк галимләре, тыйбб галимләре тарафындан расланган, икрар ителгән. Шула й булгач, кәсеб итәрлек сәламәтлеге, яшьлеге булган сәдакачыларга: сздака бирү – ул изгелек түгел, бәлки: эш яратмаган ялкауларга ярдәм булыб Алла каршында җавабка калу куркынычы бар.
Мөхтәрәм җәмәгать! Сез минем сүземне ялгыш аңлаб, муллага сәдака бирүдән дә тыя диб уйламагыз! Сәдака бирү бик тиешле, бик сәваблы эш, ләкин кемләргә бирергә кирәк? Аз гына пенсия алыб, тормыш авырлыгы белән алыб баручы, яхшы күңелле картлар, картчыклар, яки кәсеб итәргә көче җитмәгән, аяксыз, кулсыз, күзсез гарибләр. Шуны да искә алырга кирәк: җыйган сәдакаларны исерткеч вә башка бозык урынларга иткәнлекләре беленсә, моннан тагын сакланырга кирәк:
العدوان و الاثم على تعونوا لا و التقوى و البر على تعونو
Аять шәрифкә бинаэ, бозык урынларга ярдәм иткән булыб үкенчек калу ихтималыбыз бар. Тагын да рәсүл (гс)нең бер мөбәрәк сүзен сөйләб үтик:
كثرة بها الله زاده الا صلة بها يريد عطية باب رجل فتح ما السلام عليه قال
Ягъни бер адәм сәдака вәсыйле берлә-бер ишегене ачды исә, Аллаһы Тәгалә аның малының бәрәкатене арттырыр.
قلة بها الله زاده الا كثرة بها يريد مسألة باب رجل فتح ما
Ягъни бер кеше баю юлы теләге белән сорау юлына китсә, Аллаһы аның мохтаҗлыгыны, фәкыйрьлегене арттырыр, ди, малның бәрәкатен хәйран бетерер, ди. Берәүнең малы күб булыр да, хәерсез булыр, бәрәкате булмас. Аз малың, күб бәрәкате булсын. Үзеңә җитәрлек тормышыңны алыб барырлык малың булыб, сәламәтләгең, тынычлык булса, менә бәрәкатле, хәерле мал шушы була.
السفلى يد من خير العليا اليد
- бирүче кул алучы кулдан хәерлерәк, ди. Иң беренче Аллаһының дустлары, пәйгамбәрләр, һичбер вакыт сәдака алмаганлар, үз кул көчләре белән табкан малдан гаиләләрен, үзләрен тәрбия кылганлар. Әсхабе әкрам, сәләф салихин, һәркайсы, халәлдән кәсеб иткәнләр. Соңгы заманыбызда да бәгъзе бер галимләребез нинди дә булса бер кәсебкә шәрик булыб, сәдака алмаган кешеләребез булган.
Хасыйлель кәлам, җәмәгать! Сүземнем ахыры итеб, авыр булса да, шуны әйтергә кирәк. Мәет озатучы яшьләребез тарафындан еш кына ишетелә: машина утырыб барырга да урын

калмады, бу бабайлар бары сәдака җыярга гына киләләр икән, дигән сүзләр бик күб ишетелеб тора. Ул да, ничек булгандыр соңгы көннәрдә, җәмәгать. Шушындый күңелсез гадәтләр көннән-көн көчәеб бара. Сүз юк, зур яшькә җиткән, аз гына пенсия алган кешеләребез бар, яки бездә пенсия алмаган кешеләр булырга мөмкин. Арада яхшы гына киемле, яхшы гына тормышда яшәүче адәмләр дә көннән-көн күбәя бара. Бу адәмләргә, җәмәгать, бу эш зур күңелсезлек, динебез тарафындан мәкруһ күрелгән, начар гадәт (әхляк зәмим). Без, мөселман булган адәмләр, киләчәк буынга, яшьләргә һәр җәһәтдән үзенең булырга тырышырга кирәк. Ничә гасырлардан бирле шушындый начар гадәтләр безнең хәзерге вакытда да бөтен картларыбызны балаларга ямьсез итеб күрсәтергә сәбәб булган аналар кечкенә балаларын: “Әнә, бабай килә. Аның капчыгы зур”, ягъни ул нәфесле бабай, бирсәң дә, бирмәсәң дә, тартыб алырга тора, дигән мәгънәне алдатыб, хәзер капчыгына салыб китәр, диелә. Безнең нурлы йөзле, нурани картларыбызны яшьләрнең күңелләренә кечкенәдән аларга начар күз белән карарга, аларга мәхәббәтсез, начар кеше диб карарга гадәтләндерәләр. Вә халән ки, безнең картларыбыз, картчыкларыбыз һәркем тарафыннан ихтирам ителергә тиешле мөхтәрәм затлар булырга тиеш иде.
Хәзрәт рәсүлнең бер мөбарәк искә алыйк: сезнең берәвегезнең урманга барыб, утын җыеб, аркасына күтәреб китереб, сатыб, шуның акчасы белән ризыклануыгыз кешедән сәдака сорауга караганда сезнең өчен хәерлерәк. Хәзрәт рәсүлнең бу хакта әйткән сүзләре бик күб. Гыйбарәләрен укысак, вакытны күб алганлыкдан, хасыйль мәгънәләрен генә әйтергә тугъры килә. Ат өстендә чавыб (чабып – А.Х.) барган вакытда камчың төшә, янында җәяү адәм була, камчың күтәруне андан сорама, үзең төшеб ал, ди.
Ислам дине буенча балалар тәрбиясе хакында да, балаларыбызны кече яшьдән кешедән файдаланмаска өйрәтү: үз киемләрен үзе салыб торыб куйсын, урынларын үзе җыйсын, үзе җәйсен, кече яшьдән кешедән бер нәрсә дә өмед итмәскә, сорамаска, һәрвакытда, һәр урында үз тырышлыгы, үзенә генә ышаныб эш итәргә гадәтләндерергә кирәк. Кечкенәдән өйрәнгән гадәт зурайгач да һәрвакыт күңелдә нык саклана. Кешедән бер нәрсә өмед итеб, беркадәр тормышы әвешкән кешегә кул сузыб сәдака алу, кешенең кадерен югалта, абруен бетерә, башкалар аңарга саилче (сораучы – А.Х.) рәвешендә генә карарга сәбәб булганлыкдан, чын мөселман булган пәйгамбәрнең һәр сүзен дөрест диб, аның сүзен тотыб, аның гадәтләренә, сөннәтләренә иярергә тырышкан кешегә мондый күңелсез гадәтләрдән саклану тиеш. Гыйбрәтләнү өчен зияратка бару, мәетләргә Коръән уку бик тиешле, күркәм, сәваблы эшләр. Мәеткә ияреб, кабер тирәсендә сәдака алулар – күңелсез.

1392 нче Һижри, 24 нче Җәмадиль ахир.
1972 нче Миляди, 4 нче август, җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ихлас күңел белән ерак вә якын җирләрдән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселманлар! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Хөрмәтле җәмәгать! Җәмадиль ахир аеның ахыргы, соңгы җомгасы. Барчаларыбызга мөбарәк, күб елларга кадер, сәййидель әййам булган мөбарәк көнләрне (җомга көнләрен) шадлык белән күрергә насыйб булсын. Киләсе атна кич (пәнҗешәмбе көн) Рәҗәб аеның башы булыб, шул ук көн – җомга кичәсе пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгс)ның дөньяга килүенә сәбәб булган мөбарәк киче Рогаиб (رغائب) бәйрәме булачак көне – җомга

көн (10 август).
Шушы мөбарәк кичәне шадлык белән каршылаб, сәгадәт дарәйнгә сәбәб булган мөбарәк пәйгамбәргә өммәт булганыбыз өчен зур шөкранә кылыб, дин Исламга чын мәхәббәт белән пәйгамбәребезнең күрсәткән юлы белән гамәл итү насыйб булсын.
وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنْبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَنْ كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا
(النساء سورة، 36)
(0633) Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте безгә бу аенда күб хакларны ачык итеб сөйләде.
1) Бәндәчелек робубият;
2) ата-ана хакларын, исән булсалар, - тәрбия кылу, үлгән булсалар, - истигъфар белән дога кылу;
3) кардәшлек, туганлык хакында;
4) ятимләр, мескенләр хакын ригая кылу;
5) күршелек хакында. Күрше өч төрле: туган, диндәш, күрше. Өч хакы бар: күршелек канында, өченчесенең башка диндә булыб, күршелек хакы, дүртенче: яхшы, дөньяви терекләребездә иң якын - хатын хакы. Шәригатебез тарафыннан ирләрнең хатын өстендә хакы булган кебек, хатынларның даирәләр өстендә күб кенә хаклары бар. Күршелек аш урынларында күрше булу, юлда, сәфәрләрдә күрше булу, мәсҗеддә утырган вакытларда күрше булу кебек һәр урында күршеләр булыб, шуларның хакын ригая кылу хакында;
6) мөсафиргә һәм кунакка изгелек кылу, хөрмәт хакында;
7) кул ашындагы хезмәтчеләр куллар белән тиешенчә мөгамәлә хакында күбтөрле хакларны бәян, шушы хакларда ригаяле булыб, шушы гали булган күркәм сыйфатларны үтәү – һәр мөселманның изге бурычы булыб, шәригать хөкемләрен, Коръән сүзләре белән гамәл итү иманымызның – мөселманлыгымызның камил бөтен булуына сәбәб булачак. Начар гадәтләрдән булыб барча мөэмин мөселманларга бу күңелсез гадәтләрдән сакланыб, һәр җәһәтдән яшьләребезгә матур, күркәм, гали халыклар белән үрнәк булырга Аллаһы насыйб итсен. Амин.

1967 нче ел, 6 нчы октябрь, җомга көн, 2 нче Рәҗәб:
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ихлас күңелләребез белән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Рәҗәб ае җомгабыз өчен мөбарәк булыб, динебез боерганча, пәйгамбәребез кушканча изге гамәлләр кылыб, әҗер вә сәвабларга ирешергә Аллаһы насыйб итсен. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре сүрәэи “Ниса”дә шушы мөбарәк аятьне иңдерә:
استعيذ بالله وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنْبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَنْ كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا
Ягъни (وَاعْبُدُوا اللَّهَ) Аллага гына гыйбадәт. (وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا) – Дәхи Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәтдә һич нәрсәне шәрик кылмагыз, (اياك نعبد و اياك نستعين) диб, (وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا) – ата-анага изгелек кылыңыз, (وَبِذِي الْقُرْبَىٰ) - якынлык иясе булган кардәшләрегезгә, нәсел

җәһәтендән, яки дустлык җәһәтендән булсын, – һәркайсына яхшылык, изгелек кылыгыз, ди. (وَالْمَسَاكِينِ وَالْيَتَامَىٰ) - ятимләргә, мескенләргә, ягъни бик мохтаҗ кешеләргә изгелек кылыгыз. (0635) (الْقُرْبَىٰ ذِي وَالْجَارِ) – Дәхи йорт якын булган кешегә яки кардәш булган күршегә изгелек кылыгыз, ди, (الْجُنُبِ وَالْجَارِ) – дәхи кардәшлеге булмаган, фәкать күршелек хакы булган күршегә изгелек кылыгыз, (بِالْجَنْبِ وَالصَّاحِبِ) – дәхи яхшы, күркәм эшләрдә юлдаш, иптәш булган кешеләргә изгелек кылыгыз. Гыйлем өстәүдә иптәш күрше булган кеше эш урыннарында күрше булган кеше яки зәуҗиятдә (ирлек-хатынлык) җәһәтендән күрше булган кешегә һәм сәфәрдә юлдаш күрше булырга тугъры килгән кешеләр һәркайсы күрше булыб, шуларга изгелек кылыгыз, ди. (السَّبِيلِ وَابْنِ) – дәхи юл угълына, мөсафиргә яки кунакка изгелек кылыгыз, ди. (أَيْمَانُكُمْ مَلَكَتْ وَمَا) – кул астыгызда эшләүче хезмәтләргә изгелек кылыгыз, яхшылык кылыгыз, ди. (يُحِبُّ لَا اللَّهَ إِنَّ فَخُورًا مُخْتَالًا كَانَ مَنْ) – менә шушы югарыда сөйләнгән кешеләргә яхшылык, изгелек кылмаган, бәлки киресенчә, ул кешеләр белән тәкәбберлек кылыб, алар белән начар мөгамәлә булган кешеләрне Аллаһы Тәгалә сөйми. Ягъни Аллаһы Тәгалә сөйгән эшләрне, гадәтләрне кылган булыб, Аллаһының ачуына юлыгырга мөмкин.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу югарыда укылган аятьдә Ислам дине тарафыннан кылынырга тиешле беренче төрле гали, күркәм сыйфатлар сөйләнсә дә, без бүген бер генә мәудугъны (теманы – А.Х.) искә алыб үтәбез. Ягъни күршеләр белән күркәм мөгамәләр кылу, пәйгамбәребез кушканча, алар белән күркәм сыйфатда, аларга яхшылык, изгелек кылу, алар белән тыныч, тату тору, Ислам динендә иң мактаулы булган күркәм холыкларның берсе булыб, алар белән пәйгамбәр кушканча, Аллаһы кушканча, татулык, дустлык, ярдәмләшеб, (0636) күршеләргә мөмкин кадәр яхшылык, изгелек итәргә тырышыб, алар белән матур итеб яшәсәк, җаныбызның тынычлыгына, тормышыбызның күңелле булуына сәбәб булыб, дөньяда ук бәхетле булыб, Ахирәтдә әҗер вә сәвабларга ирешергә насыйб булсын. Рәсүл (сгс) әйтә:

جاره الى فاليحسن الآخر اليوم و بالله يؤمن كان من

Ягъни бер кеше чын ихласдан Аллага вә Кыямәт көненең булачагына чын-чындан ышанса, күршесенә изгелек, яхшылык итсен, ди. Икенче бер хәдисендә:

بوائقة جاره يأمن لا الذى المؤمن ليس

Ягъни күршесе – ул кешенең шәррендән, явызлыгындан, усаллыгындан әмин булмаса, ул кеше камил мөэмин булмас, ди. Рәсүл (сгс) хәзрәтләре һәрвакыт күрше белән яхшы тору хакында бик әсәрле вәгазь, нәсыйхәтләр сөйли торган булган.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аятьдән аңлануына күрә, күршелек йортлар янәшә булу, фатирлар янәшә булган кешеләр генә булмыйча, сәфәрдә булган вакытда, параходларда, поездларда йөргән вакытда да күрше булган кешегә изгелек, яхшылык итәргә тиеш була. Шулай ук мәсҗедкә килгәч, урынларыбызга утырган вакытда күршелек хакын онытмаска кирәк. Намаз укыган вакытларда урын тарлык сәбәбле шәригатемез рөхсәт бирә торыб да, алдыбызда яки артыбызда утырган адәмләргә уңайсызлаб намазлыкка сәҗдә азабланулар, күршеләребезгә уңайсыз кылу булганлыкдан, менә бу эшләрдән сакланырга тиешле эшләр һәрвакыт рәсүл (сгс)нең:

لنفسه تحب ما لالناس احب

дигән сүзен (0637) һәрвакытда кагыйдә итеб, һәрвакыт, һәр урында җанымыздагы күршебезгә изгелек, яхшылык кылырга, күршеләребезне ничек кенә булса да рәнҗетүдән саклан – иманымызның камил булуына һәм дөнья тыныч, сәламәт яшәвебезгә сәбәб булган күркәм холыкларның берседер. Рәсүл (сгс) тагын бер хәдисендә:

الطريق قبل الرفيق الدار قبل الجار

начар күршедән саклану юлларында безгә аңлатыб куйган. Уйламаган рәвешдә начар күршеләргә очрыйбыз икән, начар күршеләребез безне хаксыздан нахакдан рәнҗетәләр икән, болар тарафындан күрелгән начар гадәтләргә сабыр итү, тәхәмелле булу. Үзенсез начарлык кылган – аңар гөнаһысы булыб, сабыр итсәк – әҗер вә сәвабы безгә булачак.
Хәзрәт рәсүлгә Йәмән патшасы тарафындан килгән илче хәзрәт рәсүлдән 5 төрле нәрсә хакында сораган: әгәр син хак пәйгамбәр булсаң, шушы сөәлләремә дөрест җаваб бирерсең, дигән. Беренче: иң батыр кем?; икенче: шундый ялган ки (ялган сүз), хак дин каршында андый ялганны сөйләү гөнаһ булмас, бәлки сәваб булыр. Ул нинди ялган?; өченче: шундый кеше намаз да укый, руза да тота, әмма үзе камил, чын мөселман түгел, ди; дүртенче: иң зур байлык – нинди байлык?; бишенче: дәва табылмый авыру нинди авыру?
Беренче сөәлгә: иң зур батыр – бик каты ачуы килгән вакытда үзен-үзе тыя алган кеше (ягъни ачуны хөлем белән каплаган кеше). Икенче: шундый ялган ике кеше арасын төзәткән кеше, яки ир белән хатынны килештерү өчен беркадәр ялган сөйләсәң дә дөрест икән. Әгәр шушы ялганлаб (0638) булса да, аларны килештерүең өчен сиңа сәваб булачак. Өченче: намаз укыса да, руза тотса да, күршесен рәнҗетсә, ул камил мөэмин түгел, ди. Дүртенче: зур байлык – кәнагать байлыгы. Әгәр адәм баласы комсыз булса, аңа бөтен дөнья байлыгы аз күренәчәк. Бишенче: авыру табылмаган дәва – каты саран (لئم) булу. Үзе дә файдаланмый, кешегә дә файда итми.
Рәсүлулла шушы рәвешле җаваб биргәннең соңында, бу илче гакыл иясе булса кирәк, тәмам кәнагать хасыйль итеб, хәзрәт рәсүлгә ихлас күңеле белән иман китереб мөселман булган.
Мөхтәрәм җәмәгать! Канун Илаһи булган Коръән аятьләребез, рәхмәт лил-галимин булган Аллаһы рәсүле без адәм балаларына дөньяда бер-беребез белән татулык-дустлык, бер-беребезгә рәхимле, шәфкатьле, ярдәмле булыб, яшәүнең юлларын бик ачык белдергәнләр. Шул җөмләдән күршеләребез белән тату-дуст тору, аларга һәрвакыт яхшылык итәргә – Ислам динендә иң гали сыйфатларның берсе булыб саналган. Һәр кайсыларыбыз бу эшләрне тормыш тәҗрибәләре белән күреб, татыб беләбез.
Күршеләр хакында хәзрәт рәсүл әйтә Җәбраиль:
مَا زَالَ جِبْرِيلُ يُوصِينِي بِالْجَارِ حَتَّى ظَنَنْتُ أَنَّهُ سَيُوَرِّثُهُ
Хәзрәт Җәбраиль күрше хакында шулкадәр васыять әйтде, хәтта тиздән күршегә күрше-күршенең малына варис булачагы хакында Аллаһы тарафындан әмер киләчәкдер диб уйладым, ди. Китаблар безнең Ислам диненең өйрәтүе буенча, күрше өч төрле: берәү – кардәш булган мөселман күрше; икенче – кардәш булмаган мөселман күрше; (0639) өченче берәве – мөселман булмаган күршеләр. Һәркайсының күршелек хаклары булыб, шушылар һәрвакыт яхшы тору, тыныч-тату яшәү, аларга ярдәм итү, йомышларын үтәргә тырышу – динебез тарафындан кушылган күркәм холыкларның берсе булыб, динебез, пәйгамбәремез кушкан шушы күркәм гадәтләрне үтәсәк, дөньяда да рәхәт, тыныч яшәб, Ахирәтдә дә зур әҗер вә сәвабларга ирешәчәкбез.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга чын мөселман булыб гомер итеб, ахыр сулуыбызда мөэмин булыб, дөньядан үтәргә насыйб булсын.
1967 нче ел, 13 нче октябрь, җомга көн (9нчы Рәҗәб).
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аллаһының ризалыгын истәб (теләп – А.Х.), ерак вә якын җирләрдән җомга намазына килгән мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Җенабе Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Бүгеннән соң да илләребез тыныч булыб,

барчаларыбызга саулык-сәламәтлек, тәуфыйк, һидаять биреб, күб елларга ихлас күңелләребез белән изге гамәлләр вә гыйбадәтләр кылырга Аллаһы насыйб итсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бәгъзе бер кешеләребез, хосусан яшьрәкләр арасында: “Без намаз укый белмибез, Коръән укый белмибез. Без һичбер изгелек, гыйбадәт кыла белмибез”, - диб, Ахирәт тереклегенә өметсез карауч ылар бар. Һәм шактый гына олы яшьтәге кешеләребез дә Аллаһы кашында зур әҗер вә сәвабларга ирештерә торган, ягъни Аллаһы ризалыгына, Алланың (0640) мөэмин колларына вәгъдә кылган әусаг (иң киң – А.Х.) нигъмәтләре, оҗмах сарайлары, бүләкләнү – намаз укыб, руза тоткан бәндәләргә генә булачак диб уйлаулар булырга мөмкин. Болай уйлау – хата. Дөнья тормышында һәр ике дөньяда адәм баласын бәхеткә ирешдерә торган, Аллаһының дустлары җөмләсенә ирештерә торган сөекле һәм фарыз гамәлләренең берсе: тырышыб нинди генә булса да үз кул көчең белән, көч, тир чыгарыб ризык истәү, тормышыңны алыб бару. Пәйгамбәребез (сгс) әйтә:
المحترف المؤمن العبد يحب تعالى الله ان
Ягъни: Аллаһы Тәгалә һөнәрле, мөэмин бәндәсен сөядер, ди. Һәм икенче бер хәдисендә:
الفارع الصحيح يبعض تعالى الله ان
Ягъни: Аллаһы Тәгалә сәламәтлеге кәсеб итәргә мөмкинлеге булыб да, эш эшләми, эш сөймәгән, ялкау кешеләргә Аллаһы Тәгалә ачуланадыр, ди. Димәк, мөмкин була торыб, ялкаулыгы сәбәбле хатыны җилкәсендән яки башкалар көчендән файдаланыб, эшләми йөргән кешеләр – болар җәмәгать төбендә, кешеләр боларның дошманы. Нитәк Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте бик күб Коръән аятьләре белән кәсебнең фаразлыгын безгә аңлата:
الله فضل من ابتغوا و الارض فى فانتشروا الصلوة قضيت فاذا .بالله استعيذ
Ягъни җомга намазын үтәгеннең соңында җир йөзенә таралыгыз, Аллаһы фазлындан киң ризык истәгез (теләгез), кәсеб итегез, ди.
الدنيا من نصيبك تنسى لا و
Ягъни дөньядан олешеңне онытма, тырышыб кәсеб ит, ди.
سعى ما الا للانسان ليس
Ягъни адәм баласына үзе тырышкан кадәр булыр диб, (0641) югарыда сөйләнгән һәм башка бик күб аять вә хәдисләр белән адәм балаларына үз көнен үзе күрү фарыз булыб, тырышыб кәсеб иткән кешеләр Аллаһының әмерен, кушуын үтәгән булыб, зур әҗерле вә сәваблы булыр. Һәм хәзрәт рәсүлнең:
الْبَدْرِ لَيْلَةَ كَالْقَمَرِ وَجْهُهُ تَعَالَى اللَّهَ لَقِيَ ، الْجَارِ عَلَى وَتَعَطُّفًا ، الْعِيَالِ عَلَى وَسَعْيًا ، الْمَسْأَلَةِ عَنِ اسْتِعْفَافًا حَلالا الدُّنْيَا طَلَبَ مَنْ
Ягъни: бер кешедән моңсыз булу, кешедән, сораудан саклану өчен халәлдән дөньяны истәсә (теләсә), нинди генә эшдә булса да, кәсеб итсә (الْعِيَال عَلَى وَسَعْيًا), тәрбиясе тиешле булган гаиләсен, балачагасын, ата-анасын туйдыру, тәрбияләү өчен (الْجَارِ عَلَى وَتَعَطُّفًا) якын туганларына, тирә күршеләренә ярдәм, шәфкать кылу теләге белән, нияте белән, (اللَّهَ لَقِيَ الْبَدْرِ لَيْلَةَ كَالْقَمَرِ وَجْهُهُ تَعَالَى) Кыямәт көнендә бу кеше айның 14 нче кичәсе кебек, нурлы йөзле булган хәлдә Аллага йолыгыр, ди. Бу хакда рәсүлулланың сүзләре бик күб булыб, тагын берничәсен искә алыйк:
الحلال من الكسب الاعمال افضب
Гамәлләрнең артыграгы Аллаһы кашында, сөеклерәге – халәлдән мал табу.
الله سبيل فى كالمجاهد فهو حلال من عياله على سعى من
Ягъни берәү үзенең хаҗәтләрен туйдыру, тормыш алыб бару өчен халәлдән кәсеб итсә, бу кеше Аллаһы юлында, Аллаһы ризалыгы өчен сугыш кылучы кеше шикелле, ди.
معفورا بات الحلال طلب من كالا بات من

Бер кеше халәл ризык эстәүдән арыб-талыб кичкә керә икән, ул кеше гөнаһлары гафу ителгәне хәлдә кичкә керер, ди.
(0642) Мөхтәрәм җәмәгать! Хәзрәт рәсүлебезнең бик игътимадлы, ышанычлы сүзләренә, хәдисләренә таяныб, әйтә алабыз ки, бер кеше, кирәк кем генә булмасын, Алланың барлыгына, берлегенә, Кыямәт көненең булачагына чын күңел белән ышанганның соңында изге ният, яхшы теләкләр белән бөтен адәм балаларына яхшылык, изгелек итү нияте, теләге белән бөтен халыкка, ватанына (الايمان من الوطن حب) сүзне исдә тотыб, завод-фабрикаларга эшкә барамы, яки совхоз-колхозларда эшлиме, йә булмаса пенсиягә чыккан картларыбыз, үзебезгә караган яшелчә-алма бакчаларында, йә булмаса тавык-чебеш асрауларыбыз – һәркайсы халәлдән кәсеб итү булыб, һәркайсы Аллаһыга зур гыйбадәтдән санала. Зур, сөекле гыйбадәтдән санала, дидем. Гыйбадәт булуына, зур булуына пәйгамбәр сүзе шаһид, дәлил. Хәзрәт рәсүл әйтә:
طلب في الهموم :قال الله؟ رسول يا يكفرها فما :قالوا ،العمرة ولا الحج ولا الصيام ولا الصلاة يكفرها لا ذنوبا الذنوب من إن المعيشة
Ягъни гөнаһлардан шундыен гөнаһлар бар ки, ул гөнаһларга намаз уку, руза тоту, хаж, Гомрә хаҗы (Кече хаж) – бере көфрият була алмас. Ягъни ул гөнаһларны җуя алмас, бары аңа көфрият ялгыз үзе һәм гайәли мәгыйшәте өчен мәшкать вә кайгылар гына, ул гөнаһның бетүенә сәбәб булыр, ди. Дигән: тормыш өчен тырышыб халәлдән кәсеб Аллаһы кашында сөекле, изге гамәл-гыйбадәтдән саналмаса, гөнаһларга көфәрәт булуда башка гыйбадәтләрдән артык әсәр итә алыр идеме? Юк, әлбәттә, булмас иде.
الحلال طلب فى منها تسعة اجزاء عشرة العبادة
Гыбадәт ун өлешдән тора, унның тугыз өлеше халәл кәсебдә.
(0643) Гыйбадәт ике төрле булыб: берсе гыйбадәт ләзимә; икенче гыйбадәт мөтәгаддийә. Гыйбадәт ләзимә: намаз уку, руза тоту, нәфел гыйбадәтләр. Боларның файдасы дөньяда да, Ахирәтдә дә үзебез өчен булачак, әмма гыйбадәт мөтәгаддийә: файдасы үзебезгә генә түгел, башкаларга да үтеб китә. Зәкят, гашер һәм башкаларга ярдәм итү рәхимле, шәфкатле булалар һәм халәлдән кәсеб итүебез, тормыш кирәкләрен кайгыртыб, кешедән моңсыз булудан, кешедән сораудан саклану өчен эш эшләүләребез – һәркайсы гыйбадәт мөтәгаддийә булыб, гыйбадәт мөтәгаддийәнең башка гыйбадәтләргә (сәләф салихин) караганда сәвабы күбрәк, дигәннәр. Нитек башка гыйбадәтләр бетерә алмаган гөнаһларыбызның да бетүенә сәбәб булганлыкдан.
Инде җәмәгать! Хасылел каләм: һәркайсыларыбызның эш урынларына барыб эшләүләребез, пенсиядәге картларыбызның базарга, кибеткә барыб, сөтме, икмәкме алыб кайтыб үз гаиләбезгәме, яки күршеләребезгәме, шулай ярдәм итүебез һәм йортда утырган картчыкларыбызның эшдән кайтучыларга аш хәзерлә, бала караб, өй саклаб торулары – һәркайсы югарыдагы хәдисләрдән аңлашылуына вә янә караганда нәфел намаз, нәфел рузалар тотуга караганда зур сәваблырак, изге гамәлләр җөмләсендән икән.
Инде тагын да үземнең сөйләгән сүзләреме куәт-дәлил итеб, гыйбарәсен укыб гына хәзрәт рәсүлнең мәбарәк сүзләрен әйтәм: бер рәсүл Аллаһы хозурында әсхабе кирам җыелыб утырган вакытда бер таза, матур егет ашыгыб үтеб бара икән. Сәхабә куәтле рәвешдә ашыгыб йөрүе Аллаһы юлында булса ни, никадәр гүзәл эш булыр иде дидекләрендә, хәзрәт рәсүл аларга каршы алай әйтте: әгәр бу егетнең болай ашыгыб йөрүе үзене фәкыйрлек сорану хурлыгында коткару, саклану өчен, ягъни кәсебкә ашыкса, бу Аллаһы юлында сәгый итүчеләрдән булыр. Яки карт ата-анасын тәрбияләү, яки кәсеб гаҗиз яшь балаларын тәрбияләү өчен булса, һаман да Аллаһы юлында (الله سبيل فى) иҗтиһад итүчеләр юлында булыр, диб җаваб биргән. Һәм Гайсә (гс): бер гыйбадәт кылучы ирне күреб, ни

кәсеб итәсең, диб сорады. Җавабында бу кеше: мин гыйбадәт кылам, диде. Сине кем тәрбия кыла диб сорады. Җавабында: минем туганым тәрбия кыла, диде. Хәзрәт Гайсә: алай булгач, синең туганың гыйбадәт кылучы икән, диб җаваб бирде. Бу сүзләрдән аңлана ки, кәсеб итәргә көче җитәрлек эш яшендәге ялкаулыкка салыныб, никадәр гамәл-гыйбадәт кылсалар да, кеше кулына караб торулары сәбәбле (الله جيب الكسب), бу кешеләргә ярдәм итүебезнең изгелек булмаенча, бәлки кешеләрне ялкаулыкка, начарлыкка өйрәтү булыб, Аллаһы каршында җавабка калуыбыз мөмкин. Кәсеб итү Аллаһы каршында изге гамәл булыб, пәйгамбәрләр балта остасы булган. Ибраһим пәйгамбәр сәүдә кылган, Идрис (гс) тегүче булган, Дауд пәйгамбәр дөньяга патша булса да, үзе тимерче булган, тимердән сугыш кораллары ясаган. Муса пәйгамбәр көтү көтегән, мал-туар асраган. Әюб пәйгамбәр дә мал-туар асраган. (0645) Аллаһы дустлары – пәйгамбәрләр –һәркайсы үз кул көчләре белән табкан ризыкдан ашаганлар, гаиләләрен тәрбия кылганлар. Һәркайсыбызга халәл кәсеб итү фарыз булган. Күзебез алдында яшь вакытларында тырышыб хезмәт иткән мөхтәрәм картларыбыз торыш, хезмәтләре берә-беренә дөньяда ук мөкәфәтләрен күреб, тормышларын әвештерерлек хөкүмәтебез тарафындан пенсия алалар. Менә тырышлыкның дөньяга күрелгән җимешләре. Бу тырыш хезмәтебез берә-беренә Аллаһы каршында тагын да зуррак әҗер вә сәвабларга, зур дәрәҗәләргә ирешәчәкбез. Аллаһы насыйб итсен.

Кәсеб хакында. Сәләф салихиннең сөйләгән сүзләрен беркадәр искә алсак, тагын да файдалырак булыр. Хәзрәт Гомәр: Мөхәммәд бин Салим дигән сәхабәнең бакчада агач утыртканны күреб: мин синең бакча эше белән мәшгуль булуыңны күреб шадланам. Әһле (عيالك) өчен тырышыб кәсеб итү, шул кәсеб иткән хәлдә үлү Аллаһы юлында сугышда үлүдән дә шәрәфәтлерәк, дигән. Олугъ сәхабәләрдән Габдулла ибн Сәгуд: бер кешенең ялкаулыгын ишетсәм, бик кайгырам. Үгет-нәсыйхәт кылыб да, ул кешене ялкаулыгындан биздерә алмасам, андан нәфрәт кылам, дигән. Ибраһим бин Әдһам (зур мәшаихлардан) көймәдә вакытларында зур дулкынга очраб, хәл берничек булыр, зур бәлагә очрадык дидекләрендә бу – бер нәрсә түгел, иң каты бәла, зур кайгы – ялкау белән фәкыйрлеккә дучар булу, кешегә кул сузу, дигән. Әбу Кылаб хәзрәтләре (зур галимләрдән) бер дустына: сине дини кәсебе белән мәшгуль итеб күрүем мәсҗеддә күрүемә караганда артыграк шадланам, чөнки халәл кәсеб яхшы ният белән булса, (0646) гыйбадәт мөтәгаддийә булыб хисаблана, димеш.

Ахыр сүз итеб шуны әйтәм, мөхтәрәм җәмәгать! Бу сөйләнгән сүзләр, вәгазьләр бәгъзе берләре хата аңланырга мөмкин. Шундый хәлләр булса, имзасыз хатлар языб гөнаһлы булмыйк. Әгәр дә хаклык ул тарафында була икән, ник ул үзе, мөселман була торыб, хаклыкны әйтүдән курыкмасын. Мәсҗедкә килсен, керсен, мулла диб мине чакырыб алыб, икәүдән-икәү калыб, хәлне аңлашырга мөмкин. Кабка артындан эреб җаткан кәрлә көчек (кечкенә эт баласы – А.Х.) кебек имзасыз хатлар язу – бу мөселманлыкка хыйляф гадәтләр. Ул кәрлә көчек беркемдән дә курыкмый, үзенә зыян итсә, итәргә мөмкин, ул башкаларга зарар итә алмый.

Адәм баласы берсе дә хатадан хали түгел, кирәк мулла булсын, мөәззин булсын, мөтәвәлли булсын: җитешмәгән җире, кимчелекләре була икән, аулакда үзенә әйт. Менә чын дөрест җул (юл – А.Х.) – әсхабе шулай булу. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре үзебезне, балаларыбызны дөнья Ахирәт хурлыкка төшерә торган ялкаулык авыруына дучар булудан саклаб, Аллаһы каршында гыйбадәт мөтәгаддийә дәрәҗәсенә ирешдерә торган изге дин белән кәсеб итәргә – Аллаһы ризасына ирешдерә торган гамәлес салихат җөмләсендән булыб, Кыямәт көнендә йөзебез ак булырга сәбәб булсын. Амин.

(0647) 27 нче октябрь 1967 ел, “33 нче Рәҗәб, җомга көн”.
Әгузу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аруланыб, пакьләнеб, Аллаһының рәхмәтен өмед итеб, саф күңел белән җомга намазына килгән мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Бүгеннән соң да илләребез, җанларыбыз тыныч булыб, сәламәтлек белән Аллаһының мөбарәк йортына килеб, гыйбадәт кылырга, догалар кылышырга насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы насыйб итсә, дүшәмбе көн кич, 27 нче Рәҗәб кичәсе Ислам тарихында зур хадисә (вакыйга)лардан булган хәзрәт рәсүлнең бик аз вакыт эчендә Мәккә Мөкәррәмәдән мәсҗедель Хәрамдан Шам илендәге мәсҗед Акса, Бәйтель мөкаддәскә баруы вакыйгъ булган кичәдер. Бу хәл вакыйгъ булган кичәгә Мигъраҗ кичәсе диб атала. Бу хәлнең булуы Коръән белән сабит. Коръәндә “Исра” сүрәсендә:
استعيذ بالله سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ
(سُبْحَانَ الَّذِي) – Бөтен кимчелекләрдән пакь вә һәртөрле күркәм сыйфатлар белән сыйфатланган Аллаһы Тәгаләне искә аламын. (أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ) – Шундалаен кодрәтле Аллаһы, Ул Үзенең колы бәндәсен, ягъни Мөхәммәд (сгс)не сәйр кылдырды (сәфәргә җибәрде мәгънәсендә – А.Х.), җөртде, гиздерде. (لَيْلًا) – Кичәләрнең бер кичәдә, ягъни төшдә түгел, уяу хәлдә сәйр кылдырды. (0648) (مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى) – Ягъни: Мәккә шәһәрендә булган мәсҗед Хәрамдан Кәгъбә Аллаһыдан сәйр кылдырды. Шам илендә булган Бәйтель мөкаддәскә мәсҗеде Аксага йөртде. (الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ) – Шундалаен мәсҗед ки, Мәсҗед Акса аның әйләнәсен, ягъни Шам илен дөнья Ахирәт бөркетләре илән мөбарәк кылдык, хөрмәтләдек. Чөнки хәзрәт Муса заманындан бирле бик күб пәйгамбәрләрнең гыйбадәт кылган урыны һәм пәйгамбәрләргә вәхи килгән урын (Шам илендә бик күб пәйгамбәрләр килеб, пәйгамбәрләр бишеге диб аталган урын). Бу пәйгамбәрләр күб адәмләрне азгынлыкдан коткарыб, Аллаһы каршында зур әҗер вә сәвабларга ирештергәнләр. Һәм бу урында агым сулар, елгалар һәм төрле адәмләргә файдалы җиләк-җимешләр күб булыб, адәмләргә торыр өчен, яшәр өчен файдалы җирләр булганлыкдан, дөнья Ахирәт өчен Бәйтель мөкаддәс тирәсендәге шәһәрләрне мөбарәк кылдык, ди. (لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا) – Ягъни: Үземезнең галәмәтләребезне шушы мөбарәк урынларны күрсәтү өчен сәйр кылдырдык. (إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ) – Дөрестлекдә Ул Аллаһы һәр нәрсәне Ишетүче, Күрүчедер. Менә шушы хәзрәти рәсүлнең Мигъраҗ вә Аксасы һиҗрәтендән бер ел элек Рәҗәб аеның 27 нче кичәсендә өммеһатель (өммеһат – төгәл мәгънәдә: ана китап; өммәтнең җитәкчесе А.Х.) мөэминин булган хәзрәт өммеһани (хәзрәти Галиның кыз кардәше, ягъни сеңлесе – А.Х.) өендә Ястү намазындан соң йокылы-уяулы яткан бер хәлдә Җәбраиль фәрештә килеб: “Йә Мөхәммәд, сиңа Аллаһы Тәгалә сәлам укыды. Синнән әүвәлге һичбер пәйгамбәргә булмаган зур хөрмәт белән хөрмәтләб, Үзе теләгән урынларны сәйр кылдырыб, Үзенең күб гаҗәеб вә гарәибләрен күрсәтмәк теләде”. Хәзрәт рәсүл хәзрәти Җәбраилнең шушы сүзләрен ишеткәннең соңында торыб тәһарәт алды. (0649) Хәзрәт рәсүлнең Мәккә Мөкәррәмәдән Бәйтель мөкаддәскә баруы җисмани булыб, Коръән яате белән сабит. Мөэминдән соңгы Аллаһының югары галимләргә сәйр кылуы хәбәре мәшһүр вә хәбәре вахид белән сабит булыб, соңгы, ягъни югары галимләргә сәйр кылуы ихтиляфлы мәсъәлә булыб, ягъни җисмани һәм рухани булуы хакында безгә артык сүз озатуының кирәге булмыйча, сәйидель әнбия булган пәйгамбәремез Мөхәммәд (сгс)не башка пәйгамбәрләргә булмаган зур хөрмәт белән хөрмәтләб, Аллаһы Раббел галәмин Үзе

теләгән югары галимләрне сәйр кылдырыб, гаҗәибләрне күрсәтүе – һәркайсы хак булыб, шушы вакытда без бәндәләрнең дөнья Ахирәт сәламәтлегебезгә сәбәб булган биш вакыт намаз шушы вакыт безгә фарыз кылган.

Узган җомгада сөйләнгән сүзләремә аңлатма итеб беркадәр намаз хакында әйтеб узыйм. Ягъни бер адәмләр хaләл тырышыб иткәндә намаз укымасаң да ярый, дигән кебек аңлашулар мөмкин. Ни кадәр тырышыб, яхшы ният белән хaләлдән кәсеб итсәң дә, фарыз намазларыбыз һич өстебездән төшми, хaләлдән тырышыб кәсеб әйтүебез зур әҗерле, сәваблы гамәл булса да, биш вакыт фарыз намазларыбызны үтәмәү белән зур гөнаһлы юлыбыз.

1. Дөньяви файдалары: намаз укыган адәмнең тәне, киеме һәм башка урынлары – һәркайсы пакь булганлыкдан, бу пакьлек безнең сәламәтлегебез өчен иң беренче, иң зур сәбәбләрнең берсе;

2. Намаз – ихласдан Аллаһыны искә алу, зикер (المنكر و الفحشا عن تنهى) булыб, бөтен начар-бозык сыйфатлардан тыйганлыкдан, үзара тату-тыныч яшәвебез, дустлык белән яшәвебез өчен иң зур сәбәб булыб, гамьсез авыруларыбызга шифа булачак. Шул сәбәбле биш вакыт намазыбызны үтәргә тырышу, (0650) эшдәге адәмләрнең иртә-кич булса да үтәргә тырышу бәндә җилкәбезнең иң кирәкле бурычыдыр. Инде ахирәви (башка –А.Х.) файдаларындан сүрәэи “Хаҗ”дә:

تُفْلِحُونَ لَعَلَّكُمْ الْخَيْرَ وَافْعَلُوا رَبَّكُمْ وَاعْبُدُوا وَاسْجُدُوا ارْكَعُوا آمَنُوا الَّذِينَ أَيُّهَا يَا بالله استعيذ

- И, иман китергән бәндәләр, рөкүгъ, сәҗдә кылыгыз. Ягъни намаз укыб һәм башка изгелекләр дә эшләгез, шәед ки, Аллаһы Тәгаләнең төрле газабларындан котылырсыз, ди. Инде мөхтәрәм җәмәгать! Максадка кайтыйк. Мигъраҗ вакыйгасын “Сөбханә” диб башлавы, чөнки гарәбләр бик артык гаҗәб сүз булганда: “Сөбхане Аллаһ”, – диләр икән. Бу Мигъраҗ вакыйгасын “сөбханә” диб башлавы бу вакыйганың харикель гадә (гадәттән тыш – А.Х.) булган, галәтдә булмый торган гаҗәб эш икәнен белдерә. Чөнки Мәккә Мөкәррәмә белән Бәйтель мөкаддәс арасы гарәбләрнең ул вакытдагы йөрүләре белән чагыштыргын вакытда кырык көнлек юл икән. Менә шушы кырык көнлек араны (үтмәде керпек (керфек – А.Х.) кагыб та, күз ачыб йомган заман, Мәккәгә кайтты, түшәге җыб-җылы ирде һаман). Бу рәвешле тизлек белән сәфәр кылдырудан Аллаһы гәззә вә җәллә хәзрәте максуды: фәкать хәзрәт рәсүлне могҗиза белән генә куәтле булмыйча, бәлки аның да өстәвенә Коръән Кәримдән бу аятьләрне зикер, искә алуда бөтен өммәтләр өчен нинди дер бөек хикмәтләр вә иршадларга юнәлдерү булачагы әлбәттә бәдиһидер (аксиома, хак – А.Х.). Коръән Кәримдә бу аятьнең зикер ителүе бәни мөхтәрәм, ягъни хәзрәт рәсүлнең өйрәтүе белән башланган гыйлме тәрәккый итә-итә, гаять үзен ерак араларны кыска гына вакыт эчендә үтәрлек дәрәҗәгә кадәр тәрәккый итәр дигән сүзләрне аңларга мөмкин.

(0651) Исламиятдә булган бөек хәдисләрдән булган Мигъраҗ вакыйгасында бик зур сер вә хикмәтләр бардыр. Бәниләр кулында булган харикель гадәләр – гадәтдә булмаган хәлләр садир булу (барлыкка килү – А.Х.), бәниләрне тәэкид, ягъни аларга ышандыру өчен генә дәлил булыб калмыйча, бәлки киләчәкдә гөлүмнең, мәгарифнең сәнаигъ ирешә алачак дәрәҗәләренә мисаллар күрсәтмәк һәм мәдәният гайәләренә инсанлар фикерләрен уятмак вә юнәлдермәк булуы шиксездер. Ягъни адәм балалары мәдәният, гыйлем, сәнаигъ аркасынлда бик кыска вакытда үзен ерак араларны бик тизлек белән үтә алырлар дигән сүз.

Безнең җиребез гыйлемгә нисбәтән караганда зәррә (кечкенә генә бер кисәкчә, частица – А.Х.) кадәр генә булса да, шул җир хәлифәсе булган (әшрафел мәхлукат) адәмгә хикмәт

илаһия , гадәт, бөек куәт табигыяларны ихсан итмеш инсан: гыйлем, сәнаигъ, иҗтиһад аркасында шул бөек куәтләрне үзенә мөсәххәр итсә, буйсындырса, шушындый харикель гадә (хыял кебек) хәлләрдә һич гаҗәб юк, адәмгә гади булыб калыр. Мәшһүр мөфәссирләрдән: шушы “Исра” сүрәсендәге “Борак” сүзенең дә электрик (яшен) мәгънәсендәге (برق) мәбалигә сыйгәсе булса кирәк дигән заманымыз да мәгълүм: табигый куәтләр арасында иң бөеге барк – яшен куәте булса, Алланың яраткан табигый куәтләр арасында (барк куәте). Андан ничә мәртәбә куәтлерәк булыб, Аллаһы адәм балаларының гакыллары ирешмәслек ерак араларны бик тиз үтә алуларына ишарәләр бар дигәнләр. Мигъраҗ вакыйгасына наданларга караганда галимләр тизрәк ышанганлар һәм ышанаячаклар. Коръән Кәримдә: (العلمین رب من تنزيل) улган китаб һәрбер аятьләре генә түгел, (0652) җенабе Хак безгә шушы аятьдә иң кирәкле булган хакларыбызны сөйләб, шушы сөйләнгән хак ияләре белән күркәм мөгамәлә кылуны шушыларга кылудан сакланырга куша. Шушы эшләребездә игътибарсыз булыб, шушыларның хакларын үтәүдән саранлык кылган адәмләрнең (нинди генә сәбәбләр белән булса да) Аллаһы дуст күрмәс, ди. Ул Алланың рәхмәтендән мәхрум була дигән сүз.
1. Шәрике-тиңдәше, ярдәмче юк. Камил сыйфатлар белән сыйфатлаб, Аллага гыйбадәт.
2. Ата-анага изгелек кылу, истигъфар кылыб дога.
3. Туган кардәшләребезгә изгелек кылу.
4. Ятим, мескенләр рәхим-шәфкать белән, нинди юллар белән булса да ярдәм итү.
5. Күршеләребезгә изгелек-яхшылык. Күршенең өч хакы бар.
6. Күркәм эшләрдә эш урынларында, сәфәрдә үтәр эш булган җирләребездә, хосусан – зәүҗиятдә, ир белән хатынлыкда, иң якын түшәкдә ир хатынга, хатын иргә яхшы, күркәм мөгамәләдә булу. Гомер иткән ирне, гомер иткән хатынны рәнҗетүләр бәхилләшми торыб, гафу итми торган гөнаһлардан генә өч төрле: ширк, кеше хакы, Аллаһы белән бәндә арасында булган гөнаһ. Карт көнендә үзенең нәфсенә ияреб, шәригат дүртене алырга кушкан диб, әллә ничә хатын алмакчы. Шәригать ике-өч хатын алырга кушмый, бәлки шундый сәбәбләр килеб чыкса, рөхсәт кенә бирә.
7. Мөсафирләргә кунакчыл булу, изгелек кылу, хөрмәт итү
(واجب حق ضيف حق).
8. Кул астында булган хезмәтчеләр, яки ул шушы хакларны ригаять кылмаучылар Алла сакласын.
فخورا مختالا كان من يحب لا الله ان
(0653) Мөхтәрәм мөселманлар! Үз-үзебезне хисаблаб, тикшереб, үлчәб карарга тиешбез. Аллаһының безгә күрсәткән әмер-боерыклары белән гамәл итә алабызмы, юкмы? Сөйләнгән вәгазьләр әсәр итәме, юкмы? Кыямәт көнендә безгә Аллаһы тарафыннан хыйтаб кылынса, әйтелсә:
علیکم تتلی آیتی تکن لم ا
сезгә минем аятьләрем укылмадымы, шәригать хөкемләрен сөйләүче вәгыйзләр, хатыйблар булмадымы? – диб әйтсә, ни җаваб бирербез. Ул көндә ялганлаб котыла алмабыз.
صوابا وقال الرحمن له أذن من إلا يتكلمون لا صفا والملائكة الروح يقوم يوم
Ул Аллаһының фәрештәләре, Җәбраиль саф-саф булыб торырлар. Аллаһы тарафыннан рөхсәт бирелгән кеше генә сөйли алыр. Ул да һич ялганлый алмас, бәлки Хак сүзне генә сөйләр. Бу көн һичшиксез хак булган Кыямәт көнедер. Һәркайсыбызның башыбызга киләчәк.
Җенабел галәмин җөмлә мөэмин мөселманны шушы йөзләребез кара булудан саклаб,

Аллаһының дустлары җөмләсендән булырга мөяссәр кылсын.
(0654) Бәлки аның һәрбер аятьләре сансыз, хисабсыз хикмәт вә мәслихатьләрне шамилдер.
Мәккәнең җаһил, надан гарәбләре Мигъраҗ вакыйгасын ишеткәннең соңында: Мөхәммәд аз гына вакыт эчендә Шамга барыб кайтдым, диб сөйли. Рәсүлулланы ялганчы, хыялый диб, төрле начар исемләр тагыб, Ислам зарарына әллә ниләр сөйләб бетергәнләр. Шушы вакытда хәзрәт Әбу Бәкергә килеб: менә синең дустың нинди ялганлар сөйли диб җиткеренгәнләр. Шул вакыт хәзрәт Әбу Бәкер: хәзрәт Мөхәммәд шул сүзне әйтәме? Әйтсә, һичшиксез дөрест диб, иман китерә (ышана). Шуның өчен хәзрәт Әбу Бәкергә Сиддыйк (дөреслекне, хаклыкны сөйләүче – А.Х.) исеме бирелгән. Шуның өчен Ислам дине гыйлем, укуга шул дәрәҗәдә әһәмият биреб, гыйлем хакында, белем хакында Коръән дә һәм рәсүлнең хәдисләре бик күб булыб, гыйлем аркасында хыял дәрәҗәсендә булган эшләргә ирешергә мөмкин икәнлегенә кыска гына ишарәләр белән юллар күрсәткән.
Гыйлем хакында гомуми рәвешдә:
وبال الجهل و كمال العلم .عذاب الجهل و ثواب العلم .محنة الجهل و حكمة المعلم .نار الجهل و نور العلم
Һәм заманыбызда вакыйг булган гаҗәб күренгән хәлләргә, Коръән әһелләренә, галимләргә һич гаҗәбләнерлек хәлләр түгел һәм хәзрәт рәсүлнең: “Әбнаʼу фарсыдан шундый үткен галим адәмләр булыр, алар галимлекне Сөрәййә йолдызындан булса да алырлар” сүзләре киләчәкдә адәм балалары гыйлем аркасында йолдызларга менүләре дә гаҗәб булмас.
Аңлаткан һәм мәшһүр галимләрдән бер галим гыйлем хакында: “Камәт үстерсәк, җиһанда һичшиксез фил булу мөмкин, укыб рухың гали итсәк, Җәбраиль булу мөмкин”, - ди.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә укучы яшьләребезгә тәуфыйк, һидаять биреб, хәерле, файдалы гамәлләр насыйб итсен. Тиздән булачак шушы мөбарәк кичәләрне шадлык белән күреб, гамәл, гыйбадәт һәм сәйедель бәшар, шәфигель өмәм булган пәйгамбәребезгә күб салават әйтеб, хәзрәт рәсүлебезнең шифагәтенә ирешергә барчаларыбызга насыйб булсын.
(0656) 5нче номерлы дәфтәр
1967 нче Милядия
1. Аракы хакында сөйләнгән.
2. Кәсеб хакында.
3. Сәлам хакында.
Шәгъбан аенда сөйләнгән вәгазь.
1967 нче елда Казанда, мәсҗед Мәрҗани хозурында.
Имам Габделхабир бин Җаруллаһ тарафыннан сөйләнгән вәгазләр.
(0657) Бисмилләһир Рәханир Рәхим
1967 нче ел, 3 нче ноябрь
30 нчы Рәҗәб, җомга көн.
(Тиздән искә алырга тиешле булган зур, истәлекле көн булган – Бөек Октябрь бәйрәме).
(0658) Җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бүгенге җомга көн Рамазандан кала фазыйләтле, айларның берсе булган Шәгъбан аеның беренче көне булачак. Барчаларыбызга шушы мөбарәк айны ихтирам итеб, кадерен белеб гамәл-гыйбадәт белән уздырырга Аллаһы насыйб итсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Тагын да алдымызга килеб баскан, тагын да дөньяви бәйрәмебез бар. Ул да булса – бөтен изелгән вак милләтләргә тигез хокук вә матур тормыш биргән Бөек Октябрь бәйрәменең илле еллыгы. Шушы бөек бәйрәм барчаларыбыз өчен мөбарәк булыб,

илләребез, елларыбыз тыныч булыб, мөкаддәс, пакь булган Ислам динебезгә Аллаһы ярдәм биреб, шушы ирекле, бәхетле тормышыбызда күб елларга кадәр саулык-сәламәтлек, тынычлык, хәерле тормыш, хәерле гомер насыйб итсен .
Мөхтәрәм җәмәгать! Шушы бөтен халыкның уртак бәйрәме булган бөек бәйрәмне, адәм баласын дөнья Ахирәт хурлыкка, бәхетсезлеккә төшерә торган, дөнья Ахирәтдә үкенечкә калдыра торган, Ислам дине тарафындан катгый рәвештә тыелган, бөтен гакыл ияләре һәм медицина галимнәре тарафындан адәмнең сәламәтлегенә зур зарар, тормышына куркыныч, һәлакәт китерә торган агу икәнчелеге исбат кылынган исереклекдән сакланыб, аеклык белән үткәрергә Аллаһы насыйб итсен.
(0659) Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре “Маидә” сүрәсендә 91-95 нче аятьләрдә:
عَمَلِ مِّنْ رِجْسٌ وَالأَزْلاَمُ وَالأَنصَابُ وَالْمَيْسِرُ الْخَمْرُ إِنَّمَا آمَنُواْ الَّذِينَ أَيُّهَا يَا بالله استعيذ
تُفْلِحُونَ لَعَلَّكُمْ فَاجْتَنِبُوهُ لشَّيْطَانِ
Ягъни: И, Аллага иман китергән бәндәләр! Адәм баласын исертә торган, гакылын җибәрә торган, хәмер, аракы, автомат уенлары, нинди генә булса да һәм потларга, тәреләргә табыну – һәркайсы нәҗес булган шәйтан гамәлләредер. Шушылардан, ягъни нәҗес булган шәйтан гамәлләрендән сакланыгыз (تُفْلِحُونَ لَعَلَّكُمْ), шушы нәрсәләрдән сакланыгыз. Инша Алла дөнья Ахирәтдә һәлакәткә төшүдән котылыб, фәлах табарсыз, ди.
وَالْمَيْسِرِ الْخَمْرِ فِي وَالْبَغْضَاء الْعَدَاوَةَ بَيْنَكُمُ يُوقِعَ أَن الشَّيْطَانُ يُرِيدُ إِنَّمَا
مُّنتَهُونَ أَنتُم فَهَلْ الصَّلاَةِ وَعَنِ اللهِ ذِكْرِ عَن وَيَصُدَّكُمْ
Ягъни: шәйтан бары отыш уенны һәм исерткечләр аркылы сезне сугыштырыб, ачуланыштырыб, арагызга дошманлык салырга тели һәм Аллаһыны зикердән, Аллаһыны искә алудан тыюны тели һәм намаз укудан тыелынуны тели. Бәс шулай булгач сез үзегез мөселман була торыб да, шушы начар эшләрдән тыелыгыз, ди.
Шәригать Исламда аракы, исерткеч – иң бөек хәрамләрдән берседер. Һәрбер исерткеч Коръәннең хөкеме белән хәрам булыр. Имам Мөслим риваятендә:
حرام خمر كل و خمر مسكر كل
Һәм әһле сөннәт риваять әймеш:
حرام فقليله كثيره اسكر ما
Ягъни күбе дә исерткән нәрсәнең азы да хәрам, дигән.
Зур хәдис имамларындан Ногъман бин Бәшир һәм Әбу Дәвуд хәзрәтләрендән (0660) риваять:
خَمْرًا الْعَسَلِ وَمِنَ ، خَمْرًا التَّمْرِ وَمِنَ ، خَمْرًا الزَّبِيبِ وَمِنَ ، خَمْرًا الشَّعِيرِ وَمِنَ ، خَمْرًا الْحِنْطَةِ مِنَ إِنَّ :عهم اسول قال قلنا
Ягъни: адәм баласының гакылына зәгыйфлек исертә торган нәрсә кирәк бодайдан, кирәк арпадан, кирәк һәртөрле җимешдән: хөрмәдән, балдан, сөттән булсын, башка китә торган булса, - һәркайсы аракы булыб, һәркайсы хәрам булыб, каты рәвешдә тыелган.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бәгъзе адәмләр тарафындан шундый сүзләр ишетелә: Коръәндә аракынын хәрамлы хакында аять юк, дигән сүзләр. Аракы – искелек калдыгы дигән сүзләр булса, болар һәркайсы зур ялган. Чөнки Ислам дине мең ярым еллар элек аның хәрамлыгы, аның зарарлары хакында, дөнья Ахирәтдә хараблыкка төшерә торган куркынычлы агу диб сөйләнеб килгәннәр. “Бәкара”, “Ниса’”, Ма’идә” сүрәләрендә аракының хәрамлыгы хакында хикмәтләре сөйләнгән.
1) Зур гөнаһ булуы, кешелек дөньясына китергән зур зарарлары, гакыл кебек адәм баласына бирелгән зур нигъмәтнең китүе (الاحان من الحيأ) ятның (оятның – А.Х.) качуы, гакылы беткән адәмнең телендән, кулындан нинди зур кабәхәтлекләр эшләве, аракы сәбәбле бөтен гаиләсе, өй җәмәгатләре, дуст ишләре белән дошманлашуы. Адәмләр арасында нинди шау занҗалләре кубуы, аракы аркасында үзенең тормышына, завод-

фабрикада эшләренә зур кимчелекләр китерүе, прогул, брак эшләүләр... Аракы эчкән адәмнең ничә көнләргә кадәр авыру булыб, иштиһәсе, аппетиты бетеб, йөзендән нуры китеб, ахыр чиктә – "белая горячка" (хыялланыб) авыруы. Гомерем эчендә эшләгән җиремдә "белая горячка" авырган кешеләрне үз күзем белән күрдем. (0661) Менә быел гына, җәмәгать, эчү аркасында никадәр яшь кенә адәмләребез вакытсыз җир куынына керде. Никадәр кешеләрнең балалары ятим, хатынлары тол калды.
Мөхтәрәм җәмәгать! Шулай ук Ислам динендә аракыдан кала әфйүн салу, тәмәке тарту, борынга иснәү кебек начар гадәтләр – һәркайсы Ислам дине тарафындан каты тыелган, хәрам булган нәрсәләр. Менә бу нәрсәләр һәркайсы адәм баласының сәламәтлегенә зур зарар китергәнлекдән галимләребез хәбискә (начар; бозык; нәҗес) кертеб (و يحرم عليهم الخبائث), диб хәрам булуы белән хөкем иткәнләр. Менә шушы начар гадәтләр егерменче гасырның гакыл ияләре тарафындан һәм сәламәтлекне саклаучы медицина галимләре тарафындан сабат (исбат – А.Х.) кылынган.
Бу хакда газета-журналларда күб нәрсәләр язылыб, исереклек хөкүмәт тарафындан да каты тыелган нәрсә. Яхшы гына олы яшьтәге адәмләребез тарафындан мин үз колагым белән: аракы икмәкдән ясалган, яки җимешдән генә ясалган дигән шушы (ام الخبائث) булган, аракыны бик җиңел санаучылар бар. Җәмәгать! Бу хакда бик сак булырга кирәк (Әгәр берәү: аракы халәл диб эчсә), бу кеше шиксез гөнаһлы була. Бу адәмдән иман чыга, зарарлы хәрам икәнчелегенә ышаныб, нәфсенә хуҗа була алмый. Эчә икән, бу кешедә ят кача, иман нуры кача (الاران من الحيأ). Бу кабәхәт дөнья Ахирәтдә бәхетсезлек китерә торган нәҗагәтдән тыелу, башкаларны тыю – бөтен мөселманларның изге бурычы.
قال م عه: من امر بالمعروف و نهى من المنكرفهو حليفة الله و حليفة رسوله.
(0662) Җаһилият заманында исерткеч эчеү бик күб таралыб, бик күб адәмләр шушы начар агу белән мөбтәла булганлар. Хәзрәт рәсүлгә пәйгамбәрлек килгән вакытда [андый очраклар] никадәр күб булганлыгы түбәндәге вакыйгадан аңларга мөмкин: Мәккәдә яшәүче бер Агша исемле мөшриккә күңелендә дине Ислам (Ислам диненә – А.Х.) мәхәббәт уяна: дөясенә атланыб, рәсүлуллага иман китерү өчен диб Мәккәдән Мәдинәгә юлга чыга. Юлда моңар башка мөшрикләр очрыйлар.
— Мондан кая барасың? – диб сорыйлар. Җавабында :
— Мөхәммәдкә барам. Аның диненә керәм, – ди. Мөшрикләр аңа каршы:
— Мөхәммәд, ул Аллага гына гыйбадәт кылырга, тәреләргә гыйбадәтдән тыелырга куша, – диләр. Моңа җавабында Агша:
— Бик дөрест әйтә. Җандан да гыйбадәт бөтен нәрсәне юкдан бар кылган бер Аллаһыга гына булырга тиеш. Потларга, тәреләргә гыйбадәт кылу, әлбәттә, начар. Чын гыйбадәт – бер Аллаһыга гына булырга тиеш, - ди. – Мөхәммәд (сгс) ятимләргә, фәкыйрләргә, юксылларга ярдәм итәргә куша, диләр. Фәкыйрләргә, ятимләргә ярдәм итү бәлки күркәм эш? – ди. Дәхи әйтделәр:
— Мөхәммәд (сгс) зинадан тыя ул, – диделәр.
— Бик яхшы, зина – фәхиш вә бозык эш. Мин карт кеше, зинага якын бармам, – диде.
Тагын әйтделәр:
— Мөхәммәд исерткеч эчүдән, аракы эчүдән тыя, – диләр. Шушы вакыт Агша беркадәр уйланыб тора да, әйтә:
— Һай, менә монысы бик авыр эш, мин аракы эчми түзә алмам. Кайтыйм да, бер ел буена туйганчы рәхәтләнеб аракы эчим дә, бер елдан килеб Мөхәммәдкә (сгс)гә килеб иман китерермен.
Кире борылыб кайтыб барганда дөясе сөртенеб егыла да, бер ташка тугры килеб, муены

сыныб һәлак була. Аракы эчүгә бирелүе хакында исерек хәлендә дөньядан үтә.
Мөхтәрәм җәмәгать! Хәзерге көнебез шушы исреклек аркасында һәркөн диярлек фаҗигалы, кызганычлы хәлләрне күреб торабыз. Менә шушы адәм баласын дөнья Ахирәтдә бәхетсезлеккә китерә торган, үкенечкә, хәсрәткә төшерә торган шушы агу белән көрәшү, ата-аналарның, хөрмәтле дәү әти, дәү әниләрнең, хөрмәтле бабаларның, әбиләремезнең – барыбызның уртак булган, изге бурычыбыз. Кече яшьдән үк балаларыбызның колакларына, күңелләренә сала бару һәм яшьләребезнең колакларына, исләренә төшереб тору: урамда йөргән вакытда вә башка урынларга барганда әдәбле, инсафлы, тәрбияле, ибтәшләр белән катнашыб, начар, исерек ибтәшләрдән ерак булырга. Тәмле телләребез, матур сүзләребез белән шушы юлларга өндәсәк, инша Аллаһ, һәр мөселманның (المنكر عن نهى بالمعروف امر) булган зур бурычны үтәгән булыб, Аллаһы Раббел галәмин хозурына барган вакытда йөзебез ак булуга сәбәб булыр.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте үзебезгә, балаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, дөнья Ахирәтдә үкенечкә калудан барчаларыбызны сакласын (المستقيم صراط اهدنا).
(0664) Шәгъбанның 14 нче атна кич, пәнҗешәнбе көн, Бәра’әт кичәсе булачак. Аллаһы насыйб итсә, беркадәр аңлатма.
16нчы ноябрьдә булачак.
(0665) Мөхтәрәм җәмәгать! Бүген җомга көн. Рамазан аендан кала иң фазыйләтле айларның берсе булган – Шәгъбан аеның беренче көне. Җенабе Раббел галәмин хәзрәте өстебезгә туган Шәгъбан ае җөмләмез өчен мөбарәк кылыб, шушы хөрмәтле айның кадерен белеб, бөтен начар, бозык гадәтләребезне ташлаб, гамәл гыйбадәт вә башка изгелекләр белән уздырырга насыйб булсын. Җир шарында искитәрлек зур тарихи вакыйгаларның да иң зурысы булган, тиздән булачак – бөтен изелгән вак милләтләргә тигез хокук биргән Бөек октябрь бәйрәменең илле еллыгы мөбарәк булсын! Илләребез тыныч булыб, мөкаддәс, пакь булган Ислам динебезгә Аллаһы ярдәм биреб, шушы иркле, бәхетле тормышыбызда саулык-сәламәтлек белән күб елларга кадәр тыныч яшәргә Аллаһы насыйб итсен. Амин. Бихөрмәти сәййидель мөрсәлин.
(0666) 15 нчы ноябрь 8 нче Шәгъбан, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабе Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Җенабе Хакның сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларымызга насыйб булсын. Бүгеннән соң да Аллаһыны чын күңелдән истә тотыб, ихлас белән гыйбадәт кылырга Аллаһы насыйб итсен. Амин.
اعوذ بالله من الشيطان الرجيم. فَإِذَا قُضِيَتِ الصَّلَاةُ فَانتَشِرُوا فِي الْأَرْضِ وَابْتَغُوا مِن فَضْلِ اللَّهِ وَاذْكُرُوا اللَّهَ كَثِيرًا لَّعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ
(сүрә “Җумга”, 9 аять). Ягъни җомга намазындан бушансагыз, йир йөзенә таралыгыз да Аллаһы Тәгаләнең ризалыгыны, рәхмәтене истәгез, кәсеб итегез, мал артындан йөрегез. Фәкать мал артындан гына йөреб, бөтенләй дөньяга бирелеб китеб, Аллаһы Тәгаләне хәтердән, истән чыгармагыз. Әгәр шулай Аллаһы кушканча, Аллаһыга гыйбадәт кылыб, Аллаһыны һәрвакыт искә алыб (эш вакытында да), Аллаһыны хәтердән чыгармасагыз, инша Алла, Аллаһының газабындан, ачуындан котылырсыз, ди. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте бу аять Кәрим белән өч нәрсәгә ишарә кылган:
1) Үзене юкдан бар кылыб, төрле нигъмәтләр белән тәрбияләгән, Аллаһыга һәрбер нигъмәте өчен шөкранә кылыб, ихлас белән гыйбадәт кылырга, бигрәк тә намаз укырга тиешлелеккә.

2) Кешегә мохтаҗ булмый, рәхәт гомер итәр (0667) өчен, йир йөзенә таралыб, ризык табарга, кәсеб итәргә.
3) Һәрвакыт, Аллаһыны истә тотыб, кирәк гыйбадәт вакытында, кирәк дөнья кәсебләре вакытында, һәрвакытда Аллаһыны хәтердән чыгармый, ягъни бөтен эшләребездән Аллаһы хозурына баруны, Кыямәт көнендә хисаб бирүне истән чыгармаска, хәтердә тотуны ишарә кылган.
Аллаһы Тәбарәкә "әл-Гыймран" сүрәсендә 12 нче аятьдә әйтә: "Сезгә нәфес теләгән нәрсәләрегез һәркайсы сөекле, матур кылынды. Һәртөрле дөнья маллары: менә адәм баласы шушы дөнья малын бик сөйгәнгә күрә, шушы малны кулга төшерү өчен күб ялгышыб китә бәгъзан нәфескә ияреб, хәрамын, халәлен дә тикшерми алдарга тырыша, ант итә, ялганлый. Менә шуның, шушындый вакытларда адәм баласы Аллаһыны чын-чынлаб исендә тота алса, ягъни Аллаһы хозурына барыб, хисаб бирүне уйласа, алдау, ялган, хыянәт кебекләрдән, әлбәттә, һичшиксез саклана ала. (كثيرا الله اذكر و) Аллаһыны зикер итү, җәмәгать, үзе һәрвакыт кулында тәсбих булыр, ә үзе кеше рәнҗетүдән дә, гайбәт сөйләүдән дә, сүз йөртүдән сакланмас, менә бу, җәмәгать, кулда тәсбих тотыб кына Аллаһыны искә алу булмый, чын Аллаһыны искә алу, чын зикер һәрбер дөньяви, һәр ахирәви эшләребездә һәрвакыт Аллаһыны истдә тотыб: минем һәрбер эшләремне Аллаһы хәзрәте күреб, белеб тора, әгәр мин һәр эшемдә тугърылыкда, дөреслекдә булсам, Җенабе миндән разый булыб, Аллаһының яхшы бәндә вәгъдә кылган: әҗер вә сәвабларга ирешермен, әгәр мин Аллаһы кушканча булмасам, Аллаһының газабына, ачуына йолыгырмын, очрармын, диб курку вә уйлау.
(0668), (0669) – алдагы битләрне кабатлыйлар
(0670) Менә чын Аллаһыга зикер истә тоту шушылай булырга тиеш. Бигрәк тә намаз, гыйбадәт вакытында Аллаһыны исдә тоту намазыбыз, гыйбадәтләребезнең кабуллыгы сәбәб булганлыкдан: әгәр гыйбадәт вакытында Аллаһыны хәтеребездән чыгарсак, кылган гыйбадәтләребезнең кабул булмавы ихтимал, Аллаһы сакласын! Хәзрәт рәсүл бу хакда әйтә:
غافل قلب عن يقبل لا الله ان
Ягъни: гафил булган, ягъни кирәк гыйбадәт вакытында, кирәк дога вакытында телләребез укыб да, күңелләребез әллә кайда булса, менә бу гафил булу була. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әйтә:
ساهون صلاتهم عن هم للمصلحين فويل
Ягъни: ни үкенеч, һәлакәт шундаен намаз укучыларга, алар үзләренең намазларындан гафилләр, ди.
Рәсүлулладан намазда гафләт итүчеләр кемләр диб сораганда, алар намазны вакытында укымаучылар һәм намазның рөкенләрен ригаять итмәүчеләр, рөкугъ-сәҗдәләрен тиешенчә үтәмәү, гозерсез каумә вә җәлсәләрне ригаять итми, рөкугдән тәмам тураеб җитмичә сәҗдәгә китү һәм ике сәҗдә арасында тәмам утырыб бетмичә икенче сәҗдә китү. Менә болар һәркайсы тәгдил ирканны ригаять итмәүләр, һәркайсы гафләт булырга мөмкин. Бәгъзебер мөфәссирләр намаздан гафләт итү, гафил булу, мәсҗед эчендә сакланырга тиешле булган, мәкруһ булган эшләрдән сакланмау – һәркайсы вә һәркайсы гафләт була, дигәнләр.
Иң әүвәл, җәмәгать! Хәзрәт рәсүлебезнең:
لنفسه تحب ما للناس احب
Башкаларга урын бирү шәригатемез рөхсәт итсә, торыб (мәсагыйд), кыла торыб, урын тыгыз булу сәбәбле, кеше аркасына сәҗдә кылу (0671) һәм ишарә белән сәҗдә кылулар

зарурәт вакытда дөрест була торыб да, һаман да үзсүзләнеб, үзебезнең артыбыздагы мөселманларга аякларыбыз белән уңайсызлаб, башкаларга җәбер итә-итә, намазлыкка сәҗдә кылуларыбыз – болар һәркайсы гафләт булырга мөмкин. Боларның һәркайсындан сакланырга тырышыйк.
Мөхтәрәм җәмәгать! Гозерсез намаз укымаучылар хакында Коръәндә бик күңелсез, куркынычлы вә гайре аятьләре бар. Җөмләдән берсе “Мөдәссир” сүрәсендән:
الْمُصَلِّين مِنَ نَكُ لَمْ قَالُوا سَقَرَ فِي سَلَكَكُمْ مَا الْمُجْرِمِينَ عَنْ يَتَسَاءَلُونَ جَنَّاتٍ فِي بالله استعيذ
Ягъни җәннәт әһелләре сакр тәмугсында газаб кылынучылардан сорарлар (سَقَر فِي سَلَكَكُمْ مَا): ни сәбәбле сакр тәмугсына кертде сезне диб, (الْمُصَلِّين مِنَ نَكُ لَمْ). Шушы вакыт тәмугъ әһелләре әйтерләр: без дөнья вакытда намаз укымадык диб. Һәм “Мәрьям” сүрәсендә:
غَيًّا يَلْقَوْنَ فَسَوْفَ الشَّهَوَاتِ وَاتَّبَعُوا الصَّلَاةَ أَضَاعُوا خَلْفٌ بَعْدِهِمْ مِنْ فَخَلَفَ
Ягъни ул пәйгамбәрләрдән соң шундаен кавем килер, алар нәфселәренә ияреб, һәртөрле бозык эшләрне эшләб, намаз укымадылар (غَيًّا يَلْقَوْنَ فَسَوْفَ). Тиздән бу кешеләр тәмугъда газаб кылынырлар, ди.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әйтә:
يسرا العسر مع ان يسرا العسر مع فان
Аллаһы Тәгалә хәзрәте һәрбер авырлыкка бер йиңеллек икәнен белдерә. Шушы гыйбадәт авырлыкларына, мишкатьләренә мәсҗеддәге уңайсызлыкларга сабыр итсәк, инша Алла, моның ахыры Аллаһы каршында зур әҗер-сәвабларга ирешү булыр. Шул ук “Мәрьям” сүрәсендә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә безгә вәгъдә ... .
(0672) (әл-Иман).
Иман шул була:
.احکامه جمیع قبلت و صلعم الله رسول محمد تعالی الله عند من به جاء بما بالارکان عمل و ،بالقلب تصدیق و باللسان اقرار
(0673) Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Шәгъбан аеның 15 нче кичәсе (Бәрәат) кичәсе. Җөмләбезгә мөбарәк булыб, шушы мөбарәк кичәгә моафыйк рәвешдә хата вә кимчелекләр чын күңелдән үкенеб, тәүбәбез вә истигъфар кылыб, исемләребез җенабе Хакның сөйгән бәндәләре, мөэмин вә мөселман коллары – җөмләсендән язылыб, бөркетелеб, күңелләребез иман-Ислам үзренә карарланыб, мөселман булыб яшәб, ахыр сулуларыбызда иман-Ислам белән дөньядан күчү насыйб булсын.
Җенабе Хак “Духхан” сүрәсендә:
عِندِنَا مِّنْ أَمْرًا حَكِيمٍ أَمْرٍ كُلُّ يُفْرَقُ فِيهَا مُنذِرِينَ كُنَّا إِنَّا ۚ مُّبَارَكَةٍ لَيْلَةٍ فِي أَنزَلْنَاهُ إِنَّا
диб, мөбарәк аталган кичә – Кадер кичәсе һәм Шәгъбанның 15 нче кичәсе, дигәннәр. Ул кичә мөбарәк, мокаддәс булуы белән мөбарәк: күб хәер, күб файда-рәхмәт сәбәб булучы дигәненә, ул кичәдә рәхмәт фәрештәләренең Кадер кичәсе кебек җир йөзенә иңүләре, мөэминләргә сәлам, истигъфар кылулары – һәркайсы безгә дөньяда вә Ахирәтдә файда бирә торган шадлыклы хәбәрле эшләр. Шуның өчен Мөбарәк кичә диб атала.
(0674) Сүрәи “Фөҗер”дә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә:
عشر ليال و الفجر
Таң вакыты вә хөрмәтле ун кичә берлән дигән сүздән морад. Мөхәррәм аеның әүвәлге ун көне, Рамазанның соңгы ахыргы ун көне һәм Шәгъбан аеның уртасы икенче уны, 15 ндә Бәраәт кичәсе булган урта уны, дигәннәр.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтенең бу кичәләрне аерым рәвешдә Коръән Кәримдә зикер әйтүебез адәм балалары өчен хәерле, мөбарәк сәгадәткә сәбәб булган кичә булуына зур дәлилдер.
(0675)

(عمل و آمن و تاب من الا) الجنة يدخلون فاؤلئك صالحا عمل و
Мәгәр бер кеше чын күңеле белән тәүбә кылыб, бөтен начар гадәтләрен ташлаб яхшылыклар кылса, ошбу кешеләр җәннәткә керерләр, ди.
تقيا كان من عبادنا من نورث التى الجنة تلك
Ягъни: шундаен җәннәтдер – бөтен бозыклардан сакланыб, яхшы эшләр кылган тәкъва колларыбызга боерылды һәм хәзрәт рәсүлнең бер мөбарәк сүзен ишетеб шатланыйк:
له ذنب لا كمن الذنب من التائب
Бөтен кылган начарлыкларга чын күңелдән үкенеб, тәүбә кылган кеше – гөнаһсыз кеше, ди. Мөэмин булган кеше һәрвакыт (الرجاء و خوف بين) – курку белән Алааһының рәхмәтендән өмед итү арасында булырга тиеш. Ни кадәр яхшы булса да, җәннәтлек диб, Аллаһының газабындан әмин булу ярамаган кебек, никадәр начар булсак да, Аллаһы рәхмәтендән өмед кисәргә ярамый.
Хәзрәт рәсүлнең:
قَبْلَ وَ غِنَاكَ ، هَرِمِكَ قَبْلَ وَشَبَابَكَ ، شُغْلِكَ قَبْلَ وَفَرَاغَكَ ، سَقَمِكَ قَبْلَ وَصِحَّتَكَ ، مَوْتِكَ قَبْلَ حَيَاتَكَ : خَمْسٍ قَبْلَ خَمْسًا اغْتَنِمْ فَقْرِكَ
Исдә тотыб, сау-сәламәт вакытда мөмкин [кадәр] яхшы гамәлләр кылырга тырышу, кулыбызда хуҗалык бар вакытда хәлебездән килгән кадәр тиешле урынларга малыбыз белән ярдәм итү, үлгәнгә кадәр тәүбә итеб итәргә Аллаһы насыйб итсен.
Узганда бәндәчелек белән булган хата вә гөнаһларыбызга тәүбә кылыб, бер-беребезне рәнҗетүдән сакланыб, хәлебездән килгән кадәр яхшы гамәлләр кылыб, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең яхшы бәндәләренә вәгъдә кылган оҗмах нигъмәтләре вә дийәре шәрифләре белән мөшәррәф булырга насыйб булсын.
(0676) Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһының йортына (Бәйтуллага) намаз укыр өчен җыелган мөхтәрәм мөселманлар! Рамазан аендан кала Аллаһы кашында мөбарәк булган Шәгъбан ае, аның мөбарәк кичәләрдән саналган Бәраәт кичәсе мөбарәк булсын!
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә шушы мөбарәк көнләрдә кылган догаларыбызны кабул итеб, барчаларыбызга хәерле гомер биреб, киләчәк елларында шадлык белән күрергә насыйб итсен.
(0677) Шәгъбанның 15 нче кичәсенең Бәраәт аталуы хакында шундый риваятьләр бар:
الاتقياء و للاصفياء يعطى و رسوله و الله من برأة الجنة من برأة للاعداء الليلة هذه فى يعطى تعالى الله لان برأة سميت انما النار من برأة.
Ягъни Бәраәт аталуына сәбәб бу көндә, бу кичдә Аллаһының дошманлары кяферләр, мөшрикләр бизгүчедер, оҗмахдан, Аллаһыдан, рәсүлдән һәм Аллаһы дустлары, тәкъвалар өчен тәмугъдан бизмәгән.
Хәзрәт рәсүлнең хәдисе:
شعبان نصف ليلة من افضل القدر ليلة بعد ليلة من ما
Кадер кичәсендән кала Аллаһы кашында кадерле, әфзал кичәләрнең Шәгъбан аеның 15 нче кичәсе, ди. Икенче бер хәдис:
كلب بنى اعنام شعر بعدد الليلة هذه فى امتى يرحم الله ان
Шушы Шәгъбан аенда һәм Бәраәт кичәсендә шул кадәр кешеләрне рәхим-шәфкать итәр, ул кешеләрнең саны бәни кәльб куйларының төкләре-йөзләре сансыз булырлар, ди. (Әүвәл заманда Бәни кәльб кабиләсе куйларының күблеге һәм җөнләрының куелыгы белән мәшһүр булган). Тагын да бер хәдисендә үйтә:
الزنا المصحرعلى او الوالدين عاق او المشاحن او الساحر او الكاهن اللا الليلة هذه فى يعفر الله ان
Әгәр дә бу кичәдә ихлас белән дога вә гыйбадәт кылсалар, ягъни Рамазанның күршесе

булган Шәгъбан аенда һәм мөбарәк кичәдә бөтен кешеләрне ярлыкар, ди. Иллә мәгәр гөнаһларына үкенми, тәүбә кылмыйча, һаман да багучылык, күрәзәлек итүчене, сихерчене, озак дошманлык саклаб тотучыны, туктаусыз эчүчене, ата-анасын рәнҗетүчене, һаман да зина артындан йөрүче – (0678) шушы кешеләрне ярлыкамас, ди. Менә җәмәгать! Шушы Рамазанны каршылау алдында булган Шәгъбан аен шушы мөбарәк кичәләрдә чын ихласдан бәндәчелек, хаталык белән булган гөнаһларыбызга чын-чындан үкенеб тәүбә кылсак, бөтен гөнаһларыбыз ярлыканачак икән. Нинди зур сөенеч, шушындый яхшы айларны каршылау алдында шушындый зур сөенечләр вәгъдә ителә икән, шушындый Аллаһының зур рәхмәтдән мәхрүм калмаска тырышыйк. Форсатны, вакытны ганимәт булу диб, бер-беребез белән упкәләшкән икәнбез – бәхилләшик, телләребез белән, яки ничек кенә булса да берәүне рәнҗеткән икәнмез, - бәхилләшеб дуслашырга кирәк. Туганлар безнең хәлен белергә, ата-аналарыбыз бар икән, хатерләрен табарга, догаларда искә алырга тырышыйк, үлгәнләр икән, - аларга изге дога кылыйк. “Йә Рабб, ата-анамның гөнаһларын ярлыка”, - диб. Аллаһыдан аларның мәгъфирәт кылынуын , ярлыканавын сорыйк. Сүзебез үтәрдәй рәвешләребезме? Балаларыбызмы? Оныкларыбызмы? Мөмкин кадәр аларны яхшылыйк.
Хәзрәт рәсүл әйтә: Шушы кичәләрдә Аллаһы тарафындан бер фәрештә:
الليلة هذه في يركع لمن طوبى
،الليلة هذه يسجد لمن طوبى
، الليلة هذه في للذاكرين طوبى
، الليلة هذه في ربه دعا لمن طوبى
، الليلة هذه في تعالى الله خشية من بكى لمن طوبى
الليلة هذه في خيرا عمل لمن طويى
، الليلة هذه في القرآن قرأ لمن طوبى
سؤله فيعطى سائل من هل ، الملك ذلك ينادي ثم
دعاؤه له فيستجاب داع من وهل
له فيغفر مستغفر من وهل ؟ عليه فيتاب تائب من وهل
(0679) Ягъни: «Ни сөенеч рөкугъ кылучыларга, Ни сөенеч сәҗдә кылучыларга, Ни сөенеч Аллаһыны зикер итүчеләргә, Ни сөенеч дога кылучыларга, Ни сөенеч Аллаһыдан куркыб елаучыларга, Ни сөенеч яхшы эшләр кылучыларга, Ни сөенеч Коръән укучыларга, Моның соңында Аллаһы хан хаҗәтләрен сораб, Дога кылучылар бармы? – Сораган теләкләре кабул булыр, Тәүбә кылучылар бармы? Гөнаһлары ярлыканмыш булыр диб әйтелер, ди. Мөхтәрәм җәмәгать! Бәгъзе бер вәгазь китабларымызда шундый риваятьләр бар, шушы кичәдә барлык кылган яхшы, яман гамәлләремез исәбкә алыныр. Һәм киләчәк елда һәрбер күрәчәкләребез, ризыкларыбыз, гомерләребез билгеләнер. Шуның шушы кичәдә Аллаһыга түбәндәгечә дога кылырга тәусыя кылганлар:
ديوان في سعيدا اسمي كتبت كنت وان السعداء ديوان في واكتبني فامحه الأشقياء ديوان في شقيا اسمي كتبت كنت ان للهم
الكتاب ام وعنده ويثبت يشاء ما الله يمحو الكريم كتابك في قلت فإنك فأثبته السعداء
Ягъни: Аллаһы, әгәр минем исемемне явызлар дәфтәрендә язсаң, ул начарлар, явызлар дәфтәрендән минем исемемне бетер, алыб ташла. Әгәр минем исемемне яхшылар, изгеләр дәфтәрендә язган булсаң, шунда бөркет, шундан аерма. Нитәк Коръән Кәримдә теләгән адәмләрне җуясың, бозасың, теләгән адәмләрне беркетәсең. Аның хозурында Ләухель Мәхфуз.
(0680) Мөхтәрәм җәмәгать! Кыскача гына тәүбә догасын укыйк:
الله استغفرو - өч мәртәбә
انت انك اعلم لا الذى الذنب من و اعلم الذى الذنب من اليه اتوب و علانيه او سرا او حطأ او محمد اذنبته ذنب كل من تعالى

الذنوب عفار العيوب علام
Иляһи, әгәр минем телемдән вә күңелдән вә барча әгъзаларымдан олугъ вә кечкенә гөнаһлар садир булса, барчасындан кайтдым, тәүбә итдем, икенче эшләмәм, дибкасед вә гаһед итдем.
شره و خيره القدر و الآخر اليوم و رسوله و كتبه و ملائكته و بالله آمنت .اسوله و عبده محمدا ان اشهد و الله الا اله لا ان اشهد
.الموت بعد البعث و تعالى الله من
Мөхтәрәм җәмәгать! Тәүбә кылу хакында гафил булырга ярамый. Рәсүлулла (сгс) әйтә: Мин һәркөн Аллага йөз мәртәбә тәүбә кылам, дигән. Аллаһы дусты, сәййидел әнбия булган мөбарәк пәйгамбәр Аллага һәркөн шул рәвешле тәүбә кылса, безгә ни калды? Сирәк була торган Бәраәт кичәсе вә Кадер кичәсен генә көтеб гафил булырга ярамый. Бәлки һәр көндә, һәр кичәдә үзебезнең кимчелек вә хаталарыбызга чын күңелдән үкенеб, тәүбә кылу һәркайсыларыбызга бик тиешле булган күркәм эш.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ихлас белән кылган тәүбәләребезне кабул итеб, касдән вә хаталы булган гөнаһларыбызны гафу итеб, Үзенең изге вә салих бәндәләре җөмләсендән кылыб, Үзенең белән кубарылырга насыйб итсен. Амин.
(0681) Мәгънәсе: Аллаһы Тәбарәкә хәзрәтләренә (Аллаһыга иман китердем), ышандым, фәрештәләренә, Аллаһы китабларына, Аллаһының пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненең булачагына һәм булачак эшләрнең, тәкъдирнең һәркайсы Аллаһының теләве белән диб ышандым һәм үлгәндән соң терелеб, Аллаһы хозурына барыб, хисаб бирәчәгебезгә ышандым, иман китердем.
Аллаһы Раббел галәмин барчаларыбызга хакыйки иман насыйб итеб, Аллаһыга, пәйгамбәргә итагать кылыб, холәфә рашидин, сәләф салихин, голәмә гамилин юлы белән барыб, мөселман булыб үләргә, Аллаһының дустлары булган нәбиләр, садыйк шәһидләр белән бергә булырга насыйб итсен. Амин.
Аллаһыга итагать итү, фарыз важибләрне үтәү вә пәйгамбәремез сөннәтләренә да’имчелек һәм дини эшләребездә һәм дөньяви эшләребездә рәсүл Хода шулай булырга кушкан диеб, шундый ният белән булса, инша Алла, Аллаһыга, пәйгамбәргә итагать иткән адәмләр җөмләсендән булырмыз. Сүрәи “Ниса”, 67 нче аятьдә:
رَفِيقًا أُولَٰئِكَ وَحَسُنَ ۚ وَالصَّالِحِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصِّدِّيقِينَ النَّبِيِّينَ مِنَ عَلَيْهِمْ اللَّهُ أَنْعَمَ الَّذِينَ مَعَ فَأُولَٰئِكَ وَالرَّسُولَ اللَّهَ يُطِعِ وَمَنْ
Бу аятьнең сәбәбе нөзүле хакында Кубан (рг) рәсүл әкрамә мәхәббәте гаять зур булыб, рәсүлулладан аерылуга һич такать кылмас иде. Һәркөн рәсүл әкрам янына килеб, бик кайгылы рәвешдә күренде. Миңа нә улды? – диб. “Сезне бервакыт күрмәз исәм, кайгым, хәсрәтем арта, сезне мөштак булам (сагынам – А.Х.), Кыямәтне, Ахирәтне уйласам, хәсрәтем тагын да арта. Сез әнбияләр белән бергә булырсыз, мин сезнең белән була алмам. Әгәр, әлгыяз билләһи, җәһәннәмдә булсам, сезне бер дә күрмәм”, - диде. Бу турыда рәсүлнең хәдисе куәтле:
زمرتهم فى تعالى الله حشره قوما احب من
(0682) Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. (Шәгъбанның әүвәл яртысында)
Хәзрәти Гайшә (рг) риваять кылына:
في صياماً منه أكثر شهر في رأيته وما ،رمضان شهر إلا قط شهر صيام استكمل وسلم عليه الله صلى الله رسول رأيت ما
شعبان
Рәсүл (сгс)ның Рамазандан башка тулы ай руза тотканын күрмәдем, ди, һәм Шәгъбанаендан башка айларда Шәгъбандан күбрәк руза тотканын күрмәдем, ди. - Башка айларга караганда күбрәк Шәгъбан аенда нәфел рузалары белән мәшгуль булган икән. (Әүвәлге яртысында Шәгъбанның соңгы яртысына руза тоту кирәкле).
Инде мөхтәрәм җәмәгать!

Аллаhы Раббел галәмин хәзрәте күңелләребезне иман белән нурландырыб, Ислам дине үзрә сабит кылыб, ахыр дәмдә, ахыр сулуларымызда иманларыбызны юлдаш кылыб, Кыямәт көнендә Аллаhының дустлары, Аллаhының сөйгән коллары, пәйгамбәрләр, садыйклар белән мәҗлестдәш булырга Аллаhы насыйб итсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Күбчелек белән иман кәлимәләре укыб, иманларыбызны җаңартыйк.
Бисмилләhир Рәхманир Рәхим.
الموت بعد البعث و تعالى الله من شره و خيره القدر و الآخر اليوم و رسوله و كتبه و ملائكته و بالله آمنت
Габделхабир Ярулла.
(0683) 1392 нче Һиҗри, 14 нче Шәгъбан
1972 нче Миляди, 22 нче сентябрьдә, җомга көн.
Бисмилләhир Рәхманир Рәхим.
Ихлас күңел белән дога-гыйбадәт кылу өчен мәсҗед шәрифкә җыелган мөселманлар!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаhи вә бәрәкатуhу!
Җенабе Хак барчаларыбызның җомгага килүләребезне мөбарәк кылыб, Рамазандан кала мөбарәк ае Шәгъбан аен ихласлы гамәл-гыйбадәт белән уздыру насыйб булсын.
Хосусан Ислам галәмендә күб еллардан бирле мөбарәк кичәләрдән саналган Шәгъбан аеның бүгенге кичәбезгә тугъры килгән Бәраәт кичәсе вә бәйрәме җөмләбезгә мөбарәк булыб, шушы кичәбезгә моафыйк дөшдә хата вә кимчелекләребезгә чын күңелдән үкенеб, тәүбә-истигъфар кылыб, исемләребез җенабе Хакның сөйләгән мөэмин-мөслим коллары җөмләсендә күңелләребез иман-Ислам үзренә карарланыб, мөселман булыб яшәб, ахыргы сулуларыбызга саф иман белән дөньядан күчү насыйб булсын.
Мөхтәрәм мөселманлар! Миңа аз гына вакыт белән Уфага Диния нәзарәтенә барыб кайтырга тугъры килде. Аллага шөкер, сез мөселман кардәшләремезнең догасы берлегендәдер, юлларыбыз бик уңышлы булыб, сау-сәламәт әйләнеб кайттым. Мөфти вә казый хәзрәтләре һәм башка Нәзарәт хәдимләре белән күрешеб-утырышыб һәм мәсҗеддә булган кадәр Уфа мөселманлары белән күрешеб, сезнең тарафындан дога укыб, сәлам табшырдым. Шулай ук сез, мөселман кардәшләребезгә мөфти-казый һәм башка Нәзарәт хәдимләре һәм мәхәллә мөселманлары дога укыб, сәлам табшырырга кушдылар.
(0684) Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаhи вә бәрәкатуhу!
Хәзергә Нәзарәтдә тыныч кына мөттәфәт рәвешдә эшләрен дәвам итдерәләр. Нәзарәтдә зур гына ремонт эшләре, шулай ук мәсҗедләрдә төзекләндерү-төзәтү-тәгъмир эшләре алыб барыла икән. Мөфти хәзрәт белән утырышыбызда динебезне дәвам итдерү хакында, дин хәдимләрен хәзерләү хакында иҗтиhад кылырга, шушы хакында тиешле урынларга мөраҗәгать кылу хакында теләкләребез бар. Аллаhыны язгандыр: гомерләребез мөсагәдә (ярдәм – А.Х.) кылса диб. Киләчәкдә шул эшләргә тәшәббүс кылу (үҗәтлек; инициатива – А.Х.) теләгебез бик зур диб сөйләде. Казан мәхәлләсе, Казан мөселманларында Нәзарәт бик разый. Хәзерге хәлдә бөтен мәхәлләләр арасында Казан мәхәлләсе бөтен мөселманларга үрнәк булырлык беренче урында тора. Киләчәкдә дә шушылай өлфәт, мәхәббәт, иттифак белән динебезне дәвам итдерү насыйб булсын диб, догалар кылды.
Нинди күңелле, шадлыклы хәлләр, тагын да киләчәкдә динебезне куәтләб, динебез мәсҗедебезгә мәхәббәт итеб, матди-мәгънәви ярдәмләребезне арттырыб, hәр шәhәрдә яшәүче мөселманлар хәер дога вә рәхмәтләр ишетүгә моафыйк булырга насыйб булсын.
Мөхтәрәм мөселманлар! Шәгъбанның фазыйлеге әүвәлге яртысында руза булу хакында хәзрәти Гайшәдән шушы хәдис риваять кылына:
شعبان في منه صياما أكثر شهر في رأيته وما رمضان إلا قط شهر صيام استكمل وسلم عليه الله صلى الله رسول رأيت وما
Ягъни: рәсүл (сгс) не Рамазандан башка тулы ай руза тотканын күрмәдем, ди. Һәм

Шәгъбаннан башка айларда Шәгъбандан күбрәк фазыл рузасы белән мәшгуль булганын күрмәдем, ди.
(0685) 27 нче М., 17 нче декабрь
15 нче Шәгъбан, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аллаһының гыйбадәтенә җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм мөселманлар! Хөрмәтле Шәгъбан вә Бәраәт бәйрәме көне мөбарәк булсын! Дөнья Ахирәт сәламәтлеккә, тынычлыкка сәбәб булган мөкаддәс Ислам динендә яшәб, чын мөселман булыб, дөньядан үтәргә насыйб булсын.
قال رسول الله عليه و سلام حَقُّ الْمُسْلِمِ عَلَى الْمُسْلِمِ سِتٌّ ( قِيلَ مَا هُنَّ يَا رَسُولَ اللَّهِ : قَالَ ( إِذَا لَقِيتَهُ فَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَإِذَا دَعَاكَ فَأَجِبْهُ
وَإِذَا اسْتَنْصَحَكَ فَانْصَحْ لَهُ وَإِذَا عَطَسَ فَحَمِدَ اللَّهَ فَسَمِّتْهُ وَإِذَا مَرِضَ فَعُدْهُ وَإِذَا مَاتَ فَاتَّبِعْهُ
Ягъни: мөселман булган кешенең икенче бер мөселман өстендә алты хакы бар, ди. (إِذَا لَقِيتَهُ فَسَلِّمْ) Очрасаң, сәлам бир. (وَإِذَا دَعَاكَ فَأَجِبْهُ) Һәрвакыт зыяфәткә, кунакка чакыра икән, бар. (وَإِذَا اسْتَنْصَحَكَ فَانْصَحْ لَهُ) Нәсыйхать кылуыңны үтенсә, насыйхать кыл. (وَإِذَا عَطَسَ فَحَمِدَ اللَّهَ فَسَمِّتْهُ) Төчкереб, Аллаһыга хәмде әйтсә, җаваб бир. (وَإِذَا مَرِضَ فَعُدْهُ) Һәркайчан авырса, хәлен сора. (وَإِذَا مَاتَ فَاتَّبِعْهُ) Вафат итсә, җеназасына бар, озат.
“Хакдан” морад (шул эшне эшләү тиешле, матлуб) дигән сүз. Шуның өчен бу сүзнең астына вәҗебләр дә, сөннәт вә мәндүбләр дә керә. Беренче хак сәлам бирешү сөннәт гамәл булыб, һәр ике тараф берьюлы бирсә, шуның белән сөннәт хак (0686) үтәлгән була. Бер тараф соңга калса, соңга калган тараф сәлам алу, сәлам кайтару, җаваб бирү исемендә булыб, фарыз хөкеменә керә. (السلام) сүзе, Аллаһы Тәгалә исемнәрендән булыб, сәлам бирү. Аллаһының исеме сезнең берлә, сез Аллаһының хифезендәсез (хәтерендә – А.Х.), димәктер. Вә бәгъзе галимләр: “сәлам” сүзе “саламәт” сүзеннән алыныб, сезгә сәламәтлек, минем тарафымдан сезгә һич зарар юк, тыныч булыгыз диб, һәр ике сүздә күб аерма булмыйча, һәрхәлдә бер-береңә дога кылышу булыб Ислам диненең күркәм гадәтләрендән булган бер шигардыр. Сәлам бирү: әссәләму галәйкум, сәламун галәйкум, әссәламу галәйк, сәламун галәйк. Шушы кайсы белән әйтелсә, сәлам бирү гадәте табыла. Соңга калган тараф сәлам кайтаручы, алучы, җаваб бирүче (Вә галәйкумус сәлам, вә галәйкәс сәлам) рәвешендә үтәү – һәр икесе дөрест булыб, сәлам кайтару табыла.
Иң яхшысы – безнең арабызда әйтелә торган “Әссәламу галәйкум”, “Вә галәйкумус сәлам” сүзләр булыб, кирәк күб кешеләргә, кирәк аз, кирәк ир кеше, кирәк хатын кыз булсын, шушылай әйтү иң матуры, иң гүзәле. Җәмгы сыйгасе белән әйтү ирләрнең ирләргә, хатынларның хатынларга һәм мәхрәм, кардәшләргә. Ягъни туганларыбызга барыб керәбез икән, өй эчендә бер дә ир булмаса да, сәлам бирү тиеш икән, сәлам бирүнең тәртибләре: олы яшьтәгеләргә яшьрәкләр, утырыб торучыларга узыб баручылар, атланыб яки утырыб баручылар җәяүлеләргә, аз кешеләр күб кешеләргә, наданрак кешеләрнең галимләргә бирүе тиеш. (0687) Күб кешеләр арасыннан бер кеше сәлам бирсә, шуның белән дә үтә ала, әмма һәрберсе бирсә, яхшырак була. Һәм кайтаруда шулай ук. Факиһләр: шушы вакытларда, шушы урыннарда сәлам бирүне мәкруһ күргәннәр: хөкем залына кергәндә, хөкем барса, дәрес мәҗлесенә, Коръән уку вә зикер мәҗлесләренә, хотбә, азан, камәт укылган вакытларда, мунча вә каза, хаҗәт кебек урыннарда, гомумән берәр төрле нәрсәләр белән мәшгуль, шөгыльле адәмләр янына кергән вакытда.
(0687) Хәзрәт рәсүлгә бер ир килеб: “Әссәләму галәйкум!” – диде. Рәсүлулла сәлам кайтарыб: “Сиңа ун изгелек булды”, - диде. Икенче ир килеб: “Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаһ” дигәннең соңында рәсүл сәлам алыб: “Сиңа егерме изгелек язылды”, - диде.

Өченче бер ир килеб: “Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаhи вә бәрәкатуhу”, - диб сәлам биргәннең соңында хәзрәт рәсүл сәлам кайтарыб: “Сиңа утыз изгелек булды”, - диде. Ибн Габбас (рг)гә килеб бер ир: “Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаhи вә бәрәкатуhу” дигәннең соңында Ибн Габбас (рг): “Сәламнең ниhаятенә җитдек”, - диде. Әгәр бер кеше “Әссәләму галәйкум” диб сәлам бирсә, алучы: “Вә галәйкумус сәлам вә рәхмәтуллаh”, диб “рәхмәтуллаh” сүзен артдырса мөстәхыйб гамәлне арттырган булыр. Әгәр “Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаhи” диб сәлам бирсә, “Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаhи вә бәрәкатуhу” диб әйтү мөстәхыйбне арттырган сәламнең чиге шул. Моның өстенә башка, үз өеңгә кайтып керәсеңме, яки башка туганларың, мәхрәм кардәшләрең өенә барасыңмы, ирләр булмаса да, хатын-кызлар гына булса да, сәлам бирү – сөннәт. Өйгә кергәндә: ата-анаң яки балаларың, кызларың, мәхрәм, кардәшләрең булса, (0688) шуларга сәлам бирү – сөннәт. Һәм шул хатын-кызларның сәлам алулары тиеш. Өеңгә яки мәсҗедгә кергән вакытда hичкем булмаса, яки намаз укучылар булса, шул вакыт: “Әссәләму галәйна вә галә гыйбәдилләhис салихин” диб тиеш икән.

Шулай ук, җәмәгать! Очраганда сәлам бирү сөннәт булган шикелле, аерылышкан вакытда да сәлам биреб алышу – сөннәт икән. Хәзрәт рәсүлнең:

الكبر من برء بالسلام البادئ

дигән hәм:

تحابوا بينكم السلام افشوا

Арагызда сәламне фаш кылыгыз, мәхәббәтегез артыр дигән сүзләре – бик хикмәтле сүз. Әгәр дә берәү кычкырыб, я каты чырай белән сәлам бирә икән, чындан да бу җанларны рәхәткә күтәреб җибәрә торган бер яхшы гадәт. Тагын да хәзрәт рәсүлнең бер мөбарәк сүзен-гыйбарәсен әйтми генә, искә алыйк: “Әгәр ике мөселман бер-берсенә йолыксалар, очрасалар, сәлам биреб, кул биреб күрешсәләр, бу кешеләрнең гөнаhлары бармак араларындан коелган кебек, боларның хаталарын, гөнаhларын гафу итәр”, - ди. Ислам дине hәрвакыт дустлыкка, тынычлыкка, бер-берең белән өлфәт-мәхәббәтле булыб яшәргә чакыра торган дин.

Шулай ук, җәмәгать! Хатларга каршы язылган сәламләргә бер-беребезгә сәламәтлек теләб язылган хатларга каршыда җаваб бирү тиешле, важиб булган гадәт. Хәзрәт рәсүл әйтә:

الموكل الملك قال لأخيه دعا كلما ،به موكل ملك رأسه عند ،مستجابة الغيب بظهر لأخيه المسلم المرء دعوة

(0689) Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам дине адәм балаларын татулыкка, тынычлыкка, бердәмлеккә чакыра, дидек. Бу сүзебезне инде беркадәр дәлилләр белән исбат кылырга кирәк. Ислам сүзенең төб мәгънәсе: “сәламәтлек” сүзендән алыныб, Аллаhы Тәгалә “Маидә” сүрәсендә әйтә:

دينا الاسلام لكم رضيت و

Ягъни: сезгә дин итеб Ислам динен кабул итдем. Ислам динендә булуыгыздан разый булдым.

الاسلام الله عند الذين ان

Дөрестлектә Аллаhы кашында хак дин – Ислам дине генә, ди.

“Бәкара” сүрәсендә 112 нче аятьдә әйтә:

يَحْزَنُونَ هُمْ وَلَا عَلَيْهِمْ خَوْفٌ وَلَا رَبِّهِ عِندَ أَجْرُهُ فَلَهُ مُحْسِنٌ وَهُوَ لِلَّهِ وَجْهَهُ أَسْلَمَ مَنْ بَلَىٰ

Бәлә (Әйе – А.Х.), берәү вә изге эшләр эшләб дә үзене Аллаhыга тапшырса, ул кешегә Раббысы каршында зур әҗере булыр hәм Кыямәт куркыныч юк, hәм кайгырмаслар, ди. Һәм хәзрәт рәсүл әйтә:

يده و لسانه من المسلمون سلم من المسلم

Ягъни: мөселман – шул кеше, кем мөселманлар белән телендән дә, кулындан да

исәнләшсә, кем кулы белән дә, теле белән дә кешене рәнҗетмәсә, ди.
Һәм "Юныс" сүрәсендә, 25 аятьдә әйтә:
السلام دار الى يدعوا الله و
Ягъни: җенабе Хак сезне дөнья Ахирәтдә тынычлыкка, сәламәтлеккә, татулыкка, бердәмлеккә чакыра. Һәм Аллаһының газабындан амин булыб, рәхәт йорты булган Җәннәт йортына чакыра, ди. "Әссәләму галәйкум" диб, бер-беребезгә сәлам бирешүләребездә мәгънәсе: татулык, сәламәтлек сиңа, без тату булырга тиешбез.
(0690)
ذلك بمثل لك و آمن الملك قال
Ягъни: Ир кешенең кардәшенә читдән торыб хәер дога кыла икән, ул кешенең догасына фәрештә "амин" диб торыр, һәм кардәшеңә ничек дога кылсаң, сиңа да шулай ук булсын.
يرد لا بظهرالغيب لاخيه الاخ دعاء
Кардәшнең кардәшкә, бер адәмнең икенче адәмгә артында кылган догасы һичшиксез кабул булыр, ди.
Хасыйлел кәлам, җәмәгать! Бер-беребезгә очраган вакытда сәлам бирешү бер дә авыр эш түгел. Исламның күркәм гадәтләрендән булган шушы гүзәл, күркәм холыкны таныш булганларга да, таныш булмаганларга да сәлам бирергә гадәт итик.
Бөек адәмләрдә, гали холыклы кешеләрдә зур бәйрәмләрдә сәламәтлек, тынычлык белән хәерле гомер теләб, хатлар язу, телеграм җирү гадәтләре бар. Безнең мәсҗедебезгә дә бөтен мөселманларыбыз исеменә бик күб җирләрдән телеграмлар килде һәм үзебездә, Мәрҗани мәсҗедендә гыйбадәт кылучы бөтен мөселманлар исемендән шуларга җаваб йөзендән телеграмлар бирелде. Берсен генә укыб күрсәтим.
"Аллаһы Тәбарәкә бер-беребезгә артыбызда кылган догаларыбызны кабул итеб, барчаларыбызга сәгадәт дарәйн (ике дөньяда бәхетенә) ирешергә насыйб итсен.
(0691) 1967 нче ел, 1 нче декабрь. Шәгъбан ае, 29ы.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Шәгъбан аеның ахыры җомгасы мөбарәк булсын!
Мөхтәрәм җәмәгать! Мөбарәк Рамазан аеның ишек төбенә, кабкасына аяк бастык. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, шушы мөбарәк, хөрмәтле аеның кадерен, хөрмәтен белеб ихтирам итәргә, үлем килмәсдән ул тереклегебез, авыру-сырхау килмәсдән элек сәламәтлегебезнең кадерен белеб, ганимәт (уңыш, бәхет – А.Х.) белеб, киләчәгебез өчен өлеш алыб, әҗер вә сәвабларга ирешергә Аллаһы насыйб итсен. (Амин).
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре Коръәндә "Бәкарә" сүрәсендә әйтә:
تتقون لعلكم قبلكم من الذين على كتب كما الصيام عليكم كتب آمنوا الذين ايها يا
Ягъни: И, иман китергән бәндәләр! Сезгә руза фарыз кылынды. (قبلكم من الذين على كتب كما) Ул руза сездән әүвәлдәге өммәтләргә дә фарыз кылынган иде. (تتقون لعلكم) Шәед ки, сез Аллаһының руза тоту белән кушкан, боерган җиренә җиткереб, ягъни руза тотыб, Аллаһыга тәкъвалык кылырсыз.
Мөхтәрәм җәмәгать! Руза гыйбадәте бездән элек килгән өммәтләргә дә фарыз булган. Адәм (гс)гә ( بيض ايام) көнләре, айның унөченче, ундүртенче, унбишенче көнләрнедә руза тоту фарыз булган. Муса (гс)гә Гашурә көнендә руза тоту фарыз булган. Әмма Мөхәммәд (сгс)нең өммәтенә (معدودات اياما) мәгълүм булган сан белән һәр елда Рамазан рузасы фарыз кылынган.

(0692) Сүрәи “Хәҗер”, 9нчы аять:
الرحيم الرحمن الله بسم
لَحَافِظُونَ لَهُ وَإِنَّا الذِّكْرَ نَزَّلْنَا نَحْنُ إِنَّا
Мөхтәрәм мөселманлар! Руза тоту мәкруһ вакытлар, көнләр бар. Җомга көнендә генә хаслаб ли-каулиһи (гс):
بَعْدَهُ أَوْ قَبْلَهُ تَصُومُوا أَنْ إلا تَصُومُوهُ فَلا عِيدُكُمْ الْجُمُعَةِ يَوْمَ
(Сахихин). Шимбә хаслаб руза тоту хакында:
عليكم افترض فيما الا السبت يوم تصوموا لا
) Тирмизи хәзрәтләре).
تصوموا فلا شعبان انتصف اذا – Шәгъбанның икенче яртысында.
القاسم ابا عصى فقد الشك يوم صام من (Бохари).
Хатын кешенең ире ризалыгыннан башка.
(0693) Руза фарыз булуның хикмәте нәфесне газаблау, җәзалау түгел, бәлки Аллаһыга тәкъвалык кылу, нәфескә хуҗа булырга өйрәнү күнегү өчен. Аллаһының бәндәләрен фарыз, важиб әмре вә нәһиләрендә – һәрберендә тәгъзыймел Өлүһият вә тәһзиб инсаният кебек мөһим мәслахатләрне искә алыб, шуларга нигезләнмешдер. Нәфес, һәва, шәйтан – һәркайсы, әгәр аларга хуҗа була алмасак, адәм баласын дөнья Ахирәт һәлакәт-хәраблык чокырына, үкенечкә калырга сәбәб була торган куркыныччлы дошманлар. Зур галимләр нәфес – һәва – шөһрәтне адәм баласының атланган атына охшатканлар. Әгәр дә атланган атың яхшы, таза җөгән (уздечка – А.Х.) белән нык авызлыкланган булса, син аңа чын-чын хуҗа булыб, теләсәң – уңга, теләсәң – сулга, теләсәң – чабтырасың, теләсәң – туктатасың. Шуның нәфсеңгә син хуҗа була алсаң, яхшы авызлыкланган атка атланган кебек, бөтен-бөтен яхшылыкларны кылу, яхшы юлда йөрү, бөтен бозыклыклардан тыела ала, әгәр адәм баласына нәфсенә хуҗалык булмаса, ул нәкъ җөгәнсез, усал атка атланган шикелле, ул аны теләгән җиренә алыб бара алмый, кирәк вакытда туктата алмый, ул сине һәртөрле начар-ялганда сөйләтә, гайбәтдә сөйләтә, адәмләр арасына һәр фетнә салырга котырта, араларын бозыштырыб, бер-берсенә дошманлаштырыб, гөнаһ сазлыгына батырыб, дөнья Ахирәтдә үкенечкә калдырыб, һәлак итә. Бәгъзе вәгазь китабларыбызда шундый риваятьләр бар:
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә гакылны яратканнын соңында гакылдан хыйтаб кылыб сорый: (انت؟ من انا؟ من) Мән ана? Мән әнта? – диб. Гакыл шул Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә җаваб биреб:
العلمين رب انت و الضعيف عبدك انا
(0694) – диде. Нәфесне яратканның соңында хыйтаб кылыб әйтә:
انت؟ من انا؟ من - диб. Шул нәфес: انا – انا، انت – انت – диб, шул Аллаһының изене белән нәфес күб еллар ут газабы белән газаблана, моның соңында Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тагын да хыйтаб кылыб сорый:
انت؟ من انا؟ من Нәфес һаман да шул ук җавабны бирә, ягъни: «Син – син, мин – мин», диб. Монсында Аллаһының әмере – күб еллар ачлык белән газаб кылынганның соңында тагын да Аллаһы тарафындан хыйтаб кылына: син кем, мин кем, диб. Шушының соңында нәфес:
العلمين رب و خالق انت و الضعيف عبدك انا
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһының мөэминләргә рузаны фарыз кылудан максад – үзеңнең нәфсеңгә хуҗа булырга гадәтләндерү, күркәм холыкларга, яхшы эшләргә гадәтләнү, начар, бозык эшләрдән үзеңне тыярга өйрәнү. Рәсүл (сгс) әйтә:
إِنِّي ، صَائِمٌ إِنِّي : فَلْتَقُلْ ، عَلَيْكَ جَهِلَ أَوْ أَحَدٌ سَابَّكَ فَإِنْ ، وَالرَّفَثِ اللَّغْوِ مِنَ الصِّيَامُ إِنَّمَا ، وَالشُّرْبِ الأَكْلِ مِنَ الصِّيَامُ لَيْسَ
صَائِمٌ

Ягъни ашау-эчүдән тыелыб тору гына руза булу түгел, бәлки руза моның өстендә, ягъни сез файдасыз сүзләрдән гайбәт сүз йөртү, бөтен начарлыклардан тыелу. Әгәр бер кеше сине сүксә, берәр төрле наданлык күрсәтсә, син аңар әйт: “Мин рузада” – ике мәртәбә, яки күңелеңнән шулай уйла да, дәшмә! Тагын да рәсүл (сгс) әйтә:
وَالنَّصَبُ السَّهَرُ إِلَّا قِيَامِهِ مِنْ حَظٌّ لَهُ لَيْسَ قَائِمٍ وَرُبَّ ، وَالْعَطَشُ الْجُوعُ إِلَّا صَوْمِهِ مِنْ حَظٌّ لَهُ لَيْسَ صَائِمٍ رُبَّ
Ягъни: күб адәмләрнең рузалары ач торудан гыйбарәт. Кичәләрдә намаз укучыларның, йокы калдырыб гыйбадәтләре йөкламаудан гына гыйбарәт, ди. Хасыйлель кәлам, руза тотудан теләк һәрвакыт Аллаһының ризасын истәб, бөтен бозыклыклардан тыелыб, бөтен яхшылыкларны кылырга гадәтләнү. Рамазан чыкканның соңында да шушы гадәтләрне ташламау, үлгәнче (0695) әмер вә нәһиләрне үтәргә тырышу – бөтен мөэмин мөселманларның бурычы.
Аллаһы Раббел галәмин барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, күңелебезгә килгән һәртөрле шик-шөбһәләрдән вә һәртөрле шәйтан вәсвисәләрендән (нашептываний, наущений – А.Х.) саклаб, өстебезгә бурыч булган әмер вә нәһиләрне үтәргә тырышыб, Аллаһы тәкъва бәндәләре җөмләсендән булырга насыйб итсен. Амин.
Имам-хатыйб: Габделхабир Ярулла әл-Казани.
(0696) “Бәкарә” 220: الخمر عن يسئلونك
“Ниса’ ” 50 нче аять: الصلوة تقربو لا
“Ма’идә” 155 аять: منتهون انتم فهل
“Әлгыйман” 19 нчы аять; “Әнбия” 45 нче аять; “Ганкәбут” .
(0697) 6 нчы рәкымлы Дәфтәр
1967 нче ел, декабрь. (Вәгазь дәфтәре). №6
Рамазан рузасы хакында җомга вәгазләре.
(0698) Мөхтәрәм җәмәгать! Бүген дә сөйләнәчәк сүзләребез инсаният галәменең, кешелек дөньясының яртысын тәшкил иткән хатын-кызларыбызга Ислам дине тарафындан бирелгән хокуклар, Ислам дине аларны кимсетмәве, бәгъзе бер урынларда ирләрдән артыграк дәрәҗәләр бирелүе хакында булачак.
وَرُبَاع وَثُلَاثَ مَثْنَى النِّسَاءِ مِنَ لَكُمْ طَابَ مَا فَانْكِحُوا
диб әйтелгән икән. Бу яшь ятимләрне картларның рәнҗетеб никяхлануы хакында әйтелгән.
تعدلوا لا ان حفتم فان - гаделлек кыла алмасагыз, (فواحدة).
تقولوا لا ان ادنى ذلك – гаделлек кыла алмабыз диб курыксагыз, иң артыгы гаделлеккә иң якыны, ди.
Сәфәр хакында.
صدِّيقًا سبعينَ كعملِ المؤمنةِ المرأةِ برَّ وإنَّ ، فاجرٍ ألفِ كفجورِ الفاجرةِ المرأةِ فجُورَ إنَّ
дигән хәдисдә бар.
Күб хатын алу хакында төрле сәбәбләр белән рөхсәт кенә: авырулык, бала табмау:
بالنكاح الرزق التمسوا
Габделһади хәзрәт Газыймҗан угълы.
(0699) Ирнең хакы: киемен юар, урынын җыяр, малын саклар, ир рөхсәтендән башка чыгыб йөрмәс, иренә матур, ямьле күренергә тырышыр. Ашын пешерер, балаларын тәрбия кылыр. Белмәгән нәрсәләрен өйрәтү.
Хатынның хакы: дәрәҗәсенә кием кидерү, ризыкландыру. Тату тору, урын җирләре булдыру, диндә кирәк нәрсәләргә өйрәтү, җәбер-золым итми, сабырлык белән булу.
ساقط وشقه القيامة يوم جاء بينهما يعدل فلم امرأتان الرجل عند كان إذا
Әгәр бер ирнең ике хатыны булыб та, араларында кием-салым, ашау-эчү – бөтен тормыш

кирәкләрендә тигезлек кылмаса, Кыямәт көнендә ярты ягы корган (паралич суккан) хәлдә кубырылыр, ди. Шундый рәвешле.

Ниндидер сәбәбләр белән авыру яки бала китермәү сәбәбле икенче хатын алынган икән, бу кешегә рәсүлулла тарафыннан әйтелгән: нәсыйхәтләрне һәрвакыт хәтердә тотыб, Кыямәт көнендә хурлыклы хәлгә калудан саклану өчен мөселман мөселман адәмнең иң беренче бурычы булырга тиеш.

(0700) 1967 нче ел, декабрь. 6 нчы Рамазан, җомга көн.

Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аллаһының ризалыгын истәб, руза булган булыб гыйбадәт йортына җыелган мөселман кардәшләрем!

Рамазан шәриф аеның беренче җомгасы барчаларыбыз өчен мөбарәк булыб, барчаларыбызга саулык-сәламәтлек, тынычлык белән Рамазан рузасын үтәб вә башка изгелекләр кылыб, бәндәчелек бурычымызны үтәб, Аллаһының ризасына ирешергә насыйб булсын.

اعوذ بالله من الشيطان الرجيم. شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِيَ أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَى وَالْفُرْقَانِ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ وَمَن كَانَ مَرِيضاً أَوْ عَلَى سَفَرٍ فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ يُرِيدُ اللّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلاَ يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُواْ الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُواْ اللّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ.

(сүрә “Бәкарә”).

(شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِيَ أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآن) – ягъни шундаен ай – Рамазан ае, ул айда Коръән иңдерелде, Аллаһы тарафыннан Коръән күндерелде.

(هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَى وَالْفُرْقَان) – арганлык юлыннан һидаять юлына күндерә торган ачык галәмәтләр һәм хак белән батыйнны аера торган заһир галәмәтләр булганы хәлдә. (فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ) – Бәс бер кеше сезләрдән Рамазан аена хәзер булса, ягъни руза тотарлык хәлдә Рамазанга ирешсә, руза тотсын. (وَمَن كَانَ مَرِيضاً أَوْ عَلَى سَفَرٍ) – Бер кеше авыру булса яки бик мәшәкатьле сәфәр хәлендә булса, (فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ) – бәс ул кешеләргә, авыру һәм сәфәрдәге кешеләргә Рамазан аеннан башка көннәрдә булыр, ягъни терелгәннең соңында яки сәфәрдән кайткач (0701) каза кылыр. (يُرِيدُ اللّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلاَ يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ) – Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре сезгә бер вакытда да авырлыкны теләми, һәрвакыт йиңеллекне тели, ягъни авыру кешеләргә, мәшәкатьле сәфәрдә, юлда булган кешеләргә руза тоту белән көчләми. (وَلِتُكَبِّرُواْ اللّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ) – Үзегезне юкдан бар кылган Раббыгызны олылыкламагыз (?), тәгъзыйм өчен сезне Үзе разый булган һидаять юлына күндерде. Шәед ки, шушы Аллаһының сезгә күрсәткән юлларына, һәртөрле нигъмәтләренә шөкер кылырсыз, ди.

Мөхтәрәм җәмәгать! Руза гыйбадәте адәм балаларына үз-үзен газаблау, җәбер-золым диб уйларга ярамый. Сүрә “Бәкарә”дә 286 нчы аятьдә Аллаһы Тәбарәкә ә Тәгалә:

لا يكلف الله نفسا الا وسعها

диб әйтеб тора, ягъни Аллаһы Тәгалә һичкемне көчләмәс, мәгәр көче җиткән кадәр белән генә боерыр.

Сүрәи “Ниса”дә 27 нче аятьдә:

يريد الله ان يحفف عنكم و خلق الانسان ضعيفا

Ягъни: Аллаһы Тәгалә сезгә әхкам шәрифне, шәригать хөкемләрен инсанияткә җиңеләйтергә тели: (و خلق الانسان ضعيفا). Адәм баласы зәгыйф яратылгандан, табигатенә авыр килгән эшләргә китерә алмый. Бу аятьләрдән аңлана ки, Рамазан рузасы чын сау-сәламәт кешеләргә фарыз була. Әгәр бер кеше авыру булыб, руза тоту сәбәбле авыр кичерсә, шәригать рөхсәт бирә торыб та, шул эшне эшләсә, Аллаһы кашында мәсъүл булырга мөмкин. Ислам шәригате авыру кешеләргә, бала имезүче хатыннарга, әгәр баласына зарар килерлек булса, шулай ук йөкле хатынларга, корсагындагы баласына зарар

килерлек булса, бик артык карт кешеләргә, бик каты авырса, (0702) эшләб сәламлегенә зарар килерлек булса, шәригать рөхсәт итә. Авыруларга, юлдагы кешеләргә, бала имезүче, йөкле хатынларга рөхсәт итеб, соңындан казасы тиеш була.
Мөхтәрәм мөселманлар! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең мөселманларга рузаны фарыз итүнең бик күб сәбәбләре бар: рузаның беренче сәбәбләрендән тәннең сәламәтлеге, әгъзаләрнең ял итүе. Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкер әйтеб, нәфсә (нәфескә – А.Х.) сабырлыкны өйрәтү һәм нәфескә хуҗа булырга гадәтләнү. Бай, фәкыйрь, патша, вәзир, түрәләр һәм хезмәткәр – бар да Аллаһы кашында бертигез, бер дәрәҗәдә икәнлекне искә төшерү, нәфсеңә хуҗа булыб, инсанияп галәменә файдалы булган бөтен гадәтләргә күнектерү, инсаният галәменә зарар китерә торган җәбер-золым, исреклек, бер-береңбелән бәйләнү, кычкырышу, талашу кебек бөтен начар гадәтләрдән үзеңне биздерү, пакьләү, һәрбер яхшы гадәтләрне фәкать Аллаһы ризасы өчен диб эшләргә, бөтен начарлыклардан Аллаһы ризасы өчен тыелырга, үзеңне гадәтләндерү. Менә шушы эшләр, һәркайсы, Ислам диненең чын күрсәткән юлы, рухы, рузадан максад булган тәрбиянең нигезе.
Мөхтәрәм җәмәгать! Хәзрәт рәсүлнең мөбарәк сүзе:
به فارفق الله إلى مطيتك نفسك
Нәфсең – синең атланган атың, аңа йомышак кыл, ягъни аны дөрест тәрбияли белеб, сәгадәт дарәйн өчен файдалана бел. Ягъни нәфесебезгә дөрест хуҗа була белсәң, ул безне дөнья бәхеткә, рәхәткә ирештерәчәк. Чөнки безнең Аллаһы кашында сәваблы булуыбызда нәфес аркасында халәл кәсеб итүебез, мал табуымыз – бар да нәфес сәбәбле. (0703) Һәм өйләнеб гаилә тормышы коруыбызда – һәркайсы нәфес сәбәбле. Фәрештәләр дә нәфес юк, ирлек-хатынлык, кәсеб итү дә юк. Менә без шушы үзебезнең дөньяви тормышыбызда Аллаһы хозурына барыб, хисаб бирүне һәрвакыт исдә тотыб, нәфсебезгә хуҗа булыб, һәрвакыт дөрестлекдә булыб, ялган, хыянәт, алдау, җәберләү кебек инсаният галәменә зур зарар китерә торган начар гадәтләрдән саклансак, руза тоту – безнең җимеше хасыйл булыр. Әмма руза тотыб да, һаман да начар гадәтләремезне ташламасак, менә без бу рузабездә зур файда итә алмабыз.
Имам Бусыйри хәзрәтләре нәфесне тәрбияләү хакында түбәндәге матур сүзләрне әйтә:
ينفطم تفطمه وإن ،الرّضاع حبّ ... على شبّ تهمله إن كالطّفل والنّفس
Нәфес яшь бала кебек, ирек бирсәк, җегет булганчы, ягъни шабб (яшь егет – А.Х.) булганчы ими имәр. Әгәр имидән аерсак, туктар, ягъни имидән бизәр.
النهيم شهوت يقوي الطعام ان
Тамак туклык (туклыгы – А.Х.) комсызның шәһвәтене көчәйтә генә.
شهوتها كسر بالمعاصى ترم فلا
Көтмәмен андан әгәр гөнаһ кылырга ирек бирсәң,
Начарлык кылырга шәһвәте, теләве киселер, диб.
Шулай булгач, нәфескә теләгәнчә ирек биреб, бөтен начарлыклар, гөнаһлар белән төязеб өйрәтсәк, аны җиңгәрем (җиңәрмен – А.Х.) диб уйлама, ул сине дөнья Ахирәтдә хурлыкка өстери һәм бәхетсезлеккә этә. Гакыл ияләре әйткәнләр: әгәр нәфес ач булса, гакыл тук була, өстен була, хаким була. Әгәр нәфесне йөртсәк тук, гакыл мәхкүм була, нәфес хаким була, - дигәнләр.
Мөхтәрәм җәмәгать! Сәййидел әнбия булган мөбарәк пәйгамбәребезнең мөбарәк сүзләре белән сүземне тәмамлыйм: (0704)
السهر الا قيامه من له قائم رب ،الجوع الا صيامه من ليس صائم رب :السلام عليه قال.
Ягъни: бәгъзе бер кешеләр бар, аларның рузалары бары ач тору гына. Шулай ук бәгъзе бер

кичләрдә намаз укучылар бар, бары аларның намаз укулары җокы калдыру гына. Менә бу хәдис намаз укыб да, руза тотыб да, начарлыкдан тыелмаган кешеләр хакында әйтелгән сүз.
Мөхтәрәм җәмәгать! Руза тотыб да, намаз укыб да, телләребезне гайбәтдән, ялгандан, сүз йөртеб адәмләр арасында бозышдырыб, һәртөрле күңелсез хәлләргә, фетнәгә сәбәб булган эшләр белән мәшгуль булсак, Алла сакласын, тоткан рузаларыбыз, укыган намазларыбыз җилгә очар.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга бөтен начар гадәтләремезне ташлаб, тоткан рузаларыбыз, укыган намазларыбыз утдан пәрдә булыб, чын мөселман булыб яшәргә, чын мөселман булыб үләргә насыйб итсен.
(0705) 1967 нче ел, 15 нче декабрь. 13 нче Рамазан, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! 68нче елда беренче җомгада Рамазан шәриф аеның 2нче җомгасы барчаларыбызга мөбарәк булсын. Рамазан мөбарәкдә илләребез, җанларыбыз тыныч, тәнләребез сәламәт, бердәм булыб, кылган гамәлләребез, теләгән теләкләребез кабул булыб, сәгадәт дарәйнгә ирешергә насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Исламның бинасы, рөкене, нигезе булган руза гыйбадәте безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс)гә генә хас гыйбадәт түгел. Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс) гә кадәр килгән, бөтен сәмави динләрдә мәшругъ, ягъни тиешле гыйбадәт булмыш. “Бәкарә” сүрәсендә Аллаһы хәзрәте әйтә:
قبلكم من الذين على كتب كما
Ягъни: бу руза гадәте, руза тоту сездән әүвәлдә килгән өммәтләргә дә фарыз ителгән иде, ди. Адәм пәйгамбәрдән башлаб безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс)гә кадәр күб пәйгамбәрләр булса, һәр кайсының шәригатендә руза гыйбадәте булган. Руза гыйбадәтенең рәвеше бөтен сәмави динләрдә һич үзгәрешсез. Ягъни таңдан кояш баеганга кадәр, ягъни барлык нәфескә бик моафыйк булган ләззәтләрдән тыелыб тору булган, әмма үзгәреш шунда, бәгъзеләр айның төрле көнләрнедә 3 яки 4 көн, бәгъзеләре айның башында һәм ахырларында беренче көн руза тота торган булганлар. Һәркайсы Аллаһыны берләб, фәкать Аллаһы ризалыгы өчен генә шушы гыйбадәтне үти булганлар. Менә рәсүл (гс) дә Рамазан рузасы фарыз булганга кадәр һәр айда Мәдинәгә күчкәнче, һәр айда 3-4 көн һәм Гашурә көнләрендә руза тота торган булган.
(0706) 1968 нче елның 22 нче ноябрендә Рамазанның беренче җомгасында сөйләнде (1388 нче Һиҗри, 3нче Рамазан). “Узган ел сөйләнгән вәгазь”.
(0707) Һәм Мәдинәгә килгәч, беренче иңгән сүрә – “Бәкарә” сүрәсе 1185 сәнадә назел булгач сөйләнгән:
فليصمه الشهر منكم شهر فمن
аяте белән Рамазан аенда руза тотучы мөгәйәт өчен фарыз булыб, рәсүл (гс) һәм сәхабәләр белән берлекдә бөтен җәмәгать бердәм рәвешдә руза тота башлыйлар (разый Аллаһ ганһум вә рәхмәһум Аллаһ Тәгалә).
Аллаһының бу әмерендdә Аллага вә рәсүленә генә булган хикмәт вә маслихәтләр вә серләр әлбәттә булырга тиеш.
Коръән Кәримнең тәгълиме өйрәтүе буенча: җәмәгать һәм җәмгыять булыб бердәм рәвешдә эш кылу гаять дәрәҗәдә мактаулы бер сыйфат вә дәрәҗә булыб тора. Шунлыкдан Ислам дине буенча һәрбер хәер эшне, яхшы эшләрне, дөнья Ахирәт инсаният галәменә файда китерердәй эшләрне җәмгыят белән эшләү зур мактаулы эш санала.
Хәзрәт рәсүл (гс):

هُدًى عَلَى إِلَّا أُمَّتِي يَجْمَعَ لَنْ اللَّهَ فَإِنَّ ، بِالْجَمَاعَةِ فَعَلَيْكُمْ ، ثَلَاثَةٍ مِنْ خَيْرٌ وَأَرْبَعَةٌ ، اثْنَيْنِ مِنَ خَيْرٌ وَثَلَاثٌ ، وَاحِدٍ مِنْ خَيْرٌ اثْنَانِ
Ягъни: бер кешегә караганда ике кеше хәерлерәк, ди. Ике кешегә караганда өч кеше хәерлерәк, ди. Өчкә караганда дүрт кеше хәерлерәк, ди. Шулай булгач, һәрваыт җәмәгать белән бергә булыгыз, күбчелекдән, җәмәгатьдән аерылмагыз. Минем өммәтемне җыймас, иллә мәгәр җиде нәрсә, алар һидаятькә, тугърылыкка дөреслек тарафында гына булалар, ди.
Тагын да хәзрәт рәсүл (гс) әйтә:
الجماعة مع الله يد
Аллаһы рәхмәте – җәмәгать үзрә, ди. Аллаһы кәламе, Аллаһының рәсүле һәрвакыт, һәр урында иттифакка, берлеккә, дуслыкка, татулыкка, тынычлыкка чакыра.
(0708) Мөселман булган кеше, исламча яшим, исламча эшлим, исламча гыйбадәт кылам дисәң: بالجماعة فعليك
Һәрвакыт җәмәгать белән бергә бул, җәмәгатдән аерылма!
النار الى شذ شذ من
- ди. Бер кеше җәмәгатьдән аерылса, ул утка, җәһәннәмгә аерылды, ди. Ягъни җәһәннәм юлына таба атладың. Гафил булма! Бөтен мөселманларның һәркайсы бер иттифакда, бердәм рәвешдә, бөтенесе бер вакытда, бер айда ягъни Рамазан аенда руза тотарга чакыруы, шушы айда бөтен мөселманларның кичләрендә җәмәгать булыб тәравих намазлары укулары, бөтенесенең күңелләре ихлас белән Аллага юнәлеб, дога кылулары, дөнья Ахирәтдә максадларын сораулары, шушы җыелган җәмәгать арасында әллә нинди Аллаһының якын дустлары булырга мөмкин. Җыелган күб җәмәгать арасында яхшылар белән берлекдә догаларыбыз һичшиксез Аллаһы кашында кабул булачагы зур өмедле. Ничә йөз миллион мөселманларның бер вакытда Аллаһы ризалыгын истәб сәхәр ашаулары, бер үк вакытда ифтар кылулары. Ифтар вакытларында зарилык кылыб (зарилык кылу – Аллага зар кылу, күңелен бушату мәгънәсендә – А.Х.), Аллаһыдан дөнья Ахирәт хаҗәтләрен сораулары, һәм бердәм иттифак белән тәравих җәмәгать намазлары укулары – һәркайсы дустлыкка, тынычлыкка, татулыкка, бөтен инсаният галәменә бәхеткә сәбәб булган күркәм, гали сыйфатлар булыб, моннан башка дәхибез белән алмаган хикмәт вә маслихәтләргә мәбнә (төзелгән – А.Х.) булуына һич шик-шөбһә юк.
(0709) Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам дине, Ислам шәригате, шулай ук руза гыйбадәте, әллә кемләр уйлаганча, хәзрәт Мөхәммәд тарафындан гына чыгарылган дин түгел, бәлки Адәм пәйгамбәрдән башлаб һәрбер пәйгамбәргә Аллаһы тарафындан җибәрелгән бер дин. Илаһи һәм Аллаһыны берләү, тәүхид динедер.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Корьәндә, “Шурә” сүрәсендә әйтә:
تَتَفَرَّقُوا وَلَا الدِّينَ أَقِيمُوا أَنْ ۖوَعِيسَىٰ وَمُوسَىٰ إِبْرَاهِيمَ بِهِ وَصَّيْنَا وَمَا إِلَيْكَ أَوْحَيْنَا وَالَّذِي نُوحًا بِهِ وَصَّىٰ مَا الدِّينِ مِّنَ لَكُم شَرَعَ
يُنِيبُ مَن إِلَيْهِ وَيَهْدِي يَشَاءُ مَن إِلَيْهِ يَجْتَبِي اللَّهُ ۚ إِلَيْهِ تَدْعُوهُمْ مَا الْمُشْرِكِينَ عَلَى كَبُرَ ۚ فِيهِ
Ягъни: (شَرَعَ لَكُم مِّنَ الدِّينِ مَا وَصَّىٰ بِهِ نُوحًا) – Аллаһы Тәгалә сезгә бер шәригать, бер дин (тәүхид дине) бәян итде ки, ул дин белән Нух пәйгамбәргә әмер итмеш иде. (وَالَّذِي أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ) – Сиңа шушы тәүхид дине, Ислам дине вәхи итдек. (وَمَا وَصَّيْنَا بِهِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَىٰ وَعِيسَىٰ ۖ) Ягъни: ул дин берлә Ибраһим, Муса вә Гайсә (гс) ләргә әмер иткән идек, ягъни аларда шушы тәүхид дине булган Ислам дине белән мәэмур булдылар, халыкны шушы Ислам диненә өндәделәр. (أَنْ أَقِيمُوا الدِّينَ وَلَا تَتَفَرَّقُوا فِيهِ) – Ягъни: шушы динне торгызу, халыкка ирештерү тәблигъ итәргә тиешмез, диде. Менә шушы аятькә бинаэ галәйһи (таянып – А.Х.), Ислам дине тәүхид дине булыб, пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс) дән әүвәлге пәйгамбәрләр шул Ислам динен өйрәтер өчен булыб, безем пәйгамбәребез Мөхәммәд (гс)гә, шул динне камилләб, кәмаләткә ирешдереб, халыкка табшыру өчен бәшир һәм нәзир булыб, хатимен

набийин булуы да шундан гыйбарәт.
(0710) Рәсүл (гс) нең 74 көн гомере калган вакытда хәҗҗәтел видагъдә (الوداع حجة)
түбәндәге аять нәзел булды "Ма'идә" сүрәсендә:
دِينًا الْإِسْلَامَ لَكُمُ وَرَضِيتُ نِعْمَتِي عَلَيْكُمْ وَأَتْمَمْتُ دِينَكُمْ لَكُمْ أَكْمَلْتُ الْيَوْمَ
Аяте нәзел булыб, пәйгамбәр (гс)нең динендә, шәригатендә бәгъзе бер кәмаләтләр кушылыб, диннең тәмам камилләнеб, бөтен дөнья өчен ярарлык, бөтен мәдәният гыйлем заманын кәнагатьләндерерлек, башкача үзгәртүләргә һич ихтыяҗ калмаслык бер дин табшырылганын рәсүл (гс)гә белдермешдер.
Нәкъ бүгендәге руза гыйбадәтемездә шулай булды. Рәсүл (сгс)нең гомеренең әүвәлендә һәм пәйгамбәрлегенең әүвәлге 14 елында рузаны әүвәлдәге пәйгамбәрләр динендәге кебек үтәсә дә, Мәдинәгә күчеб барыб ел ярым узгач, сүрәи "Бәкарә"дә 182-185 нче аятьләрнең күрсәтүе, әмере кушуы буенча, руза гыйбадәтенең үтәлүе кәмаләткә ирешкән исламдагы рәвешле үтәлергә тиешлеге хакында аять килеб (нәзел булыб), инде руза гыйбадәте таркау үтәлүдән (ягъни һәркем үз теләгән вакытында түгел), бердәм рәвешдә, җәмәгать белән, ягъни Рамазан аенда гына үтәлергә тиеш диб әмер кылына (фарыз кылына). Әүвәлге өммәтләр – һәркем үзе теләгән вакытда руза тотарга маэмур булса, Мөхәммәд (гс) өммәтенә Рамазан аенда гына, җәмәгать булыб руза тотарга фарыз булуы әлбәттә Аллаһының зур рәхмәте булыб, монда безнең гакылыбыз ирешмәгән зур хикмәтләр вә мәслахәтләр булуында шик-шөбһә булырга мөмкин түгел.
(0711)
الجنة له وجب بخروجه حزن و رمضان شهر بدخول فرح من
(0712) Бөтендөнья мөселманларының Рамазан шәрифне бердәм рәвешдә, шадланыб каршы алулары, бөтендөнья мөселманларының бер вакытда, җәмәгать булыб тәравих укулары, бөтенесе бер гаилә кебек таң алдындан сәхәр ашаулары, бөтен мөселманларның көндезләрендә, бөтен начар, күңелсез гадәтләрдән тыелыб, сакланыб, гел яхшы ниятдә, изгелек теләге белән булулары, кояш баеганның соңында ифтар кылулары, бер-берсенә гаибәнә дога кылулары, гакыл салыб уйлаб карасак, мөселманларны шулкадәр иттифак белән гамәл итәргә, эш итәргә юнәлдергән, – бу гыйбадәткә хәйран калмаска мөмкин түгел. Әгәр дә руза гыйбадәте таркау рәвешдә үтәлсә, бу хәлләр, бу җәмәгать фазыйләте табылмас иде.
Шушылар өчен генәме? Алай гына түгел. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә:
امثالها عشر فله بالحسنة جاء من
Ягъни: бер изгелеккә ун өлеш сәваб бирелер, диб әйтелсә, әмма руза хакында хәдис:
به اجزى انا و لي الصوم
Ягъни: руза тоткан бәндәләргә (معين اجر) юк, ягъни күбме кадәр сәваб бирелүе әйтелми, ягъни руза гыйбадәтенә, руза тотучыларга чикләнмәгән рәвешдә, ягъни үзләре риза булырлык дәрәҗәдә сәваб бирермен диб, вәгъдә кыла. Аллаһы насыйб итсен.
Җенабе барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, Ислам динен дөрест итеб аңларга, кушканнары белән гамәл итеб, сугыш колларына вәгъдә кылган бөек мөкафәтләргә, зур сәвабларга ирешергә насыйб булсын.
(0713) Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы насыйб итсә, киләчәк җомгада тагын Рамазан хакында беркадәр сөйләргә тырышырмыз. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тоткан рузаларыбызны вә кылган башка изгелекләребезне риясыз (риясыз – икейөзле – А.Х.) гамәлләр кылыб, ихлас белән руза тоткан бәндәләргә вәгъдә кылган чиксез әҗер вә сәвабларына ирешергә Аллаһы насыйб итсен.

1967 нче ел, 22 нче декабрь, җомга көн. 25 нче Рамазан.
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенә чын күңелебез белән ышаныб, Аллаһы рәхмәтендән өмед итеб, гыйбадәт йортына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Күңелләребездә булган бозык, начар игътикад вә начар гадәтләребездән пакьләнеб, сафланыб, күркәм вә яхшы холыклар белән холыкланыб, гыйбадәт йортына, хосусан җомга гыйбадәтенә дәвам итәргә Аллаһы насыйб итсен.
السالكين دعائنا تقبل مجيب يا
Мөхтәрәм җәмәгать! Бүгенге сөйли торган нәрсәм – Ислам диненең әмер вә нәһиләре хакында, ягъни: Аллаһының безгә кылырга кушкан эшләре һәм тыйган эшләре хакында булачак. Ихлас белән тыңлагыз! Бәлки рәсүл (гс)дән шундый хәдис, шундый сүзләр сөйләнә:
تنتهكوها فلا ، أشياء وحرم ، تعتدوها فلا حدودا وحد ، تضيعوها فلا ، فرائض فرض الله إن
(0714) Ягъни: сезгә күб нәрсәләрне хәрам кылды, аларны кылмагыз. Алардан ерак булыгыз, сакланыгыз, диде. Аллаһының безгә үтәргә кушкан фарызлары нәрсәләр? Иң зурлары, алар Исламның бинасы, нигезе диб аталдылар. Рәсүл (гс) моны безгә ачык итеб аңлаткан:
وصوم ، البيت وحج ، الزكاة وإيتاء ، الصلاة وإقام ، الله رسول محمدا وأن ، الله إلا إله لا أن شهادة : خمس على الإسلام بني رمضان
Ягъни: шушы биш төрле нәрсәне иман итүебезгә фарыз булды. Шушыларның фарызлыгына ышанмаса, ул кеше мөселман була алмый. Әгәр шушыларның фарызлыгына чын күңеле белән ышанса (гәрчә үти алмаса да), мөселман була (гәрчә фасик була) .
1. Ул – Аллаһының барлыгына, берлегенә чын күңел белән ышану, һәм Мөхәммәд (гс) Аллаһы тарафындан бәндәләренә хак булган Ислам динен өйрәтер өчен җибәрелгән (илче пәйгамбәр диб ышану);
2. Биш вакыт намазның фарызлыгына ышану;
3. Рамазан рузасының фарызлыгына ышану.
4. Тиешле байлыгы булган адәмләргә закят бирүнең фарызлыгына;
5. Көче җиткән адәмләргә гомерендә бер мәртәбә хаҗ кылу.
Шушы нәрсәләр Исламның бинасы, нигезе диб аталыб, шушыларның берсенә генә ышанмаса, яки шик тотса, ул адәм чын мөселман булмый.
Инде, мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте безне бөтен мәхлукатдән өстен итеб яраткан, безгә акыл биргән, гыйлем өйрәнергә кушкан, һәрнәрсәнең хакыйкатен (0715) эзләнергә, гакылга салыб, үлчәб карарга кушкан, гакыл белән уйлаб, үлчәб карау хакында рәсүл (гс)дә шул рәвешле бер хәдис бар:
له عقل لا لمن دين لا و عقله المرء قوام
Ягъни: адәм баласының таяначак нәрсәсе, ышанычы – үзенең гакылы, ди. Гакылы бөтен булган адәмнең дине дә бөтен булмас, ди. Адәм балаларын башка хәйванлардан аера торган нәрсә – сөйләшә белү генә түгел, чөнки хәйванлар да үзара сөйләшәләр, үзләренең теләкләрене аңлашалар. Хәйванларның сөйләшүләре Коръән белән сабит булган шикелле, хәзерге вакытда да бу фән белән дә исбат кылынган хәл (“Нәмел” сүрәсендә кырмыскаларның сөйләшүләре). Бәлки адәмләрне хәйванлардан аера торган сыйфат – гакылдыр. Димәк дөньядагы башка хәйванлар гакылсыз хәйванлар булганы хәлдә адәм баласы гакыллы хәйвандыр. Шуның өчен һәрнәрсәне яхшылаб уйлаб, тәфсилләб карау

адәмчелекнең беренче бурычыдыр.
Бик күбләрнең башына шундый бер сөаль, сорау килә: динләр бик күб төрле. Аларның кайсы хак дин, кайсы дөрест? – дигән уй килә. Менә инде шушы вакыт безгә беркадәр гакылыбыз белән уйлаб карау тиеш. Кем нәрсә әйтсә, шуның сүзенә иярү – бу гакыллы адәм эше түгел. Шуның өчен иман тәкълиде шәригать кашында зәгыйф иман санала. Ягъни ата-бабалар мөселман булган, без дә мөселман диб әйтү менә никъ ышанычлы иман түгел. Чын, дөрест иманга ирешү өчен динләрнең кушкан вә тыйган эшләрен яхшылаб белергә, тикшерергә тиешбез. Әүвәлән безгә иман, соңында Исламның бинасы – намаз хакында беркадәр (0716) гакыл белән уйлаб карарга кирәк.
Намаз укуның иң беренче шарты – пакьлек. Хәзрәт рәсүл (гс) әйтә:
نظيف الا الجنة يدخل لا فانه فتنظفوا نظيف الاسلام ان
- ди. Ягъни: Ислам дине – пакь диндер. Пакь булырга тырышыгыз. Пакь булмаган кеше җәннәткә кермәс, ди.
النظافة على الدين بنى ; الامان نصف الطهور
Һәм пакьлек – иманның яртысы. Ислам дине пакьек үзренә бина кылынды, ди.
Инде уйлаб карыйк, хәзерге заманда, гыйлемнән тәрәккый иткән заманда бөтен фән галимләре, медицина белгечләре иң беренче адәм баласының сәламәтлегенә зарур булган нәрсә пакьлек, чисталык. Кая барсак – анда пакьлек, арулык (чисталык – А.Х.) хакында һәртөрле плакатлар, лозунглар тулыб тора. Хөкүмәтебез тарафындан эшләнгән һәрбер яңа йортларда гасел-коену өчен, пакьләнер өчен бассейнлар, душлар булдыра. Әгәр тикшереб карасак, шушы кадәр пакьлек һичбер диндә юк. Хәзрәт рәсүл әйтә:
أفنيتكم فنظفوا ، الجود يحب جواد ، الكرم يحب كريم ، النظافة يُحب نظيف ،الطيب يُحب طيب الله إن
Ислам дине пакьлеккә шулкадәр ригаять кылырга куша, мөселман булган адәмнең тәне, киеме һәм бөтен тормышы пакь булырга тиеш. Ашый-эчә торган савыты, йорты, җире, ишек аллары – һәркайсы пакь, чиста булырга куша. Тышкы кыяфәте пакь булган шикелле, аның эче дә, күңеле бөтен начар, бозык сыйфатлардан, нчар гадәтләрдән пакь булырга тиеш. Хөсед, гайбәт сөйләү, тәкәбберлек (0717) кебек бөтен начар сыйфатлардан аның күңеле дә пакь булырга кирәк.
Ислам хәкимләрендән: дин нәрсә? – диб сораучыга: дин исламият галәменә, кеше дөньясына файда китерердәй бөтен яхшы сыйфатлар, күркәм холыклар белән холыклану, бөтен кешелек дөньясын хәраб итә торган, зарар китерүдәй бөтен начар гадәтләр, начар холыклардан тыелу, диб җаваб бирә.
Ислам дине бөтен адәм балаларын тынычлыкка, татулыкка дустлыкка, бөтен адәм балаларына мәрхәмәтле, шәфкатьле, файда китерерлек чакыручы бер дине илаһидыр. Дәлилебез рәсүл хәзрәт әйтә:
للناسِ أنفعُهم الناسِ خيرُ
Сезнең изгерәгегез – бөтен халыкка файда китергән кеше, ди. Һәм Коръән Кәримдә әйтә:
اتقاكم الله عند اكرمكم ان
Ягъни Аллаһы кашында сезнең хөрмәтлерәгегез – тәкъва булганыгыз, ди. Ягъни байлык-фәкыйрьлек, нәсел-нәсеб белән түгел, тәкъвалык белән, ди. Тәкъвалык нәрсә белән була? Бөтен начарлыкдан тыелу, бөтен яхшылыклар белән табыла торган сыйфатдыр. Инде тыелырга кушкан, Аллаһы Тәгалә безгә хәрам иткән нәрсәләрдән хәзрәт рәсүл (гс)нең:
تنتهكوها فلا اشياء حرم و
Ягъни: сезгә күб нәрсәләрне хәрам кылды, тыйды. Ул эшләргә якын бармагыз, сакланыгыз дигән сүзен тикшереб карыйк җөмләдән. Шушы хәрам булган нәрсәләрне Аллаһы тыйган, якын бармагыз, дөнья Ахирәтдә һәлак булырсыз. Хәраб дигән олугъ гөнаһларның иң

зурысы (الكبائر اكبر) аталган аракы эчү, спиртлы агулар эчеб, үзебезнең бөтен (0718) хәйванлардан өстен булуыбызга, дөнья Ахирәтдә бәхеткә ирештерә торган Аллаһы тарафындан ихсан ителгән иң кадерле нигъмәт – гакылыбызны югалта торган, дуңгыздан да иман хәлгә китереб, нәҗес, пычрак урынларда ауната торган, үзендән косыгы, астындан бөле (сидеге – А.Х.) агыб, адәм көлкесенә калдыра торган, бөтен аек адәмләр кыяфәтендән җирәнеб китә торган хәлгә төшергән, бөтен гакыл ияләре, медицина галимләре тарафындан аның зарарлары хакында өзлексез радиолардан кычкырыб сөйләб торалар. Газета-журналларда, кинотеатрларда исерекләрдән килгән аяныч, кызганыч хәлләрне укыб һәм күзләребез белән күреб торабыз. Шулай булса да, җәмәгать, шушы агу-дошманга шулкадәр бирелгәнбез, күрәләтә шушы явыз дошманның тырнагына барыб керәбез, үзебезнең газабланыб, тир түгеб табкан халәл акчаларыбызны хәрамгә әйләндереб, дөнья Ахирәтдә хәраб булабыз. Мондан килгән аяныч, кызганыч хәлләрне сөйләб бетерерлек түгел. Яшьләребез генә түгел, хәтта олугъ яшьтәге, үзләрен иман әһеле, мөселман диб йөргән кешеләребез дә шушы кәбахәт дошмандан саклана алмыйбыз. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, шушы куркынычлы агудан җөмләбезне сакласын.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтенең безгә хәрам кылган, тыйган нәрсәләрендән тагын берен әйтеб үтәм. Хәрам булган нәрсәләр ике төрле булыб: бер төрлесе – зольми, икенчесе хәрам – гайре зольми.
(0719) Хәрам гайре зольми булганы: намаз укымау, тәмәке тарту кебекләрне санарга мөмкин. Ягъни бу эшләрне эшләгән адәмнең зарары үзенә генә була. Әмма хәрам зольми булганы: боның зарары белән үзе генә зарарланыб калмый, башкаларга зур зарар китерә. Боларның мисаллары аракы эчеб, хулиганствовать итеб, үзенең гаиләсен, тирә-күршеләрен, туганларын, тагын әллә кемләрне сүгеб, теле белән һәм кулы белән башкаларга зарар китерүләр.
Боларның хөкеме: әгәр башкаларга зарар тидерми торган хәрамләрне, гөнаһларны эшләсә, Аллаһыга чын күңелендән кылган гөнаһларына үкенеб тәүбә кылса, бу гөнаһны Аллаһы хәзрәте гафу итәргә мөмкин. Әмма хәрам зольми: башкаларга җәбере, зарары тия торган хәрам эшләрне, гөнаһларны кылса, бу гөнаһ тәүбә белән генә кичерелми. Җәмәгать, шуны яхшы белергә кирәк, кулың беләнме, телең беләнме берәүне рәнҗетәсең икән, әлбәттә шул кеше бәхилләтергә тиеш. Шул вакытда гына бу гөнаһ кичерелергә мөмкин.
Иң әүвәл башлаб ир булган гаилә эчендә семья арасында күркәм мөгамәлә кылырга. Мин ир диб, урынсызга хатынны рәнҗетергә ярамый. Әгәр кимчелекләре булса, яхшылык белән әйтергә, өйрәтергә кирәк. Коръән Кәримнең әйткән сүзен, ягъни:
و عاشروهن بالمعروف
Ягъни: хатынлар белән яхшылык нигезендә эш итегез. Бу сүзләрне истә тотарга кирәк. Шулай ук хатын булган кешедә иргә итәгать итеб, бер-беренә күркәм мөгамәләдә булу – менә Ислам диненең күрсәткән (0720) юлы шул.
Гаиләбездән кала күршеләребез белән күркәм мөгамәлә кылу, аларга җәбер-золым итмәү, мондан кала бөтен дөнья халкы белән эш итү: боларның киресе булган, болар белән начар мөгамәләдә булсак, аларны хаксызга рәнҗетсәк – болар һәркайсы хәрам зольми булыб, мәзлумларны бәхилләтми торыб, тәүбәбез дә кабул булмас.
Сүзнең ахыры итеб, җәмәгать, шуны әйтим: Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә безгә бер гамәлне фарыз итде исә мотлак. Ул эш, ул фарыз безнең дөньябыз, Ахирәтебез өчен дә файдалы эш. Әгәр дә безнең дөньябыз тарафындан бер эш безгә хәрам ителде исә, ул хәрам булган нәрсә мотлак безнең дөньябыз, Ахирәтебез өчен зур зарар һәм үкенечкщ калдыра торган,

гаять куркынычлы хәлләргә сәбәб булган эшләрдер.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте һәркайларыбызга (һәркайсыбызга – А.Х.) фарызны фарыз диб белеб гамәл кылырга. Һәм хәрамны хәрам диб белеб, ул эшләрдән сакланыб, безгә вәгъдә кылган зур әҗер вә сәвабларга ирешергә Аллаһы насыйб итсен.
(0721) 1967 нче ел, 29 нчы декабрь. Рамазан 27 нче көне
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Рамазан шәрифнең ахыргы җомгасы мөбарәк булсын! Киләчәк елда да барчаларыбызга илләребез, җанларыбыз тыныч булыб, тәнләребез сәламәт булыб, шадлык белән күрергә насыйб булсын.
Аллаһы хәзрәте Коръәндә әйтә:
مذكر انت انما فذكر
ди. Ягъни: пәйгамбәренә исләренә төшерәм: Аллаһы Тәгалә Коръәндә "Тәүбә" сүрәсендә әйтә:
الآخر اليوم و بالله آمن من الله مساجد يعمر انما
Бары мәсҗедне гыймарәт итәр (төзер – А.Х.) чын күңелендән Аллаһыга ышанган һәм Кыямәт көненә иман китергән кеше генә, ди. Төзекләндерер, ярдәм итәр, ди.
Мәсҗедебезгә ярдәм: матди вә мәгънәви рәвешдә ярдәм итү булыб, мәсҗедебезгә мәхәббәт итеб, җомгага вә биш вакыт намазга килүләребез – болар мәгънәви гыймарәт булыб, матди ярдәм: мәсҗедебезнең тышкы төзеклегенә, аның дәвам итүенә, баруына хәлебездән килгән кадәр малларыбыз белән ярдәм итү, аны төзекләндерергә биргән тиенләребез, аны гыймарәт, тәгъмир булыб, Аллаһының чын мөэминләре җөмләсенә керүебезгә сәбәб булачак.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мәсҗедебезгә килә торган доходның иң күб өлеше шушы Рамазан аенда булыб, җыл (ел – А.Х.) әйләнәсе сәламәт яшәвебезнең шөкранәсе булган фитыр сәдакаларыбызны шушы мөбарәк көнләрдә, бу көнләрдә кылган изгелекләргә бер өлеш, мең өлеш сәваб бирелә торган, важиб сәдакаларыбызны мәсҗедкә табшырыб, (0722) зур сәвабларга ирешик, чөнки мәсҗедебезгә биргән сәдакаларыбыз чын мәгънәсе белән (فى الله سبيل)Аллаһы юлына кылынган сәдака булуында һич шик юк. Инде җылда бер мәртәбә бирелә торган фитыр сәдакаларыбызны тиешсез урынларга биреб, мәсҗедебезне мәхрүм итсәк, мәсҗедкә чын мөселманлар, адәмләр генә ярдәм итәр, аны төзекләндерергә тырышыр дигән Аллаһының сүзендән читкә чыгыб калу куркынычы бар. Рамазанның ахыр көнләренә килеб җитдек, ләкин мәсҗедебезгә килгән фитыр сәдакаларыбыз башка елдагы фитыр сәдакалары белән чагыштырганда бик түбән. Елдагының 45 проценты да юк. Бу бик күңелсез хәл. Үзебезнең тирә күршеләребез, мәсҗедкә килә алмаган туган-тумачаларыбыз, дус-ишләребезгә шуны аңлатсак, бу изгелекләребез динебезгә, мәсҗедебезгә зур ярдәм иткән булыб, Аллаһы кашында зур әҗер-сәвабларга ирешербез.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Рамазан шәрифнең ахырына килеб җитдек. Әлхәмде лилләһи Раббел галәмин, Аллаһы хәзрәте ярдәм биреб, рузаларыбызны тотдык, намазларыбызны укыдык. Мәсҗедкә килә алмаганларыбыз да мәсҗедебезгә күб кенә важиб һәм нәфел сәдакаларын табшырдылар. Һәркайсы Аллаһы кашында кабул булган гамәлес салихат җөмләсендән булыб, Ахирәт көнендә әҗер вә сәвабларын күрергә Аллаһы насыйб итсен.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтенең
المأوى هى الجنة فان الهوى عن النفس نهى و ربه مقام خاف من اما و
аятенә бинаән, ягъни: күрше үзенең нәфсен тыйса, нәфсенә (0723) хуҗа булыб, нәфсен начар, бозык эшләрдән тыеб, яхшы гадәтләргә гадәтләнеб, шушы эшләрне һәркайсын

Аллаһыдан куркыб, Аллаһы хозурына баруны исдә тотыб эшләсә, менә бу кешенең барачак урыны Аллаһының салих, тәкъва бәндәләренә вәгъдә кылган җәннәт булачак, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Көн саен күбме кадәр туганларыбыз, дус-ишләребез бу дөньядан китеб торалар. Бу сәфәрдән беребез дә котылыб калачак түгел, бу хәл барыбызга да киләчәк. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сүрәи “Ниса”да, 31 нче аятьдә әйтә:
فكيف اذا جئنا من كل امة بشهيد و جئنا بك على هؤلاء شهيدا
Һәркайчан без һәрбер өммәтнең пәйгамбәрләрен өммәтләре каршына шаһид итеб китерсәк һәм сине дә өммәтләрең алдына шаһид итеб китерәбез, ди. Ягъни хисаб мәйданында гарсәат (عرصات) көнендә барлык пәйгамбәрләрне өммәтләрен хисаб кылган вакытда бастырган кебек, синең өммәтләреңне хисаб кылганда китереб бастырырбыз, ди. Рәсүл (гс) шушы аять килгәннең соңында тыела алмый җылаган (елаган – А.Х.).
Мөхтәрәм җәмәгать! Хәдис буенча өндәб, начар холыклардан, начар гадәтләрдән тыелырга тырышырга сөйләдем шает (бәлки – А.Х.). Кыямәт көнендә безгә имамлар сөйләмәделәр, аңлатмадылар диб, Кыямәт көнендә безне тоткын итмәссез. Бу көндәнсоң да нәфесебезгә хуҗа булыб, Рамазан аенда гөнаһларыбыздан тәүбә кылыб, пакъләнгәннең соңында Рамазан (0724) чыкканның соңында да, һич булмаса, атнага бер мәртәбә җомгадан калмаска тырышыйк. Мунча кереб, пакъләнеб, аруланыб, чиста киемләр кигәннең соңында пычракка, нәҗескә кереб баткан кеше кебек, начар эшләрдән, динебез кушмаган, Аллаһы кушмаган, Аллаһы тыйган хәрам эшләрдән ерак булыйк.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мөбарәк бәйрәм көнебез Яңа ел көненә тугъры килгәнлекдән, шушы хөрмәтле дини бәйрәмебезне эчеб, исереб каршылаудан сакланыйк. Үзебез генә түгел, балаларыбызга, оныкларыбызга, тирә күршеләребезгә аңлатыйк. Рәсүл (гс) нең:
من رأى منكم منكرا فليغيره بيده ، فإن لم يستطع فبلسانه ، فإن لم يستطع فبقلبه ، وذلك أضعف الإيمان
Ягъни: сезнең берәвегез икенче берәүдә бер начар, мөнкәр эшне күрсә, көч-хәл белән туктатсын, я булмаса теле белән әйтсен. Инде теле белән әйтергә көче җитмәсә, күңеле белән шуны шушы эшкә разый булмасын, ди.
Инде шушы мөбарәк бәйрәм көнләребездә халәл ризыкларыбыз, яисә хәрам булган аракылар алыб кереб, шушыңар картларыбыз яки ата-аналар риза булыб торсак, бездән Кыямәт көнендә һәркайсын да соралачак.
Инде җылаб-җылаб, шушы эшләрдән ерак булуларын үтенеб аңлатырга сорау тиешбез. Тыңламасалар, безнең өстебездән бурыч төшәр. Әмма бер дә әйтми калсак, гөнаһының уртак булачагы бар.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Быел ике зур бәйрәм бергә килә. Бәйрәм – шадлык дигән сүз. Быел ике шадлык бергә җыела.
1. Әлхәмделилләһи Раббел галәмин диб, шушы мөкаддәс (0725) Рамазан аена ирешеб, өстебездә бурыч булган Рамазан рузасын тотыб һәм изгелекләр кылыб, бөтен начарлыклардан тыелыб, гөнаһларыбыздан пакъләнеб, руза бәйрәменә ирешү шадлыгы
2. Узган елларыбызда халкыбызга, ватаныбызга зур, файдалы хезмәтләр итеб, сау-сәламәт булганыбыз хәлдә зур, иркен, матур тормышта, илләребез тыныч булыб Яңа елны каршылау бәхетенә ирешүебезнең шадлыгы.
Мөхтәрәм җәмәгать! Быелгы Яңа елыбыз, әгәр дә дөрест иттереб инсаният, исламият кушканча матур итеб каршыйлый белсәк, киләчәк Яңа елыбызда бөтен дөнья халкына тынычлык, бәхетле, матур тормыш, нурлы киләчәк, зур уңышлар, ватаныбызга, халкыбызга бөтен дөньяда изелгән, мәзлум халыкларга ярдәм итәргә диб, эш башындагы бөтен дөнья халкына тынычлык, юлларында файдалы эшләр башкару насыйб иде диб теләгән теләкләрне, Аллаһының безгә вәгъдә иткән кылган догалар, теләгән теләкләр

кабул була торган мөбарәк Гаед фитырына туры килә. Шушы кичәдә инде без зур сынау астында Аллаһының без бәндәләренә имтихан өчен биргән көне бу.
Рамазан аенда кылган тәүбәләребез, Аллаһыга биргән вәгъдәләребез ничек булачак, Кыямәт көненә Аллаһыга кашына барачакларыбызга ышануыбызның дәрәҗәләре – һәркайсы мәгълүм санала торган көн. Әгәр без шушы киләчәк елларда бәхет тели торган Яңа ел таңгын җандан да бөтен туганнарыбызны шадландырырга тырышыб, читдәге туганнарыбызга бәхетле, уңышлы тормышлар, киләчәкдә саулык-сәламәтлек белән хәерле гомерләр теләб, (0726) хатлар язсак, телеграммлар бирсәк, халәл ризыклар белән генә балаларыбыз, туганнарыбыз, дустларыбыз белән әдәби рәвешдә генә мәҗлес ясаб, бер-беребезгә киләчәк елыбыз өчен матур теләкләр теләшсәк, менә бу рәвешле каршылаган бәйрәмебез чын мәгънәсе белән шадлыклы бәйрәм булачак. Әгәр дә шушы зур бәхетләр көтә торган, зур уңышлар тели торган Яңа ел таңгын, мөкаддәс булган елга бер генә була торган Гаед фитыр таңгын (الحباءث ام) бөтен бозыклыкның анасы булган, динебез тарафыннан каты рәвешдә тыелган, хәрам ителгән, бөтен медицина галимләре тарафыннан аның һәртөрле зарарлы исбат кылынган адәм баласын (سافلين اسفل) төшерә торган, гакылны аяк астына салыб, табтаб, адәм баласын хәйвандан нәҗес, хәйвандан да түбән дәрәҗәгә төшереб, урам чатларында, алдындан, артындан нәҗесләре агыб, пычракларда аунарга сәбәб була торган явыз дошман – аракыны өстәл уртасына меңгереб куйсак, менә инде нәфес бүген син теләгәнеңне эшли, мин сиңа ярдәмче диб, аракыны кулыбызга тотсак, менә бу бәйрәм түгел (шадлык көне кугыл) түгел инде, бу кайгы, хәсрәт, фаҗигалы, үкенечле хәлләргә сәбәб була торган кайгы көне булачак. Шушындый мәҗлеснең ахыры Әллә нинди күңелсез хәлләр булганы турында еш кына күреб, ишетеб торабыз.
Гакылларын юк итеб, нәфесләренә хуҗа була алмый шушындый начар юлда булган адәмләр хакында Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә:
اضل هم بل كالانعام اولئك
ди. Хәйван дәрәҗәсендә, бәлки алардан начарраклар, ди.
Аллаһы барыбызга тәуфыйк бирсен.
(0727) Ахыр сүз итеб 66 нчы елда календарь кәгазендә язган бер галим безнең яшьләргә карата әйткән сүзен искә алмый булдыра алмыйм. Җитмешнең югары ягында булган зур галим яшьләр белән чаңгы ярышына чыга, беренче километр барыб, бер агачлыкда туктаб ут ягалар. Шушы вакыт кайсы тәмәке, кайсы аракы чыгарыб, кайсы тартырга, кайсы эчәргә хәзерләнә. Шул вакыт олы яшьтәге гакыл иясе булган галим яшьләргә сүз башлый: “И, газиз балалар! Сез дөньяда бөтен кызыкны, бөтен ләззәтне, тәмне аракы белән тәмәке дә зарарлы икәнен беләсез. Дөньяда шулкадәр кызыклар күб, без ничә йөз еллар яшәмәкдә ул кызык, ул ләззәтләрне татыб бетерә алмас идек. Менә мин җитмешдән югары чыгыб да, ничә еллар яшәдем. Минем сәламәтлегем шулкадәр яхшы, хәтта 30-35 яшьләр арасында булган, үземнең оныкларым кебек кешеләр белән ярышта катнашам. Бәлки минем организм сезгә караганда да әллә ничә өлеш сәламәтлерәкдер. Шуның сәбәбле мин гомерем эчендә аракы эчмәдем дә тәмәке тартмадым, гигиена кагыйдәләрен яхшы сакладым”, – диб җаваб бирә, – “Мин дөньяда башка нәрсәләрдән кызык табыб яшим”.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Эчмәгән кешенең бер вакытда да авызына көчләб салмыйлар. Сирәк булса да туй мәҗлесләрне, Яңа елны каршы алу шадлыклы көннәрен бер дә аракыдан башка да, әдәби рәвешдә (әдәб даирәсендә) (уйныйлар, шадланалар, җырлыйлар, бииләр һәм башкаларны шадландыралар, ләкин агудан ерак торалар. Мин бик күб эчүчеләрне беләм. Мескенләр, шадланыб (0728) бәйрәм итәсе урынында, көн эчәләр, төн эчәләр, мескенләр, бәйрәм үткәч, кыяфәтәренә карасаң, - төсләре киткән, күзләренең

нуры беткән, авызларында тәм юк, ашдан күңелләре кайткан, кайсының күзе, кайсының авызы шешкән була, әллә каһәрләр белән бәйләнгән, әллә кемләр белән сугышыб-талашыб беткән, җитмәсә, мескенләр, шушы хәлләргә үкенеб, кайгырасы урынында, шушы начарлыкларын зур кешелеккә санаб: шул эчкәнемне, кайда җөргәнемне, кайда барганымны, кайда йоклаганымны белмәгәнмен, ди. Хатынын елаткан, балаларын куркыткан... Шушымы шадлыклы бәйрәм көне?
Менә адәмләр хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:
فأما من طغى وآثر الحياة الدنيا فإن الجحيم هي المأوى وأما من خاف مقام ربه ونهى النفس عن الهوى فإن الجنة هي المأوى
Аллаһы тыйган эшләрдән тыелмый хәддә чиктән тыш начарлыкка бирелсә, яхшы эшләрдән ерак булса, аның барачак урыны җәхим, тәмугъсы, ди.
Мөхтәрәм кардәшләрем! Ахирәтдә генә түгел, бу кеше әллә нинди бәхетсезлеккә очраб, дөньяда ук әллә нинди газабларга очрый. Эчмәгән кешене кеше арасына керми, керә алмый диб, үзләренчә хурлау бар. Киресенчә – эчкән кеше арасындан чыгыб китсә, сөекле гаиләсендән аерыла. Гакыллы кешеләр андан нәфрәт итә. Ахыр чикдә ул мескенгә дөнья тар була, үзен-үзе юк итә, балчык астына барыб керә. Шуның өчен пәйгамбәребез:
ما اسكر كثيره فقليله حرام
Күбе исерткән нәрсәнең азы да хәрам, ди. Башда, җәмәгать, аздан башлана. Гадәтләнү белән күбме эчкәнен дә белми. Гомерем эчендә “белая горячка” белән хыялланыб булган адәмләр бу сүзләрне колагына алырлар, инша Алла.
(0729) Ике шадлык бергә җыелган бәйрәм көнләребезне аеклык белән уздырыр өчен, мөселман булыб яшәргә, чын мөселман булыб үтәргә насыйб итсен. Амин, йә Мөҗибес Сәилин.
1967 нче елда Казан шәһәрендә Габделхабир Ярулла тарафындан төзәлгән һәм сөйләнгән вәгазьләр.
(0732) 7нче рәкымлы Дәфтәр
1968 нче елның 1 нче җомгасындан башлана. №7
1) Мәрҗани хакында.
2) Коръәнне хөрмәтләү хакында.
3) Ганият хакында.
4) Кабер, үлем хакында.
(0733) Татар халкы арасындан башлаб дини вә милли бөек хезмәтләр итмеш Мәрҗани Шиһабеддин хәзрәтенең тууына бүгенге көн яңача 3 нче гыйнвардә, иске стиль белән 1818 нче ел, Һиҗри ел белән 1232 нче елда 7 нче Рәбигель әүвәлдә дөньяга килгән. Менә бүгенге көн чәһаршәнбе 3 нче гыйнварда 1968 нче ел, ошбу мәхәлдә имам вә мәхәллә мәдрәсәсендә дәрес әйткән, мөдәррис булыб, дәрес әйтеб 1889 нчы ел 18 нче апрельдә вафат (Һиҗри 1356 елда Шәгъбан 29 ндә вафат).
Инша Алла аның хакында тулырак мәгълүмат киләсе җомгада сөйләргә тырышырбыз һәм мәрхүмнең рухына һәм башка галимләребезнең рухына Коръән багышларбыз.

(0734) 1968 нче ел, 5 нче гыйнвар (5нче Шәввал, 1387ел Һиҗри).
Җомга көн. Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Амин.
Бөтен Казан мөселманларының гыйбадәт йорты булган мәсҗедебез аның исеме белән йөртелә торган, Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтенең нәселе-нәсәбе: Шиһабеддин бин

Баһа̓эддин бин Сөбхан бин Габделкәрим бин Габделтәваб бин Габделгани бин Габделкоддус бин Йәдеш бин Ядкарь бин Гомәрдер.
Мәрҗани хәзрәтенең бишенче бабасы Габделкоддус Зур Әтнә авылы якынында Мәрҗан карьясенең урынына беренче мәртәбә килеб ултырыб, күчеб килеб, шул карьяне тәэсис итдекендән - нисбәтләрендән атасы һәм бабалары Мәрҗани дия мәшһүр булмышлардыр. Мәрҗан карьясе Казандан 55 (“чакрым” сүзе төшеп калгандыр монда – А.Х.) еракльщкдадыр. Мәрҗани хәзрәтләренең ата вә ана тарафлары һәркайсы заманасының бөек галимләрендән улыб, нәселләрендә бик күб имам, галимләр булганлыкдан, Мәрҗани хәзрәтенендә булган фазыйләт вә кәмаләтнең бер өлеше бабаларындан мирас буларак калмышдыр.
Мәрҗани хәзрәтенең бабасы Сөбхан хәзрәт яшьдән тырыш, иҗтиһадлы, гыйлемгә ихласлы булыб, шәкерт вакытында гарәби, фарси буларак алтмышдан артык китаб күчереб язмышдыр. Ошбу Сөбхан бабасы халыкның тарихи әхвалләренә бик ихласлы, бик күб борынгы хәлләрдән хәбәрдар булыб, Шиһаб хәзрәт Мәрҗани дә шушы бабасындан бик күб тарихи мәгълүмат алмышдыр. Бәгъзе вакыт бабасының бу тарихи сүзләренә: “Әбиемнең (абыемның? – А.Х.) кәефе китеб, үткән-беткән (0735) хәлләр белән вакыт уздырасың”, дидекдә: “Бабам, мин фәкать узгандагы хәлләрне генә беләм, киләчәкләрне белмим. Киләчәкләрне белсәң, син сөйлә, без рәхәтләнеб тыңларбыз”, - дия иде. Шушы бабасы Җәки, Коснә карьяләрнедә 25 сәналәр имам вә шәкерд укыту белән, 87 яшендә Коснә карьясендә вафат булмышдыр. Бу бабасы Шиһаб хәзрәтне анадан ятим калганлыкдан аны бик кызгана вә ярата торган булыб, күб янында йөртә торган булган. Бу вакыт Мәрҗани 16 яшендә булмышдыр.
Мәрҗани Шиһаб хәзрәтнең атасы Бәһа’эддин хәзрәт Бохарага барыб, укучыларның иң мөгътәбир вә алдынгыларындан булыб, Бохарада зур голәма мәҗлесләрендә мәкбул затлардан булыб, әмир тарафындан бүләкләр килмешдер. Шушы Бәһа’эддин хәзрәт Ташкичү карьясендә (Ташкичү Казандан 70 чакрым) имам вә мөдәррис булыб, заманында мәгъруф булганлардан, укытыб, байтак имамлар, галимләр йитешдермешдер (җитештергән – А.Х.). (Атасындан укыб чыккан имамлардан 35 кешенең исемләрен саный). Бәһа’эддин хәзрәт Бохарада татарлар арасында җиткән галимләрнең тәрҗемәи хәлләре белән яхшы таныш (белүчеләрдән) булыб, Шиһабеддин хәзрәт үзенең тарихи әсәрләрен язуда атасындан зур истифадә итмешдер.
Мәрҗани хәзрәтенең анасы – Бибихөбәйбә исемле гакыллы, күркәм холыклы бер хатын булыб, 29 яшендә яшьләй вафат булган. Мәрҗани хәзрәтләре анасындан 5 нче яшендә ятим калмышдыр. Мәрҗанинең ана тарафындан бабасы – мулла Габденнасыйр тарафындан Чукалы исемле авылындан булыб, соңра Ашәт карьясенә имам вә мөдәррис булыб, бөтен гомерене гыйлемгә хезмәт итеб үткәрмешдер.
(0736) Мәрҗани хәзрәтләре (1233 нче сәна Һиҗри 7 Рәбигель әүвәл) 1818 нче ел гыйнвар эчендә 3 кич Ястү вакытында Ябынчы карьясендә дөньяга килеб, Мәрҗани хәзрәте туган вакытда атасы 32 яшендә, анасы 24 яшендә булыб, Мәрҗани хәзрәте бишенче яшендә вакытда анасы икенче баладан вафат булыб, Мәрҗани хәзрәте анадан ятим калмыш. Мәрҗани хәзрәте 3-4 яшьләрдә вакыт Ябынчы карьясендән Ташкичү карьясенә күчкәннәр. Мәрҗани хәзрәтдә бала вакытында бик шук булыб, уен вакытларында башлаб йөри, шаяру уенны бик сөя торган булган. Күб вакыт кәгазь битлек ясаб ... бала вакытдан ук укырга күңел биреб, үзенең яшьтәшләре арасында һәрвакыт беренчеләрдән булган. Мәрҗани хәзрәтләренең укуга ихласы белән батырлыгы, кыюлыгы өстенә тән җәһәтендән таза вә куәтле булыб, 17-18 яшьләрендә көрәшкә бик оста булыб, Ташкичү тирәсендә

батырлык белән исем алган көрәшчеләрне җиңеб, Янәшә тирә “көрәшче Шиһаби” исеме белән йөртә булганлар . 19 яшьләрендә вакытда шул заманда Ибрай батыр дигән берәү белән көрәшкә тугъры янында булганнар. Көрәшмәскә киңәш бирсәләр дә, көрәшеб шушы мәшһүр Ибрай батырны еккан.

Мәрҗани хәзрәт бала вакытдан ук дингә ихласлы, диянәтле улыб, намазга даимчылык кыла. Бервакыт бәлагатендән элек тир кыстасы белән авырыб, тирлегенең соңында авыру вакытда калган намазларын һәркайсын каза кылган (үтәгән – А.Х.).

(0737) Атасы Бәһаэддин хәзрәт кыска көнләрдә Ястүнең сөкуты (килеп җитүе – А.Х.) илән каил (әйтүче; сөйләүче – А.Х.) булганга, кыска төнләрдә Ястү намазы важиб түгел, дигән галимләрдән булган. Шушы вакыт атасына ияреб калдырган Ястү намазларын (үзе зур галим булыб, кыска төнләрдә дә Ястү намазының важиб фарызлыгына кәнагать хасыйл итдекендән, Бохарадан кайтканның соңында шул вакытда калган намазларын һәркайсын каза кылмышдыр.

Мәрҗани хәзрәтләре атасының мәдрәсәсендә нәхү, сарыф дәресләрене хәлифәләрдән укыб тәмам итдекенең сонында атасындан укыб, ул заман мәдрәсәләрдә укылмыкда улган дәресләрне укыб, хәтме китаб кылмышдыр. Шушы вакытлардан ук гыйлемгә бик ихласлы булыб, атасының көтөбханәсендә булган китабларны тырышыб-тырышыб моталәга кыла торган булган. Һәм шушы вакытда ук тарихка һәм тәрҗемәи хәлләргә ихласы булыб, укыган китабларының мәснафләренең язучыларның кем икәнлеген – тәрҗемәи хәлләрен белергә тырышкан. Мәрҗани хәзрәте ижтиһади, тырышлыгы, гыйлемгә ихласы аркасында мәдрәсәдә булган ибтәшләре арасында бик тиз игътибар казанмыш.

Япь-яшь көенчә гыйлем илә исеме чыгыб, 17 яшендән башлаб атасының мәдрәсәсендә укыта башламышдыр. Шушы вакытдагы тәртибсез укытуларга эче пошыб, укыту тәртибләрен үзгәртү тиешлеген уйлана башлаб, бәгъзе бер дәресләрне атасының рөхсәте белән шәкердләренә үзе языб, укыта башлаган. Яшь вакытындан тарихи нәрсәләр белән кызыксыныб, зияратларда булган ташларны тикшерә башлаган.

(0738) Мәрҗани хәзрәте Миляди белән 20 яшь, Һиҗри белән 21 яшь булыб, 1838 нче елны май сәфәргә хәзерләнмешләр. Ул вакытларда татарларның Урта Азия белән сәүдәләре бик куәтле булыб, Бохара белән Казан арасында һәрвакыт кәраван йөреб тора, һәрвакыт барыб-килеб йөрүче сәүдәгәрләр булыб, Бохарага сәфәр итүче шәкерд вә муллаларны, аларның әманәтләрене йөретә булганлар.

Мәрҗани хәзрәтләренә дә меңәр сәүдәгәренең Бохарага баручы йөкләре белән сәфәр итәргә тугъры килгән. Бу вакытда Мәрҗани хәзрәте үз тирәләрендәге берничә авылдан башканы күрмәмеш. Казанны да бер мәртәбә дә күрмәмеш, ошбу беренче сәфәр Мәрҗани хәзрәтләренең – Ташкичүдер. Чыгыб, җиде ай чамасы юлда үткәреб, 1838 нче елның декабрендә Бохарага барыб җитәләр. Мәрҗани Шиһаб хәзрәт Бохарада күб галимләрдән дәрес алыб һәм үзе шәкертләр укытыб, Бохарада унбер ел тора. Шул ук вакытларда Сәмәрканд шәһәрендә дә була. Андагы зур галимләр белән катнашыб, алардан дәрес алыб һәм аларның бик күб китаблары булган көтөбханәләрендән файдаланыб, зур гыйлемгә ия була. Мәрҗани хәзрәтенең бөтен замандашларындан өстен булырлык тырышлыгы һәм тән җәһәтендә тазалыгы, сәламәтлеге булуы, сәламәтлеген сакларга зур әһәмият бирүе – һәркайсы зур галим булуына сәбәб булган. Бохара халкы арасында таралган әфьүн, вак тәмәке кебек бөтен начар гадәтләрдән бик сакланган.

(0739) Мәрҗани хәзрәте Бохарада унбер ел торыб, 1849 нчы елда Казанга кайтыб, ата-аналары белән күрешә. Мәрҗани хәзрәтенең Бохарадан кайткан вакытларында Казанның беренче мәхәлләсендәге имамы Сәгыйд хәзрәт имаматчанлыгын ташлаб, хаҗга киткән

булыб, шушы мәхәллә имамсыз калган. Казан байлары, хосусан Ибраһим бай, үзләренә имам сайлаб, Мәрҗанинең зур галим икәнлеген ишетеб, Ибраһим бай зур голәмә мәҗлесе ясаб, Казан имамлары һәм зур галимләрне чакырган. Шиһаб хәзрәтнең гыйльменә зур бәя биреб, беренче мәхәлләгә имам булырга, моңардан тиешле, лаек адәм булмас диб, шәһадәт бирүләре белән Ибраһим башка мәхәллә халкының теләве буенча Бохарадан кайтканның ике-өч ай соңында беренче мәхәлләгә имам тәгаен кылыныб, 1266 нчы Һиҗри, 21 нче Мөхәррәмдә беренче мәртәбә җомга намазы укыган.
Мөхтәрәм фазыйләтле дамелла Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәте шушы мәсҗеддә, шушы мәхәлләдә имам, ахун һәм мөдәррис булыб, дәрес әйтеб, күб галимләр җитешдереб, күб санда дини-гыйльми фәнни китаблар языб, Ислам динендә зөһүр иткән (барлыкка килгән – А.Х.) һәртөрле бидгать гамәлләр вә хөрафәтләр белән көрәшеб, имамлар динен Гасыр сәгадәтдәге пакълегенә, сафлыгына кайтарырга тырышыб, зур галим мөҗтәһид вә мөхәббид (محبد) булыб, 1889 нчы ел, апрель 18 ндә вафат булган. Вафатында иң соңгы сүзләре: (العلمين رب ربنا الله) (جميعا الامر الله بل).
Мәрҗани хәзрәтлере безнең халыклары эчендә генә түгел, үзенең дини, гыйльми хезмәтләре белән Йауропаның зур шәһәрләрендә дә (Лондон) һәм башкалар, Гарәбестан, Һиндестан, Африка илләрендә дә танылган, мәшһүр, зур галим.
(0740) Филология фәннәре кандидаты Х. Хисмәтуллин
Шиһаб хәзрәт Мәрҗани хакында түбәндәгеләрне яза:
“Шиһаб Мәрҗани Казанда мулла булыб торган. Ләкин ул үз чорындагы барлык муллалардан үзгә буларак, Казан, Петербург һәм Лондон галимләре белән бәйләнеш тоткан. Казан университеты янындагы Тарих, этнография һәм археология җәмгыятенең члены булган. Мәрҗани татар халкы тарихын, этнографиясен һәм культурасын өйрәнүгә бик күб көч куйган. Шуның нәтиҗәсендә ул хәзерге татар халкының Урта Идел һәм Кама буенда формалашкан халык икәнен исбат иткән.
Мәрҗани көнчыгыш галимләре турында “Вафиятель асляф” исемле гарәбчә сигез томлык әсәр. Болгар һәм Казан турында “Мөстафадель әхбар” исемле татарча икетомлык әсәр һәм башка китаблар язган. Аның “Галәләтуз зәман” (الزمان علة) исемле әсәре рус теленә дә тәрҗемә ителгән. Казанда татар укытучылар мәктәбен ачыга ярдәм иткән. Аның үз карамагындагы мәдрәсәсе дә заманының алдынгы мәдрәсәләрендән булган (саналган).
Мәрҗани гыйлем байлыкдан өстен, шуңа күрә галимләр байларга баш ияргә тиеш түгел диб караган. Шул карашы аркасында ул күб кыенлыкларга дучар булган.
Шиһаб Мәрҗанинең шул хезмәтләрен исәбкә алыб, татар әдәбияты классиклары: Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов аңа зур хөрмәт белән караганлар.
Календарь 1959 нчы ел, 30 апрель “Мәрҗанинең үлүенә 70 ел тулу уңае белән” мәшһүр галим Фазил Гамилбулган Шиһаб әл-Мүрҗани хәзрәтләренең аяк баскан, вәгазь сөйләгән мәсҗедендә намаз укыймыз. Остаз мәрхүм Аллаһының рәхмәтендә булсын, җаны шад булсын. Бер шушы галим эзендән барыб, һәртөрле бидгать вә хөрәфәтләрдән ерак булыб, безгә дә мөкаддәс Ислам динен дөрест итеб аңларга, дөрест итеб гамәл итәргә Аллаһы насыйб итсен.
1968 нче ел, 12 нче гыйнварьда , җомга көн. 12 нче Шәввал
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Тәнләребез, киемләребез пакъ булган кебек, күңелләребезне дә пакъләб, саф күңел, дөрест ният белән җомга гыйбадәтенә җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Мөхтәрәм җәмәгать! Берничә адәм тарафындан миңа хатлар табшырылды. Бу хатларда

мәсҗедебездә намазга килгән адәмләр тарафыннан күрелгән тәртибсезлек һәм әдәбсезлек. Гомумән, мәсҗед эчендә генә түгел, башка урынларда да сакланырга тиеш булган, мәкрүһ булган күңелсез гадәтләр булганлыкдан, шушындый күңелсез, ямьсез эшләр хакында беркадәр мәсҗед әһелләренә "тәнбиһ" кылсагыз, аңлатыб узсагыз, зур мәрхәмәтегездән булыр иде, диб үтенеб язалар. Моңа кадәр дә бик күб хәзрәтләр тарафыннан бу хакда сөйләүләр булса да, тагын да беркадәр аңлатма булса, бердән, шушы мөселманлар-кардәшләребезнең үтенечен үтәгән булсак, икенчедән, - тыңлаучыларга да, инша Алла, файда хали булмас диб беләм. Бер адәм ачыныб яза: "Мәсҗедебездә бәгъзе адәмләр Коръәнләр белән бик игътибарсыз мөгамәлә кылалар. Коръәннең хөрмәтен сакламыйлар. (0742) Коръәнне алалар да, бер почмагыннан тотыб, ал тарафдан гаурәте тугърысында, я арт дәбере (دبرى) тугърысына тоткан адәмләр бар, диб яза.
Мөхтәрәм җәмәгать! "Әхкаф" сүрәсендә:
الحكيم العزيز من الكتاب تنزيل حم
Һәм "Җа'ийа" сүрәсендә:
الحكيم العزيز الله من الكتاب تنزيل
Һәм "Фәзыйләт" сүрәсендә:
آيته فضلت كتب الرحيم الرحمن من تنزيل حم تعالى الله قال
Ул Китаб Рәхимле, Шәфкатьле булган Аллаһы татафыннан иңдерелгән Коръән. Аятьләре мәгънәләренең төрле-төрле булуы берлә әхкам вә тарихи вакыйгаларны бәян улынды. Һәм "Сад" сүрәсендә әйтә:
الذكر ذى القرآن و ص
Ягъни: Коръән хакы өчен Ул Коръән гыйззәт, шәрәф ияседер, диндә мохтаҗ булган гәкаид вә шәригатьләр, зикер Китабыдыр, ди.
Газиз, хәким сыйфатлары сыйфатланган Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы тарафыннан килгән канун илаһи, Кәлам Аллаһ булган Китаб белән игътибарсыз булу, җәмәгать, һәркайсыбыз өчен гафу ителмәслек, күңелсез хәл. Һәрбер мөселман тарафыннан зур хөрмәт, ихтирам ителергә тиеш булган мөкаддәс Китабдыр. Һәм Коръән аятьләре укылган вакытда ихлас белән тыңлаб тору хакында "Әгъраф" сүрәсендә әйтә:
تُرْحَمُونَ لَعَلَّكُمْ وَأَنْصِتُوا لَهُ فَاسْتَمِعُوا الْقُرْآنُ قُرِئَ وَإِذَا
ди. Ягъни: һәркайчан Коръән укылса, тыңлагыз, ишетегез, тик торыгыз. Шәет ки, Аллаһының рәхмәтенә ирешерсез, рәхмәт кылынырсыз, ди. Шулай булгач, мөселман адәмгә һәрвакыт Коръән хакында бик игътибарлы, ихтирамлы булырга тиеш буладыр.
Икенче: мәсҗедебезгә түбәнге катта намаз укый торган урынга кадәр бәдрәфдә йөргән аяк киемләре белән керәләр, диб бер мөселман яза. Шулай ук хаттаязылган: "Бу хакда һәрбер мөселман, (0743) адәм үзе белергә кирәк". Хәзрәт рәсүл:
الامان نصف النظافة الامان؛ من النظافة
диб, пакълек – иманның яртысы; пакълек – имандан.
Камил адәм булмак өчен һәрвакыт пакълек, нәзавәт – иң беренче кирәкле нәрсәләрендәндер. Әгәр адәм баласы нәзафәткә, пакълеккә ригаять кылса, аның тәне сәламәт була. Сәламәт тәндә генә сәламәт гакыл була, дигәнләр.Чын мөселман адәм түгел мәсҗеддә генә, киеме-салымы гына, түгел, – бөтен тормышында урыны-җире, савыты-сабасы, һәр нәрсәсе пакъ булырга тиеш.
Мөхтәрәм җәмәгать! Без кайсыларыбыз балалар түгел, үзебез белергә кирәк. Шушындый салкын көндә тышкы түбәндәге урынларга намаз укучылар барын истән чыгармаска кирәк. Хәзрәт рәсүлнең:
لنفسك تحب ما للناس احب

Үзең өчен сөйгәнне башкаларга сөй, дигән сүзен һәрвакыт истә тотыб әйткән кешеләргә ачуланмыйк.
Иң күңелсез хәлләрдән берсе, җәмәгать, бик еш кына була торган начар гадәт: аяк киемләребез алышыну, алыштыру гадәте бар. Түгел аяк киемләре генә, баш киемләребез, өст киемләребез дә алышынулар бар. Әгәр дә хата булса, шул ук алышынган киемләребезне, кирәк – баш киеме, кирәк – өст киеме, кирәк – аяк киеме, шуларны икенче җомгада алыштырырга мөмкин, я, булмаса, бөтенләй (0744) урынына калдырмый, югала торган хәлләр дә булгалый.
Мөхтәрәм җәмәгать! Менә эшләр касдән булса, һич мөселманлык белән килешә торган исламият тарафыннан каты тыелган начар эшләр: хәзрәт пәйгамбәребез (гс) әйтә:
الْقِيَامَةِ يَوْمَ مِنْهُ اللَّهُ انْتَقَمَ إِلَّا ،مُؤْمِنًا مِنْكُمْ أَحَدٌ يَظْلِمُ وَلَا رَبَّكُمْ اتَّقُوا ،النَّاسُ أَيُّهَا يَا
Ягъни: и, адәмләр! Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз. Һәрбер гөнаһ эшләрдән сакланыгыз. Валлаһи, мөэмин мөэмингә золым кылмас, ничек кенә булса, мөэмин мөэминне рәнҗетмәс, иллә мәгәр шулай булса, ягъни мөэмин мөэминне, мөселман мөселманны рәнҗетсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә ул кешедән үч алыр, ди.
Тагын да хәзрәт рәсүл (гс) әйтә:
دمه و عرضه و ماله حرام المسلم على المسلم كل
ди. Ягъни: һәрбер мөселманның икенче мөселманга малы, гарзе (әйберләре, товары – А.Х.), каны – хәрам, ди. Тагын да әйтә:
ماكره او ضره او مسلما عش من منا ليس
ди. Бер кеше икенче адәмне алдаса, ничек кенә булса да зарар китерсә, яисә ул яратмаган бер эшне эшләсә, ул бездән түгел, ди.
اللَّهَ آذَى فَقَدْ آذَانِي وَمَنْ ، آذَانِي فَقَدْ مُسْلِمًا آذَى مَنْ
Ягъни: бер кеше бер мөселманны рәнҗетсә, тәхкыйк ул мине рәнҗетде, ди. Әгәр бер адәм мине рәнҗетсә, Аллаһыны рәнҗетде, ди. Тагын да әйтә:
القيامة يوم خصمته خصمه كنت ومن خصمه فأنا ذميا آذى من
Түгел мөселман адәмне генә, бер кеше башка милләтдән булган бер адәмне рәнҗетсә, Кыямәт көнендә мин ул кеше дәгъвалашучы, ди.
(0745) Кем дә кем белән мин Кыямәт көнендә Аллаһы хозурында ул адәм белән хөкемдә булсам, әлбәттә, мин ул адәмне җиңәрмен, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Үзебезне хак мөселман диб йөри торыб да, шушындый начар эшләрне эшләсәк, безнең иманыбыз, мөселмаглыгыбыз, мәсҗедгә килеб намаз укуларыбыз кайда булырга кирәк (кая китәчәк) белә торыб да, берәүнең аяк өсте киемен киеб китсәк, намаз укырга килгән бер мөселманны шушы рәвешле рәнҗетсәк, борчуга салсак, үзебезне ничек диб уйларга кирәк? Бәйтулла – мәсҗед адәмләрне рәнҗетә торган, кычкырыш, талаш, гау-га, хыянәт, алдау, ялган урыны түгел, бәлки тынычлык, дустлык, тугърылык, гаделлек, тигезлек, дөнья Ахирәтдә бәхетле булырлык, әхлакый тәрбия алырлык, адәм баласының рухани авыруларына шифа бирерлек мөкаддәс бер йортыдыр.
Мәсҗедгә килгән адәм - адәм түгел касдән шундый начарлыкны эшләсә, аяк астындан табылган тиенләргә кадәр хуҗасына бирергә ашыгырга тиеш. Бәгъзе адәмләребез акчаларын югалтдылар, бүрекләрен алдырдылар, пәльтәләрен алдырдылар, яки алыштырдылар, аяк киемләре югалды. Шушындый адәмләр касдән белә торыб, бу эшне эшләгән булсалар, үлем килмәсдән әүвәл, әгәр үзләрен пәйгамбәргә өмет булуны, чын мөселман булуны теләсәләр, моңа кадәр булган эшләре өчен җылый-җылый үкенергә, тәүбә кылырга, мондан соң андый эшләрдән ерак булырга, үзләренә гәһед, сүз бирергә тиешләр.

(0746) Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга бөтен адәм балалары белән дуст-тату, тугърылык, дустлык белән яшәргә , башкаларга җәбер-золым кылудан, ничек кенә бер-беребезне рәнҗетүдән сакланыб, Кыямәт көнендә рисвай галим булудан, барчаларыбызны сакласын. Амин, йә Мөҗибес-саилин.
1968 нче ел, 19 нчы гыйнвар. 1387 нче Һиҗри, Шәвваль 17. Җомга көн.
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһының рәхмәтен өмед итеб гыйбадәт йортына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Безне юкдан бар кылган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә вә хәзрәтләрнең сәламе вә рәхмәте вә бәракәте барчаларыбызга насыйб булсын.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте Коръән Кәримдә әйтә:
اثم الظن بعض ان الظن من كثيرا اجتنبوا آمنوا الذين ايها يا بالله استعيذ
Аллаһы хәзрәте әйтә: И, иман китермәгән бәндәләр! Күб гөман кылудан сакланыгыз, дөрестлекдә гөманның бәгъзе Аллаһы кашында зур гөнаһ, ди. Гөман бер адәмнең икенче адәм хакында уйлавы. Менә гөман икетөрле булыб, берсе хөсне зөнн (шик – А.Х.), икенчесе сүэ (начар – А.Х.) зөнн.
Хөсне зөнн: башка кешеләр хакында яхшы кеше диб уйлау. Менә бу әхлак хөснедән саналган күркәм. Матур сыйфат. Әгәр дә бер адәмне якыны начарлыгын күргәнең юк икән, яки бер дә белмәгән, яңа танышкан кеше хакында шушылай уйлау, динебез кушкан матур гадәт. (0747) Үзара дустлык, мәхәббәткә сәбәб булыб Аллаһы кашында сәваблы эш. Әмма икенчесе бер дә белмәгән кеше хакында, я булмаса бер адәмнең адәм хакында, ачык белми торыб, аның: ул шулай – начар эш булырга кирәк. Аның яман уйда яман исәбтә булу – менә бу шәригатебез хакында хәрам булган, үзара дустлык, татулыкны җимереб, дошманлык тудыра торган әллә нинди фетнәләргә юллар ачу булыб, иң начар, сүэ холыкларның берседер, начар гадәтләрнең берседер. Хәзрәт пәйгамбәр (гс) әйтә:
إِخْوَانًا اللَّهِ عِبَادَ وَكُونُوا تَبَاغَضُوا وَلَا تَدَابَرُوا وَلَا تَحَاسَدُوا وَلَا تَجَسَّسُوا وَلَا تَحَسَّسُوا وَلَا الْحَدِيثِ أَكْذَبُ الظَّنَّ فَإِنَّ وَالظَّنَّ إِيَّاكُمْ
Ягъни сүэ зөндән сакланыгыз, зира (чөнки – А.Х.) бер-берең хакында сүэ зөнн кылу сүзләрнең хәбәрләр ялганрагыдыр.
Холыкның хәлләрене вә күзгә күренмәгән гайберләрене тикшерешмәгез, ягъни тырнак астындан кер эзләмәгез, яшерен рәвешдә бер-берегезне тыңламагыз, бер-берегезгә хөсед-көнчелек кылмагыз, кылышмагыз, бер-берегезгә ачуланышмагыз, ачу сакламагыз, бер-берегезгә ачу тотыб, үбкәләшеб йөрмәгез:
اخوانا الله كونوا عباد و
И, Аллаһының бәндәләре, бөтенегез бертуган кардәш кебек булыгыз, ди. Бер-берең хакында явыз гөман, сүэ зөнн кылу, бер-беребезнең гаебләрен тикшерү, көнчелек кылу, бер-берең белән ачуланышыб үбкәләшеб – менә бу эшләр һәркайсы Ислам дине кашында тыелган, арада дустлык, татулык, иттифакны бетерүгә сәбәб булган начар нәтиҗәләргә сәбәб була. Әхлак замиме – начар гадәтләр булыб, мөселман булган адәм бу сыйфатлардан бик ерак булырга тиеш.
(0748) Гөманның важиб дәрәҗәсе бар һәм мөстәҗиб булганы, хәрам булганы бар. Важиб – тиеш булганы. Аллаһы Гәззә вә Җәллә хәзрәте хакында: ягъни ни кадәр начар булсаң да, Аллаһының рәхмәтендән өмед кисмәү вә Аллаһының рәхмәте минем кимчелек-гөнаһларымдан киңрәк, диб уйлау.
Бөтен адәмләр хакында хөсне зөнnле булу – монысы һәркайсыбызларга мөстәҗиб. Әмма башкалар хакында сүэ зөнн кылу – бу хәрам, Аллаһы тыйган, начар сыйфат.
(0749) Явыз гөман төрлечә булырга мөмкин. Бер адәм һич явыз нияте булмаенча,

шушындый берәр урынына кердегене күрдекдә, Рамазанда берәр ашханәгә керер. Ул анда бөтенләй икенче бер йомыш белән керер: я берәр адәмне күрергә, я берәр эчемлек кибетенә керер, я, булмаса, ялгышыб анда керер. Менә шушындый хәлләрдә ул адәмгә ашыгыб сүэ зөнн кылырга ярамый. Инде берәү шундый юлда йөри икән, ул кеше хакында явыз гөман кылырга юл.
Суфьян әс-Сәүри хәзрәте әйтә: гөман ике төрле: берсе гөнаһ булган гөман бер мөэмин кардәш хакында сүэ зөнн кылыр да, шуны башкаларга да сөйләр. Менә бу гөман газабка мөстәхыйк булган гөман . Икенче гөман кылурда – башкаларга сөйләмәс, шулай уйлаб кына калыр, ди
Мөхтәрәм мөселманлар! Башкалар хакында сүэ зөнн, явыз гөман кылу – Аллаһы кашында тыелган, начар гадәт булыб, мондый начар хәлләргә гәрифтар булыб, Аллаһы газабына очраудан Аллаһы барыбызны да сакласын. Мәсҗедебездә хезмәт итүчеләребез хакында төрле начар уйлаучыларыбыз бар. Тәгаен хакыйкатне белмәенчә күңелебезгә килгән һәртөрле начар уйларны сөйләүдән Аллаһыдан куркыйк. Башда укыган аятьнең ахырында Аллаһы Тәбарәкә әйтә:
وَلَا تَجَسَّسُوا وَلَا يَغْتَبْ بَعْضُكُمْ بَعْضًا أَيُحِبُّ أَحَدُكُمْ أَنْ يَأْكُلَ لَحْمَ أَخِيهِ مَيْتًا فَكَرِهْتُمُوهُ وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ تَوَّابٌ رَحِيمٌ
(0750) Ягъни: и, мөселманлар! Бер-берегезне тикшерешмәгез, бер-берегезне гайбәт кылышмагыз! (Гайбәт кешенең артында, әгәр ул сүзне ул адәм ишетмәсә, аның турында начар сүз, начар фикер әйтү, шул гайбәт була). (Әбу һөрәйра) Рәсүл (гс) әйтә: “Бер вакытда бездән сорады: гайбәт нәрсә ул, диб. Без шул вакыт Аллаһы вә Аның рәсүле белгүчерәк диб, җаваб бирдек”, – ди. Мөселман кардәшеңне үзе яратмый торган эше белән искә алсаң, шул гайбәт була, диде. Әбу Һөрәйра (рг) әйтә: “Мин әйтдем: йә рәсүлулла, чындан да ул начар эш анда булсадамы, диб сорадым, ди. Әгәр мин әйткән начар эш анда булса, син тәхкыйк гайбәт кылдың, әгәр анда булмаганны сөйләсәң, ул вакытда бөһтан (яла, русча: клевета, наговор – А.Х.) белән яктың. Монысы тагын да хәрам, ди”.
ا يحب احدكم ان يأكل لحم اخيه ميتا فكرهتموه
Әйа, сезнең беревегез карәндәше итене мәет булдыгы хәлдә ашауны сөярме? – ди. Әлбәттә ашамас идегез, мәкруһ күрерсез, ди.
Әнәс бин Малик (рг) дан шундый бер хәдис кылына: рәсүл (сгс) әйтә, ди: Мигъраҗ кичәсендә шундый бер кавем яныннан уздым, аларның корычдан үткен тырнаклары бар ки, шушы тырнаклары белән йөзләрене, итләрене вә күкрәкләрене тырныйлар. Җәбраил фәрештәдән сорадым: болар кемләр? – диб. Җәбраил фәрештә әйтде: бонлар адәм ите ашаучылар (ягъни гайбәт сөйләүчеләр) һәм адәмләр йөз суын түгүчеләр, диде.
(0751) Сәләф салихиндән Мәймун бин Ясар дигән адәмдән риваять кылына: төшемдә бер зәнҗи (кара тәнле адәм) уләксәне күрдем вә бер кеше миңа шушы үләксәне, мәетне ашарга куша, ди. Мин һич үләксә ашамыйм, дидем. Юк, ашарсың, син – фәлән адәмнең гайбәтне ашадың бит, диде. Валлаһи, мин ул адәмнең начарлыгын һәм изгелеген дә сөйләмәдем, дидем. Мәзкүр адәм әйтде: дөрест, син сөйләмәдең, ләкин башкалар сөйләгәнне тыңладың һәм разый булыб тордың, диде.
Ошбу вакыйгадан соң һич гайбәтләмәдем һәм башкаларга гайбәт сөйләргә ирек бирмәдем, дигән.
و اتقوا الله ان الله تواب رحيم
Шушы хәрам булган гайбәт кылу хакында Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз, Аллаһыдан куркыгыз, Аллаһыга тәүбә кылыгыз, хакыйкатдә Аллаһы Тәбарәкә ихлас тәүбә кылучыларның тәүбәләрен кабул кылгучыдыр, ди.
Шушы югарыда Аллаһының каләме, пәйгамбәремезнең мөбарәк сүзләре белән гамәл

кылсак, шуларны хәтердә тотсак, инша Алла, күңелләребезне әхлак замимидән пакъләргә, Аллаһы кашында йөзебез ак булуга сәбәб булыр иде.
Инде үз хәлләребезгә күз салсак, җәмәгать! Аллаһы газзә вә җәллә вә Аның рәсүле безне сүэ зөнндән (начар, тискәре караштан – А.Х.) тыйган икән, безнең арабызда сүэ зөнндән күб нәрсә юк, кеше гаебен тикшерүдән безне тыйган икән, үз гаебебез башдан ашкан, аны күрмимез, кеше гаебен тикшерәбез. Гәйбәт сөйләү Аллаһы вә рәсүле тарафыннан катгый тыелган бер хәрам эш (0752) икән, хәтта без аларны хәрам диб дә белмибез, мөбах гамәл кебек итеб рәхәтләнеб, тәмләнеб сөйлибез.
Дин вә дөньяның төреклеге (тәһзиб әхлак) аркасында гына хасыйл була. Шуның өчен әхлак китаблары диндән мәксуд да тәһзиб әхлак дигәнләр. Хәзрәт рәсүл (гс) әйткән:
الاخلاق حسن لاتمم بعثت
Мин изге холыкларны тәмам өйрәтү өчен җибәрелдем, ди. Димәк, Аллаһы тарафыннан һәрбер пәйгамбәр күркәм холыкларны өйрәтүне, начар, бозык гадәтләрдән пакъләү өчен Аллаһы тарафыннан җибәрелгән булсалар, Хатимель әнбия хәзрәтләре шуларны тәмамлау өчен җибәрелгән. Шулай булса, чын күңелләребез белән хәзрәт рәсүлгә өмет булуны теләсәк, Аллаһының салих, тәкъва бәндәләренә вәгъдә кылган, оҗмах нигъмәтләренә ирешүне теләсәк, үлем килгәнгә кадәр динебез тыйган бозык гадәтләребезне ташларга тырышу – мөселман адәмләргә изге бурыч.
Аллаһы хәзрәте барчаларыбызга инсаф биреб, кимчелекләребезгә тәүбә кылыб, хөсне хатимә белән дөньядан үтәргә насыйб булсын. Амин.
1968 нче ел, 25 нче гыйнварда / 1387 Һибри, 25 Шәввал, җомга көн.
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Җомга көнебез, җомга гыйбадәтебез, Аллаһы кашында мәкбул булыб, җөмләбез өчен (0753) мөбарәк булгай иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгс) әйтә:
مَوْتِكَ قَبْلَ حَيَاتَكَ وَ شغلك قبل فَرَاغَكَ وَ فَقْرِكَ قَبْلَ غِنَاكَ وَ سُقْمِكَ قَبْلَ صِحَّتَكَ وَ هَرَمِكَ قَبْلَ : شَبَابَكَ :خَمْسٍ قَبْلَ خَمْساً اغْتَنِمْ
Пәйгамбәр Хода биш нәрсә килми рәддән. Ул биш нәрсәнең кадерен бел, ди. Ганимәт санады, үлем килүдән тереклегеңне, авыру килгәнгә кадәр сәламәт булыб җөрүеңне, буш вакытыңны шөгылыңдән, әүвәл тыныч вакытыңны тынычсызлык килгәнгә кадәр, яшь вакытыңны картлык килгәнгә кадәр, бай вакытыңны фәкыйрлекдән. Ягъни үз кулыңда хуҗалык бар вакытны хуҗалыгың китүдән ул кадерен бел, ганимәт бел. Бу биш нәрсәнең кыйммәтләре үзләре китеб, анлар урынына зыйддалары (антиподлары – А.Х.) килгәндән соң беленәдер. Моны һәркем үз тәҗрибәсен аңларга була. Шушы эшләрнең булачагын беләбез, шулай булса да һаман алданыб, мәгърур булыб йөрибез. Менә шул җәһәтдән хәзрәт рәсүл өммәтләренә хәтерләренә төшерә, гафләт итмәү хакында тәнбиһ кыладыр.
Гарәб шагыйрьләрендән бер шагыйрь әйтә:
الأمـــل طـــــــــــــول غـره قـــد*** أشـتـغـل بـدنيـاه مـــــــن يا
الـعـمـــل صنــــــــــــدوق والقبــــــر*** بـغتــة يـأتـي المـــــــــــوت
الأجـــل منــــــك دنـــــــــا حتـــى ***غـفلــــــة فـــي تـــزل ولـــم
(0754) И, дөнья белән мәшгуль мескен адәм, киләчәккә һәртөрле бәлалар кору белән мәгърур булыб, алдагы аны шул алдануы белән гафил булды, гафләтдә булды үлем якынланганга кадәр, үлем килгәнгә кадәр. Вә халән (хәзер – А.Х.) ки, аңар хәбәр китергән иде, чәчләре, сакаллары агарды. Шулай ук кабернең гамәлләре сандыгы, гамәлләр урыны икәнен дә исәбкә алмады, ди. Локман хәкимдән риваять кылына:
للدود هو ما وأما فعمله لنفسه هو ما وأما فروحه لله هو ما فأما للدود وثلث لنفسه وثلث لله ثلث أثلاث ثلاث الناس إن بني يا

فجسمه
Локман хаким үзенең вәгазь фәсыйхат кылыб, әйтә адәм балалары өч кисәкгә бүлеб: өч кисәге өч нәрсә өчен, ди. Ул – җаны Аллаһы хозурына барачак, Аллаһыга кайтачак. Ягъни өчдән бере Аллаһы өчен, өчдән бере үзе өчен, өчдән бере картлар өчен, ди. Аллаһы өчен булганы – җаны Аллаһы хозурына кайтачак, үзе өчен булганы – изге гамәл булса да, начар, явыз гамәл булса да, - гамәлләр ди. Әмма картлар өчен булганы – тәне, җисме, ди. Мөхтәрәм кабер – дөнья йортарының иң соңгысы, Ахирәт йортларының әүвәлгесе, дигәнләр.
Хәзрәт Госман (рг) каберлекгә барган вакытда каты җылый торган булган. Бервакытда сораганлар: Ахирәт хәлләре сөйләнгән вакытларда да бу кадәр (0755) еламыйсың, диб. Әмма каберләрдә шулкадәр әсәрләнеб җылыйсың, дигәнләр. Шул вакыт хәзрәт Госман: Адәм баласының ахирәви хәяте шушы көндән башлана. Шушы кабергә куелган көндә аның хәле яхшылык белән башланса, аның бөтен ахирәви хәяте яхшы булачак. Шушы көндә беренче мәртәбә төб йортка кайткан көнебез ничек булачак – һич беремез моны ачык белмибез, диб җаваб биргән.
Сәләфләрдән бер галим дөньяда яшәвебезне, анда яхшылыклар кылуыбызны, үлгәннең соңында иң беренче мәртәбә яхшы гамәлләребезнең адәм баласына файда бирүен, ягъни ахирәви тормышыбызның матур булыб башланыб китеб, Аллаһының газабындан булуы хакында шушындый мисал китерә: дөньяда бер адәмнең өч дусты була: беренче дустын шул дәрәҗәдә ярата, хәтта мөмкин булса, аның өчен җанын да кызганмас иде. Икенче дустын, анысын тегенең кадәр яратмады, азрак ярата. Әмма өченче дустын теләр-теләмәс кенә дуст булыб йөри. Бер заман аның башына нахак бәла белән хөкемгә бирәләр. Бу адәм дустларын чакырыб, бик кайгырыб, үзенең башына килгән нахак бәлане, кайгысын сөйли. Миңа бу нахак бәладән котылу өчен сиңа бик ышанычлы шаһидлар, яклаучылар кирәк. Валлаһи, минем эшем хәраб, ди. Дустлары моңа һәркайсы вәгъдә бирәләр: Тыныч бул, без сине бу бәладән коткарабыз, бу эшдә синең һич гөнаһың юклыгыңны сөйләб, шәһадәт биреб, сине бу бәладән коткарырбыз, диб вәгъдә бирәләр. (0756) Вәгъдә кылынган көн – хөкем көне килеб җитә: болар дүртәүләб мәхкәмәгә казый, хаким хозурына китәләр. Урамдан беркадәр баргач, иң яраткан дусты төрле сәбәбләр, гөзерләр күрсәтеб, аерылыб кала. Өчәүләб мәхкәмәгә хөкем залына җиткәч, ишекдән кергән вакытда гына моның икенче дәрәҗәдәге дусты да ишекдән керми, ишек төбендә кала. Әмма моның өченче дусты, бу адәмнең теләр-теләмәс кенә дуст булыб йөргән адәме моның белән хаким хозурына барыб, суд залында моның хакында шундый ышанычлы дәлилләр белән бу адәмне яклый, химайә калуы аркасында бу адәмне гаебсез тавыб, котылдырыб чыгаралар. Дөньяда яшәгән вакытда дөнья дагы шушыңар охшый, иң беренче адәм баласының сөйгән дусты – дөнья малы, дөнья безгә шуклкадәр матур, дөнья малы шулкадәр сөекле булыб күренә, дөнья малы өчен бик күбләрнең җанларындан да аерылалар. Дустлары белән дошман булалар, туганларыннан аерылышалар, ата-аналарын рәнҗетәләр, мал өчен әллә нинди хыянәтләр, ялганлардан да курыкмый шулкадәр малны сөеб. Әмма икенче дәрәҗәдәге дусты – туганлары, балалары, дустлары. Әмма өченче дәрәҗәдәге, нәфсенә бик авыр булган, теләр-теләмәс кенә эшләгән изге гамәлләре, яхшылыклары. Нәфескә намаз уку да бик авыр, руза тоту да бик читен, тиешле урынларга мал белән ярдәм итү дә бик авыр. Шушы рәвешле адәм баласы дөньяда яшәб (كل نفس ذائقة الموت) мәүҗебенчә (0757) дөнья белән аерылыша. Гакыйбәт Әхкамель хакимин булган Аллаһы хозурына кайтырга вакыт килә. Суд залына барган кебек, Аллаһы кашында дөньяда кылган эшләребезгә җаваб вакыт килеб җитә. Хаким хозурында җаваб биргән вакытда яклаучы, гадел

шаһидлар кирәк булган кебек - безгә үлгәннең соңында үзебезне аклау өчен Аллаһының гадел хөкеменә тугъры килерлек чын дустлар кирәк булачак. Инде безнең яраткан дустыбыз – җаныбыз кебек күргән дөнья малы, бүген күзебез җомылды, ул бездән аерылачак. Урамда аерылыб калган иң яраткан кебек, ул дөньяда ук аерылачак. Икенче дәрәҗәдәге дустларыбыз – туганларыбыз, балаларыбыз, дөньядагы дустларыбыз, безене чыгыб, кәфенләб, кабергә кадәр озата баралар да, суд ишеге төбендә аерылыб калган икенче дустыбыз кебек, безне кабергә салыб күмәләр дә, үзләре кайтыб китәләр. Инде дөньяда вакытда теләр-теләмәс кенә дуст булыб йөргән, бик авырлык белән генә нәфсебез белән, шәйтаныбыз белән көрәшә-көрәшә кылган яхшы гамәлләребез үзебез белән кабергә керәчәк. Менә шушы яхшы гамәлләребез генә безне Аллаһының газабындан, Аллаһының ачуындан коткарыб калачак. Менә шушы изге гамәлләребез аркасында –
الْبَرِيَّةِ خَيْرُ هُمْ أُولَٰئِكَ الصَّالِحَاتِ وَعَمِلُوا آمَنُوا الَّذِينَ إِنَّ
ۖأَبَدًا فِيهَا خَالِدِينَ الْأَنْهَارُ تَحْتِهَا مِن تَجْرِي عَدْنٍ جَنَّاتُ رَبِّهِمْ عِندَ جَزَاؤُهُمْ
(0758) адәмләр җөмләсендән булыб, мәңгелек сәгадәткә, бәхеткә ирешеб, Аллаһының газабындан котылачаклар.
Хәзрәт Әбу Бәкер (рг) әйтә:
سفينة بلا البحر ركب فكأنما ،زادٍ بلا القبر دخل من
Яхшы гамәлләрдән башка кабергә керү көймәсез диңгезгә кергән адәм кебек, ди. Көймәсез диңгезгә керүне кадәр куркыныч булса, яхшы гамәлләрдән башка үлем дә шул кадәр куркыныч икән. Нәфесләребез, шәйтанларыбыз белән көрәшеб, кылган яхшылыкларыбыз Аллаһы кашында мәкбул булыб, Аллаһы газабындан котылыб, Аллаһының рәхмәтенә, Аллаһы дустлары җөмләсендән булырга насыйб булсын. Амин. Йә Мөҗибес саликин.
Казан шәһәре мәсҗед, җамигында Габделхәбир
бин Ярулла тарафындан сөйләнгән вәгазьләр.
(0761) 8 нче рәкымлы дәфтәр
1068 нче ел Миляди, гыйнвардан / 1387 нче Һиҗри Шәввал
Җомга вәгазьләре, шәһри Казан, мәсҗед Мәрҗани, №8.
1) Мал, балалар хакында.
2) Җумартлык (юмартлык – А.Х.) хакында.
3) Исраф хакында.
4) Ният хакында.
(0762) 1968 нче ел. 2 нче февраль
Җомга көн, Зөль Кагъдә
1387 Һиҗри, Зөль Кагъдә башы чаһаршәнбе көн, 31 нче гыйнварда булды, 1968 ел.
عظيم اجر عنده الله و فتنة اولادكم و اموالكم انما
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһының рәхмәтен өмед итеб, пәйгамбәребезгә чын өмед булуны теләб, ихлас белән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөседман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Шулай ук өстебезгә туган Зөл Кагъдә ае мөбарәк булыб, илләребез, җанларыбыз тыныч булыб, сәламәтлек гамәл гыйбадәт белән яхшы юлда үткәрергә насыйб итсен. Амин.
Сәдака бирү җумартлык (юмартлык – А.Х.) белән Миңа якын булыр дисәң, бән дәхи рәхмәтем илән сиңа якын булырмын, дигән.
(0763) Мөхтәрәм җәмәгать! Узган җомгада сөйләгән сүзләреме беркадәр өстәмә рәвешдә Аллаһының каләмен вә пәйгамбәремезнең мөбарәк сүзләрен исегезгә төшереб үтмәк

булам. Җенабе Хак дөрест әйтеб аңлатырга, дөрест итеб аңларга ярдәм бирсен.
Аллаһы газзә вә җәллә хәзрәте Каләм Шәрифдә беренче урында әйтә:
عظيم اجر عنده الله ان و فتنة اولادكم و اموالكم انما اعلموا و
ди. Белегез: малларыгыз, балаларыгыз – бары фетнәдер, Ахирәт гамәлләрендән коры калдыручыдыр. Хакыйкатдә Аллаһы кашында Кыямәт көнендә малларыгыз, балаларыгыз сәбәбле сезгә зур әҗер вә сәваблар бардыр, ди.
Шушы Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә аятьләрендән безгә ике төрле халь аңлана. Беренче зур мәхәббәт куеб, күб мәшәкатләр белән үстергән балаларыбыз хакында безгә Аллаһының вәгыйде, Аллаһының газабына очрау куркынычы булса, икенче җәһәтдән, - шушы малларыбыз, балаларыбыз сәбәбле Аллаһының зур вәгъдәләре, зур әҗер вә сәвабларга ирешүебез мөмкин икәне аңлана. Әгәр без Аллаһының пәйгамбәре аркылы (әр-Рәхманер Рәхим), Аллаһы тарафындан килгән хак дин өйрәтүе буенча гамәл итә белсәк, менә бу вакытда безнең малларыбыз һәм балаларыбыз фетнә, газаб түгел, бәлки малларыбыз, балаларыбыз безне дөнья Ахирәтдә бәхеткә, сәгадәткә ирешдерүче безнең дустларыбыз булырга мөмкин икән. Әмма инде шушы малларыбыз, балаларыбыз безгә (0764) дөнья Ахирәттә фетнә вә газаб булуы да мөмкин икән. Һәр ике хальгә ирешүебез, иҗтиһад итсәк, без теләкләребезгә ирешергә мөмкинлек үз кулыбызда дияргә була. Һәркайсыбызга бик мәхәббәтле булган дөнья малы, изге ният бәлән хәләлдән кәсеб итүне исдә тотыб, дөньяви кәсебләребездә һәрвакыт Аллаһы хозурына барыб, хисаб бирүне хәтердән чыгармый, алдау, хыянәт, ялган, җәбер-золым кебек начар гадәтләрдән сакланыб, дөрестлек белән табкан малларыбызны тиешле урынларга сарыф итә белсәк, исраф булган урынларга тотудан саклансак, бу вакытда безнең малларыбыз безгә дөньяда дуст булыб, Ахирәт бәхетенә ирешдерәчәк.
Хосусан рәсүлулла (сгс) нең түбәндәге сүзләрен искә алыб:
كَانَ وَقَدْ كَذَا وَلِفُلَانٍ كَذَا لِفُلَانٍ قُلْتَ الْحُلْقُومَ بَلَغَتْ إِذَا حَتَّى تُمْهِلُ وَلَا الْغِنَى وَتَأْمُلُ الْفَقْرَ تَخْشَى شَحِيحٌ صَحِيحٌ وَأَنْتَ تَصَدَّقَ لِفُلَانٍ
Ягъни: сәдакаларның әфзале (иң яхшысы – А.Х.), артыграгы, иң сәваблысы – үзең сау-сәламәт, малны бик яратсаң, фәкыйрьлекдән куркасың, байлыкны бик теләгән вакытыңда биргән сәдакадер. Игътибарсыз булма! Дикъкать кыл, уйлаб кара! Үлем хәстәлеге килгәндән соң, фәлән нәрсәм фәләнгә, фәлән нәрсәм фәләнгә, диб әйтерсең дә ул вакыт синең хуҗалыгың киткән булыр. Бу вакытда бу рәвешле васыять әйтү дә күб файда таба алмассың, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Нәкъ пәйгамбәребезнең шушы сүзе белән (0765) гамәл иткән адәмләребез бар. Алар үзләре исән вакытда мәсҗедебезгә узган җомгада гына да никадәр адәмләр фидия сәдакасы диб табшырдылар. Менә шушы, үзләре сау-сәламәт, бәлки күб еллар гомер сөрүләре дә мөмкин булган. Бер вакытда үз куллары белән мәсҗедебезгә ярдәм итүләр – һәркайсы сәдака җария булыб, үзләре белән бергә кабергә барачак, Кыямәт көнендә ярдәмче булачак. Үзләренә дуст булыб, Аллаһы хозурында зур әҗер вә сәвабларга ирешдергән Коръәндә “хәер”, “фазыл”, “рәхмәт” исемләре белән аталган хәерле мал – менә шушы булачак. Әгәр малны дөрест юллар белән тавыб, дөрестлек белән сарыф итә белсәң, менә бу дөнья маллары шәригатемез каршында мәмдух булган гамәлес салихат җөмләсендән булыб, әхкамель хакимин – Аллаһы хозурында безнең йөзебез ак булырга шаһид булыб, безне Аллаһының газабындан коткарыб, мәңгелек сәгадәткә ирешүебезгә сәбәб булыр, инша Алла. Бер фидия сәдакаларыбыз гына түгел, башка тиешле урынларга – фәкыйрьләргә, туганнарыбызга үзебезгә нәфкасе тиешле кешеләрне тәрбияләвебезгә, Аллаһы ризалыгын өмед итеб, уздырылган дога мәҗлесләребезгә тоткан

акчаларыбыз һәм укучы балаларга ярдәм, балалар укытуга тоткан акчаларыбыз - һәркайсы файдалы, хәерле мал булыб, Ахирәт көнендә безгә чын дуст булган, ярдәм итүчеләр булса кирәк.
(0766) Шулай ук газиз балаларыбызны әдәб-тәрбиягә, рәхимле-шәфкатьле булырлар, якты чырайлар, тәмле сүзле булыб, бөтен файдасы тиярдәй кеше идеб тәрбияләргә тырышсак, шушы балаларыбыз безне үлгәннең соңында яхшылык белән искә алсалар. Менә шушындый балалар калдыра алсак иде.
Коръән Кәримдә вәгъдә кылынган:
و ان عنده اجر عظيم
дигән сүзләренә мөсәддак булыб (ышаныч белдереб, ышаныб – А.Х.), инша Алла, зур әҗер вә сәвабларга ирешербез.
Инде дөньяга, дөнья малына бик артык мәхәббәт кылыб, хәрамын-халәлын тикшерми, Аллаһыны, Аллаһы хозурына баруны исдән чыгарыб, алдау, хыянәт, ялган, җәбер-золымлардан курыкмый, шушы рәвешдә мал җыеб да, шушы табкан малларыбызны хәрам булган урынларга,эшләргә исраф кылмасак иде. Шулай ук газиз балаларыбызны да кечкенә вакытда әдәб, инсаф, күркәм гадәтләргә өйрәтми, укытмый калдырыб, аларның бөтен кешелек дөньясына зарарлы адәмләр булыб калсалар, без шушы сәбәбенә керешми вә без сәбәбле дөнья Ахирәт үкенечкә калуыбыз куркынычы бар, Аллаһы Үзе сакласын.
“Мөнафикыйн” сүрәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُلْهِكُمْ أَمْوَالُكُمْ وَلَا أَوْلَادُكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ فَأُوْلَئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ وَأَنفِقُوا مِن مَّا رَزَقْنَاكُم مِّن
قَبْلِ أَن يَأْتِيَ أَحَدَكُمُ الْمَوْتُ فَيَقُولَ رَبِّ لَوْلَا أَخَّرْتَنِي إِلَى أَجَلٍ قَرِيبٍ فَأَصَّدَّقَ وَأَكُن مِّنَ الصَّالِحِينَ
(0767) Аллаһының ирешдерә торган, Аллаһы нигъмәт йорты булган җәннәтгә тоташдыра торган. Дөньяда яшәгән вакытда адәм балалары арасында татулык, дустлыкны арттыра торган күркәм сыйфат – җумардлык хакында һәм аның нәкъ киресенчә булган Аллаһының рәхмәтендән ераклашдыра, Аллаһы газабына якынайта торган һәм адәмләр арасында өлфәт, мәхәббәтне бетереб, адәмләрдән ераклашдыра торган, динебез һәм пәйгамбәребез тарафындан тыелган саранлык хакында: беркадәр пәйгамбәребезнең сүзләрен сөйләмәк булам, Аллаһы ярдәм бирсен.
(0768) Һәркайсыбызга мәхәббәтле булган дөнья малларын дөрест юл белән, халәл юллар белән табканның, шуларны киләчәгебез өчен дуст булырлык, үзебезгә ярдәмче булырлык рәвешдә сарыф кыла белсәк, шулай ук балаларыбыз хакында да кече яшьдән үк әдәбле, инсафлы, халыкка рәхимле, шәфкатьле, файдалы адәм итү теләге белән, шуның сәбәбенә керешсәк иде. Инша Алла шушы изге ниятләребез аркасында Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтләренең Коръән Кәримдә “Саба” сүрәсендә зур сөенечләр вәгъдә кылган адәмләр җөмләсенә керүебез бик мөмкин булган сөенечле хәлләрдән булачак.
Алланың колларына вәгъдә кылган зур мөкафәтләренә ирешәчәкбез. Аллаһы хәзрәте “Саба” сүрәсендә әйтә:
وما أموالكم ولا أولادكم بالتي تقربكم عندنا زلفى
Ягъни: Сезнең балаларыгыз да, малларыгыз да Безгә сезне якын итмәс. (Саба, 34).
Инде, җәмәгать! Бу вакытда үкенү файда бирмәс, гүя Аллаһы хәзрәте әйтә:
و لن يؤخر الله نفسا اذا جاء اجالها
Инде берәүгә әҗел вәгъдәсе ирешдеме, инде ул адәмнең гомере һич кичектерелми. Һәр эшне вакытында кадерен белеб, файдаланыб калырга кирәк.
و الله جبير بما تعملون
Аллаһы хәзрәте безнең һәрбер гамәлләребезне белеб, хәбәрдар булгучыдыр.
Җенабе Раббел галәмин хәзрәте үзебезнең малларыбызны үлгәннең соңында үзебезгә

шәфагатьче, ярдәмче булырлык рәвешдә тота белергә, балаларыбыз үзебезгә үлгәннең соңында догачы булырлык рәвешдә тәрбия кылырга насыйб булсын. Амин.
(0769) عَمِلُوا بِمَا الضِّعْفِ جَزَاءُ لَهُمْ فَأُولَئِكَ صَالِحًا وَعَمِلَ آمَنَ مَنْ إِلَّا
Мәгәр шундалаен адәмләрнең генә маллары, балалары Безгә якында иләр, алар Аллага иман китереб, һәр эшләрендә Аллаһыны исдә тотыб, маллары, балалары сәбәбле гамәлес салихат кылдылар. Аларның шушы яхшы гамәлләренә каршы мөкафәтләре артдырыб бирелер.
آمنون العرفات فی هم و
Менә болар күңелләренә мәкрүһ күрелгән һәрбер күңелсез хәлләрдән әмин булыб, котылыб, җәннәт сарайларында, җәннәт чардакларында булачаклар, ди. Аллаһы насыйб итсен.
(0770) И, иман китергән адәмләр! Сезне малларыгыз, балалар Аллаһының зикерендән мәшгуль итеб, Аллаһыны исдән чыгаруга сәбәбче булыб, сезне һәлакәткә төшермәсенләр. Дөнья маллары, балалары сәбәбле, аларга артык мәхәббәт итеб тиешле рәвешдә була алмаулары, аларны зур үкенечкә калдырачак. Моның соңында:
الصَّالِحِينَ مِنَ وَأَكُنْ فَأَصَّدَّقَ قَرِيبٍ أَجَلٍ إِلَىٰ أَخَّرْتَنِي لَوْلَا رَبِّ فَيَقُولَ الْمَوْتُ أَحَدَكُمُ يَأْتِيَ أَنْ قَبْلِ مِنْ رَزَقْنَاكُمْ مَا مِنْ وَأَنْفِقُوا
Ягъни: үзегезнең малларыгыздан, ризыкларыгыздан (болардан морад гастәр закят кебек важиб сәдакалар диб дә әйткәнләр) үлем килгәнче инфак кылыгыз (сарыф итегез – А.Х.). Инде үлем килгәннең соңында әйтер: и Алла, аз гына вакытка минем әҗәлемне кичектерсәң, үземнем малымдан тиешле урынларга сәдака кылыб, яхшы адәмләрдән булыр идем.
(0771) 1968 нче ел, 9 нчы гыйнварь, җомга көн / 10 нчы Зөль Кагъдә 1387 Һижри.
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Җомга көнен хөрмәтләб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Җомгага килүләребез мөбарәк булыб, барчаларыбызга Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате насыйб булсын иде.
الْغُصْنُ ذَلِكَ فَسَاقَهُ ، أَغْصَانِهَا مِنْ بِغُصْنٍ تَعَلَّقَ سَخِيًّا كَانَ فَمَنْ ، الدُّنْيَا فِي مُدَلاةٌ أَغْصَانُ لَهَا ، الْجَنَّةِ أَشْجَارِ مِنْ شَجَرَةٌ السَّخَاءَ
فَسَاقَهُ ، أَغْصَانِهَا مِنْ بِغُصْنٍ تَعَلَّقَ بَخِيلاً كَانَ فَمَنْ ، الدُّنْيَا فِي مُدَلاةٌ أَغْصَانُ لَهَا ، النَّارِ أَشْجَارِ مِنْ شَجَرَةٌ وَالْبُخْلُ . الْجَنَّةِ إِلَى
النَّارِ إِلَى الْغُصْنُ ذَلِكَ
Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгс) әйтә: Җумартлык җәннәт агачларындан җәннәт эчендә бер агач, ди. Аның ботаклары җир өстендә, ди. Кем дә кем шушы агачның бер ботагына тотынса, ябышса, инде ул ботак аны җәннәткә тарта, өстери ди. Шулай ук шушы мактаулы сәгатьнең, күркәм гадәтнең зыйдде булган, капма-каршы, начар сыйфат – саранлык тәмугъ эчендә булган бер агач, ди. Шулай ук аның да ботаклары җир йөзенә таралган, җир өстендә, ди. Шушы ук хәдисне безгә тагын да икенче гыйбарә белән әйтә:
فمن النار في شجرة والشُّحُّ ،الجنة يُدخِلَه حتى الغصن يتركه فلم ،منها بغصن أخذ سخياً كان فمن الجنة في شجرةٌ السَّخاء ان
النار يدخله حتى الغصن يتركه فلم منها بغصن أخذ شحيحا كان
(0772) ди. Ягъни: Сәха (юмартлык) исеме белән аталган бер күркәм сыйфат, матур гадәт – җәннәт эчендә булган бер агач ул, ди. Инде кем дә кем күркәм сыйфатга ия булды, ягъни исә инде ул җәннәт эчендә булган агачның бер ботагына тотынды, ди, инде җумартлык агачының ботагына тотындымы, ул ботак аны җәннәтгә керткәнче, үзендән калдырмый, ташлаб китми, һичшиксез аны җәннәткә кертә, ди. Шулай ук җумартлыкка капма-каршы булган начар гадәт – саранлык: тәмугъ агачларындан бер агач булыб, әгәр бер кеше бик каты саран булса, ул кеше тәмугъ агачының бер ботагын тотды инде, ул ботак аны тәмугъга керткәнгә кадәр үзендән калдырмый инде аны, ди. Мондан башка да

рәсүлебезнең юмартлык хакында сөйләгән хәдисләре бик күб. Җөмләдән берсе: үзебез ана телебезгә әйләндереб, тәрҗемә кылыб иткәндә болай була: җумарт адәм Аллаһының рәхмәтенә якын, Аллаһының җәннәтенә якын һәм дөньяда вакытда адәмләрнең һәркайсына якын, ди. Җумартлык шундый бер матур сыйфат, ул җумартлык дошманларын да дуст кыла, дошманларның дустлыкны арттыра. Җумарт адәмгә бөтен кеше дуст була, җумартлык бөтен адәм балалары белән тыныч-тату яшәргә сәбәб булганлыкдан, бер адәмдә шушы күркәм сыйфат табыла икән, ул адәм дөньяда ук бәхетле була. Инде саранлык, Аллаһы сакласын, дөнья Ахирәтдә бәхетсезлеккә сәбәб булган, дөнья Ахирәтдә хәраблыкка, хурлыкка төшерә торган иң начар сыйфат. Артык саран кешеләр китабларда ләʼим атала.

(0773) Ләʼим кеше – шундый кеше, үзе дә ашамый, җәмәгатьләрендән, гаиләсендән кызгана. Менә мондый адәмләр нәкъ печән өстендә яткан усал эт кебек. Эт печәнне үзе дә ашый алмый, башка печән ашардай хәйванларны да җибәрми. Шушындый артык ифратка киткән саран адәмләрне күзебез белән күрдек. Өстләрендә җүнле (юньле – А.Х.) киеми кимиләр, тамаклары җүнле ризык күрми, мескен кыяфәттә җөреб, аларның маллары кая китде?

Җенабе Раббел галәмин хәзрәте менә бу кешеләргә дөньяда ук җәзасын бирде, Ахирәтнең газабы, Аллаһы сакласын, тагын да катырак булачак.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бик яхшы аңларга кирәк, җумартлык кылу – мал белән генә җумартлык кылу түгел, бәлки җумартлык кылу – күңел белән, тел белән, барлык вөҗүдебез белән җумартлык кылу бар. Шуширван Гаделдән сораганлар малы булмаган фәкыйрьләр: без бик җумартлык кылыр идек, безнең малыбыз юк бит, диб. Шушы вакыт Шуширван Гадел әйтә: һәркемнең кулындан килә торган, эшли ала торган җумартлыклар да дөньяда бик күб, ди. Күңелең белән бөтен адәмләргә яхшылык, изгелек теләү, бөтен адәм балаларына якты чырайлы булу, бөтен адәм балаларына тәмле телле булу, – менә бу эшләр һәркайсы юмартлыкның әгълә дәрәҗәсе булыб, һәркемнең хәлендән килә торган, җәннәткә тоташтыра торган, тәмугъдан ерак кала торган изге гамәлләрнең сөеклесе, диб җаваб бирә. Шулай ук үзеңнең бер белгән эшең бар, шул белгән эшеңне шул эшдә яхшы тәҗрибәң бар икән, менә шушы үзеңнең эшеңне башкалар белән уртаклашу кирәк (0774) динең өчен, кирәк булган белемлек, кирәк Ахирәтең өчен, кирәк булган файдалы сүзне яки эшне башкалар белән уртаклашуың, башка өйрәүең, – менә шушы һәркайсы синең тарафдан күрсәтелгән җумартлык булыб, җәннәтгә тарта торган, алыб бара торган яхшы гамәл булачак.

Инде менә нәкъ шушы эшләрнең киресе булган, күңелебездә башкаларга көнчелек кылыб, башкаларга яхшылык теләмәсәң, башкаларга начарлык теләб, аларга шушындый күңелле булсак, якты чыраебызны, тәмле сүзләребезне кызганыб, караңгы чырайлы, ачы телле булсак, белгән белемләребезне башкаларга өйрәтүдән ерак торсак, менә бу эшләр һәркайсы күңелләребез, телләребез белән саранлык күрсәтү булыб, адәмләрдән ераклашдыра, дустлык-тынычлыкны, өлфәт-мәхәббәтне бетерә торган, Аллаһының рәхмәтендән ераклашдыра торган, тәмугъка якынайта торган, дөнья Ахирәтдә бәхетсезлекгә сәбәб була торган, үкенечкә калдыра торган начар сыйфатлар. Мондый эшләрдән ерак булу барыбызга тиешле булган, ваҗиб, сөннәт булган эшләр. Нитек рәсүлулла (сгс) әйтә:

بالسلام بخل من الناس ابخل

сезнең саранығыз шул кеше, ди, кем сәлам бирүдә саранлык кылды, ди. Икенче хәдисендә әйтә:

علي يصل فلم عنده ذكرت من البخيل
ди. Бер кешенең алдында мине искә алыныб да миңа салават әйтмәгән кеше сезнең иң сараныгыз, ди. Инде пәйгамбәребезнең бу мөбарәк сүзләрендән аңлана ки, җумардлык, саранлык мал белән генә булмый икән, бәлки күңел белән, тел белән җумарт, саран булырга мөмкин икән.
(0775) Инде, җәмәгать! Бу саранлык сәлам бирүдә генә түгел, шулай ук сәлам алуда да саранлык булырга мөмкин. Бәгъзе адәмләребездә шундый күңелсез хәлләр сизелә, үзләрен бик артык суфига, тәкъвага санаб, ифратка китеб, кепка кигән яки эшләпә кигән адәмдән дә сәлам алмаган кешеләр ишетелә. Менә бу эшләр һәркайсы, бигрәк дә мөселман адәмләргә, бик сакланырга тиешле булган хәлләр.
Рәсүлулла үзенең башка диндәге адәмләргә хат язган вакытда:
الهدى ابتع من على السلام
диб яза торган булган. Берәү олылыклаб (олылаб – А.Х.) сәлам бирә икән, ул адәмнең сәламен алмасак, ул нинди мөселманлык булыр. Мәрхүм Аллаһының рәхмәтендә булсын. Казан мәдрәсәсендә күб еллар дәрес иткән, күб мөдәррисләр чыгарган Җиһанша хәлифә бар иде. Ул тәмәке тартыб җыелыб торган адәмләргә һәм дә сәлам биреб, хәтта хәлифәнең шушы күркәм мөгамәләсен күреб, бик күб инсафка килүләрен сөйли иде. Менә шушы яхшылык белән үрнәк булырга кирәк.
Аллаһы насыйб итеб итсә, тиздән җәйгә чыгабыз. Тагын да дөньяның һәр тарафындан мәсҗедебезне карар экскурсантлар, туристлар, һәртөрле яшьләр килер. Шушы килгән кунакларга, яшьләргә бик игътибарлы булырга кирәк, үзебезне әдәбле, инсафлы, әхлаклы итеб күрсәтергә тырышырга, җакты чырай, тәмле сүз, матур итеб озату һәр инсаният һәм исламият вазыйфасы булачак. Безнең күрсәткән гадәт-холыкларыбыз, аларның хатирә дәфтәренә язылачак, хатирә дәфтәрендән, тарих сәхифәләренә кереб (0776) калуы да бик ихтимал булган хәлләрдән. Менә шушы вакытларда без телләребез, гадәтләребез белән аларга җумардлык күрсәтсәк, киләчәктә үзебез дөньядан киткәннең соңында да яхшылык белән зикер кылынырга, искә алынырга сәбәб булыр. Инде үзебез үлгәннең соңында яхшы гадәтләребез белән искә алалар икән, менә безнең һәркайсыбызга дога булыб, безгә әҗер-сәваб булачак. Инде кирәк кемдән генә булса да якты чырайларыбызны, тәмле телләребезне кызгансак, караңгы чырайлы, төксе телле булсак, бу күңелсез гадәт дөньяда адәмләрдән ераклаштырса (чөнки аны беркем дә яратмый), Ахирәтдә җәннәтдән ераклаштыра, Аллаһы Үзе сакласын.
Хөрмәтле бабалар! Шушы күркәм сыйфатны үзебезнең ана телебездә нинди матур итеб сөйләб калдырганлар. Ипи-тоз, якты йөз, тәмле сүз – җан азыгы, яман сүзе баш казагы. Саранның малы үзенә боермас. Шушы хәлләрне һәркайсымыз күзебез белән күреб торабыз.
Аллаһының рәхмәтендән ерак кала торган начар гадәтләрдән ерак булуга пәйгамбәребез кушкан. Аллаһының рәхмәтенә, Аллаһының нигъмәт йортына тоташтыра торган күркәм холыклар белән холыкланыб, Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга җәннәт йорты вә җәннәт нигъмәтләре белән мөшәррәф булырга насыйб итсен.
(٤١٦) الخلق سؤ و البخل مؤمن فى يجتمعان لا خصلتان
(0777) 1968 нче Миляди, 16 гыйнвар, җомга көн / 1387 Һиҗри, 17 нче Зөль Кагъдә
Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабее Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Дөнья Ахирәтдә сәламәтлек, Аллаһының рәхмәте, Аллаһының бәрәкате барчаларыбызга

насыйб булсын.
Мөхтәрәм мөселманлар! Узган җомгада җумартлак һәм саранлык хакында сөйләгән идем. Узган җомгада ут булмау сәбәбле түбәндә утыручылар ишетмәгәнлекдән беркадәр кабатлау булса да, бәгъзе берәүләрнең теләве буенча әйтеб китергә туры килә... Алдагы битләрдән кара...
Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам диненең тоткан юлына безгә өйрәткән кагыйдәләрен тикшереб карасак, пәйгамбәребезнең безгә өйрәткән юлы: ифрат-тәфритдән бик пакъ, саф булыб, һәрвакыт тәвәссат (уртача, чамалы; рус.: умеренный – А.Х.) дәрәҗәсендә, һәр эшебездә уртача булу белән тәвәссыя кылынган хәзрәт рәсүл (сгс) әйтә:
اوسطها الامور خير
Ягъни: хәерлесе: эшләребездә уртача булу хәерлерәгедер, ди. Икенче бер хәдисендә:
اوسطها الله الى الاعمال احب
Һәрбер эшләрнең Аллаһы сөеклерәге, Аллаһыга якынайта торган гамәлләр - уртача булганыдыр. Инде шушы рәхмәтенә тоташтыра торган мактатаулы сыйфат, гадәт булган – җумартлык сыйфаты. Әгәр дә тәфрыйт тарафында, ягъни тиешле урында малларыбыз, телләребез белән ингам, ихсан, ярдәм һәм телләребез белән кешеләргә төксе телле булыб тәмьле телләребезне кызгансак, менә тәфрыйт булыб, Ислам дине кашында мәзмум булган начар сыйфат, начар гадәт була.
(0778) Инде шушы җумартлык – мактаулы сыйфат да, ифратка артыкка китсәк, менә бу гадәт тагын Аллаһы кашында мәзмум булган, начар сыйфат булыб, исрафка керергә мөмкин. Гүя Аллаһының каляме шәригатьдә исраф хакында бик күб сүзләр булыб, җөмләдән берсе "Әгъраф" сүрәсендә:
المسرفون يحب لا انه تسرفوا لا و اشربوا و كلوا
Ягъни: Аллаһы халәл кылган нәрсәләрдән ашагыз, эчегез. Шушы халәл ризыкларыгызны, халәл малларыгызны исраф кылу белән хәрамга әйләндермәгез. (المسرفون يحب لا انه)
Дөрестлекдә, хакыйкатьдә Ул – Аллаһы Тәгалә хәзрәте исраф кылучыларны сөйми, ди. Һәм "Бәни Исраиль" сүрәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:
كَفُوراً لِرَبِّهِ الشَّيْطَانُ وَكَانَ الشَّيَاطِينِ إِخْوَانَ كَانُوا الْمُبَذِّرِينَ إِنَّ * تَبْذِيراً تُبَذِّرْ وَلَا
ди. Ягъни: малны урынсыз урынга сарыф кылу белән исраф кылмагыл, ди. Урынсызга сарыф итү, исраф кылу мал нигъмәте хакында гына түгел, сәламәтлегебез нигъмәте хакында исраф кылудан аракы эчү, тәмәке тарту, әфьүн – һәркайсы сәламәтлекгә зарар булган нәрсәләр, һәркайсы сәламәтлегебезне исраф кылу була.
الشياطين اخوان كانوا المبذرين ان
Менә шушы Аллаһы биргән нигъмәтләрен: кирәк мал нигъмәте, кирәк сәламәтлек нигъмәте булсын, урынсыз урынга сарыф кылучылар – болар шәйтан кардәше булдылар, ди.
كفورا لربه الشيطان فكان
Шәйтан үзенең Раббысына көфран нигъмәт кылучылардан булды, ди. Инде шәйтанның кардәше, ди, шәйтан була. Шәйтан – Аллаһының рәхмәтендән ерак булыб, аның төб кайтачак урыны – Аллаһының газаб йорты, тәмугъ булачак.
(0779) Инде тагын да шул ук "Бәни Исраиль" сүрәсендә Аллаһы газзә вә җәллә хәзрәте үзенең пәйгамбәренә хыйтаб кылыб әйтә: "Моның хөкеме барчабызга гамь" булыб, без дә шуның белән гамәл итәргә, эш кылырга тиешбез.
مَحْسُورًا مَلُومًا فَتَقْعُدَ الْبَسْطِ كُلَّ تَبْسُطْهَا وَلَا عُنُقِكَ إِلَىٰ مَغْلُولَةً يَدَكَ تَجْعَلْ وَلَا
ди. Ягъни: Саран булыб, башкалар өчен җумартлык ишегеңне багъланмыш бикләнмеш кылмады. Шуның белән бергә:

البسط كل تبسطها لا و
Син ифратка китеб, артык җумартланыб, үзеңгә калдырмый, актык нәрсәңне биреб бетермә, ди.
محسورا ملوما فتقعد
Әгәр шушылай ифратка китеб, үзеңгә калдырмый, актык нәрсәңне бирсәң, Аллаһы кашында һәм адәмләр хозурында шелтәләнмеш булырсың һәм үкенечкә калырсың, ди. Бу аятьнең әйтүенә сәбәб – хәзрәт рәсүлгә бер бала килеб: йә рәсүл, анамның өстенә киярлек күлмәге юк, анам күлмәк сорады, ди. Шул рәсүл (гс) бераздан: әйләнеб кил, диб, бала анасына кайтыб, әйткәннең соңында баланы тагын җибәрә: бар, бар, артык күлмәге булмаса, өстендәге күлмәген булса да бирсен, ди. Бала килгәч, рәсүл (гс) өстендәге күлмәкне биреб, үзе ялангач калыб, хәзрәт Биләл намазга азан әйтде. Сәхабәләр намазга китделәр, рәсүл (гс), күлмәге булмау сәбәбле, намазга чыга алмады. Шул вакыт Аллаһы тарафыннан шушы аять назел була.
Мөхтәрәм җәмәгать! Безгә бик дикъкать итәргә тиешле нәрсә: Ислам дине безне һичбер вакытда да көч җитмәгән нәрсә белән көчләмәгән.
(0780)
وسعها الا نفسا الله يكلف لا
Кирәк гыйбадәт хакында, кирәк малларыбыз белән ингам, ихсан-яхшылык кылу хакында без һәрвакыт һәр эшләребездә уртача булу белән боерган, кушкан һәр эштә уртача булуны Аллаһы кашында сөекле гамәл итеб күрсәткән. Искә алырга тиешле эшләребездән Аллаһы ризалыгы эстәб (теләп – А.Х.), сәваб өмед итеб, уздырган Коръән мәҗлесләрендә артык тәкәллефләрдән бик сакланырга тиешле. Шушы сәваблы мәҗлесләребездә ифратка китеб, үзебез көндәлек тормышыбызга кимчелек китерердәй бурычка керүләр булса, яки ризыкларыбызны кирәгендән артык, бик мул булсын, мәҗлесдә ашалыб бетмичә тәмле, татлы нигъмәтләребез помой чокырларына ташланса, бу күңелсез хәлләр исрафка кереб, көфран нигъмәт булу куркынычы бар. Хәзрәт рәсүл (гс) әйтә:
عليها فتصدق بنفسك ابدأ
Сәдака хакында ул: үзеңгә сәдака кыл, ягъни үз хаҗәтләреңне тәмам кыл, бурычларың булса, бурычларыңны түләб, үзеңне мәсъүлиятдән коткар, дигән. Шушылай мәҗлесләр сәбәбле бурычка керсәң, я булмаса, өстебезгә тәрбиясе тиешле булган балалар безнең тәрбияләренә кимчелек килердәй булса, мондый хәлләрдә Аллаһы каршында җавабка калуыбыз бик мөмкин. Инде тормышыбызда кирәк гыйбадәт бабында, кирәк мөгамәлат бабында ифратка китүдән бик сак булырга. Гыйбадәт бабында ифратка китсәк, бу – тәкъвалык булмаенча, мира’илык (шик – А.Х.) булыб, диндә гөлү (бөек, бөеклек – А.Х.) кылу булырга. Мәсәлән, кием-салым хакында, кыска киемләр белән намаз дөрест түгел, дисәк, радио тыңлау, телевизор карау, магнитофон кебек нәрсәләр хакында – ярамый, дөрест түгел (0781), диб фәтвалар бирсәк, менә бу эшләр һәркайсы диндә артыкка китү булыб, динебез тарафыннан тыелган, пәйгамбәребез тарафыннан тыелган, сакланырга тиеш булган эшләрдер. Кайчандыр Коръәннең хөкеме Кыяматкә кадәр бакый хатимен нәби, бөтен пәйгамбәрләрнең соңгысы диб, иман итүебез нәрсә булыб калыр.
Инде шушы адәм баласының гакылы, гыйльме аркасында фәннең тәрәккый итүе сәбәбле шушындый радио, телевизор, магнитофон һәм башкалар хакында шушылай ялгыш карашда булсак, аңлы-белемле адәмләребез Ислам диненә ничек карарлар. Юк, бу дин искергән икән, бу гакылга, хикмәткә, мәдәниаткә, фәнгә каршы килә икән, диб әйтмәсләрме? Юк, җәмәгать, Ислам дине гакылга, хикмәткә моафыйк булган. Һичбер вакытда, һичбер урында гыйлемгә, мәдәниаткә, дөнья тормышында мөгамәләт бабында

киләчәкдә тагын да әллә нинди гаҗәб нәрсәләр барлыкка килсә дә, Ислам динендә боларның берсенә каршылык, бу ярамый, теге хәрам, мәкруһ дигән күзлекдән карау, гакыл ияләренә динене ямьсез итеб күрсәтүгә, дингә нәфрәт күзе карауга сәбәб булачак. Нитәк рәсүл (гс):
تنفروا لا و بشروا ،تعسرو لا و يسروا
дигән сүзене хыйляф булачак.
Кыяматкә кадәр хөкеме бакый булган Коръән Шәрифтән Коръән хөкемен дөрест аңларга һәм дөрест итеб аңлатырга һәм пәйгамбәребезнең сүзләре белән гамәл итеб, барчаларыбызга пәйгамбәребезнең шифагәтенә ирешергә Аллаһы насыйб итсен.
(0782) 1968 нче ел, 23 нче февраль, бомга көн / 1387 Һиҗри, 24 нче Зөль Кагъдә
Әгүзе билләһи минәш шәйтанир Рәҗим. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Җомга көнебез мөбарәк булыб, илләребез тыныч булыб, саулык-сәламәтлек, тынычлык белән күб елларга киләчәк җомгаларны да шадлык белән күрергә Аллаһы насыйб итсен.
الله إلى فهجرته ،ورسوله الله إلى هجرته كانت فمن ،نوى ما امرئ لكل وإنما ،بالنيات الأعمال إنما :سلم و عليه الله رسول قال إليه هاجر ما إلى فهجرته ،ينكحها امرأة أو يصيبها لدنيا هجرته كانت ومن ،ورسوله
Сахих әл-Бохари. Сахих Мөслим.
Хәзрәт рәсүл (гс) әйтә: мөкәллиф булган бәндәләрнең кылган эшләре бары ният белән генә. Аллаһы ризалыгы һәм Аллаһының рәсүле өчен, һиҗрәт кылган булса, ул кешегә һиҗрәт кылу сәвабы булыр. Әгәр һиҗрәте дөнья өчен, яки бер хатынны никяхлану өчен булса, дөньяви максадларына, яки ул хатынына никяхланудан гыйбадәт булыр. Рәсүл (сгс) бу хәдисне бу адәмнең күңелендәге ниятен белгәннән соң әйткән иде. Ул адәмнең теләге Аллаһы рәсүле вә мөселманлар белән бергә булу түгел, бәлки бер хатынны никяхлану өчен булган.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бу хәдиснең зикер ителү бер адәмгә хаслаб әйтелсә дә, мәксуд (0783) исә бөтенебезгә гамь (уртак – А.Х.) булыб (кирәк тән гамәле, кирәк тел гамәле, кирәк аз, кирәк күб булсын) нитек караб булуны белдерәдер.
Ниятләребез төзек булса, бөтен гамәлләребез төзек, ниятләребез бозык булса, бөтен гамәлләребез бозык булуын белдерәдер. Шуның өчен гыйбадәт вакытларында тел белән сөйләүнең вә укуның мәгънәсе, файдасы булмый, дигәнләр. Ният урыны – күңел. Әгәр берәү күңеле белән Икенде укырга ниятләнсә, теле белән Әхшам намазы нияте укыса, яки тик торса, һичнәрсә зарары булмас. Мәсәлән, теле белән Икенде укыб, күңеле гафил булса, күңелендән ният итмәсә, намазы намаздан китмәс, дигәнләр. Һәр гамәлдә күңелебез белән ният итеб, Аллаһыга якынаюны, Аллаһының ризалыгы өчен диб, ният әйтү тиеш. Ният күңел гамәле булыб, ниткә һич бертөрле рия керергә мөмкин түгел. Адәм баласының мәңге җәннәтдә булуы дөньяда вакытында мәңге мөэмин булуыны ният иткәнлеге өчен диючеләр бар. Бер адәмبالله العياذ علق تلو булса, дөньяда вакытында Аллаһыга гасый булыб торуны ният иткәне өчен булырга мөмкин икән. (Үкенү, тәүбә кылу) бөтен гөнаһларны юкка чыгарса, ният эшләмәгән эшләрне дә бар итә.
Рәсүл (сгс) әйтә бер сугышда: Мәдинәдә бер кавем бар. Алар газз (عذ) сәбәбле безнең белән юлдаш була алмадылар. Әмма алар ниятләре аркасында безгә һәрбер гамәлләребездә уртак булдылар фи сәбилилләһ. Сугыш кылучылар сәвабына, әҗренә ирешделәр, диде. (0784) Бәни Исраил кавеме арасында бер фәкыйрьнең нияте аркасында бер дә эшләмәгән эш белән (Муса пәйгамбәр аркылы), ул адәмнең зур әҗер вә сәвабларга

ирешүе белдерелгән. Ягъни ачлык вакытында бер тауга караб, шушы тау кадәр игенем булсын иде, ди. Шул игенемне ачларга өләшсәм иде диб, ният кылганы өчен эшләмәгән гамәле өчен зур сәваблы булуын белдергән. Хасыйлел кәлям, минем әйтергә теләгән сүзем. Аллаһы насыйб итсә, бүгенге көн Казан шәһәрендән бөтен Казан мөселманлары исемендән (Аллаһының мөбарәк йорты урнашкан сәййидел бәшәр вә шәфигель умам булган пәйгамбәребезнең туган, торган урынына зиярәт итәр өчен сәфәр чыгу алдында торабыз. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте сәфәребезне мөбарәк кылсын, һәркайсыларыбызның һәр урында һәрвакытда Ярдәмчебез Аллаһы хәзрәте булсын. Бу сәфәребез кыска гына сәфәр түгел. Моның расходы да бик зур. Шушы сәфәрнең чыгымлары, расходлары сез, мөселман кардәшләремнең Аллаһы ризалыгы өчен бирелгән тиенләрегездән, тәңкәләрегездән тотылачак.
Инде, мөхтәрәм кардәшләрем! Хәзрәт рәсүлнең югарыда әйтелгән мөбарәк хәдисенә бинаэ, изге ниятегез аркасында (Аллаһы насыйб итсә, киләчәкдә кылыначак шушы зур гыйбадәт - хаҗ гыйбадәтенең сәвабында), әҗрендә, инша Аллаһур Рәхман, һәркайсыңыз уртак булачаксыз. Шадланыгыз, туганларым! Изге ният белән биргән сәдакаларыгыз бик урынлы булачак.
(0785) Мөхтәрәм җәмәгать! Бик аз гына вакыт эчендә мин сездән, олыларыгыздан, галимләрегездән бик зур хөрмәт күрдем, турыгызда утырдым, тәмле-татлы нигъмәтләрегезне ашадым. Сезнең тиенләрегез белән алынган машинагызда утырыб җөрдем. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте сезнең барчаларыгыздан разый булсын. Бу көндән соң да барчаларыгызга саулык-сәламәтлек, тынычлык белән хәерле гомер биреб, өлфәт, мәхәббәт, дустлык, татулык белән яшәргә насыйб булсын.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте Коръәндә “Локман” сүрәсенең ахырында әйтә:
إِنَّ اللَّهَ عِندَهُ عِلْمُ السَّاعَةِ وَيُنَزِّلُ الْغَيْثَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْأَرْحَامِ ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ مَّاذَا تَكْسِبُ غَدًا ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ
تَمُوتُ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ
Ягъни: Кыямәтнең кайчан булачагы Аллаһыга гына мәгълүм, Аллаһыдан башка һичкемгә мәгълүм түгел. Ул – Аллаһы теләгән вакытда яңгыр яудыра, ана корсагындагы баланы ирме, кызмы, яхшымы, яманмы? – Аллаһы белер. Иртәгә нәрсә эшлисен,ниләр буласын һичкем белмәс, Аллаһыдан гайре, һичкем белмәс. Шулай ук һичбер адәм кайда үләсен, кайчан үләсен Аллаһыдан башка беребезгә дә мәгълүм түгел. (إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ). Дөрестлекдә Аллаһы Тәгалә хәзрәте һәр эшләребездән хәбәрдар булыб, һәр эшләребезне бик белүчедер. Менә шушы югарыда укылган аятьдә биш төрле эшнең (хакыйкәте Аллаһыдан башкага мәгълүм түгел, бәгъзе эшләрдә тәҗрибә белән тәхминән чама белән (0786) бәгъзе берләрен вакыт җиткәч кенә белсәләр дә, алдан һичкем белми, ягъни киләчәк җәйләр яңгырлымы, яңгырсызмы? Ул булган яңгырлар файдалымы, файдасызмы? Булачак, ягъни дөнья балаң яхшымы, яманмы? Кызмы, улмы? Киләчәкдә ниләр күрәсемез, кайда үләсемез Аллаһыдан башка беребезгә мәгълүм түгел. Менә бу эшләр Галим булган, Хәким булган Аллаһы газзә вә җәллә хәзрәтләренә генә хасыйль гыйлемләр.
Мөхтәрәм җәмәгать! Тагын бер мәртәбә әйтим: Аллаһы Тәбарәкә сәфәребезне уң кылыб, мөбарәк кылыб, сез мөселман кардәшләремез шадланыб күрешергә насыйб булсын иде. Гәрчә ул заманлар белән чагыштырганда юл мәшәкатьләре күб мәртәбәләр җиңел булса да, киләчәкдә ниләр буласын беребез дә белмибез. Һәркайсыбызга үлем кайда булса да, бер киләчәк. Кайчанга кадәр гомер итәсебез берәүгә дә мәгълүм түгел.
Дөнья эше дөньяда бетсен, бер-беребездән бәхил булышыйк. Кыямәт көнендә Аллаһы хозурында бер-беребездән разый булмыйча, бер-беребезне тоткан колырдай йөзебезгә каралык килердәй эшләрдән, мәсъулиятле эшләрдән бәхил булышыйк. Мин сезнең

һәркайсыгыздан риза, бәхил, миңа иткән хөрмәтләрегез берә-беренә, Аллаһы Тәгалә хәзрәте сезнең барчаларыгызны йөзләр кызара торган, үкунечкә калдыра торган куркынычлы көнләрдә барчаларыбызны Аллаһының хөрмәтенә ирешергә насыйб итсен. Амин.
(0787) Мөхтәрәм җәмәгать! Күршеләребез шушы мәсҗед тирәсендә генә булсын, поездга озатырга төшеб йөрмәгез.
Бөтен мөселман кардәшләремнең сәламен пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа хәзрәтенә ирешергә насыйб булсын. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте барчаларыбызның һәрвакытда, һәр урында яд мөхибез булсын. Сәфәребез мөбарәк булыб, хаҗларыбыз “мәбрур” булсын. Шадлык белән әйләнеб кайтырга, шадлык белән күрешергә Аллаһы насыйб итсен, йә Мөҗибес саилин.
ربنا تقبل دعائنا انك انت السميع العليم
Мөхтәрәм җәмәгать! Дини ләвәзимләребезне (кирәклеләрне – А.Х.), Аллаһы насыйб итсә, мулла Сафиулла башкарыр. Тыныч кына, матур гына яшәргә Аллаһы насыйб итсен. Барыгызга да саулак-сәламәтлек, тынычлык белән яшәб, хөсне хатимә белән дөнья куярга насыйб булсын.
(0789) Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте динебезнең бинасы булган, бишенче рөкене булган хаҗ гыйбадәтен үтәргә Аллаһы насыйб итсен. Аллаһының мөбарәк, мөкаддәс йөрты – Кәгъба мөгаззыймәне зиярәт, догалар кабул була торган мөбарәк урынларны күреб, бөтен мөселман кардәшләремнең, хосусан, ватандашларым исемендән җенабе Хакка зарилык кылыб дога кылырга һәм шулай ук шаригъ кәрим, хатимел әнбия, сәййидел әнбия булган пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа (сгс)нең туган шәһәрен, торган шәһәрен Мәдинә Мөнәвварәне, сөекле пәйгамбәребезнең рауза мөтаһһәрәсен – кабер шәрифне зиярәт кылырга һәм пәйгамбәребезнең хөләфәӗ рәшидиннең һәм әсхабе кирам хәзрәтләренең аяк баскан урынларына кадәм куярга Аллаһы насыйб итеб, бөтен мөселман кардәшләремнең пәйгамбәребезгә догаларын, сәламләрен ирешдереб, сау-сәламәт, шадлык белән әйләнеб кайтыб, анда күргән шадлыклы хәлләремне, тәэсирәтемне бөтен кардәшләрем белән уртаклашырга Аллаһы насыйб итсен. Амин.
(0790)
"السَّخَاءُ شَجَرَةٌ مِنْ أَشْجَارِ الْجَنَّةِ لَهَا أَغْصَانٌ مُتَدَلِّيَةٌ فِي الدُّنْيَا , فَمَنْ كَانَ سَخِيًّا تَعَلَّقَ بِغُصْنٍ مِنْ أَغْصَانِهَا فَسَاقَهُ ذَلِكَ الْغُصْنُ إِلَى
الْجَنَّةِ ، وَالْبُخْلُ شَجَرَةٌ مِنْ أَشْجَارِ النَّارِ , لَهَا أَغْصَانٌ مُتَدَلِّيَةٌ فِي النَّارِ ، فَمَنْ كَانَ بَخِيلا تَعَلَّقَ بِغُصْنٍ مِنْ أَغْصَانِهَا فَسَاقَهُ ذَلِكَ
الْغُصْنُ إِلَى النَّارِ
ان السَّخاء شجرةٌ في الجنة فمن كان سخياً أخذ بغصن منها، فلم يتركه الغصن حتى يُدخِلَه الجنة، والشُّحُّ شجرة في النار فمن
كان شحيحا أخذ بغصن منها فلم يتركه الغصن حتى يدخله النار
(0791) 1968 нче ел, 5 апрель
“Бөек сәфәрдән” кайту белән башлана.
9 нчы номерлы сан.
Соңгы взгазь 3 нче май. 2 нче сәфәрдә сөйләнә.
(0792) 1968 нче ел, 6 нчы апрель / 1388 нче Һиҗри 7 Мөхәррәм, җомга.
Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһының ярдәме, Аллаһының теләве белән сез – мөселман кардәшләребезнең догасы аркасында (сәясендә) Ислам диненең бөек рөкене булган хаҗ гыйбадәтен үтәб, бөтен мөселман кардәшләребез исемендән Аллаһыга зарилык кылыб,

җылаб-җылаб догалар кылырга.

Аллаһы хәзрәте хаҗ юлдашым Харис Әби белән икебезгә насыйб итде. Хаҗ гыйбадәебез, кылган догаларыбыз кабул булыб, киләчәк елда да Казан шәһәрендә яшәүче мөселман кардәшләремә дә (сәййидел әнбия булган), Аллаһының йорты булган Кәгъбә мөгаззимәне тәвваф кылырга, раузә мөтаһһәрене зиярәт кылыб, тагын да бөтен мөселманлар исемендән пәйгамбәребезгә сәлам вә догаларга кылырга насыйб булсын.

Шушы бөек гыйбадәтләрдән саналган хаҗ нияте белән ерак сәфәребез хакында сезгә сөйләб үтәргә телим. 23 нче февраль, җомга көн Казандан чыгыб китдек. Мәскәүдә берничә көн торыб, Мәскәү мөселманлары дога кылыб, 28 нче февраль кич сәгать сигездә Щербаковский аэродромындан Берләшкән Гарәб Илләренең башкаласы Каһирәгә (? – А.Х.) караб юл тоткан 29 нчы февральга каршы төнге сәгать икедә Каһирәдә, аэродромда булдык. Анда зурлаб каршы алыб, бер сәгать аэропортда торыб, Каһирәдән кузгалыб китдек. Сәгать өчләрдә кузгалыб китдек таң алдындан Судан җөмһүриятенең башкаласы Хәртумда булдык. Посольстводан, мөфти янындан баш казый һәм башка галимләр каршы алдылар. Хәртум шәһәрендә сәгать бишләргә кадәр ял итеб, беркадәр урынларны караб, зиярәт кылыб, мәсҗеддә һәм мөфти хәзрәтләре белән күрешеб сәгать бишдә Сәгудия хөкүмәтенең, самолетына утырыб, Җиддә шәһәренә сәфәр кылдык. Сәгать бишдә кузгалыб китеб, Мәскәү вакыты белән җиденче унбиш минутларда Кызыл диңгезне үтеб, Җиддә шәһәренә килеб җитдек. Аэродромда бөек адәмләр һәркайсыбызны зур хөрмәт белән каршы алдылар. Җиддә шәһәренең аэродромында таможный адәмләр үзебезне һәм нәрсәләребезне тәфтиш кылыб, аэродромның өченче этажында урын биреб урнаштырдылар. Шушы көн кич безгә Ихрамга керерсез диб белдерү ясадылар. Һәм без кичдән кунакларыбызны кисеб, һич сакларыбызны төзәтеб, таң алдындан гөселләр коеныб, Ихрам багъладык (хаҗ киемләребезне кидек) һәм беренче март җомга көн Җиддә шәһәрендә Иртә намазы һәм Җомга намазы укыб, кояш баер алдындан Мәккә Мөкәрәмәгә барыр өчен пассажирский автобусларга төялдек. Караңгы төшкәндә генә Җиддә шәһәрендән кузгалыб киттек. Кузгалу белән бөтен хаҗилар (0794) (киләчәк хаҗилар), бездән башка да автобуслар күб иде, кычкырыб, тәлбиһ әйтә башладылар:

لبيك اللهم لبيك ، لبيك لا شريك لك لبيك ، إن الحمد ، والنعمة لك والملك ، لا شريك لك

диб.

Сәгать сигезләр чамасы, булса кирәк, Мәккә Мөкәррәмәгә якынлашдык. Мәккә Мөкәррәмәне күрү белән тагын ничә меңләр хаҗилар җылаб-җылаб, тәлбиһ һәм тәкбир тавышларын тагын да көчәйтделәр. Бөтен күңелләребез нечкәреб, күз яшьләребез белән (рәхмәт лилгаләмин булган) пәгамбәребезнең туган урыны, Аллаһы тарафындан Коръән аятьләре килә башлаган мөкаддәс Бәйтуллаһ булган Мәккә Мөкәррәмә шәһәрен күрү белән мөшәррәф булдык. Безне мөсафирханәләргә урнашканның соңында, бераз гына тамак ялгаб, Кәгъбәтулланы тәвваф кылырга ашыкдык. Камил таһарәт белән, күз яшьләребез белән Кәгъбәтуллага юнәлдек. Җиде мәртәбә тәвваф кылдык, мәкам Ибраһим аталган (Кәгъбәтулла тирәсендә) урынга туктаб, ике рәкәгать намаз кылдык. Мөлтәзим һәм мөлзәм дигән (Кәгъбә ишеге белән хөҗрәт әсуад арасында) караб, җылаб-җылаб, мөселманлар исемендән һәм үлгән мөселманларыбызның ярлыкавын һәм Аллаһы рәхмәтен өмед итеб, җылаб-җылаб дога кылдык.

Арасында Сафа –Мәрва сәгый кылдык (әйләнеб-әйләнеб) Сафа тавы, башында һәм Мәрва тавы башында Кәгъбәтуллага караб дога кыласың. Һәркайсында бөтенемез өчен дога кылдык, бөтен мөселман-кардәшләремезне күңелләребез белән (0795) күз алдына китердек. Аллаһы кабул итсен.

1 нче мартда, кич. Кәгъбәтулла.
Мәккә Мөкәррәмәгә килгән идек. 7 мартка кадәр Мәккә Мөкәррәмәдә булдык. Һәркөн Ирә намазын мәсҗед Хәрамдә укыдык, һәркөн биш вакыт намазны Хәрам Шәрифдә укырга тырышдык. 7 нче март, 8 нче Зөл Хөҗҗә хаҗ гыйбадәтенең фарыз булган Гарәфәткә чыкдык. (7 нчы март Гарәфәтдә җәбәлер рәхмә (الرحمة جبل) дигән тауга барыб, ике рәкәгать намаз укыдык һәм мәсҗед Нәбирә дигән мәсҗедгә барыб зиярәт кылдык, ике рәкәгать намаз укыдык. Гарәфәтдә Өйлә берлә Икенде бергә укылды.
8 нче март җомга, Гарәфә көн. Гарәфәтдән Минага китдек. Кичдән китеб, Мөздәлифә дигән урында туктаб, Әхшам вә Ястү намазы укыдык. Мина тавында таш атар өчен, ташлар җыеб, таң вакытына кадәр Мөздәлифәдә тордык. Менә Мөздәлифәдә тору – хаҗның важибләрендән. Таң аткач, Иртә намазы укыб, Мина тавына китдек. Бик акрынлык белән барыб, Мина таулары арасына барыб җитдек. Мина тавында ял итү, җир шарының бөтен почмакларындан килгән мөселманларның бер-берсе белән күрешеб, бер-беренә догалар кылышу арада дустлык, мәхәббәт, тынычлыкны даир булган вәгазь-нәсыйхатләр кылыша торган урын икән. Без дә шушы урында җир шарының төрле почмакларындан килгән, төрле-төрле төсдәге күбтөрле халыклар күрдек. Ләкин бу халыкларның төс-кыяфәтләре , телләре башка-башка булса да, боларның күңелләре һәркайсының (0796) бертөсле булыб, бер Аллага гына гыйбадәт кылыб, Ислам дине белән гамәл итүче, рәсүлуллага мәхәббәт итүче, саф күңелле мөселманлар иде. Һәркайсы намаз укыганда йөзләре белән Кыйблага, күңелләре Аллага юнәлеб гыйбадәт кылучы мөселманлар иде.
10 нчы март. Мина тавында мәсҗед хәйф дигән мәсҗедгә барыб, Иртә намазы укыдык. Минада Мәккә король Фәйсал белән күрешдек.
Шинбә көн иртә белән (الاولى عقبة) Гакабател улә дигән урында җидешәр таш атыб, шул Мәккә Мөкәррәмәгә кайтдык һәм (җидешәр) 21 хаҗи өч сыер чалдык. Кәгъбәтуллага барыб, фарыз тәвафны кылдык, чәч-сакалларыбызны төзәтеб, Әхрамдан чыкдык, гөселләр коеныб, үз киемләребезне киеб, яңадан Минага китдек. Минада күб хаҗилар, галимләр белән күрешеб, мәсҗед Хәйфгә бардык. Анда иртәнге намаз укыдык.
10 нчы март. Мәккә мөкәррәмә короле Фәйсал белән күрешдек.
11 нче март. Мәккә мөкәррәмәгә кайтдык.
12 нче март. Кәгъбәтуллага барыб, видагъ тәвафын кылдык һәм җылаб-җылаб Кәгъбәтулла белән аерылышдык.
13 нче март. Иртәдән үк Мәдинә мөнәвварәгә барырга диб, машинада китдек. Мәккә мөкәррәмәдә Җәннәтель мәгълән (المعلا جنت) дигән тарихи шаригель Мәгълә дигән урынларда булдык.
(0797) 1968 нче ел, 18 нче апрель, җомга көн / 1388 Һиҗри, 20 нче Мөхәррәм.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ислам диненә мәхәббәт итеб, Аллаһының ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Сабый вакытларыбыздан бирле күңелләребезгә кереб урнашкан чын мәхәббәт. Аллаһының дусты Ибраһим, Хәлилулла, һәм Аллаһының бәни вә рәсүле Исмәгыйл пәйгамбәрләре тарафындан бина кылынган, Аллаһыга ихлас күңелләре белән гыйбадәт кылучыларның. Көндә биш мәртәбә юнәлдем Кыйбла тарафына халисан лилләһ диб, йөзләре белән каршы була торган кыйблалары вә Кәгъбәтулла, Бәйтулла,

Кәгъбә мөгаззыймә атала торган мөбарәк вә мөкаддәс бинаның дөньяның кай тарафында, ни рәвешдә икәнен белергә кем генә теләмәс?
Һичшиксез, бу мөбарәк бина хакында һәркемнең белергә теләве бик зур. Менә шушы намаз саен каршы булыб, укый торган Кәгъбәтулла шәб диңгезе – Кызыл диңгездән 75-85 километр еркалыкда. Мәккә мөкәррәмә шәһәренең уртасына салынган әйләнәсе, мәсҗед Хәрам диб аталган зур мәсҗед белән әйләндереб алынган, бөеклеге 27 аршин (13 метр чамасында), буе 24 (12 м), ташдан салынган бер бинадыр.
(0798)
لِّلْعَالَمِينَ وَهُدًى مُبَارَكًا بِبَكَّةَ لَلَّذِي لِلنَّاسِ وُضِعَ بَيْتٍ أَوَّلَ إِنَّ
إِبْرَاهِيمَ مَّقَامُ بَيِّنَاتٌ آيَاتٌ يهِ
Ягъни: дөрестлекдә адәмләргә җир йөзендә гыйбадәт өчен Аллаһы тарафындан куелган йортларның әүвәлгесе Кәгъбәтулладыр. Мөбарәк булган, бәракәт иясе йөртдер амәл һәм бөтен галимне хаклыкка күндергүче булган хальдә.
آمنا كان دخله من و
Мәсҗед Хәрамгә кем генә керсә дә, әмин булды. Малын, җанын саклаган (мөшрик вакытда ук нинди зур дошманы булса да, аны үтермәгәндер).
(0799) Мәккә Мөкәррәмә төндән кошлык (бик иртәнге чак; таң аткаг чак – А.Х.) тарафына сузылган бер чокырда як-яклары бөек вә каты ташлардан гыйбарәт булыб, бу шәһәргә керә торган өч кабка булыб, башка урынлардан керергә мөмкин булмаган бу кабкалар хәзер булмаса да, боларның исемләре һаман да телләрдә сөйләнә икән. Бу шәһәр бик борынгы, иске шәһәр булыб, Ибраһим пәйгамбәрнең угълы Исмәгыйл пәйгамбәр заманында Бәни Җәрһәм кабиләсе (Бәни Кахтан Җәрһәм кабиләсе – А.Х.) тарафындан төзелгән бер шәһәрдер.
Бу тирәдә Ибраһим пәйгамбәр үзенең хатыны Хахрәт (Хаҗәр – А.Х.) Һаҗир белән, угълы Исмәгыйл пәйгамбәрне күтәреб куйганга бу тирәләрдә халык (торучылар) булмаган. Ибраһим пәйгамбәр Аллаһының әмере белән яшь баласы белән хатынын шушы урында калдырыб итә. Аллаһының теләве белән тиберченеб яткан урыныннан (Зәмзәм коесы) хасыйл булыб, су булганның соңында шушы тирәгә халыклар күчеб киләләр. Шушы рәвешле Мәккә Мөкәррәмә шәһәре барлыкка килә.
Башда бу шәһәрдә (Зәмзәм) коесындан башка су булмый. Габбасийә хәлифәләрендән Һарун Рәшиднең хатыны Зөбәйдә ханым беренче көнлек юлдан Гарәфәткә Мина тауларына һәм Мәккә шәһәренә җир астындан трубалар белән су китертә. Менә хәзерге Мәккә шәһәренең үзендә һәм Гарәфәтдә һәм Минада шушы сулар һәркайсы (الزبيدة عين) Гайне Зөбәйдә исем алганлар. Безгә Гайне зөбәйдәдән рәхим итегез. Без дә тукталышлар ясадык, без дә сулар алдык, эчдек.
(0800) Мәккә Мөкәррәмә шәһәренең кыскача тарихы шундан гыйбарәт.
(0801) Беркадәр шушы Мәдинәи Мөнәвварә шәһәре хакында сөйләб үтәм. Мәдинәи Мөнәвварә шәһәре Мәккә Мөкәррәмәдән шимальгә табарак, аралары 500 чакрым, диләр. Гарәбстан әүвәлгесенең иң матур, иң тигез урнашкан бер шәһәр булыб, моның хөрмә бакчалары да күб икән. Шимал тарафында мәшһүр Өхөд таулары булыб, иске исеме – Ясраб исемле булыб, соңындан Мәдинәтер рәсүл, Мәдинәи тайыб, Мәдинәи Мөнәвварә исемләре белән аталган. Кайчан төзелүе хакында тарихда күб сүзләр булса да, рәсүлуллага пәйгамбәрлек килгәннең соңында мөшрикләрнең җәбер-золымларындан котылу өчен Аллаһының әмере белән Мәдинәи Мөнәвварәгә бөтен сәхабәләр һәм хәзрәт рәсүл шушы шәһәргә күчеб, бик тизлек белән Ислам диненең таралуына сәбәб булган мөбарәк шәһәрдер.

Шушы рәвешле, Мәккә Мөкәррәмәдә вакытыбыз сыйдырганча гыйбадәтләребезне кылыб, догаларыбызны кылыб, тугыз көн торыб Гарәфәт, Мина тауларында булыб, догалар кылыб, 13 нче март Ястү вакытында, кич кенә Мәккә Мөкәррәмәгә кузгалыб, Мәдинәи Мөнәввәрәгә сәфәр кылдык. Юлда тукталышыбызда (Вадил Газыйм) дигән бер тигез сәхрадә тукталдык. Андан Бәдур исемендәге урында һәм мәсҗед Гали дигән урынларда һәм башка күб кенә урынларда тукталыб, Икенде алдындан Мәдинәи Мөнәввәрәгә килеб кердек. Шәһәргә кергәч дә безне туктатдылар. Һәм уң кул якдагы бер йортка алыб кереб, паспортларыбызны тикшерделәр. Шул вакыт каршыбызда (Рауза Мөтаһһәрә) булган пәйгамбәребезнең мәсҗеденең манаралары күренеб тора иде. Мәсҗеден нәбинең манараларын күрү белән күңелләребез нечкәрде, күзләребез яшьләнде. Мәсҗедгә караб пәйгамбәребезгә сәламләребезне табшырыб салаватлар укыдык, догаларыбызны кылдык. Уң якда (урамның икенче ягында гына) мәсҗед Ганбәр дигән ике манаралы мәсҗед бар иде. Шуның ахатәсендә (ара-тирәдә – А.Х.) Харис Аби белән икәү Икенде намазыбызны үтәдек. Паспортларыбызны тикшергәннең соңында безне мөсафирханәләргә урнаштырдылар. Бу арада инде вакыт үтде. Әхшам намазына мәсҗедгә барырга тугъры (0802) килде. Нәрсәләребезне тәмам урнаштыргач, Ястү намазына Мәсҗеден нәбигә ашыкдык. Никадәр ашыксак да, без рәсүлулла мәсҗеденә эчкә керергә соңга калган идек. Безнең кебек соңгарак калган хаҗилар белән мәсҗед әйләнәсендә Ястү намазын үтәб, без шул көнне халыкның мәсҗеддән чыгуларын көтеб, беркадәр халык бушангач, Мәсҗеден нәбигә кереб, ике рәкәгать намаз укыдык һәм Рәузә мөтаһһәрә тирәсен әйләнеб, догалар кылыб чыктык.
Икенче көндә Иртә намазындан соң, беркадәр вакыт узгач, тагын да барыбыз җыелыб, рәсүлулланың мәсҗеденә бардык. Рәузә мөтаһһәрәне зиярәт кылдык. Коръән укыб, пәйгамбәребезгә салаватлар укыб, мәсҗеднең бер тарафында ике рәкәгать намаз укыб чыкдык.
Икенче көнне Иртә намазындан соң ук (Рәузә мөтаһһәрә булган) рәсүлулланың мәсҗеденнән ерак түгел Җәннәтель бәкыйг исемендә булган сәхабәләр зияратына бардык. Бу каберләрдә әсхабе әкрамдән хәзрәт Госман, хәзрәт Габбас, Госман бин Мәзгун, Гбдеррахман бин Гауф, Сагъд бин Әби Вәккас, Габдулла бин Мәсгуд, Мәлик бин Әнас хәзрәтләре. Имһатель мөэминин хәзрәтләренең каберләре һәм рәсүлулланың сөт анасы Хәлимә (рг) нең кабере. Хәзрәт Ибраһим кабере һәм башка бик күб әсхабе кирам (рг) ларның каберләре.
Зиярәт кылдык, җылаб-җылаб догалар кылдык. Андан китеб, хәзрәт рәсүлнең Мәдинәи Мөнәввәрәгә һиҗрәт вакытында (ул вакыт Мәдинәи Мөнәввәрәдән читендәрәк булган) мәсҗед Кыйбланы зиярәт кылыб, эченә кереб, ике рәкәгать намаз укыб, догалар кылдык. (0803) Андан мәшһүр Өхөд тавы итәгенә барыб, шушы итәгендә Өхөд сугышында вафат (шәһид) булган сәхабәләрнең каберләренә зиярәт кылдык. Бу каберләр арасында хәзрәт рәсүлнең атасы белән бертуган кардәше, Исламга зур файдалары тигән хәзрәт Хәмзә кабере дә. Менә шушы тау итәгендә бу сугышда җитмешләб сәхабә шәһид булыб, һәркайсы шушы тау итәгендә күмелгәнләр.
Андан кайтышлый Мәсҗедель кабиләтәйн, Мәсҗед Әбу Бәкер, вә Салман әл-Фариси, Мәсҗед Гомәр, Мәсҗед Хәндак, Мәсҗед әл-Гали исемле. Беренче мәсҗедгә кереб, икешәр рәкәгать намаз укыб, догалар кылыб чыктык.
(0804) 1968 нче Миляди, 26 нчы апрель / 1388 Һижри, 28 Мөхәррәм, җомга көн. Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ихлас күңел белән ерак вә якын җирләрдән җомга намазы укыр өчен быелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә

рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
28 нче апрель якшәнбе көн 1388 нче Һиҗри ел икенче ае – Сәфәр аеның башы булачак җенабе Хак шадлык белән каршы алыб, саулык-сәламәтлек, тынычлык белән үткәрергә насыйб булсын.
Аллаһы Раббел галәмин “Ибраһим” сүрәсендә шушы аятьне сөйли:
لَشَدِيدٌ عَذَابِي إِنَّ كَفَرْتُمْ وَلَئِن لَأَزِيدَنَّكُمْ شَكَرْتُمْ لَئِن رَبُّكُمْ تَأَذَّنَ وَإِذْ
ди. Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкранә кылсагыз, без сезгә нигъмәтләребезне, әлбәттә, артдырыб бирербез. Әгәр биргән нигъмәтләрем көфран нигъмәт кылсагыз, нигъмәтләрнең кадерен белмәсәгез (لَشَدِيد عَذَابِي إِنَّ), минем газабым бик каты булыр, ди. Һәм рәсүлулла (сгс) әйтә:
لزاوالها امان نعمة على الحمد
Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкранә кылу – ул нигъмәтнең китмәвенә, имин булуына сәбәб, ди.
Аллаһы безгә сәламәтлек нигъмәте биргән, безгә нинди иркен ризыклар белән, матур тормышлар биргән. Күңелсез, караңгы кышларны үткәреб, якты, матур язларга чыкдык. Менә болар, әгәр уйлаб карасак, һәркайсы Аллаһының безгә биргән нигъмәтләре тагын мондан башка да Аллаһының безгә биргән нигъмәтләре бик күб.
(0805) Тагын Коръәндә “Ибраһим” сүрәсендә Аллаһы әйтә:
كفار لظلوم الانسان ان تحصوها لا الله انعمت و تعد ان و
ди. Ягъни Аллаһының сезгә биргән нигъмәтләре бик күб. Сез аларны санаб бетерә алмассыз, ди. Хакыйкатьдә адәм баласы үз-үзенә бик золым итүче, каты көфран нигъмәт кылучыдыр, ди. Ягъни булган нигъмәтләрнең кадерен белмичә, көфран нигъмәт кылыб, ул нигъмәтләрнең китүенә сәбәбче булыб, дөньяда ук бәхетсезлеккә, я булмаса Ахирәтдә Аллаһының каты газабына дучар булыб, үзен кызганмый, үзенә золым итәдер.
Мөхтәрәм җәмәгать! Әлхәмделилләһи Раббел галәмин. Аллаһының ярдәме белән сау-сәламәт, караңгы, салкын кышларны үткәреб, исән-сау, матур, ямьле яз көнләрен күрдек. Бу бик зур шадлык. Азмы кешеләребез шушы якты дөнья белән саубуллашды. Бу вакытларда безнең арабызда, безнең кебек үк шадланыб язны каршы алган кешеләребез бүген җир астында яталар. Шул хәлләрне уйласак, искә алсак, бүгенге көн безнең өчен нинди зур шадлык.
Икенче. Әлхәмделилләһ, илләребез тыныч, зур, иркен тормышлар. Бөтен халык бәйрәме булган – май бәйрәме итү алдында торабыз. Шушы матур тормышыбызның шөкранәсе һәм сау-сәламәт, матур җәйләрне күрүебезнең шөкранәсен онытмыйча, шушы бәйрәм (бәйрәм – шадлык дигән сүз) көнләрен матур итеб каршы алыб, инсаният, Исламият нигезендә чын туганларча, дустларча, шадланыб һәм башкаларны да шадландырыб, күңелле итеб уздыру – безнең адәмчелегебезнең (0806) мөкаддәс, изге бурычыбыз.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә адәм балаларына дөнья тереклегендә яшәр һәркайсыларыбызга хәләлдән кәсеб итүне бурыч итеб куйган. Шуның өчен сау-сәламәт, гакыллы яшь кешенең эшләми ялкауланыб ятуы Ислам шәригате каршында хәрам ителгән. Пәйгамбәребез әйтә:
مسلم كل على واجب الحلال طلب
Ягъни: хәләлдән кәсеб итү һәрбер мөселманга ваҗиб, ди. Шушы рәвешле хәләлдән кәсеб итеб арган-талган адәм баласының атнага бер мәртәбә ял итүе канун һәм шәригат тарафындан тиешле табылган. Ул гына да түгел, инсаният һәм Исламият тарафыннан елга

берничә мәртәбәләр бәйрәм итү, ял итү (гаед ясау), шадлану тиеш табылган. Шәригатьнең һәркеме инсанларның мәслихате өчендер.
Менә шушы бәйрәм көнләре, дини һәм милли бәйрәмләр булыб, һәркайсы шадлыклы көнләрдер. Шушы көнләрне без ничек үткәрергә тиеш? Шушы бәйрәм көнләрендә үзебез һәм бөтен гаиләбез генә дә түгел, бөтен туган, дуст-ишләрне, гариб вә ятимләрнең – һәркайсын шадландырырга тиешбез. Ата-аналарыбызның, туганларыбызеың вә дустларның хәлләрен белү һәм авыру, кайгы-хәсрәтле, борчулы кешеләрнең хәлләрен белү, бер-береңне халәл ризыклар белән кунакка чакыру, мунчалар керү, арулану, пакъләнү, яхшы киемләр кию, дустлык-татлык нигезендә ял итү – менә чындан да шадлык һәм бәйрәм булачак.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Безнең арабызда шушындый күңелсез хәлләр дә бик күб. Инде яшьләребезне бер якка куеб, яхшы гына олугъ яшьдәге кешеләребез дә бәйрәм хөрмәтенә диб, хәрам булган (0807) ризыклар белән дә чуалучылар ишетелә, чәче-сакалы агарыб да, шуның катгый рәвешдә Аллаһы тарафыннан тыелганын белә торыб, шушы олы яшьдәге кешеләребез хакында нәрсә диб әйтергә кирәк, картаеб да инсафка килмәгән адәмләрнең хәлләре бик куркыныч, Аллаһы сакласын. Ул гына да түгел, шушы исерткеч аракысында үзенең гомер иткән карчыгын җәберләүче һәм үзенең балаларына тәрбиясез, начар сүзләр әйтүче кешеләр дә ишетелгәләде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгалә тарафыннан сачы-сакалы агарган олугъ яшьдәге адәмләргә каралыб (караб – А.Х.), шушы адәмләргә көнгә ничә мәртәбә хыйтаб кылыныр икән, и бәндәм! Сачың-сакалың агарды, яшең олыгайды, үлмәк (үлем – А.Х.) якыйнайды. Гөнаһ кылырга оял, мин сине газаб кылырга оялырмын, диб.
Шушы аракы, исерткеч хакында пәйгамбәребезнең әйткән сүзләрен гарәби гыйбарәсендә әйтеб күрсәтәм:
1) Сәхих Бохари вә Сәхих Мөслимидә: “Зина кылган кеше мөэмин булганы хәлдә зина кылмас. Исерткеч эчүче кеше мөэмин, мөселман булганы хәлдә исерткеч эчмәс”. Ягъни: мондый эшләрне кылган вакытда ул адәмдән иман аерылган булыр.
2) Имам Тирмизи, Ибн Мажи риваять кылалар: “Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә исерткечгә, аны эчүчеләргә, эчертүчеләргә, ясаучыга, сатучыга, алыб кайтучыга, хасыль кәлам, – шушы бозыклыкка аз гына катнашы булган адәмләргә ләгънәт әйтер. (0808)
3) Хәдис. Бер кеше исерткеч эчсә, ул кешедән башындан күлмәге салынган кебек, иман чыгар, суылыр, ди.
4) Бер хәдис. Рәсүлдән исерткеч хакында сораганда: уналты кадаклы бер савыты исертсә (алты кило чамасында), шуның бер йотымы да хәарм, дигән.
Менә бу күңелсез хәлләребезне искә алу да бик күңелсез, ләкин хаклыкны, ачы булса да, әйтми мөмкин түгел. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте безне Ислам нигъмәте, иман нигъмәте, сәламәтлек нигъмәте һ. б. бик күб төрле нигъмәтләр белән сыйлаган. Әгәр без шушы нигъмәтләрнең кадерен белмәсәк, көфран нигъмәт кылсак, шөкранә кылмасак, Аллаһы сакласын, дөнья Ахирәтдә үкенечкә калырбыз.
Ахыр сүз итеб әйтәм. Мөхтәрәм җәмәгать! Үзебезнең дәрәҗәләребезне белеб, үзебезне-үзебез тота белергә тиешбез. Әгәр дә Аллаһы хозурына барасыбызга чын күңелдән ышансак, һәрбер эшләребездә хисаб бирәсебез бар диб ышансак, ир уртасы булган һәм пенсиягә чыккан олы яшьдәге кешеләр, барыбыз да үзебезнең балаларыбызга, оныкларыбызга яхшылык белән үрнәк булырга, адәм баласын дөнья Ахирәтдә үкенечкә калдыра торган эчемлекдән ерак булыб, ямьсез, күңелсез сүзләр белән сүгенүдән бик сак булырга тиешмез.

Хәзрәт рәсүл (сгс) әйтә:
الْخُلُقِ وَحُسْنُ الصَّمْتُ ؟ الْبَدَنِ عَلَى وَأَهْوَنِهَا الْعِبَادَةِ بِأَيْسَرِ أُخْبِرُكُمْ أَلا
Ягъни: мин сезгә гыйбадәтләрнең иң җиңеллесен ансатыгн, тәнгә дә җиңгел булганы белән хәбәр бирмәм? – ди.
(0809) Менә ул җиңеллек һич мәшаккакате (мәшакате – А.Х.) булмаган гыйбарәт: тик тору, начарлыкдан тыелыб тик тору һәм күркәм холык, ди. Күркәм холыкның төрләре бик күб. Үзебезне һич булмаса начар, тәрбиясез сүзләр белән сүгенүдән тыю – һәркайсы Аллаһы кашында гыйбадәтдән булыб, моның өстенә йомшак, тәмле телле булсак, менә бу эшләр Аллаһы каршында гыйбадәт булыб, зур әҗер-сәвабларга ирешдерәчәк.
Үзебез шушындый матур сыйфатлар белән яшьләребезгә үрнәк була алсак, бу вакытда безнең үзебездән түбәнләргә әйткән сүзебез, үгет-нәсыйхәтләребез – һәркайсы үтемле булыр. Үзебездән кечеләребез арасында йөзебез ак булыр. Бала-чага атасы булыб, олугъ яшькә җитеб, үзебезне мөселман диб җөреб дә, динемез тыйган начар гадәтләрдән тыелмасак, динемез кушкан күркәм гадәтләрне аяк астына салыб табтасак, Аллаһы биргән, безгә өйрәткән Ислам нигъмәтенә көфран нигъмәт кылган булыб, дөнья Ахирәтдә үкенечкә калырмыз. Үзебезгә-үзебез бик каты золым итәрбез.
“Инсан” сүрәсендә Аллаһы хәзрәте әйтә:
كفورا وإما شاكرا إما السبيل هديناه إنا
ди. Ягъни: без һидаять юлы белән азгынлык юлыны (начар юл белән яхшы юлны) ачык итеб күрсәттек, инде адәм баласының ихтыяры үзендә: теләсә, Аллаһының биргән нигъмәтләренең, кадерен белеб, яхшылыкка көнләб шөкранә кыла, йә булмаса бу нигъмәтләр кадерен белми, начарлык юлына китеб, көфран нигъмәт кыла, ди.
(0810) Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, көфран нигъмәт кылудан сакласын. Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкранә кылыб, барчаларыбызга
الساكرين م الله ان
дигән адәмләре җөмләсендән булырга Аллаһы насыйб итсен.
1968нче ел, 3 нче май, җомга көн / 1388 нче ел, 4 нче Сәфәр.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аллаһының хозурына барыб хисаб бирүгә ышанган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте Коръәндә “Хәшәр” сүрәсендә без – бәндәләренә карата түбәндәге аятьләрне бәян итә:
فانتهوا عنه نهاكم وما فخذوه الرسول آتاكم وما
Аллаһы тарафыннан сезгә рәсүл нәрсәләр китерде исә, сез аны алыгыз, ягъни: нәрсә белән боерды, (әмер) итсә, аны тотыгыз. Ниндидер эшләрдән пәйгамбәр сезне тыйды исә, эшләмәгез, ярамый диб тәнбиһ кылса, инде сез ул нәрсәдән тыелыгыз, эшләмәгез, ди.
العقاب شدسد الله ان الله اتقوا و
Инде шушылай булса, сез үзегезне пәйгамбәргә иярүче хак мөселман диб белсәгез, пәйгамбәргә каршылык, аның сүзенә хилафлык кылудан сакланыгыз. Әгәр нәфесләрегезгә ияреб, пәйгамбәр кушкан эшләрне кылмаенча, тыйганларындан тыелмасагыз, (0811) Аллаһының газабы катыдыр, ди.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте безгә Үзенең пәйгамбәре аркылы һәркайсын ачык, мәгълүм иткән, белдергән.
بين الحرام و بين الحلال

диб, тагын да:
تضيّعوها فلا فرائض فرض تعالى الله إن
диб, һәркайсын ачык бәян кылды. Рәсүл Ходა безгә Коръәннең хөкемләрен ачык бәян кылган, аңлаткан.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Үз-үзебезне хисаб кылыб, тикшереб карыйк. Аның өчен безгә мөбарәк пәйгамбәребез әйтә:
تحاسبوا ان قبل انفسكم حاسبوا
Үз-үзегезне тикшереб, хисаб кылыб карагыз. Аллаһы кашына барыб хисаб кылынганга кадәр, ди.
توزنوا ان قبل انفسكم زنوا و
ди. Үз-үзегезне үлчәб карагыз: яхшылыкларыгызны, яманлыкларыгызны Аллаһы хозурына барыб үлчәнгәнгә кадәр, ди.
Инде без, әлхәмделилләһи, Коръән дә укыймыз, тәфсирләр дә карыйбыз һәм башка китаблар да укыйбыз. Ләкин Коръән хөкемен, пәйгамбәр кушканны тиешенчә үтибезме, юкмы? Кәлям Шәриф Аллаһының рәсүле безгә фарыз важибләребезне үтәгәннең соңында хәрам булган эшләрдән бик каты сакланырга куша! Менә без шушы хәрам булган өметләрдән саклана алабызмы, юкмы?
Мөхтәрәм җәмәгать! Кызганычка каршы, безнең арабызда Коръән укылыр, китаблар укылыр. Ләкин укыганны үзләре ишетмәүчеләр дә бар. Гайбәт – хәрам, андан сакланмыймыз, (0812) бер өйдән икенче өйгә сүз ташыб, гайбәт сатыб йөри торган ялкау хатынлар кебек халык арасында фетнәгә, тынычсызлыкка сәбәб булган нәммам (гайбәт сөйләү – А.Х.) җәфәте белән җәфәтләнүчеләребез дә бар. Хәзрәт рәсүл әйтә:
نمام الجنة يدخل لا
Ягъни: мөселманлар арасын бозар өчен сүз йөртүче җәннәтгә кермәс, ди.
Бер-беребезгә хөсед-көнчелек итү, көнчеләнеб зарар китерү – пәйгамбәр тыйган начар сыйфатларның берсе. Шулай ук башкаларны кул белән, тел белән рәнҗетү, яки кешенең малын, я нәрсәсен булса да талаб, урлаб алу – менә бу эшләр һәркайсы Шәригать тыйган, хәрам булган сыйфатлар. Һәм нахакдан кеше рәнҗетүләр – һәркайсы пәйгамбәр тыйган начар гадәтләр. Рәсүлулла (сгс) әйтә: әгәр бер адәм икенче берәүнең хәрам булган рәвешдә хакына керсә я урласа, Кыямәт көнендә Хисаб мәйданында шушы ике адәм китерелеб, кешенең бер нәрсәсен талаб яки урлаб алган адәмнең изге гамәлләрендән алыб-алыныб, мәзлумгә яки урланучы, таланучы адәмгә бирелер, ди. Инде ул залимнең яки талаучы, урлаучы адәмнең изгелекләре булмаса, мәзлумның яки урланучы, таланучы адәмнең гөнаһлары ул залимгә йөкләтелер, ди. Коръәндә:
الْمُبِينُ الْخُسْرَانُ هُوَ ذَٰلِكَ أَلَا الْقِيَامَةِ يَوْمَ وَأَهْلِيهِمْ أَنفُسَهُمْ خَسِرُوا الَّذِينَ الْخَاسِرِينَ إِنَّ
Ягъни: Кыямәт көнендә үкенечкә калучы кешеләр, шул кешеләр үзләренең золымлары сәбәбле Аллаһының биргән (0813) нигъмәтләрендән мәхрум булдылар, ягъни аларга биреләчәк әҗер вә сәваблар, алар тарафындан золым кылынган мәзлумларга бирелеб, алар тәмугъ газабына дучар булырлар, ди.
Хәзрәт рәсүл әйтә:
لسانه و يده من المسلمون سلم من المسلم
ди. Ягъни чын мөселман адәм – шул кеше, башка кешеләр ул адәмнең телендән дә, кулындан да һичбер зарар күрмәсләр. Ягъни мөселман адәм теле белән гайбәт кылмас, теле белән сүз йөртмәс, кулы һичкемгә җәбер-золым итмәс, кеше нәрсәсен урламас вә таламас, ди. Коръән шәригатьнең һәм хәзрәт рәсүлнең мондан башка да безгә тыелырга кушкан начар гадәтләр, гөнаһ булган дөнья Ахирәтдә хурлыкка төшерә торган күңелсез

сыйфатлар бик күб булыб, Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте җөмләмезне шушы начар гадәтләрдән ерак кылсын.
(0814) Дөньяда шундый намуслы, инсафлы адәмләр дә бар, хәтта табкан нәрсәләрен дә тиешле урынларга итеб (илтеб – А.Х.) табшыралар. Чын, күркәм сыйфат менә шулай булырга тиеш. Әгәр бер адәмнең югалткан нәрсәсен табыб бирсәң, ул адәм никадәр шадланыб, никадәр рәхмәтләр әйтәчәк, нинди зур изгелек булачак. Хәзрәт рәсүл әйтә:
كره ما او اوضره مسلما عشى من منا ليس
Ягъни: бер кешене алдаган, талаган, нәрсәсен урлаган, хәйлә вә мәкер кылган кеше – минем өммәтемдән түгел.
منه انا لا و كهانة لا و نميمة و حسد ذو منى س
Хөсед кылучылар, сүз йөртүчеләр, багучылар миндән түгел, без алардан түгел, ди.
(0815) Сәлам җибәр шу хакда:
بِمِثْلٍ وَلَكَ :الْمَلَكُ قَالَ إلاَّ ،الْغَيْبِ بِظَهْرِ لأَخِيهِ يَدْعُو مُسْلِمٍ عَبْدٍ مِنْ مَا
диб. Ягъни: бер мөселман икенче мөселманга ни рәвешле дога кылса, теләк теләсә, ул кеше өчен дә фәрештә нәкъ шулай ук дога кылыр.
Хасылел кәлям: Коръәнне һәм башка шәригать китабларын укыб да, үзебез аларның хилафынча булсак, ягъни Коръәнне укыб, пәйгамбәр сүзләрен алар буенча гамәл итмәсәк, моның мисалы шуның кебек: әгәр бер министрның икенче бер шәһәрдә бер кул астында эшләүче икенче бер түрәсе булыб, шуңгар бер приказ-боерык җибәрсә, берникадәр вакытдан синең шәһәреңгә барырмын, мин барышка менә шушы эшләрне эшләб куй, (0816) берничә төрле задания бирсә, боеру җибәрелмеш тора. Бы министр тарафындан боерыкны, әмерне алганның соңында һәркөн бу боерыкны берничә мәртәбә алыб-алыб укыса, әмма үзе моның әмер-боерыкларын үтәмәсә, билгеләнгән вакытда шушы министр килсә, моның боерыклары һич берсе үтәлмәгән, менә шушы вакыт бу министр кул астындагы башлыкка ни әйтәчәк? Әлбәттә ул аңгар урыныннан алыб ташлаб җәза, наказание бирәчәк. Шуның кебек үк әгәр без үзебез канун илаһи булган шәригать китабы булган Коръәнне укыб да, аның хөкеме белән, кушканнары белән гамәл итмәсәк (эш итмәсәк), Аллаһы каршында зур мәсъүлияткә калачакмыз. Кыскасы, хәзрәт рәсүл безгә үзебезне үлчәр өчен кыска гына сүзләр белән зур мәгънәләр аңлатыб, дөнья Ахирәт бәхетле булуыбыз өчен, матур юллар өйрәткән. Хәзрәт рәсүл әйтә:
مؤمن فأنت , سيئتك ساءتك و حسنتك سرتك إذا
Ягъни: синең башкаларга аз гына изгелек, яхшылык эшләвең шатландырса, начар эшләрең сине кайгыртса, борчуга салса, син үзеңне саф мөселман, халис мөэмин диб бел. Әгәр киресенчә булса, ул вакытда мөселманлыгыңда, әлбәттә, зур кимчелек була.
(0817) Мөхтәрәм җәмәгать! Әгәр башкаларга телебез белән дә, кулыбыз белән дә яхшылык итәргә тырышсак, телләребез, кулларыбыз белән башкаларга зарар итүдән саклансак, гайбәт, нәмим сүз йөртү, ялган сөйләү, хөсед эшләрдән ерак булырга тырышсак, дөнья Ахирәтдә җаныбыз тыныч булыб, Аллаһы каршында да йөзебез ак булыр. Әгәр шушылай булсак, Коръән белән гамәл итеб, пәйгамбәр кушкан юлдан барган булыб, Аллаһы хәзрәтенең:
المهتدون هم اولئك و رحمة و ربهم من صلوة عليهم اولئك
Ягъни: Аларга Рабблары тарафындан рәхмәт, шәфкать булыр һәм менә шушы кешеләр хак юлга күнелмеш Аллаһы кушкан юлдан баручы адәмләр булыб.
يحزنون هم لا و عليهم خوف لا
Ягъни: ул кешеләр хәвеф (курку- А.Х.) хәтәрләрдән, куркынычлардан әмин булдылар һәм аларга киләчәкдә дә кайгы-хәсрәтләр булачак түгел дигән адәмләр җөмләсендән булыб,

иншаАллаһур Рәхман, сәгадәт дарәйнгә ирешүчеләр җөмләсендән булырбыз. Амин.
الضَّالِّينَ وَلاَ عَلَيهِمْ المَغضُوبِ غَيرِ عَلَيهِمْ أَنعَمتَ الَّذِينَ صِرَاطَ المُستَقِيمَ الصِّرَاطَ اهدِنَــــا
(0819) Зәйнәтулла Бикмулла угълының Фатыйма Җиһанша кызы Мөгаллимә Зариф кызы
(0820) 1968 нче ел 10 нчы майда башлана. 1388 нче Һиҗри Сафарель хайр.
10 нчы номерлы дәфтәр (Тагын да 1970 нче елның 9 нчы гыйнварь җомгасында.
1) بين الحرام و بين الحلال хәдисе хакында.
2) Мәрҗани хәзрәт хөтбәсе хакында.
3) Намаз хакында.
Саржуйдан Зыяддин хәзрәтдән һәм мөселманлар Төрекмәнстандан.
(0821) 1968 нче ел, 10нчы май / 1388 нче Һиҗри, 13 нче Сафарель хайр, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Халык арасында, дөнья тормышында һәртөрле хәлләр булыб, кайбер бәхетле гаиләләр, ир белән хатын, йә булмаса, карт белән картчык картлык көннәрендә бер-берләренә зур ярдәмләр күрсәтеб, үзләренең картлык вә картлык сәбәбле килгән авыруларын да онытыб, матур гына, күңелле генә соңгы гомерләрен тыныч кына, дуст кына авыштырган бәхетле адәмләр булган шикелле, дөнья бер генә төрле түгел, шулар арасында шушы (0822) тормышларның соңгы көннәрендә, гомер иткән картчыкның я гомер иткән картның хәтерен калдырыб, хәтта бер-берсен рәнҗетеб, холыксызланыб, күңелсез, бәхетсез тормышда яшәүчеләр дә юк түгел. Тормышда шушындый хәлләр дә ишетелә. Менә шушы хакда беркадәр Коръән аятьләрен сөекле пәйгамбәребезнең безгә әйткән үгет-нәсыйхәтләрен беркадәр исегезгә төшереб үтмәкче булам. Аллаһы Тәбарәкә хәзрәте “Бәкарә” сүрәсендә әйтә:
خليفة الأرض في جاعل إني للملائكة ربك قال وإذ
Ягъни: Вакытны зикер ит, искә төшер, синең Раббың фәрештәләргә әйтде: Мин җир йөзенә хәлифә хуҗа яратачакмын, ди.
الدماء ويسفك فيها يفسد من فيها أتجعل قالوا
Шушы вакытда фәрештәләр әйтделәр: И, раббымыз! Син җир йөзендә бозыклык кылучы, кан коючы затны яратыб, җир йөзенә хуҗа кылмакчы буласыңмы? – диделәр.
لَكَ وَنُقَدِّسُ بِحَمْدِكَ نُسَبِّحُ وَنَحْنُ
Бер сиңа тәсбих итәбез, хәмид әйтәбез.
تَعْلَمُونَ لاَ مَا أَعْلَمُ إِنِّي قَالَ
Шушы вакыт Аллаһы Тәбарәкә вә Тәбарәкә хәзрәтләре фәрештәләргә әйтде: Мин сез белмәгән нәрсәләрне беләмен, диде.
الملائكة على عرضهم ثم كلها الأسماء آدم وعلم
Аллаһы Тәбарәкә хәзрәте шул вакыт адәм баласына бөтен нәрсәләрнең исемләрен өйрәтде, белдерде.
صديقين كنتم ان هؤلاء بأسماء انبؤنى فقال
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә фәрештәләргә әйтә: инде әгәр сез әйткән сүзләрегездә растлыкда булсагыз (йир йөзенә хәлифә яратуымны сезнең күңелләрегез мәкруһ күрсә), сез менә шушы нәрсәләрнең исемләрендән хәбәр бирегез инде диб, (0823) менә шулвакыт фәрештәләр Аллаһыга әйтәләр инде:
الْحَكِيمُ الْعَلِيمُ أَنتَ إِنَّكَ ۖ عَلَّمْتَنَا مَا إِلَّا لَنَا عِلْمَ لَا سُبْحَانَكَ قَالُوا
“И Аллаһ, без син белдергән нәрсәләрне генә беләбез диб, үзләренең хаталарын игътираф

кылалар, Аллаһыга тәсбих итәләр”. Шулвакыт Аллаһы Тәгалә хәзрәте Адәмгә хыйтаб кылыб, менә син шушы нәрсәләрнең исемләрендән хәбәр бирдегенең, Адәм пәйгамбәр шушы нәрсәләрдән, исемләрдән сөйләб биргәннең соңында Адәмнең фәрештәләр кашында дәрәҗәсе күтәрелә. Менә шушы хәл адәм балаларының Аллаһының теләве буенча фәрештәләр каршында дәрәҗәсе күтәрелүгә сәбәб һәм Адәмнең үзләренә караганда гыйлем җәһатендән артык икәненә мөслим булыб фәрештәләр каршында гыйззәтле вә хөрмәтле булуларына сәбәб. Аллаһының әмере белән фәрештәләр Адәмгә сәҗдә кылдылар, җенабе Аллаһының Үзенә генә мәгълүм булган серләргә бина, адәм баласын нигъмәт йорты, шадлык йорты булган җәннәтгә урнаштырганның соңында, шушындый зур хөрмәтләр белән бүләкләнгәннең соңында, бу хәл фәрештәләрнең дикъкатен тагын да җәлеб итделәр.
Адәм (гс)дә Аллаһы тарафындан бу кадәр наз вә нигъмәтләрә ирешдеге өчен Аллаһыга һәрвакыт хәмде вә сәналарын укыр вә артдырырга тырышыр иде. Шушы рәвешле Адәм пәйгамбәр Аллаһы тарафындан шушындый дәрәҗәләргә ирешеб, тирәсендә хур вә гыйльманлар (җәннәттә яшь хезмәтчеләр – А.Х.) вә фәрештәләр һәрвакыт хазир булыб торсалар да, күз күрмәгән, колак итшетмәгән, адәм баласының хәтеренә дә килмәгән зур дәрәҗәләргә ирешсә дә, җәннәт бакчаларында сәйр кылса да, һаман да күңелендә бер җитешсезлек сизә, (0824) зира (чөнки – А.Х.) үзе белмәгән җәннәт нигъмәтләрендән кадерлерәк булган.
Бер нәрсәне табигате, күңеле тели иде. Бервакыт Адәм пәйгамбәрне йокы баскан кебек булыб китә. Азмы күбме вакыт узганның соңында күзен ачыб җибәрсә, янында (Аллаһының рәхмәте белән барлыкка килгән) хәзрәти Хауваны (Хаува – Һава) күрү зур шадлык булыб, бөтен эч пошулары онытдыра. Шул вакыт Аллаһы тарафындан хыйтаб кылына: И, Адәм! Шушы кадәр җәннәт нигъмәтләре белән дә тулмаган, күңелендә булган эч пошуларыңны бетерер өчен, нигъмәтләремнең ниһаясе итеб үз җенесеңдән булган шушы кызны сиңа һиба (бүләк – А.Х.) итдем. Шуның белән бергә һәрвакыт бер-берегезгә хәсән мәгашрәтдә, күркәм мөгамәләдә булуыгызны тәусыя (васыять – А.Х.) идәрәм, диде.
Адәм пәйгамбәр хәзрәти Хауваны күрү белән чын күңелендән мәхәббәт итде, шулай ук хәзрәти Хаува да Адәм пәйгамбәрне чын күңелдән яратды. Менә шул көндән башлаб адәм балалары кануни илаһи тарафындан һәм табигать тарафындан гадәт сөннәт булыб калды. Адәм балаларында түгел, хәтта бөтен җан ияләренә җир шарында гадәт хөсне булыб урнашды. Һәм Ислам шәригате сау-сәламәт булган тәрбияләргә көче җиткән бөтен адәмләр балаларына никяхлануны фарыз итеб куйды.
Аллаһы Тәгалә сурәи “Нур”да әйтә:
عَلِيمٌ وَاسِعٌ وَاللَّهُ ۚ فَضْلِهِ مِن اللَّهُ يُغْنِهِمُ فُقَرَاءَ يَكُونُوا إِن ۚ وَإِمَائِكُمْ عِبَادِكُمْ مِنْ وَالصَّالِحِينَ مِنكُمْ الْأَيَامَىٰ وَأَنكِحُوا
Һәм хәзрәт рәсүл:
القيامة يوم الأمم بكم مباه فإني تكاثروا تناسلوا تناكحوا
Сәламәтлеге булыб, тормыш итүдән куркыб өйләнми җөрүчеләр хакында хәзрәт әйтә:
عزّابكم شراركم
ди. (0825) Сәламәтлеге булыб өйләнми йөрүчеләр, сезнең ...
(0826) 1970 нче ел, гыйнварь 9нчы көне / 1389 нчы Һиҗрия, Зөл Кагъдә 1 нче көне, җомга.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең рәхмәтен теләб, ихлас күңелдән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Барчаларыбыз дөнья Ахирәт сәламәтлек вә җенабе Хакның рәхмәт вә ризасына ирешеб, хәерле вә бәрәкатле тормыәлар (гомерләр) насыйб итсен.
Һиҗри елыбызның 11нче ае булган Зөл Кагъдәнең беренче җомгасы барчаларыбызга

мөбарәк булыб, алдагы булачак күб җомгаларны да ил, җан тынычлыгы, сәламәтлек белән күрергә насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Халкыбыз арасында һәртөрле нигъмәтләр, ашау-эчү нәрсәләре хакында күбтөрле сөәәлләр булды һәм була. Дөрестме, түгелме? Дигән, кебек сүзләр. Шушы хакда Коръән аятьләрен пәйгамбәребезнең мөбарәк сүзләренә күз салыб карыйк.
Рәсүл әкрам хәзрәтләре әйтә:
وقع ومن وعرضه لدينه استبرأ الشبهات اتقى فمن الناس من كثير يعلمهن لا مشتبهات أمور وبينهما بين والحرام بين الحلال إن الحرام في وقع الشبهات في
Шөбһәле ризыклар төрлечә булырга мөмкин. Кеше хаклары булыб, шул җәһатдән шөбһәле булырга мөмкин, (0827) ягъни халәл һәм хәрам булган нәрсәләр ачык рәвешдә бәян кылынган, ачык сөйләнгән, белдерелгән. Менә халәл белән хәрам нәрсәләр арасында шөбһәле нәрсәләр булыб, бу нәһиләрнең хөкемләре бик күбләргә мәгълүм түгел. Әгәр бер адәм халәл, хәрам икәнлеге ачык мәгълүм булмаган нәрсәләрдән сакланса, ул динене һәм йөз сөрене саклаган булыр.
الحرام فى وقع الشبهات فى وقع من و
Ягъни: бер адәм шөбһәле нәрсәләрдән сакланмаса, хәрам эшләргә мөбталә булуы бик мөмкин. Рәсүл әкрам хәзрәте шөбһәле нәрсәләрдән саклану хакында түбәндәге мисалны китерә:
يواقعه ان يشك الحمى حول يرعى كراع
Ягъни: шундайда көтүче шикелле хайванлар керергә тыелган йиргә китүен якын китерүе кебек, гарәбләр хайванлар керергә ярамый торган урынны (حمى) хәми диб атыйлар икән. Шушы хәми янына якын килгән хайванларның хәми эченә кереб көтүләре бик мөмкин. Инде хайванларны көтүче бу керергә ярамый торган урынлардан еракрак йөртсә хәмига керү куркынычы булмый.
حمى مالك لكل وان لا ا
Агәһ булыгыз, һәрбер патшаның хайванларга керергә ярамый торган урыны хәмисы буладыр.
محارمه ارضه فى الله حمى ان و لا ا
Агәһ булыгыз, хәбәрдар булыгыз, белеб торыгыз, Аллаһы Тәгаләнең дә җир йөзендә хәмисы, керергә ярамый урынлары бар. Алар нәрсәләр? Аллаһының без хәрам иткән нәрсәләре – Аллаһының хәмисы. Боларга якын бармау – һәр мөселманның бурычы. Хәрам нәрсәләрдән чын, ихлас күңел белән сакланырга, ерак (0828) булырга телибез икән, инде һичшиксез шөбһәле, сакланырга тиеш булабыз.
Хәдиснең ахырында әйтә:
الْقَلْبُ وَهِيَ أَلا كُلَّهُ الْجَسَدُ فَسَدَ فَسَدَتْ وَإِذَا ، كُلُّهُ الْجَسَدُ صَلُحَ صَلُحَتْ إِذَا مُضْغَةً الْجَسَدِ فِي إِنَّ أَلا
Агәһ булыгыз, хәбәрдар булыгыз, тәндә бу ит кисәге бар, әгәр шул ит кисәге төзек булса, бөтен тән төзек була, дустлык да була. Әгәр ул ит кисәге бозык булса, бөтен тән бозык була. Беләсезме, ул ит кисәге – калебдер (йөрәк – А.Х.).
Тагын да рәсүл Хода икенче бер хәдисендә безгә әйтә:
يريبك لا ما الى يريبك ما دع
Ягъни: шөбһәле нәрсәләрне куй, калдыр. Шәбһәсез нәрсәләрне ихтыяр ит, ал. Менә хәзрәт рәсүлнең бу сүзе безгә аз суз белән мәгънәне аңлаткан, һәр эшләребездә дөстүрель гамәл (эш конституциясе – А.Х.), (төб кагыйдә, кануны) булырга тиеш. Бу урында шөбһәле я шәбһәсез ашау ризыклары, яки кулга керергә мөмкин булган маллар, яки сүз сөйләгәндә шушындый шөбһәле сүзләр, яки гыйбадәтдә сөннәтме, бидгәтме икәнлеге шөбһәле эшләр һәрвакытда шөбһәле нәрсәләрдән тыелуын аңлата.

Менә бу хәдисләрне сөйләүдән мәксуд: кибетләрдә сатыла торган итләр хакында, суелуы хакында һәртөрле шик-шөбһәләргә игътибар итсәк икән. Әлбәттә, һичшиксез, бу хәдискә бина (таянып – А.Х.), саклану тиеш була. Инде тагын да пәйгамбәребезнең икенче бер хәдисен укыб карыйк:
(0829)
كلُوا ،وَاشْرَبُوا وَالْبَسُوا ،وَتَصَدَّقُوا فِي غَيْرِ إِسْرَافٍ وَلَا مَخِيلَةٍ
Ягъни: исраф вә гөҗүб итүдән (масаю, тәкәбберләнүдән) саклану шарты белән ашагыз, эчегез, сәдака бирегез, киенегез, ди.
Беркадәр изах кылсак, һәркайсыбызга мәгълүм: ашаудан мәксуд теләгебез – тәнебезнең төзекләнгән сәламәтлеген саклау. Инде сәламәтлегебезгә зарар китерердәй ризыклар гәрчә халәл ризык булса да, исраф хөкеменә керергә мөмкин мисал өчен пешеб, өлгереб җитмәгән җиләк-җимешләр, пешеб җитмәгән камыр ризыклары, пешеб җитмәгән итләр гомумән ашказанына яки берәр әгъзагә зарар биреб хәстәлеккә сәбәб булса, менә мондый ризыклар исраф хөкеменә керәләр (исраф булдымы, хәрам була). Һәрбер ризыкны тәнебезнең сәламәтлеген, төзеклеген саклау өчен ашасак, ризыкны һәрвакыт ашаган вакытда җаның теләб, нәфрәтләнмичә, җирәнмичә, күңелеңгә, күз алдыңга шушындый нәрсәләрне китермичә, тәмам күңелең җөкләп ашарга тиеш. Бу рәвешле җаның теләб, жиркәнми ашау табиблар тарафыннан да исбат кылынган нәрсә: әгәр бер ризыкны җаның теләми, күңелең җөкләми, җирәнеб ашыйсың икән, бу ризыкдан сиңа сәламәтлегеңне сакларга файда итү түгел, бәлки киресенчә – зур зарар булыб, авыру ясарга мөмкин. Инде нинди генә ризык: итме, яки башка төрле шушындый шөбһәле нәрсәләрдән сәламәтлекне саклар өчен дә сакланырга тиеш була.
(0830) Рәсүлулланың тагын да бер шушындый сүзе, хәдисе бар:
دواء كل رأس الحمية و الداء بيت المعدة
Ягъни: ашказаны – һәртөрле авыруларның урыны, йорты. Инде ризыкны чамалаб, кирәгеннән артык ашамау һәм җаның теләб, чиркәнми ашау дәваларның башы да. Инде шушындый шөбһәле ризыклардан сакланырга хәзерге вакытда бик күб төрле мөмкинлекләр бар. Ит ашамыймыз, аның урынына бигрәк картлар ризыгы булган сөтдән ясалган ризыклар базарда булсын, кибетләрдә тулыб ята.
Хәзер, дөресен генә әйткәндә, без нәфесләребезне бик үзендереб җибәрдек, бик тәмлегә өйрәндек. Хәлең бар икән, шөбһәсез булган, шәригатьчә суелган ит, хәлең җитми икән, нәфсеңне ул кадәр азындырма, сөт ал, катык ал, кефир, шулар белән кәнагатьлән. Нинди авыр вакытлар башыбыздан узмады, мин үзем гомерем эчендә ничә мәртәбә шундый хәлне башымдан уздырдым. Адәм баласы туйганчы кара икмәк ашаса, нинди авыр эшләрендә эшләргә хәле җитәчәк икән, диб әйтә идем. Адәм баласының нәфесе бик начар дөньяда да бик рәхәт торуны сөябез, бик тәмле ашарга да яратабыз. Кыямәт көнендә Аллаһының дустлары, нәбиләре, вәлиләре белән булуны да телибез. Дөньяда алар кебек була алмыймыз, булырга да теләмибез. Аллаһы пәйгамбәрләре күбрәк арпа икмәге ашаб, бер ашаганда ике төрле ризык да ашамаганлар. Хәзрәт Әбу Бәкернең хатыны хәзрәти Әсма хәлифә (0831) хатыны була торыб, авырлы вакытында хәлва ашарга теләгән. Көндәлек ризык аласы акчаларын кыса-кыса, беренче көндә хәлва алырлык акча хасыйл иткән һәм хәлва алган. Хәлваны хәзрәт Әбу Бәкер белән бергә ашамак булыб китергәннең соңында хәзрәт Әбу Бәкер хәзрәти Әсмадән хәлваның кайдан килгәнен сере һәм белгәннең соңында Бәйтель малга барыб, үзенең айлык вазыйфасын киметүне сорый.
Менә җәмәгать! Хөләфа рашидин, әсхабе кирам ничек булган да без ничек? Коръәндә җенабе Раббел галәмин хәзрәте "Әхкаф" сүрәсендә 25 нче аятьтә әйтә:

الْهُونِ عَذَابَ تُجْزَوْنَ فَالْيَوْمَ بِهَا وَاسْتَمْتَعْتُم الدُّنْيَا حَيَاتِكُمُ فِي طَيِّبَاتِكُمْ أَذْهَبْتُمْ
Ягъни: Кыямәт көнендә нәфесләренә хуҗа булмый, берсендән-берсе тәмле, татлы нигъмәтләр нәфесләр азындырган адәмнәргә ителерде. Инде сезнең бөтен ләззәтләрегезне дөньяда кылыб бетердегез, сезгә бу көндә ләззәт алырдай нигъмәтләр юк инде, сез бу көндә хурлык иясе булган, хурлыклы булган Аллаһының газабы белән җәзаланмыш булырсыз, диб әйтелер икән, йә Рабб. Мәңгелек йортта шушындый хәсрәткә, үкенечкә калудан барчаларыбызны сакла.
Вәгазь китабларыбызда шундый сүзләр бар: шөбһәле ризыклар белән ризыкланган адәмнең кылган гыйбадәтләре, теләгән теләкләре кабул булмас, дигән куркынычлы, күңелсез сүзләр дә бар. Хөтбә укыган вакыт хәзрәтләребез шушы хакда безгә исебезгә төшерә килгәнләр (Аллаһының рәхмәтенә булсынлар).
عتاب الشبهات وفي ،عقاب حرامها وفي ،حساب حلالها في
(Җенабе Хак ишеткән сүзләребез, вәгазьләребез белән гамәл итәргә насыйб итсен).
(0832) 1970 нче Миляди, 16 нчы гыйнварь / 1389 нчы Һиҗри, 8 нче Зөл Кагъдә, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабе Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Зөл Кагъдә аеның 2 нче җомгасы җөмләбез өчен мөбарәк булыб, киләчәк җомгаларны да тынычлык, шадлык белән күрергә насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Дөньяда булган һәртөрле мәдәниятле милләт вә мәдәниятле кавем вә кешеләр һәркайсы үзләрендән алда дөньяга килеб киткән халыкка файдалы хезмәтләр күрсәткән, файдалы гамәлләр кылдырган, күренекле кешеләрне, галимләрне туган һәм үлгән көнләрендә аларны зур ихтирам белән искә алыб үтәләр, аларның халыкка күрсәткән файдалы хезмәтләре белән сәңгы буынларны танышдырыб үтәләр. Менә бу рәвешле күркәм гадәт – Коръән тәгълиме буенча, пәйгамбәребезнең хәдисе буенча да узганда булган кешеләребезне искә алырга тиешбез.
ایبراهیم الکتاب فی اذکر و بالله استعیذ
اسماعیل الکتاب فی اذکر و
ادریس کتاب فی اذکر و
(0833) Һәм башка бик күб аятьләр. Һәм хәзрәт рәсүлебез:
موتاکم امحاسن و اذکر
Ягъни: үлгәнләрегезне калдырган күркәм гадәтләре, файдалы хезмәтләре белән зикер итегез, искә төшерегез, ди.
Әлхәмделилләһи Раббел галәмин, шушы Татарстан өлкәсендә яшәүче мөселманлар өчен дә бөек, ихтирамга лаек булган дини, дөньяви гыйлемләрне шамил белгән, хәзерге вакытда да шуларның мөкатдәс хезмәтләре булган гыйльми әсәрләре, китаблары белән файдалана. Һәркайсы Аллаһының рәхмәтендә булсынлар, зур әҗер вә сәвабларга наил булсынлар (ирешсеннәр – А.Х.).
Шул җөмләдән шушы мәсҗедебездә имам вә мөдәррис булган, күб дини вә дөньяви китаблар язып, бөтен Ислам гыйлемендә исеме танылган Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең бүгенге көн 16нчы гыйнварьда дөньяга килүенә 152 ел туган көн, Аллаһының рәхмәтендә булсын, рухы шад булсын.
Шушы мөнәсәбәт белән Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең сөйләгән бер хөтбәсен исегезгә төшереб сөйләмәкче булам. Гаять дәрәҗәдә әсәрле, гыйбрәтле вәгазь, дикъкать

белән тыңлагыз:
“Әмма бугъдә! Аллаһыга хәмде вә пәйгамбәребезгә салават соңында: гомернең сәгатьләре очкан кош кебек үтә, үлем сәгатьләре якынлаша бара. Ирешергә теләгән мәксудлар вә теләкләр булганы булыб, булмаганы булмый калыб, йокыдагы саташу кебек югала тора. Үткен үлем кылычы кынысыннан (قنسندان) сөререлгән, кабергә табут (кабык) җеназа (0834) агачларына салынган, дустлар, туганлар, кардәшләр берәм-берәм Ахирәт сәфәренә китә тора, кайда? Юл өчен хәзерләнгән кирәк-яраклар, кайда? Ахирәт азыклары, гафләт йокысыннан айнырга вакыт, исереклекдән туктарга, оялырга вакыт. Үлем сәгате йитсә, Аллаһы аны кичектермәс. Адәмнең хәле гаҗәб, ул һич үлемдән котылачак түгел, кабергә керми калачак түгел. Соңра Аллаһы Тәбарәкә хозурына барасы бар, үзенең гомере буе кылган эшләрендән җаваб бирәсе бар. Кеше шулай була торыб да яманлыкны ташламый, дөнья малына, акчага динен сата, яхшы эшләрне кылмый, һаман кичектерә бара, бозык эшләрне ташламый, куймый, бәлки ашыктыра. Нәфеснең былчырак (пычрак – А.Х.) теләкләрене артыннан йөрүне, аны төгәлләүне исендән чыгармый. Әмма кабер хәлләрен – Кыямәт катылыкларын уйламый, исенә дә төшерми. Хәлбуки, үзе үлем тырнагына эләгеб беткән, үлемнең тырнак батыру сәгатьләре килеб җиткән.
И, адәм баласы! Уйла, үлем сәгате йитсә, Аллаһы Тәгалә аны һич кичектермәс. Хәленең авырлыгына, сөякләренең сызлавына караб сырхауны, авырыб ятучыны үлем кызганмый, үтерми алыб китми, калдырмый. Балалары күб дә, вак да, ач да, ялангач да булуга караб, үлем бер фәкыйрьне калдырамы? Зур дәүләт ияләренең, байларның байлыкларына күз салыб ригая кыламы? Залим түрәләренең золымыннан, (0835) батшаларның күб гаскәрендән, куәтле коралларыннан куркамы? Зур табибларның, хаким-хан колларның дәвалары файда, шифа бирәме? Кем үлми кала? Кем кабергә керми кала? Сырхауны караучы, тәрбия кылучы өмеден өзсә, тереклек, кояш сүнсә, сырхау барачак йирен күрсә, шул вакыт бу сүзләргә ышаныр, инаныр. Шул чакда бозык эшләренә, сөйләнгән былчырак сүзләренә үкенер, оялыр. Адәмләрне рәнҗеткәне, ябкан ялалары-ялганлары, сөйләгән гайбәтләре өчен тәмам хәсрәт басар, кайгы чолгаб алыр. Шул вакыт хәлен сорасаң, җаваб бирмәс.
اجالها جاء اذا نفسا الله يؤخر لن ة
Үлем сәгате йитсә, аны Аллаһы Тәгалә кичектермәс.
Катылыгы белән исертә торган үлем сәгатләре нинди авыр сәгатләр. Сырхау ул сәгатьдә ятагында көеб яна, ауный, тәгәри, әйләнә, үлем ачысындан-катылыгындан сырхауның хәлләре бетә, телләре бәйләнә, шул чаклы авыр-кайгылы ишетүедә, авыр булган бу сәгатьләр бервакыт һәр адәмгә, барчабызга киләчәк:
الموت ذائقة نفس كل
Шул вакыт адәм баласы өстенә тау-тау хәсрәтләр өеләчәк. Андан соңгы хәл исә тар кабергә күмелү, караңгы гүргә керү. Күб адәмләр шушы каберлекдәге хәлләрне күреб, гыйбрәт алмый, кабер әһелләре үзләре дә башларына килгән хәлләрне сөйли алмый, тел биргән Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә аларны телсез иткән. Юкдан бар кылган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә аларны туфрак иткән, (0836) юк иткән. Беркөн килер, ул таралган гәүдәләрне Аллаһы Тәгалә хәзрәте кодрәте белән җыяр, әүвәлге хәлләренә кайтарыр, Кыямәт көн Мәхшәр мәйданында һәркайсын Хисаб мәйданына җыеб, дөньяда кылган эшләрендән хисаб алыр, җаваб алыр. Шул көндә адәм баласына изге гамәле вә яхшы эшләрендән башка һич нәрсә файда бирмәс.
الالباب اوٕلى يا فاعتبروا
И, гакыл ияләре! Бу сүзләрдән гыйбрәтләнегез, дөнья белән генә мәшгул булыб, Ахирәтне

онытмагыз".
Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең сөйләгән хөтбәсенә мөнәсәбәте булганлыкдан пәйгамбәр (сгс)нең бер хәдис шәрифен исегезгә төшерәмен. Рәсүл әкрам (сгс) Гаффәр кабиләсендән булган Әбузяр (ابو ذر) исемле сәхабәгә караб әйтә:
يا أباذر
أحكم السفينة فإنّ البحر عميق , واستكثر الزاد فإنّ السفر طويل , وخفف ظهرك فإنّ العقبة كؤود , وأخلص العمل فإنّ الناقد بصير
Ягъни: И, Әбузяр! Көймәңне яңарт, төзек-таза кыл, диңгез бик тирән, куркынычлы, азагыңны, ашау-эчү нәрсәләреңне мул ал, барачак юл бик ерак. Йөгеңне җиңгел кыл, барачак йирең бик-бик мәшакатле. Гамәлеңне ихлас белән халисән лилЛәһи кыл. Моңа бәя бирүче, кабул итүче, үтә күрүче, бик караб алучы рәсүл әкрам (сгс) бу хәдисендә, бу нәсыйхәтендә дөньяда яшәүне, тереклек кылуны тирән диңгездә сәфәр кылуга охшаткан. Тирән, зур диңгездә (0838) сәфәр кылу өчен киемең төзек вә таза, ышанычлы булуы кирәк, юкса, һичшиксез, һәлак булуы мөмкин. Бу мөбарәк сүзләр: кешегә гомер сәфәрендә иң беренче нәрсә пакъ, чын иманлы, саф, сәламәт күңелле булуны аңлату булса кирәк. Чөнки бу рәвешдә булмаган адәмнең тормыш сәфәрендәге мәшәкатләрне үткәрүе читен, һәлак булуы мөмкин (юк кына авырлыкларга да сабыр итми һәлак булулар – иман зәгыйфлекрәк). Азык-телекне мул ал дигән сүзе, чөнки барачак юл ерак сүзе: кешеләрнең дөньяда яшәб Ахирәт сәфәренә баруларын озын вә мәшәкатьле юлга, сәфәргә чыгуга охшаткан. Кеше ерак вә мәшәкатьле сәфәргә чыгачак булса, азыкны яхшырак, муллырак алырга тырыша. Дөньяга килгән һәр адәм теләсә дә, теләмәсә дә Ахирәткә сәфәр кылачак. Бу сәфәргә исә адәм баласы дөнья нәрсәләрен алыб бара алмый, бәлки үзенә азык итеб, юлдаш итеб алган нәрсәсе: тәнендәге куәтне, кулындагы малны Аллаһы Тәгалә ризасы өчен (Аллаһы ризасы булган урынларга) сарыф кылыб, табкан изгелекләре, үзендән соң калдырган яхшы эшләре, яхшы исеме булачак.
Һәм йөгеңне җиңгел ал, юл мәшәкатьле дигән сүзе: гомер сәфәрендә кеше өстенә йөкләнә торган бозык, начар, гөнаһлы эшләр булыб, Кыямәтдә җенабе Хак хозурныда зур мәсъүлияткә, хурлыкка калдыра торган нәрсәләрдән саклануны вә ерак булуны аңлаткан. Җенабе Раббел галәмин хәзрәте без-бәндәләренә пәйгамбәрләре аркылы дөнья вә Ахирәт сәгадәтенә ирешү юлларын күрсәткән кебек, дөнья Ахирәтдә һәлакәтле сәбәб була торган нәрсәләрендә безгә ачык бәян кылган.
Гомер юлында булган гакыл ияләре бу әхкам вә тәвсыяләрне кабул итү вә эшкә ашыру белән генә сәгадәткә ирешүне хәтердә тотыб, шундан читкә таелмаска, һидаять вә истикамәт юлындан аерылыб, үзенә вә бөтен кешелек дөньясына җәбер-золым итүгә мәел итмәскә. Андый начар сыйфатлардан ерак булырга тиеш.
Җенабе Хак барчаларыбызны хата вә кимчелекләребезгә тәүбә-истигъфар кылыб, шик-шөбһә вә көферлек бычракларындан имин кылыб, җенабе Хак хозурына кальбе мөслим белән кайтырга насыйб итсен.
(0840) 1970 нче Миляди, 23 нче гыйнварь / 1389 нчы Һиҗри, 23 нче Зөл Кагъдә 15 нче, җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ихлас күңел белән бәйт Аллага, мәсҗед җәмигъга гыйбадәт кылу теләге белән җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Зөл Кагъдә аеның 3 нче җомгасы җөмләбез өчен мөбарәк булыб, кылган гыйбадәтләребез җенабе Раббел галәмин хәзрәте каршында дөньяви, ахирәви теләкләребезне теләб, кылган догаларыбыз мәкбуль булыб, сәгадәт дарының дөньяви, ахирәви теләкләребезгә ирешергә

насыйб булсын иде.
Бу җомгада була алмадым (авырыб калдым).
(0841) 1970 нче Миляди, 30 нчы гыйнварь / 1389 нчы Һиҗри, 22 нче Зөл Кагъдә, җомга көн.
Шәһәребезнең һәртөрле почмакларындан җенабе Раббел галәмин хәзрәтенә бәндәчелек кальбе ихлас күңелдән гыйбадәт кылырга мәсҗед йортына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Барчаларыбызга дөнья вә Ахирәтдә сәламәтлек, Аллаһының рәхмәтенә ирешергә хәерле вә бәрәкатле гомерләр насыйб итсен.
Зөл Кагъдә аеның дүртенче җомгасы вә җомга гыйбадәтенә килүләребез мөбарәк вә мәкбуль булыб, киләчәк җомгаларын да шадлык белән күреб җенабе Хакның ризасына муафыйк рәвешдә уздыруларны насыйб вә мөйәссәр кылсын.
Мөхтәрәм мөселманлар! Бүген мин сезгә хәлемдән килгән кадәр Исламның бинасы, мөселманлыкның билгесе, мөэминнең нуры, Аллаһыдан куркуның, Аллаһының ризасына ирешү теләге белән күңелебездәге иманның заһири (тышкы – А.Х.) билгесе булган намаз гыйбадәте хакында сөйләмәкче булам. Бу хакда ни кадәр сөйләсәк дә, сүзләр бетмәс. Күңелебез Аллаһыга рәхмәт итсен, Аллаһы кабул итсен. Намазны ихласда бер дә калдырмаска тырышкан адәмләр булган кебек, арабызда намазны бик җиңгел санаб яшибез. Олугъ чәчебез, сакалыбыз агаруга карамастан, биш вакытны укымаучыларыбыз да бик күб. Инде шуның белән бергә арабызда Аллаһының һидаяте белән пенсиягә чыккан яки пенсиягә чыгу алдында торган, гомерләренең соңгы чирегенә җиткән кешеләребез арасында (0842), яшь вакытда өйрәнә алмаган яки өйрәнеб дә яшьлек гафләте, дөнья мәшәкате белән мәшгуль булыб, бөтенләй намаз укый белмәүчеләребез дә бар, яки намаз укыб да күб кенә ялгыш вә хаталарыбыз да бар. Арабызда ихлас күңел белән шушы хаталарыбызны белергә, шушы хаталарыбызны бетерергә тырышучыларыбыз да бар.
Аллаһыга рәхмәт итеб, бу сөйләчәк сүзләремдә
1) намазның фазыйләте, тиешлеге хакында. Коръән аятьләре хәзрәт рәсүл әкрамнең хәдисләре;
2) намазны җиңел санаб, намазны калдыручыларга Коръәндә вәгидләр (вәгъдәләр – А.Х.) һәм хәдисләр. Һәм намаз уку хакында рәсүл әкрам тарафындан сөйләнгән хәдисләр һәм шәригате Ислам тарафындан күрсәтелгән рөхсәт вә файдалар, инша Алла, ихлас күңелле адәмләргә файда бирер.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Кәлам шәрифдә сүрәи “Бәкарә”дә 21 нче аять шәрифдә:
تَتَّقُونَ لَعَلَّكُمْ قَبْلِكُمْ مِن وَالَّذِينَ خَلَقَكُمْ الَّذِي رَبَّكُمُ اعْبُدُوا النَّاسُ أَيُّهَا يَا
Ягъни: и, адәмләр! Сезне һәм сездән килгән адәмләрне яраткан Раббыңызга гыйбадәт кылыгыз. Шәед ки, сезгә, сездән әүвәлдәге өммәтләргә шамил булган тәрбия кылучы, юкдан бар кылучы Халикыңыза тәкъвалык кылырсыз.
Аллаһының бу хыйтабы, әмере бөтен адәм балаларына гамь (уртак – А.Х.) булыб, үзләренең юкдан бар кылучы, халыкларына тәрбия кылучы Раббларына коллык кылу, ихлас күңел белән гыйбадәт кылырга чакыра. Шушы рәвешле ихласдан гыйбадәт кылуыбыз сәгадәт дәрәйндә фәуз вә нәҗат вәсилә икәнен ачык бәян итәр.
(0843) Мөхтәрәм җәмәгать! Без һәркайсыбыз, әлхәмделилләһи Раббел галәмин, әһле иман әһелләредер. Иман нәрсә? Иман – ышану, мөэмин-мөселманларбыз.
(البقرة سورة) الصلوة يؤمنون و بالغيب يؤمنون الذين
Мөэмин кем була? Мөселман кем була? Мөэмин күз белән күрмәгән галәм гәебкә ышанучы (иман китерүче), ягъни Аллаһының барлыгына, берлегенә, Кыямәт көненең

булачагына, фәрештәләргә, пәйгамбәрләргә, кыскасы, - күз белән күрмәгән нәрсәләргә ышану. Мөселман кем була?
من سلم المسلمون من لسانه و يده
Ягъни: мөселман – шул адәм, бөтен кеше аның җәбер-золымыннан тыныч булыр, имин булыр. Теле белән, кулы белән дә һичкемне рәнҗетмәс. Икенче төрле итеб әйткәндә, мөэмин мөселман булу шуның белән була: Аллаһының пәйгамбәре рәсүлулла Аллаһы тарафыннан (дин, шәригать хөкемләрен) китергән дин, шәригать хөкемләрен кабул итеб, шуларны кылырга. Кушканларын кылу, тыелырга кушканларыннан тыелу белән, шуңар сүз бирү, гаһед кылу дигән сүз була. Шушы Аллаһынаң пәйгамбәре тарафыннан әмер вә гыйбадәтләрне үтәргә өстемә алдым, гаһед кылдым, ант итдем, шуларга вәфа кылырмын (тугърылыклы булырмын – А.Х.), диб сүз бирүдән гыйбадәт. Шулай булгач өсткә алган нәрсәне ида итәргә тырышу – һәр мөселманның бурычыдыр.
Хосусан намаз гыйбадәтен үтәү – мөселманлыкның Аллаһыга ышануның зур билгеседер. Намаз уку җиңел, фәкать моңар нәфсеңне җигеб гадәтләнергә генә кирәк. Ходага мең-мең шөкранәләр кылсак да, аз була. Һәртөрле кием-салымнарыбыз (0844) бар. Аруланыр, пакъләнер өчен бөтен мөмкинлекләребез бар. Мунчалар инде күбләребезгә банныйлы җуына торган бүлмәле фатирлар биреб тора. Әүвәлге вакыт авыл җирләрендә 25-30 градус суыкларда лабасда селкәм (?) өстендә гөсел коенган адәмләр була иде. Менә бу эшләр чын иман аркасында үтәлгән гамәлләр. Хәзерге вакытда безнең хосусан пенсиягә чыккан кешеләребезгә намаз калдырырга һичбер гозер юк, фәкат чын иман, нык ышану гына кирәк.
Мөхтәрәм җәмәгать! Намазның фазыйләте хакында рәсүлулланың берничә хәдисен исегезгә төшереб узам:
قال رسول الله صلعم إذا كبر العبد للصلاة يقول الله تعالى للملائكة ارفعوا ذنوب عبدي عن رقبته حتى يعبدني طاهرا
Ягъни: һәркайчан бер адәм намаз укырга тәкбир итсә, Аллаһы тарафыннан фәрештәләргә әйтәләр икән: бу бәндәне мең гөнаһларыннан (вак гөнаһларыннан) пакъләгез, пакъ булган хәлдә намаз укысын, диб.
Икенче бер хәдис:
خَمْسُ صَلَوَاتٍ كَتَبَهُنَّ اللَّهُ عَلَى الْعِبَادِ، فَمَنْ جَاءَ بِهِنَّ لَمْ يُضَيِّعْ مِنْهُنَّ شَيْئًا اسْتِخْفَافًا بِحَقِّهِنَّ ، كَانَ لَهُ عِنْدَ اللَّهِ عَهْدٌ أَنْ يُدْخِلَهُ الْجَنَّةَ،
وَمَنْ لَمْ يَأْتِ بِهِنَّ فَلَيْسَ لَهُ عِنْدَ اللَّهِ عَهْدٌ، إِنْ شَاءَ عَذَّبَهُ، وَإِنْ شَاءَ أَدْخَلَهُ الْجَنَّةَ
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бәндәләре үзренә биш вакыт намазны фарыз итде, боерды. Кем дә кем биш намазны хакын белеб ида итсә, үтәсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Раббел галәмин хозурында ике арада булган гаһедне, вәгъдәне үтәгән булыб, җенабе Хак ул бәндәне җәннәткә кертер. Инде биш намазны үтәмәгән булса, вәгъдәсен, гаһеден үтәмәгән (0845) булыб, теләсә – газаб кылыр, теләсә – гафу итеб җәннәткә кертер, ди.
Намаз калдыру хакында Аллаһының бик куркынычлы вәгыйдләре бар, җөмләдән берсе: “Мәрьям” сүрәсендә 56 нчы аятьдә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте әйтә:
فَخَلَفَ مِنْ بَعْدِهِمْ خَلْفٌ أَضَاعُوا الصَّلَاةَ وَاتَّبَعُوا الشَّهَوَاتِ فَسَوْفَ يَلْقَوْنَ غَيًّا
Пәйгамбәрләр соңында шундый явыз кавем намазны калдырдылар, яки вакытыннан кичектерүләр һәм нәфесләренә ияреб, һәртөрле бозык, начар, гөнаһ эшләрне кылырлар. Менә бу адәмләр тиз көндән Аллаһының каты газабы Гай чокырына йолкырлар, ди.
Һәр рәсүл Хода әйтә:
كُلُّ أُمَّتِي يَدْخُلُونَ الْجَنَّةَ إِلَّا مَنْ أَبَى
قَالُوا يَا رَسُولَ اللَّهِ وَمَنْ يَأْبَى قَالَ مَنْ أَطَاعَنِي دَخَلَ الْجَنَّةَ وَمَنْ عَصَانِي فَقَدْ أَبَى
Инде пәйгамбәргә өмет булуны дәгъва кылыб да, аның әйткәнләре белән гамәл кылмасак, бу бик күңелсез, мөселманлыкка хилаф булган, Аллаһыга, пәйгамбәргә каршылык кылу

була.
1.Әгәр бер адәм ихлас күңелдән биш вакыт намазга гадәт кылса, беренче аның табкан малы бәрәкатле булыб, гаиләсе эчендә тынычлык, тормышы ямьле булыр.
المنكر و الفحشاء عن تنهى الصلوة ان
Чын намаз күркәм холыклы булуга сәбәб була.
2. Каберендә газаб булмас, гамәл дәфтәре уң тарафындан бирелер, сыйратдән (күпердән – А.Х.) йиңел үтәр.
Белмим диб, моның белән котыла алмыйбыз. Ихлас күңел белән һәр нәрсәне өйрәнергә мөмкин (وجد جهد من). Бер дә белмәүчеләр хакында Рифага бин Малик сәхабә рәсүлулладан күчереб әйтә:
من شيء معه يكن لم ان و فليقرأ القرآن من شيء معه كان يكبرفان ثم تعالى الله امر كما فليتوضا الصلوة الى احدكم قام اذا اليكبر و فليحمد القرآن
(0846) Рәсүлулла вакытында Коръәндән бер аятен дә белмәүчеләр булган икән. Менә шуларга караб рәсүлулла шушы сүзләрне әйткән. Мөселман адәмгә намаз калдырырга һич бертөрле юл юк. Авыру булсак яки су булмаган булыб да, суны истигъмәл кылырга хәлебездән килмәсә, тәмим сугыб укырга, зарурат вакытларда, урын тыгыз вакытларда ишарә белән укырга шәригатебез рөхсәт иткән. Шәригатьнең бу рөхсәтләрен ганимәт булыб, шулардан файдаланырга тиешмез.
وسعها الا نفسا الله يكلف لا
Яшь вакытда калган намазларыбызны мөмкин булган кадәр укырга тырышырга кирәк. Безнең казага калган намазларыбыз күбрәк гозер белән түгел, намазны җиңелгә санаб калдырылган намазлар. Болар өчен күз яшьләребез белән җылаб-җылаб, Аллага тәүбә кылырга тиешбез, чөнки намаз калдыру хакында:
الدين هدم فقد تركها من و
كفر فقد متعمدا الصلوة ترك من و
Бер кеше гозерсез намазны куйса, көферлеккә якын булды, ди. (Иблис вакыйгасы).
Мөхтәрәм җәмәгать! Намаз, имандан кала, Исламның нигезе вә бөек рөкенедер. Намаз бәндәнең Халикына, Мәгъбүденә, Раббысына булган бөек мөнәҗәте. Намаз бәндәнең Аллаһыга булган итагәте, Ислам диненә, пәйгамбәргә мәхәббәтен, күңелендә булган чын иманын заһири рәвешдә, тышкы җәһатдән белдерә торган күркәм гадәт вә сыйфатдыр. Намаз бәндәнең эчен, тышын пакъләб, арулаб, Аллаһыдан, пәйгамбәрдән ераклашдырыб, шәйтанга якынайта торган гөнаһ керләрендән вә көферлек пычракларындан арулаб, иманга куәт биреб, иманны вә мөэмин күңелләрне нурландыра торган, (افضل الاعمال احب الاعمال ) булган олугъ гыйбадәт. Иман намаз белән нурлана, иманның ныгуына, Аллаһы хозурында мәкбуль вә мөгътәбир булыб, бәндәнең нәҗатына сәбәб була. Намазсыз иман, дин зәгыйфь була, намазсыз иман җимешсез агач кеби бетергә торган нәрсә вә үләргә торган авыру була. Аллаһы Раббел галәмин барыбызның күңелләребезгә тәуфыйк, һидаять биреб, яшь вакытларыбызда укый алмаганларыбызга укытыб, гомеребезнең соңгы чирекләрендә намазларыбызны укыб, чын мөселман булыб, дөньядан үтәргә насыйб булсын.
(0847) 11.
“Зияратне тазарту хакында”
1968 нче ел, 10 нчы май / 13 нче Сәфәрел хәйр
Соңгы вәгазь 31 нче май / 4 нче Рәбигел әүвәл
(0848) 1968 нче ел, 10 нчы май, бомга / 1388 нче Һижри, 13 Сәфәрел хәйр
Сәваб өмед итеб, Аллаһы хозурына баруны искә алыб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм

мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Саулык-сәламәтлек, тынычлык белән алдагы күб җомгаларны күрүгә насыйб булса иде. Амин.
Мөхтәрәм мөселманлар! Шәригъ кәрим нәби, мөхтәрәм хәзрәт, рәсүл (гс) әйтә:
اللذات هاذم ذكر اكثروا
Бөтен ләззәтләрне, рәхәтләрне кисә торган, бетерә торган үлемне күб зикер итегез, күб искә алыгыз, ди.
Үлемне искә алу ничек була соң? Үлемне искә алабыз диб, бәгъзе берәүләребез гел намазлык өстендә генә утырыб, тәсбих тартыб, үлемне искә алу диб күзаллыйлар. Алай уйларга ярамый. Үлемне искә алу фарыз гамәлләреңне ихлас белән үтәргә тырышу, халәлдән кәсеб итү, хыянәтдән, ялгандан, кеше хакындан саклану, үзеңдән башкаларга хәлеңдән килгән кадәр файда, ярдәм, яхшылык итәргә тырышу, һәрбер эшләреңдә дөньяви, ахирәви эшләреңдә Аллаһы хозурына барыб хисаб бирәсе барын уйлау – менә үзеңне шушы тотарга, булдырырга тырышсак, менә монлар һәрберсе үлемне искә алу була. Үлемне исдә тоту тормышы авыр булган адәмләргә дә беркадәр җиңеллек биреб, үзенең бар кадәр тормышына кәнагать хасыйль итәргә (0849) мөмкинлек бирәчәк, әмма тормышы иркен, бай адәмләрне, тәкбирлеге бетеб, инсафка килүләренә сәбәб булачак. Үлемне һәркайсыларыбызның күз алдыбызда күреб торабыз. Уйламаганда кинәтдән генә дә үлемләр була. Бүген сау-сәламәт йөргән адәмләр беркөн эчендә кабер иясе булалар. Менә үлемне һәрвакыт исдә, хәтердә, күз алдында тотсак, кечкенә генә бер начарлыкдан тыелыб калсак да, үзебезгә зур файда бирәчәк. Тагын да хәзрәт рәсүл әйтә:
موعظا بالموت كفي
Ягъни: гыйбрәт алу, вәгазьләнү йөзендән үлем җитә, ди.
Инде, кызганычка каршы, без бертуганбыз, яки бер белгән адәмебез улыб җатканы хәлдә, һич гыйбрәт алмыйча, бәйләнү, низагълашу, ул гына да түгел, шушы үлем, мәет өстендә ялган, хыянәт юлына кереб китеб, үзебезне бик суфи, бик белдекле галим итеб күрсәтеб, кесәсен тутырыб җөрүчеләр дә бар. Менә күбтән түгел булган хәл. Мәсҗеддән тәһлил кеше чакырылган бер карт кереб: мәсҗеддән кешеләр килми, килә алмыйлар, - ялганлаб, тәһлил багышлаб, бөтен сәдакаларын җыеб китә. Бу кеше үзе олы яшьдәге бер картдыр. Бәлки сакалы да бардыр, мөселман киеме киенгәндер. Менә шушымы? Үлемдән гыйбрәт алу шушымы? Мөселманчылыкмы бу?
Хәзрәт рәсүлнең тагын бер мөбарәк сүзе искә төшә:
قلوبكم إلى ينظر ولكن ،صوركم إلى ولا ،أجسامكم إلى ينظر لا الله إن
Аллаһы Тәгалә сезнең малларыгызга, тышкы кыяфәтләрегезгә карамый, күңелләрегезгә, гамәлләрегезгә карый, ди.
(0850) Минем сүземдән аңламагыз, мулла башкаларга сәдака бирергә кушмый диб, бирегез, ләкин яхшы күңелле, хыянәтдән, ялгандан саклана торган ихласлы картларга бирегез. Менә мондый алдакчы, ялганчы картларга бирүдән сакланыгыз, диб әйтүем. Инде бер адәм үлем өстендә ялганлаудан, алдаудан курыкмый икән, башка вакытда буниләр эшләмәскә мөмкин. Аллаһы сакласын.
Хәзрәт рәсүл тагын да әйтә:
الآخرة تذكركم فانها القبور زوروا
Каберләрне зиярат кылыгыз, каберләрне зиярат кылу Ахирәтне искә төшерер, ди.
Каберлекләргә бару, аларны тазарту, мәетләргә Коръән укыб, дога кылулар Ахирәтне искә төшерүгә һәм үлемне искә алуга, без шушында киләчәк диб гыйбрәтләнүгә сәбәб икәне

аңлана бу хәдисдән.
Хәзрәт Госман каберлекләргә бару белән тыела алмый җылый икән. Бер вакытда хәзрәт Госмандан берәү сорый: йә Госман, җәннәтне, тәмугъны искә алган вакытда да болай җыламыйсың, әмма каберлекләрдә җылыйсыз. Моның сәбәбе нәрсәдә, – диб сорады.
Хәзрәт Госман әйтте: хәзрәт рәсүлдән бервакытда ишетдем. Ахирәт сәфәренең иң әүвәлге туктала торган урыны, мәнзеле – кабердер. Әгәр дә кабердә эшләр яхшы булса, андан соңгылары да яхшы булачак. Әмма кабердә эшләр начар булса, андан соңгылары да начар булачак диб ишетдем, ди. Шушы сүз хәтеремә килеб җылыйм, диб җаваб биргән.
Каберләрне зиярат итү хакындагы башка хәдисләр күб. (0851) Менә шушындый ниятләр белән каберләрне зиярат, мәетләр өчен истигъфар кылу, дога кылу мәшругъ, сәваблы эшләр. Әмма алардан ярдәм истәү, алардан хаҗәт истәү шәригать кашында мәмнугъ, ярамаган эш.
Фәлән җирдә изгеләр зиярате бар, шунда барыб корбан чалырга, нәзерләр әйтү, алардан ярдәм истәү, хаҗәтләр үтәлүне сорау – болары пәйгамбәр тарафындан тыелган эшләр.
Чын мөселманның гакыйдәсе:
اياك نعبد و اياك نستعين
булырга тиеш. Рәсүлулла үзе дә каберлекләргә барыб, зиярат кыла торган булган. Бервакытда ул анасының каберен зиярат кылыб, бик әсәрләнеб җылаган, һәм янында булганларны да җылаткан иде.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Бер кадәр сәз уңаенда хатын-кызлар хакында искә алыб китәргә кирәк. Һәрбер үлгән адәмнең гәүдәсе янында аның туганлары, якынлары җыелу гадәт. Бу яхшы, күркәм гадәт. Шул җыелган картлар, карчыклар, ничек дә олы яшьдәге адәмләр булмый калмый. Шушы янына җыелган адәмләр һәркайсы яшьләргә, һәркайсына бик яхшы исләренә төшерергә кирәк. Арусыз (чистарынмыйча – А.Х.) булган көйгә зияратка бармаска, исерек килеш зияратка бармаска. Менә шуларны искә төшерү барыбызның да бурычы, шуны яхшы аңлагыз. Яшь кенә хатын-кызлар, балалар, бигрәк дә җәйге көнләрдә җиңсез күлмәкләрдән мәетне озата бару, зияратка керүләр – болар барысы да яраган эшләр түгел. Мәетнең якынлары менә шушы хакда, аларга яхшылаб аңлатырга (0852) тиеш. Яланаяк, җиңсез күлмәк кию тыела. Әдәб рәвешендә дә хатын-кызлар җеназага иярмәгәнләр, бәлки зарурат вакытда ирләр җитешмәгән вакытларда мәетне күмәргә барулары булган. Әмма башка вакытларда пакъләнеб, тәһарәтләнеб, гыйбрәтләнү йөзендән үлемне искә төшерү, якынларына дога кылу өчен әдәби киемләр киеб зияратка барулары – монысы мәмнугъ тыелган эш түгел, моңа дәлилләр хәзрәти Фатыйма һәр җомгада хәзрәт Хәмзәнең каберен зиярат кылуы (Мөхәммәд әл-Кари “Шәрх” Сәхих әл-Бохари шәрхендә) язылган. Һәм хәзрәт рәсүлнең хәзрәти Гайшәгә каберләрне зиярат кылганда укыр өчен догалар өйрәтүе менә шушы сүзләргә бина, хатын-кызларын, әдәб рәвешдә тәһарәтләнеб, каберләрне зиярат кылулары дөрест дигәннәр.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Мәксудка килик. Һәркайсыларыбызның барачак урыны булган, хөрмәтле аналарыбызның, хөрмәтле бабаларыбызның, сөекле балаларыбызны әдәб-тәрбия, гыйлем өйрәткән бөек остазларыбызның гәүдәләре күмелгән урын булганлыкдан зиярат, каберлекләр һәркем тарафындан хөрмәт ителергә тиеш. Каберлекләрне кадерсез итү, каберлекләрдә начар эшләрдән, начар гадәтләрдән саклану исламият җәһатендән генә түгел, һәрбер вөҗданлы инсан тарафындан тыелырга тиеш.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Хәзрәт рәсүлнең безгә васыять итеб әйткән тагын да бер сүзен искә алыб:
ان الله طيب يحب الطيب

Аллаһы Тәгалә һәрбер кимчелекләрдән пакъ, башкаларның да шулай булуын сөя.
ان الله نظيف يحب النظافة
Дөрестлекдә Аллаһы пакъ, таһир, вә пакъ булган эшләрне сөяр. Һәм бәндәләрнең дә һәр эшдә пакълекләрен сөяр.
فنظفوا افنيتكم
Ишек алларыгызны, урамларыгызны да пакъ тотыгыз, ди.
ان الله جميل يحب الجمال
Аллаһы Тәгалә җәмил, башкаларның һәр эшдә җәмил вә матур булуларын сөя, ди.
Пәйгамбәр Хода безнең ишек алларыбызның, урамларыбызның таза-пакъ булуы белән боера икән, инде безнең һәркайсыларыбызның барачак урыны булган зияратларыбыз, каберлекләребез бигрәк дә пакъ, чиста, матур булырга тиеш.
Хәзер җәйгә чыкдык, илебезнең күб шәһәрләрендән, хәтта чит илләрендән сияхлар (туристлар – А.Х.) килергә мөмкин. Читдән килгән сияхларның искедән калган, килгән гадәтләре: бер җиргә барсалар, тарихи, истәлекле урынларны карау, тикшерү була. Сияхлар арасында тарихчылар, тагын әллә нинди зур фән галимләре булыр. Менә зур адәмләр үзләренең күргән нәрсәләрен тарих битләренә яза баралар. Безнең Казан шәһәре, бигрәк дә Татарстан мәркәзе, үзәге булганлыкдан, татар халкы тарихда бик мәгълүм бер милләт булыб, һәр илнең галимләре Казан белән бик кызыксыналар. Һәр җәһатдән килгән сияхлар кирәк, үз илебезнең башка шәһәрләрендән килсенләр кирәк, чит илләрдән килсенләр, алар күбләре безнең зияратларыбызны, (0854) мәсҗедләребезне караячаклар. Инде безнең бабаларыбыз Казан шәһәрен бөтен галәмгә танытыб, тарихи бер шәһәр итеб калдырганлар. Без дә үз буыныбызда тарихи шәһәребезнең иң беренче исдәлекле урыны булган зиратымызны таза, пакъ, матур итү – безнең һәркайсыбызның изге бурычы. Менә шуларны искә алыб, җәмәгать, киләчәк якшембе көн 12нче майда көрәкме, сәнәкме, тырмамы алыб барыб зияратемезне тазартсак, беренчедән тарих битләрендә матур исемемез калуга сәбәб булса, икенчедән, пәйгамбәребезнең безгә кушкан васыятен үтәгән булыб, Ахирәтебез өчен зур, сәваблы эш эшләгән булырбыз. Өченчедән, ата-аналарыбыз, бабаларыбызның, остазларыбызның җанларын шадландырган булырбыз.
Мөхтәрәм җәмәгать! Зур гөзерләребез булмаса, шушы зур, сәваблы эшдән читдә калмаска тырышыйк!
Җенабе Аллаһы барыбызга да хәйрен нас булыб яшәргә, үзебезнең үлгәннең соңында да исемләребез яхшылык белән искә алына кешеләр җөмләсендә булырга насыйб булсын.
Казан шәһәре мәсҗедендә Габделхәбир Ярулла угълы тарафыннан сөйләнгән вәгазьләр.
(0855) 1968 нче ел, 17 нче май / 1388 нче Һиҗри, 25 нче Сәфәрель Хәйр, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабе Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мәсҗедебезнең мөгътәбир картларыбыздан бер картыбыз Куйбышев (әүвәлге Самара) шәһәренә барган икән. Киткән вакытда безнең белән күрешеб, без дә инде аңар хәерле юл теләб: исән барсагыз Казан мөселманлары барыбызның исемдән дога үтенеб сәлам сөйләргә кушкан идек. Ул безнең тарафдан куйбышев мөселманларына сәламләребезне табшырган. Шулай ук Куйбышев шәһәрендә яңа ачылган мәсҗеддә җыелган шушы картыбыз аркылы безгә дә дога вә сәламләрен әйтеб үтенгәнләр. Инде хәзрәт рәсүлнең мөбарәк сүзләренә бина:

أَدِّ الأَمَانَةَ إِلَى مَنِ ائْتَمَنَكَ ، وَلا تَخُنْ مَنْ خَانَكَ
Ягъни: үзеңгә амәнәт ителгән нәрсәне тиешле урынына табшыр, үзеңгә хыянәт иткән адәмгә дә хыянәт итмә, дигән хәдисенең бина, бу картыбызның өстендә дә бурыч булыб, һәм минем өстемдә дә бурыч булмасын. Шушы Куйбышев шәһәре мөселманларының сәламен (0856) табшырамын: Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Тәбарәкә хәзрәте шушы ачылган мәсҗеднең дәвамын насыйб итеб, Аллаһы ярдәм бирсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Узган җомгада зияратымызны тазарту хакында беркадәр сөйләгән идем. Ни сәбәбледер, белмим, мин аңлата алмадыммы, халык бик аз булды. Рәхмәт, ниндидер организацияләр тарафындан өч ат да бирелгән иде. Кеше аз булу сәбәбле ул атлардан да кирәгенчә файдалана алмадык.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мин сезгә үз сүземне әйтмим, Коръәнебез кычкырыб тора. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әйтә:
تعاونوا على البر و التقوى
Ягъни: ярдәм итешегез һәр яхшы эшләргә вә тәкъвалеккә. Менә бу сүз – Коръән сүзе. Әгәр үзебезне мөселман диб беләбез икән, Коръән сүзен гамәл итәбез дисәк, җомгада иң аз дигәндә 700-800 адәм булса, шуларның бер ундан бер генә булса да 75-85 адәм булырга кирәк иде. Шушы каберлекләребездә күбләребезнең туганлары, ата-аналары, остазлары бар һәм кайсыларыбызның бүген, бүген булмаса иртәгә һәрберебезнең барачак урынымыз, төб йортыбыз. Инде тагын да шимбә, якшәмбе тибрәнеб карасак:
انما الاحسان بالاتمام
дигән сүзгә бина, инде бер изгелек башласак, тәмам итәргә тырышу, изгелек тәмам итү белән була, дигән. (Рәхмәт итсен бу адәмләргә. Бердән, дәгъвәткә иҗабәт итү, икенчедән, – зур, сәваблы эш кылдылар). (0857) Сүзне истә тотыб, тагын да берәр мәртәбә барсак, бердән, кабер әһелләре бездән разый булыб, Аллаһының рәхмәт фәрештәләре безгә рәхмәт укырлар иде. Икенчедән, зияратыбызны килеб караучылар рәхмәт әйтерләр иде. Шушы эшдә үзебез генә түгел, тирә-күрше, туган-тумача, яшьләрне дә димләсәк, пәйамбәребезнең
الدال على الخير كفاعله
исдә тотыб, ягъни яхшы эшләргә, изге эшләргә өндәүче, башкаларны чакыручы, үзе эшли алмаса да, аның өндәве сәбәбле башкалар эшләсә дә, нәкъ изгелекне эшләгән шикелле, ди. Һәм дә:
همت الرجال تقطع الجبال
Мәфһүменчә, ягъни һиммәт иткән, тырышкан ирләр тау, ташларны күчерәләр дигән сүзләрне хәтергә алыб һәм Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтенең:
ادع الى سبيل ربك بالحكمة و الموعظة الحسنة
Ягъни: яхшы эшләргә Аллаһының юлына хикмәтле сүзләр, күркәм, матур вәгазьләр, тәмле телләр белән чакырсак, бәлки шимбә, якшәмбе көннәрдә яшьләребез дә бәлки бераз булышырлар иде. Инде, җәмәгать, анда барган вакытда беренче дүрт сәнәк һәм көрәк, балта яки кабчыкмы булса, яхшы булыр иде. Эчтәнрәк җәймәләр белән юлларга чыгарыб өйсәк, ихтимал, бу якшәмбе машина булуы да ихтимал.
Мөхтәрәм җәмәгать! Зинһар, әйткән сүземне ялгыш аңлый күрмәгез. Ихтимал, (0859) бәгъзе сүзләрне ялгыш әйтергә мөмкин. Бәгъзе берәүләр колаклары начар ишетү сәбәбле, бәгъзе сөйләнгән сүзләр ялгыш аңланса, туб-туры үземә әйтегез.
Узган җомгада бер карт минем сөйләгәнләремне нәкъ киресенчә үзе ишеткәнме? Берәүләр аңа сөйләгәнләрме? Ни дә булса булган, тәһлилгә барган җирдә: хәзрәт, син яшьләрнең,

хатын-кызларның теләсә ничек зияратка баруларын дөрест диб әйткәнсең диб, күземә караб әйтде. (0858) Ялган сөйләү дөнья Ахирәт харап итә торган, адәмләр арасына фетнә вә башка әллә нинди афәтләргә, дошманлашдыруга, кеше арасында ялганчының абруе, ышанычы бетүгә сәбәб булганлыкдан, Аллаһы Тәгалә ялганны каты хәрам кылган. Ялганчылар хакында Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бер "Мүрсәләт" сүрәсендә генә дә ун мәртәбә зикер кылган.
ويل يوم للمكذبين
Ягъни: ни үкенеч, ни кайгы! Кыямәт көнендә ялган сөйләүчеләргә (ялганның төрлесе була ...)
(0858 битнең дәвамы) Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга хаклыкны, дөрестлекне дөрест итеб күрергә, дөрест итеб аңларга, хаклык белән гамәл итәргә насыйб итсен. Батыйлны, бозыкны, гөнаһ эшләрне батыйл, бозык, гөнаһ диб күрергә, шуларны аңлаб, бозык эшләрдән сакланырга Аллаһы насыйб итсен.
للهم أرنا الحقّ حقًا وارزقنا اتباعه, وأرنا الباطل باطلاً وارزقنا اجتنابه
Сөйләнгән вәгазьләрне моңа кадәр дә ялгыш ишетүчеләр булгалады. Әгәр чындан да ялгыш ишеткән булса, моны яхшылаб тәфтиш кылырга, сорашырга кирәк, уйларга кирәк. Әгәр шуны халык арасында сөйләб йөрсә, ялган тараткан була. Әгәр белә торыб, начар ният белән киресенчә сөйләсә, монысы бәһтан яла ягу булыб, һәр икесе хәрам булыб, бу чын монафыйклык галәмәтен кылган була. Хәзрәт рәсүл әйтә:
إِنَّ الصِّدْقَ يَهْدِي إِلَى الْبِرِّ وَإِنَّ الْبِرَّ يَهْدِي إِلَى الْجَنَّةِ وَإِنَّ الرَّجُلَ لَيَصْدُقُ حَتَّى يَكُونَ صِدِّيقًا
(0860) Ягъни: дөрестлек һәрвакыт изгелеккә тоташдыра, изгелек җәннәткә тоташдыра. Адәм баласы сүзендә, гамәлендә дөрест булуы сәбәбле Аллаһы каршында садыйклар җөмләсендә саналыр, ди.
وَإِنَّ الْكَذِبَ يَهْدِي إِلَى الْفُجُورِ وَإِنَّ الْفُجُورَ يَهْدِي إِلَى النَّارِ
Мәсҗедгә килеб, намаз укыб җөрүләребездән ни файда, шушы кадәр сөйләнмәгән сүзләрне сөйләб йөргәч, Аллаһы сакласын.
Рәсүлуладан берәү сорый: йә Мөхәммәд, мин иман китерәм, минем берничә төрле начар гадәтләрем бар: ялган сөйлим, урлыйм, исерткеч эчәм. Шуларны барын да берьюлы ташлый алмыйм, берсен генә ташлыйм, берсендән генә тыелам. Кайсындан тыелырга кушасың дигәндә, рәсүлулла бу адәмне ялган сөйләмәскә диб вәгъдә, гәһед ала. Бу адәмгә ялган сөйләүдән тәүбә кылдыра. Көнләрдән беркөн бу адәмгә исерткеч эчергә туры килә. Бу адәм уйлый: тукта, мин исерткеч эчсәм, бу хәл рәсүлуллага ишетелсә, моның өчен миңа шәригатьчә җәза бирәчәкләр. Әгәр дә эчмәдем диб инкяр кылсам, ялганласам, мин ялган сөйләмәм диб тәүбә итдем, рәсүлуллага вәгъдә бирдем диб, ялгандан саклануы аркасында исерткеч эчүен дә, урлавын да һәм башка начарлыкларындан тыелыб, хак мөселман була. Җенабе барчабызга монафыйклык галәмәте булган гайбәт, ялган, бәһтан вә башка начарлыклардан сакланыб, хак мөселман булыб яшәргә, хак мөселман (0861) булганыбыз хәлдә улырга, дөньядан үтәргә насыйб итсен. Амин.
1968 нче Милядия, 24 нче май / 1388 нче Һиҗрия, 27 нче Сәфәрел хәйр, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Җомга көнебез мөбарәк булыб, киләчәкдәге күб җомгаларны шадлык белән күрергә барчаларыбызга насыйб булса иде!
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы насыйб итсә, 28 нче сишәмбе көн шәригъ, кәрим пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгс) нең туган ае Мәүлед аеның, Рәбигел әүвәл аеның

башы булачак. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга шадлык белән күреб, пәйгамбәребезнең сөннәтенә моафыйк рәвешдә гамәл итәргә Аллаһы насыйб итсен. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Коръәндә, хәтеремдә ялгыш булмасын, 75 дән артык урында намазны зикер кыла. Сүрәи “Ниса”, 157 нче аятьдә әйтә:
ان الصلوة كانت على المؤمنين كتبا موقوتا
Ягъни: намаз уку мөэминнәргә вакытлы фарыз ителде. Ягъни: иртә, көндез, Өйлә намазы, Икенде, Әхшам, Ястү намазлары. Һәм “Таһ” сүрәсендә 13 нче аятьдә (0862) Аллаһы Тәгалә хәзрәте әйтә:
و اقم الصلوة لذكري
Ягъни: Мине искә алу, зикер өчен намаз укы, ди. Сүрәи “Ганкабут”да 44нче аятьдә Аллаһы хәзрәте әйтә:
ام الصلوة تنهى عن الفحشاء و المنكر
Ягъни: ихлас белән намаз укы. Дөрестлекдә, чын күңелдән Аллаһыны зикер итеб, Аллаһыдан куркыб, Аллаһы хозурына баруны исдә тотыб укылган намаз бөтен бозыклыкдан тыя, ди.
Инде һәркайсыбыз, әлхәмделилләһи Раббел галәмин, намазның фарыз икәнен һәм вакытлы фарыз, ягъни вакытында укырга тиеш икәнен, аларның вакытларын да күбләребез яхшы беләбез. Ләкин әле шулай да арада белеб җиткермәгән нәрсәләребез дә ифрат дәрәҗәдә. Инде менә шушы белмәгәнләребезгә өйрәнү һәркайсыбызга тиешле эш, моны да яхшы аңлыйбыз. Безнең арабызда күбләребезнең эчен пошырган, зәвал вакыты, ягъни тиеш вакыты, кояшның тәмам күтәрелеб туктаган вакытында намаз уку – менә бу вакытда намаз уку мәкруһ булган вакыт. Бу хакда әүвәлге елларда да хәзрәтләр тарафындан күб әйтелгән булса да, һаман бу хакда сораучылар күб. Һәркөнне өч вакытда намаз дөрест булмый: 1) кояш чыкканда; 2) зәвәл вакыты: кояшның тәмам күтәрелеб туктаган вакыты; 3) кояш баеган вакыт. Менә бер аерма бар: кояш баеган вакытда фәкать шул көннең Икендесе, кәрәһать белән булса да, дөрест. Берәр сәбәб белән кояш баеганчы укый алмый икән, кояш баеганчы шул көннең Икендесен ниятләб калса, шул намазы намаздан китә. Ләкин (0863) мөмкин булган кадәр Икендене мәкруһ вакытка кадәр кичекдермәскә тиешле. Инде зәвал вакытын белер өчен мәсҗедебезнең алдагы бүлмәсендә зәвәл вакыты күрсәткән җәдвал куелган, инша Алла. Мәсҗедебезнең сәгате дөрест булса кирәк. Шушы мәсҗед сәгате белән 11 сәгать 40 минутдан 45 минутка кадәр, бер биш минут араны сабыр итеб зикер тәсбих белән үткәрсәк, инша Алла, мәкруһ вакытда намаз укымаган булырбыз. 1нче июньдән башлаб 15 нче июньга кадәр 42 минутдан 47 минутка кадәр зәвәл вакыты биш минут булмый, ул берничә секундлар гына була, кыскарыб туктый да озая (озыная – А.Х.) башлый. Шушы җәдвал тикшеренүләр идарәсе тарафындан төзелгәнлекдән, һич ялгышу булырга мөмкин түгел. Әүвәлге вакытда тиеш вакыты сәгать уникеләрдә булган, хәзер ник алай үзгәргән диб, бу җәдвал Мәскәү вакыты белән күрсәтелгәнчә 45-46 минут алдан күрсәтелә. Әгәр 46 минутны чыгарсак, зәвал вакыты 12 сәг. 25 минутларга туры килә. Менә бу хакда аңлашыб җитә алмаган кешеләр булырга мөмкин. Әле хәзерге безнең галимләребез бар әле, шулар белән аңлашырга, сорашырга мөмкин. Инде белергә тиешле бер мәсъәлә булса, ул да җомга көнендә төшлек (зәвал) вакытында ике рәкәгать Тәхиятель мәсҗед намазыны укуны дөрест күргәнләр. Зур галимләребездән Галимхан хәзрәт шушы хакда сәхих хәдисләрдән берничә хәдис риваять кыла. Шушы хәдисләргә бина, (0864) җомга көнендә мәсҗедгә килгәннең соңында, зәвал вакыты туры килсә дә, ике рәкәгать Тәхиятель мәсҗед намазын укырга тиеш, дигәнләр. Сәләф салихидән, мөҗтәһидләрдән байтак адәмләр шушы хәдисләрне дикъкать теләб

тикшергәннең соңында фәкать җомга көн, (зәвал) вакытында булса да, ике рәкәгать намаз укырга тиеш табканнар. Хәзрәт Җабир һәм хәзрәт Әбу Һөрәйрадан дөрест хәдисләр риваять кылына.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Тагын да намаз хакында беркадәр искә алыйк. “Әгъла” сүрәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:
قد افلح من تزکی و ذکر اسم ربه فصلی
Ягъни: фәлах табтылар, ягъни: Аллаһының газабындан котылдылар, күңелләрен, телләрен гөнаһ пычракларындан пакъләб, Аллаһыны искә алдылар, зикер итделәр һәм ихлас белән намаз укыдылар. Хәзрәт рәсүл әйтә:
الصَّلَوَاتُ الْخَمْسُ وَالْجُمْعَةُ إِلَى الْجُمْعَةِ وَرَمَضَانُ إِلَى رَمَضَانَ مُكَفِّرَاتٌ مَا بَيْنَهُنَّ إِذَا اجْتَنَبَ الْكَبَائِرَ
Ягъни: биш вакыт намаз һәм җомга намазы. Бер җомгадан икенче җомгага кадәр, Рамазан рузасы икенче Рамазанга кадәр кечкенә гөнаһларыбызның көффәрәтенә кичелүенә сәбәб, ди, әгәр дә олугъ гөнаһлардан сакланса, ди. Тагын да бер хәдис: берәүнең ишеге төбендә саф сулы бер елга булса, шул суда биш-биш (еш – А.Х.) юынса, тәнендә кере калмаган кебек, ул кеше гөнаһ керләрендән, гөнаһ пычракларындан да пакъләнер, ди.
Инде җәмәгать! Намазда шушындый зур фазыйләтләр булса, безнең арабызда җитешсез якларыбыз да бик күб инде. Менә шул (0865) җитешсез якларыбызны искә алыб, шулардан саклансак, намазларыбызның сәвабы күбрәк булыр иде. Азабланыб, ихлас белән укыган намазларыбызның сәвабы бетмәс иде. Намазның фарызлары, ваҗибләре, сөннәтләре, мөстәҗибләре булыб, шушыларын ригаять кылсак, безнең намазыбыз камил булыб, сәвабы күбрәк булачак.
Намазга керешкәнче булган сөннәт мөстәҗибләрен дә исдә тотарга кирәк. Иң әүвәл – сафларыбызны тигез кылу. Намазга килдек икән, мөәзин, йә башка кешеләрнең өндәүләрен көтеб тормыйча, алдагы урынларга, сафларга кереб, торыб утыру. Намазга керешкәндә, җәмәгать намазында имамдан алда колак кагу (җеназа намазында бигрәк дә имамдан алда колак кагулар күрелә) һәм алда рөкугъка китерү, сәҗдәгә китү, гөзерсез тамак кырулар – менә болар бик каты сакланырга тиешле булган эшләр. Инде тагын да берникадәр итеб дә бәгъзе бер адәмләребез һич колакка да алмыйлар. Бу эшләр хакында авыл җирләрендә дә әүвәл вакытларда мәсҗедләргә гаед вакытларында бәгъзан җомга намазларына җыеша (җыелыша – А.Х.) алмаганлыкдан, шундый зарурат вакытларда кеше аркасына сәҗдә кылу, иша белән укуда дөрест һәрвакыт әйтелә килсә дә, һаман да мәсҗеддә җомга намазларында артдагы кешеләргә аякларыбыз белән комачаулаб, артдагы адәмләрне җәберләб, рәнҗетеб, башларыбызны кырыйга бәрә-бәрә намаз укыйбыз. Һаман да шул гадәтне ташлый алмыйбыз. Шәригать исламия шушындый уңайсыз вакытларда (0866) безгә мөсагәдәт, иркенчелек рөхсәт иткән эшләрдән без һаман да читкә китәбез. Бу бит, җәмәгать, юк, мин шәригатьне тыңламыйм, мин үз белгәнчә эшлим, диб шәригатькә буйсынма, тыңламау дигән сүз була. Һәм башка эшләребездә дә һаман да хаклыкны ишетми, үз дигәнебезчә булу, башка гадәтләребез дә бар: галимләрнең сүзен ишетмәү, һаман да шәригать кушканларны игътибарга алмау, Корьәндә әйтелгән шушындый адәмләр җөмләсенә керү куркынычымыз Аллаһы Тәгалә “Локман” сүрәсендә әйтә:
وَإِذَا قِيلَ لَهُمُ اتَّبِعُوا مَا أَنزَلَ اللَّهُ قَالُوا بَلْ نَتَّبِعُ مَا أَلْفَيْنَا عَلَيْهِ آبَاءَنَا ۗ
Ягъни: аларга әйтелсә Аллаһының Корьәненә, шәригатенә иярегез диб, алар әйтәләр: инде юк, без үзебезнең иске гадәт юлларыбызга иярәбез, безнең ата-бабаларыбыз да шул юлда булганнар, диб әйтерләр, ди.
أَوَلَوْ كَانَ الشَّيْطَانُ يَدْعُوهُمْ إِلَىٰ عَذَابِ السَّعِيرِ
Шәйтан аларны һәртөрле юллар белән вәсвәсәгә салыб, Аллаһы газабына чакырыр булса

да, ди.
Инде без Аллаһының ризалыгын теләб, нәфесебезне җиңгеб, шәйтан белән сугыша-сугыша намазга килгән икәнбез. Шәйтан инде шушы намазларыбызны юкка чыгарырга, инде һич булмаса, шуларның сәвабын киметергә тырыша, һәм намаздан чыкканның соңында да гайбәт, нәмим, көнчелек, сүз йөртү һәм кием-салым алганда бер-беребезне этешү-төртешү кебек бер-беребезгә хәтәр калдырырдай сүзләр әйттереб, бәйләнеб китүләр, белә торыб икенче адәмнең (0867) аяк киемен киеб китүләр – болар һәркайсы кылган гыйбадәтләрне юкка чыгара торган, һич булмаса, сәвабын югалта, киметә торган кызганычлы, үкенечкә калдыра торган начар гадәтләр.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызны кылган гыйбадәтләребезнең әҗерен җугалта торган начар гадәтләрдән сакланыб, кылган гыйбадәтләребез Аллаһы каршында мәкбуль булыб, Кыямәт көнендә йөзләребез ак булуга сәбәб булсын. Амин.
1968 нче ел Миляди, 31 нче май / 1388 нче Һиҗри, 4 нче Рәбигел әүвәл, җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабе Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Сәйидель әнбия вә затимен набийин булган пәйгамбәремез туган ае барчаларыбызга мөбарәк булсын!
Рәсүлебезнең сөннәтенә моафыйк рәвешдә гамәл гыйбадәт кылыб, Кыямәт көнендә пәйгамбәребезнең шифагәтенә ирешергә Аллаһы насыйб итсен. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Узган җомгада 27 нче Сәфәрел хәйрдә Ислам диненең рәваҗына, ягъни таралыб китүенә, өстенлек табуына иң зур сәбәбләрнең берсе – Һиҗрәт вакыйгасын аз гына искә алыб үткән идем. Шушы Һиҗрәт вакыйгасы мөселманлар өчен зур, шадлыклы вакыйга булыб, шушы вакыйгадан Ислам диненә вә мөселманларга гына хас булган, ел башы саналганлыкдан, шушы Һиҗрәт хакында (0868) кыскача гына булса да хәтердә калдыру, үзләренең дини тарихда булу һәр мөселманга белергә кирәкле, тиешле булган вакыйгадыр.
Бүгенге көнебездән 1387 ел, 2 ай элек Рәбигел әүвәлнең 12сенә кадәр пәйгамбәребез сәфәрдә булганлыкдан Һиҗрәт хакында беркадәр сөйләб үтмәкче булам, Аллаһы ярдәм бирсен.
Шәригъ, кәбир рәсүл Хода 53 вакытда (яшендә – А.Х.) тарих Миляди 622нче ел булганда Аллаһы Тәгалә әмере белән Мәккә Мөкәррәмәдән Мәдинәи Мөнәввәрәгә күб кенә сәхабәләр белән Мөхәррәм аенда күчеб киткәнләр иде. Бу вакытда Мәккә шәһәрендә рәсүлулла хәзрәт Әбу Бәкер, хәзрәт Гали һәм мөшрикләр тарафындан тоткын булган сәхабәләр генә калган иде. Мәккәдә иман китергән сәхабәләрнең Мәдинәгә барыб урнашулары, Мәдинә халкының араларында Ислам диненә керүчеләрнең күбәюе, бу рәвешле булса, мөселманларның куәт тавыб, бигрәк дә Мәккә хәлифәнең Мәдинә шәһәре аркылы Шәм иленә йөри торган юллары булганлыкдан, әгәр дә мөселманлар куәтләнсәләр, Шәм йиренә сәүдә белән йөрүләренә зур тоткарлык булачагын күз алларына китереб, бу эшнең ахыры начар булачак. Моңа ничек дә хәзердән бер чара табарга кирәк диб, мөшрикләр бик зур борчуга төшделәр.Үзләеренең киңәш йорты булган дарез зәура (دار الذروه)га җыелыб, (0869) төрлечә уйлашдылар, киңәшделәр. Соңра Әбу Җәһелнең фикере буенча һәр кабиләдән берәр кеше җыелыб, иттифак белән бердән һөҗүм итеб (басыб кереб), рәсүлулланы үтерергә карар бирделәр: әгәр шушы рәвешле Мөхәммәд (сгс)ны үтерсәк, котылырбыз. Үз урынына пәйгамбәр булырлык баласы юк, Ислам дине сүнәр, диделәр. Сәфәр аеның 27 нче кичәсендә һәр кабиләнең таза-таза егетләре һәм

мөшрикләрнең рәисләрендән, зурларындан Әбу Җәһел, Хөкем бин Гас, Әбу Ләһһәб, Вәлид бин Мөгәйрә кебекләр, анлар белән бергә булыб, күзәтеб торалар иде. Шул вакыт хәзрәт Җәбраил килеб, мөшрикләрнең хәлендән хәбәр бирде. Һәм шушы кичен хәзрәт Әбу Бәкер белән берлекдә Мәккәдән Мәдинәгә күчәргә Аллаһы тарафындан әмер булганын сөйләде. Шул вакыт хәзрәт рәсүл Хода хәзрәт Галине дәшеб, берничә төрле әманәтләрен әйтеб: шушы әманәтләрне хуҗаларына табшыр һәм соңындан үзең дә безнең артындан килерсең. Хәзергә минем түшәгемә ят. Мөшрекләр мине урынында ята диб белсенләр, диде. Гали (рг)ны үз урынына яткырыб, ышанычлы моәррих (مؤرخ) язуына бина, рәсүл шул вакыт урыныннан яшел төстәге хиркасын иң башына салыб, җирдән бер уч туфрак алыб, “Ясин” сүрәсендәге
و جعلنا من بين ايديهم سدا و من خلفهم سدا فاعشينهم فهم لا يبصرون
аять кәримәсене укыб, сакчыларның (0870) яныннан чыгыб китде. Мөшрикләр нинди сәбәбләр белән гафләтдә калыб, хәзрәт рәсүлнең чыгыб киткәнен сизмәделәр. Хәзрәт рәсүлнең урынына караб, урынында ята диб, уйладылар иде. Беркадәр вакытдан соң белделәр хәзрәт рәсүл урынында хәзрәт ята. Шул абтыраб калалар, йортына басыб керәләр, хәзрәт Галидән сорыйлар. Рәсүлулла шул вакыт хәзрәт Әбу Бәкернең йортына барыб, Һиҗрәтдән хәбәр бирә. Хәзрәт Әбу Бәкер шадлыгындан җылаб җибәрә (ягъни хәзрәт рәсүл белән Һиҗрәт (сәфәр кылу) шәрәфенә ирешүендән. Тиз-тиз генә җыеныб, Мәккә шәһәрендән бер сәгатьлек юлда Саур тавына килеб, бер мәгарәгә, тау тишегенә керәләр. Шушы тау эчендә өч көн яталар. Гар чокыр авызына бик каты үрмәкүчләр пәрәвез саралар һәм бер пар күгәрчен килеб, оя ясаб, йомырка сала. Мөшрикләрнең хәзрәт рәсүлнең йорты тирәсендәге сакчылары гафләт йокысындан уяныб, ханәгә кереб карасалар, өйдә рәсүлулла шул хәлдә. Шашыныб калалар, һәр якка эзләүчеләр җибәреб, кем дә кем Мөхәммәд (сгс)не тавыб китерсә, йөз дәва (дөя – А.Х.) бирәбез диб, вәгъдә кылалар. Һәм мөшрикләрнең батыр егетләре малга кызыгыб, һәр тарафка чабышалар. Эзләүчеләрнең берничәсе тау буйларына киләләр. Мөшрикләрнең зурларындан булган Өмая бин Халәф (Умайя ибн Халяф – А.Х.) белән гар янына килеб җитәләр. Тау чокырына, гарга кермәкче булалар. Шул Исламның зур дошманларындан Өмая бин Халәф әйтә: әллә сез гакылдан (0871) яздыгызмы? – ди. Бу үрмәкүч пәрәвезләре, бу күгәрчен оялары Мөхәммәд туганчы булган нәрсәләр монда ничек булсын, диб китеб баралар. Шул вакыт хәзрәт Әбу Бәкер: мөшрикләрнең тавышын ишетеб, ярсулы: и Алла, мин бер гади адәммен, үтерсәләр, һичнәрсә юк. Хода сакласын, сиңа берәр зарар китерсәләр, бөтен өммәт һәлак булачак! Аллаһы безнең берлә бергә, диде. Чөнки Аллаһы тарафындан кәферләрнең зарарындан саклармын диб вәгъдә бирелгәч, һич курыкма, ди. Һәм хәзрәт Әбу Бәкернең тезенә башын куеб йоклаб китде.

Мәгарәдә ятканда шушы тау тирәсендә Әбу Бәкернең азад иткән колларындан берсе куй (сарык – А.Х.) көтә иде. Кичәләрдә куй савыб, куй сөте китерә иде. Һәм хәзрәт Әбу Бәкер угълы Габдулла кичләрдә килеб мөшрикләрнең хәлендән хәер бирер иде. Шушы рәвешле тау тишегендә өч көн ятыб, Рәбигел әүвәл башында Мәдинәгә караб юлга чыгалар. Габдулла бин Арайкат дигән бер юл күрсәтүчене алыб, бәхре Ахмәр сахилендән (ярыннан – А.Х.) Мәдинәгә караб юл тоталар. Мөшрикләрнең хәзрәт рәсүлне тотыб китерүчеләргә йөз дөя биреләчәге янәшә-тирәгә дә таралган иде. Шушы тирәдә. Сәхрәдә яшәүче гарәбләрдән Сурака бин Малик дигән берәү, диңгез сахилендән үтеб баручы ике дөяне күзәтеб, йөз дөя алу теләге белән аларның артындан куа чыга. Анлар Кадид исемендә бер тукталышдан (мәнзелдән) кузгалыб китүләренә Сурака бонлар килеб җитәм дигәндә генә Сураканың атының аяклары тезгә кадәр җиргә бата. Шул вакыт Сурака: йә Мөхәммәд,

дога кыл, мин котылаем һәм сезне (0872) килүчеләрне дә сезнең тарафка җибәрмәм диб, рәсүлулла ялынды, хәзрәт рәсүл дога кылды. Хәзрәт рәсүлнең догасы мәкбуль булыб, Сурака котылыб юлына китде һәм юлда очраган мөшрикләргә: мин тарафны карадым, алар бу якда юк, диб, икенче тарафка юллады.
Шушы рәвешле рәсүлулла (сгс) хәзрәт Әбу Бәкер белән берлекдә өч гардә ятыб, 8 көн юлда йөреб, сигезенчә Рәбигел әүвәлдә Мәдинә якынында Куба дигән кечкенә авылга барыб урнашалар.Шушы Куба карьясендә дүрт көн торыб, бер мәсҗед бина кылалар. Һәм Коръәндә Аллаһы Тәбарәкә әйтә:
المسجد اسس على التقوى من اول يوم احق ان تقوم فيه
Ягъни: халис ният белән Аллаһы ризалыгы әүвәл көнендән тәкъвалык үзренә бина кылынды. Синең анда намаз укуың хаклыракдыр, ди.
Шушы Куба мәсҗеде Тәкъвалар мәсҗеде аталган мәсҗедне бина кылалар. Шушы мәсҗед хәзер дә саклана, анда биш вакыт намаз укыла. Шушында хаҗилар хәзер дә зиярат кылалар. Кечерәк кенә манарасының өч ягы өстенә, бер ягы бөтенләй ачык...
Дүрт көн шушы Кубада торыб, җомга көн иртә белән 622 Миляди сентябрь 25 була. Рәбигель әүвәлнең 12ндә Мәдинә Мөнәввәрәгә килеб керәләр. Мәдинә халкы зур шадлык белән каршы ала. Балалар, кызлар, кәнизәкләр шадлыкларындан матур шигырьләр әйтәләр. Бу вакытда рәсүлулла (сгс)гә 53 яшь тулган иде камәре (ай елы белән), ел белән. Рәсүлулла (сгс)нең Мәдинәгә күчеб килүе, Һиҗрәте бик тизлек белән Ислам диненең таралуына һәм мөһәҗирләр белән ансар арасында дустлык, мәхәббәт, иттифакга зур сәбәб була (0873) һәм мөселманлар арасында зур бәйрәм була.
Мөселманларның һәм рәсүлулланың Һиҗрәтендән соң ягъни шушы зур, шадлыклы тарихи вакыйгадан 16 ел үтеб, хәзрәт Гомәрнең хәлифәлеге вакытында Әбу Муса әл-Әшгари (рг) хәзрәт Гомәргә килеб, бер тәкъдим ясады. Һәртөрле халыкның үзләренә махсус тарихы бар, һәм тарихи зур вакыйгалардан үзләренә тарих башы ясаганлар. Безгә дә Ислам тарихын, мөселманлар тарихын булдыру һәм тарихи ел башы ясау, тәгаенләү бик мәслихать булыр иде диб, тәкъдим иткәннең соңында Әбу Муса әл-Әшгари хәзрәтләренең бу тәкъдимен хәзрәт Гомәр хәлиф бик хуб күреб, халыкны җыеб, шушы хакда киңәшә (мөзакәрә) башлады. Сәхабәләр җыелыб, төрлечә тәкъдимләр ясадылар.
1. Бәгъзеләр вилаят рәсүлдән, рәсүлулланың туган көнендән ел башы ясыйк, диделәр.
2. Бәгъзеләр рәсүлуллага пәйгамбәрлек килүдән, бәгәсдән ел башы ясыйк, диделәр.
3. Ахыр кәлям хәзрәт Гали Һиҗрәтдән ел башы тарих башы ясыйк, чөнки Ислам өчен Һиҗрәт вакыйгасы зур ярмәмче, Ислам диненең алга китүенә сәбәб, Исламның таралуына сәбәб булды диб сөйләгәннең соңында сәхабәләр, мөселманлар бер тавышдан хәзрәт Галинең тәкъдимен дөрест табыб, (0874) тарих Һиҗринең башын күчү башланудан, Һиҗрәт башланудан тәгаен итделәр. Сәхабәләрнең күбрәге Мөхәррәм аенда күчә башлаганлыкдан, Һиҗри ел башын 1нче Мөхәррәмдән билгеләделәр
622 нче Миляди (кояш елы белән) җомга көн, Мөхәррәм булыб, шул көндән, шул елдан Ислам тарихы Һиҗри ел башлана. Менә бүгенге көн Һиҗри елдан 1387 ел, ике айда 4нче көн.
Мөхтәрәм җәмәгать! Һәрбер мөселман булган адәмгә үзенең дини тарихын белү, Һиҗри елының кайчан башлануын белү бик тиешле эш. Үзебез, мөселман булыб да, үзебезнең дини, тарихи ел башыбызны белсәк, бу безгә зур файда булачак. Шуның өчен беркадәр хәлемдән килгән кадәр сөйләдем. Аңлашылмаган урынлары булса, соңындан сорарга мөмкин.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять бирсен, динебезне

дөрест итеб аңларга насыйб итсен. Рәсүл Хода хәлифә рашидин, саләфе салихин күрсәктән юл белән барыб, Аллаһы дустлары җөмләсендән кубарылырга насыйб булсын.
توفنا مسلمين و الحقنا بالصالحين
диб, кылган догаларыбыз мәкбуль булсын.
(0875) 27нче Сәфәрел хәйрдә рәсүлулла (сгс)
Рәсүлулла (сгс) бүгенге көндә Мәккә Мөкәррәмәдән Мәдинәи Мөнәввәрә сәфәр кылган 12нче Рәбигель әүвәлдә Мәдинәи Мөнәввәрәгә барыб җитә. Ничә көнләр Саур тавында гардә ятыб, дөяләр белән бәхре Ахмәр сахилендән (Кызыл диңгез яры буеннан – А.Х.) сәфәр итеб 15 көнләр юлда була.
(0876)
12. 1968 нче ел 5 нче июльдән башлана.
“Җомга вәгазьләре”
(0877) 1968нче ел, 5нче июль, җомга көн / 1388 нче ел, 9 нчы Рәбигель ахир (или: Рәбигус сани – А.Х.), җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Аллаһыга иман китереб, Аллаһының рәхмәтендән өмед итеб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Җенабе Хакның сәламе, рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын. Киләчәкдә дә саулык-сәламәтлек, тынычлык белән күб елларага кадәр гыйбадәт кылырга насыйб булсын.
Мәсҗедебезгә бер адәм намазлыклар алуда зур ярдәм күрсәтде. Транспорт акчаларын да үзяныннан түләде. Шушы мәсҗедебезгә зур ярдәм күрсәткән адәмгә дога кылыйк.
(0878) Әстәгыйзу билләһи. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сүрәи “Ниса”да түбәндәге вәгазь аятьләрен безгә бәян кыла:
إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تُؤَدُّوا الْأَمَانَاتِ إِلَىٰ أَهْلِهَا وَإِذَا حَكَمْتُم بَيْنَ النَّاسِ أَن تَحْكُمُوا بِالْعَدْلِ ۚ إِنَّ اللَّهَ نِعِمَّا يَعِظُكُم بِهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ سَمِيعًا بَصِيرًا
Ягъни: Аллаһы хәзрәте сезгә әманәтне әһленә (тиешле кешесенә) табшырырга һәм кешеләр арасында хөкем иткәндә гаделлек белән хөкем итәргә боера, ди. Аллаһы сезне нинди гүзәл хөкем (һәрбер әманәтне иясенә табшыру вә хөкемдә гаделлек кылу) берлә вәгазь кыла. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте сезнең һәрбер эшләрегезне һәм әманәтне тиешле йиренә вә тиешле рәвешдә үтисезме икәнен һәркайсын көтеб, ишетеб тора, ди.
Мөфәссирләр: бу аятьнең түбәндәге вакыйга сәбәбле нәзел булуын сөйлиләр. Рәсүлулла Мәккә шәһәрен алгач, Кәгъбәнең сакчы вә йөз аклаучыларындан булган Госман бин Талех Кәгъбәтулланың ишеген йозаклаб, үзе Кәгъбәтулланың түбәсенә менеб киткән (качкан). Ачкычны рәсүлуллага бирүдән баш тартыб, бирмәс өчен: әгәр дә мин Мөхәммәднең (сгс) Аллаһының рәсүле икәнен ачык белсәм, ачкычны бирер идем, кызганмаган булыр идем, дигән. Шул вакыт хәзрәт Гали Госманны тавыб, ачкычны кулындан алыб, Кәгъбәтулланың ишеген ачыб, рәсүл әкрам (сгс) Кәгъбәтуллага кереб ике рәкәгать намаз (0879) укый. Рәсүлулла Кәгъбәтулладан чыккан уңайга хәзрәт Габбас килеб, Кәгъбәтулланың ачкычын үзенә бирелүен һәм Зәм-зәм суы белән сугару һәм Кәгъбәтулланы саклауның үзендә булуын рәсүлулладан үтенә. Менә шул вакыт рәсүлуллага шушы югарыда укыган аять нәзел булыб, хәзрәт Габбасның үтенечен кире кагыб, хәзрәт Галигә, Госманны тавыб, ачкычны табшырырга куша. Шушы вакыт Госман: башта ачкычны миндән талаб алдың да, хәзер гафу үтенгән буласың дидекдә. Хәзрәт Гали: юк, менә синең хакыңда Аллаһы тарафыннан шушы аять иңде, шуңа күрә рәсүл Хода ачкычны сиңа тапшырырга кушды. Шушы вакыт Госман, Ислам белән мөшәррәф булыб,

Кәгъбәнең сакчылыгы һаман да Госман һәм аның нәселендә кала. Менә аятьнең килүе Госман бин Талех хакында булса да, бу аятьнең хөкеме гамь (гомуми – А.Х.) була барыбызга да. Сәбәб хөкеме хосусый булыб, хөкеме гамь булуга манигъ түгел (каршы килми – А.Х.). Әманәт: һәркайсыбыз белә, бер ышанычлы кешенең кулына сакларга, яки берәр җиргә әйтеб табшырырга бирелгән нәрсәдер.

Мөхтәрәм җәмәгать! Һәрбер адәм баласының мөгамәләсе дөньяда өч төрле була: яраткан Тәңресе белән, халык белән һәм үзе белән. Менә шушы эшләрнең һәрберсендә зур әманәтләр булыб, һәрвакытда әманәтнең хыянәт итмәү тиешле була.

1. Аллаһы берлә ике арада булган (0880) әманәтләребез (мөгамәләребез)не ригаять кылу, үтәү белән була. Аллаһының кылырга кушкан эшләрне кылу, тыелырга кушкан эшләрдән тыелу белән була. Аллаһының безгә боерыклары бар да безнең өстебездә әманәт була. Хәзрәт рәсүл әкрам әйтә бәет:

قل آمنت بالله ثم استقم

Аллаһыга иман китердегең, моның соңында һәр эшләреңдә тугъры бул, истикамәтле бул (хәерле истикамәт бирсен, диб әйтә идек). Инде истикамәтле булу шуның белән белә Аллаһы белән булган әманәтләрне дә укый, намаз да укый, руза дә тота, башка изгелекләр дә кыла, бөтен начарлыклардан да тыела, күркәм холыклы да була. Истикамәткә бөтен яхшы эшләрне кылу, бөтен начарлыклардан тыелу – бар да керә. Берәү чындан да истикамәтле булса, Аллаһы белән булган бөтен әманәтләрне үтәгән була. Менә шушы истикамәтле адәмләр хакында Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّ الَّذِينَ قَالُوا رَبُّنَا اللَّهُ ثُمَّ اسْتَقَامُوا تَتَنَزَّلُ عَلَيْهِمُ الْمَلَائِكَةُ أَلَّا تَخَافُوا وَلَا تَحْزَنُوا وَأَبْشِرُوا بِالْجَنَّةِ الَّتِي كُنتُمْ تُوعَدُونَ

диб, ул адәмләргә җәннәт белән сөенеч бирелә. Шулай ук Аллаһының безгә биргән бөтен әгъзаләребез дә, һәркайсы безгә бирелгән әманәт, шушы әгъзаләребезне тиешле урында файдалану, куллану лязим (бурыч). Телләребез белән гыйлем өйрәнү, гыйлем өйрәтү, Коръән уку, Аллаһыны зикер әйтү, файдалы сүзләр сөйләү халыкка, тәмле телле булу. Телебезне шушы рәвешдә файдалана белсәк, әманәтне үтәгән булабыз. Әмма телебезне ялгандан, гайбәтдән, сүз (0881) йөртү, кеше белән талашу, кычкырышу, начар телле булсак, менә бу вакыт инде әманәткә хыянәт иткән булабыз. Башка әгъзаләребез дә шулай ук һәркайсында Аллаһы кашында җаваб бирәчәкбез. “Бәни Исраил” сүрәсендә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәт әйтә:

إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ كُلُّ أُولَئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْئُولاً

Ягъни: күзләребез, колакларыбыз, күңелләребез хакында – һәркайсын да Кыямәт көнендә соралачакбыз. Шулай ук “Ясин” сүрәсендә Аллаһы хәзрәте әйтә:

الْيَوْمَ نَخْتِمُ عَلَى أَفْوَاهِهِمْ وَتُكَلِّمُنَا أَيْدِيهِمْ وَتَشْهَدُ أَرْجُلُهُم بِمَا كَانُوا يَكْسِبُونَ

Ягъни: ул көндә Безаларның авызларын печатьләрбез, Безгә аларның аяклары, куллары кылган гамәлләрендән шәһадәт бирелер, ди.

Шулай ук Ислам динендә бер адәмгә мал-нигъмәте бирелә икән, менә бу малларда һәркайсы Аллаһы тарафындан бәндәгә бирелгән әманәт итеб хисаблана. Ислам дине каршында нинди генә нигъмәт булмасын, һәркайсы Аллаһы тарафындан бирелгән әманәт булыб, һәрбер әманәтне хыянәт кылмаенча тиешле рәвешдә үтәргә кушыла. Әгәр дә һәркем Аллаһы тарафындан үзенә табшырылган әманәтләрне тиешле урынына табшырса иде, җир йөзендә җәбер-золым, ялган, хыянәт булмый, тынычлык хөкем сөрер иде. Малны, үзеңнең гаиләң сәламәтлеген саклау, хәрам, бозык урынларга исраф итүдән саклану, фәкыйрь-мескенләргә ярдәм итү (0882), тиешле адәмләрне тәрбия итү, шушындый хакларны ригаять кылу, мал әманәтен үтәү.

2. Кешенең халык белән мөгамәләсе бәндә әманәткә ригаять кылуыдыр. Берәүгә ышаныб

табшырылган нәрсәне иясенә табшыру, һәртөрле үлчәүдә хыянәт кылмау, дөрест үлчәү. Бер мәҗлесдә сер итеб сөйләнгән сүзләрне башкаларга җиткермәү, кеше гаебләрен тикшермәү, кирәк кайда гына эшләсә дә, халык байлыгына хыянәт кылмау, ир хатынына , хатын иренә хыянәт кылмау, бер-берсенә хакларын ригаять кылу, балалар булса, кечкенә вакытда әдәб-тәрбия, күркәм холыкларга өйрәтү, эш башларына әһел булган адәмләрне сайлау, имамәтчелек урынларына, мөэззинлек, мөтәвәллият – һәркайсына әһел булган эш башкарырдай адәмләрне сайлау, имам булган яки, имам булмаса да, галим адәмләрнең башкаларга гыйлеме белән файда итәргә, вәгазь-нәсыйхәт кылырга тиешле булыб, болар һәркайсы үзеңдә булган, Аллаһы тарафындан бирелгән әманәт булыб, шуларның һәркайсын хәлдән килгән кадәр үтәргә тырышу – һәркайсы Аллаһының биргән нигъмәтләрен тиешенчә үтәү буладыр.

3. Адәм баласының үзе белән мөгамәләсендә әманәткә ригаять итүе, дөньясы Ахирәте өчен файдалы булган эшләрне генә эшләргә тырышуы. Аллаһы Тәгалә адәм баласына көч-куәт биргән, менә шушы Аллаһыдан (0883) бирелгән көч-куәтне үзенә зарар китердәй эшләрдә кулланмау, үзенә файда китердәй урынларда файдалану, әманәтне үтәү буладыр. Үзенең җанына-тәненә зарар китердәй һәртөрле сырхаулардан саклау, гакылын җуя торган нәрсәләрдән саклану, гакылы белән рухыны тәрбия кылу, начар холыклардан сакланыб, күркәм холыклар белән холыкланырга тырышу. “Кыямәт көнендә адәм балаларындан Аллаһының биргән нигъмәтләренең әүвәлгесе сәламәтлегеңне саkладыңмы?” – диб сорарлар. Рәсүлулла. Аллаһының сүзе:

و اذا حكمتم بين الناس ان تحكموا بالعدل

Адәмләр арасында хөкем итсәгез, гаделлек белән генә хөкем итегез, ди.

Ислам динендә гадәләт (гаделлек) мәсъәләсе Исламда иң беренче ригаять кылынырга тиешле иң мөһим бурычыдыр. Коръәндә, рәсүлулланың хәдисләрендә гадәләт хакында хисабсыз күб аять, хәдисләр килгәндер. Галәмнең төзеклеге дә гадәләт аркасында дәвам итәдер. Әгәр дә кояш, җир вә башка планеталар үзләренең йөри торган юлларындан тузан кадәр генә читкә тайпылсалар да, бөтен галәм һәлак булыр иде.

Шуңа күрә гадәләт, тигезлек иң мөһим мәсъәлә булганга хөләфа рашидин, сәләф салихин гадәләтне иң соң дәрәҗәдә ригаять кылганнар.

Хәзрәт Гали белән бер яһуди вакыйгасы: ниндидер юллар белән хәзрәт Галинең сугыш киеме бер яһуди кулына керә. Хәзрәт Гали моны күреб, яһудине (0884) хөкемгә чакыра. Казый хәзрәт Галигә шаһидләр китерергә куша. Шул вакыт хәзрәт Гали угълы Хәсән белән бер адәмне шаһид итеб куя. Казый хәзрәт Хәсәннең шиһадәтен кабул итми, яһуд файдасына хөкем итә: яһуд иман китерә. Һәм икенче мисал. Имам Әбу Йосыф (казый әл-каза ) үлем хәлендә: йә Рабб, Үзең беләсең, мин һичкемне яклаб хөкем итмәдем, ләкин, шулай булса да, бер нәсрани белән Һарун Рәшид белән икесен бертигез урында утыртмадым, шуның өчен Аллаһы кашында ни җаваб бирермен? – каты елаган. Шуның өчен хәзрәт Гөмәр казыйларга зур вазыйфалар тәгаен кылган. Хөкем итүче адәмләрнең тормышлары җитеш булсын, тормышлары җитеш булмаса, халыктан ришвәт вә заткә алулары мөмкин диб, томышларын һәр җәһатдән җитеш итәргә тырышкан.

Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте пәйгамбәрнең күрсәткән юлын дөрест итеб аңларга, Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкранә кылыб, безгә әманәт итеб бирелгән һәртөрле нигъмәтләргә көфран нигъмәт кылыб, хыянәт кылудан ерак булырга, бөтен өммәтләр хозурында рәсвай (?) галәм булудан саклаб, үзенең дустлары җөмләсендән булырга насыйб итсен.

(0885) 1968 нче Миляди, 12 нче июль / 1388 нче Һиҗри, 16 нчы Рәбигел ахир, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Аллаһы Тәбарәкә хәзрәтләре безгә Коръән Кәримнең 2нче сүрәсендә 3-4нче аятьләрендә мөэмин булу, мөселман булу, тәкъва, мөтыгый адәмләрнең сыйфатлары турында бәян кыла:
الَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِالْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ وَالَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْكَ وَمَا أُنزِلَ مِن قَبْلِكَ وَبِالْآخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ
Ягъни: Коръән белән көнлеген һидаять табкан тәкъва, мөттакый кешеләр, ишанлар һәм намазны торгызулар вә Без биргән нәрсәләрдән халыкларны файдаландырырлар. Вә шундай кешеләр кем, и Мөхәммәд, сиңа иңдерелгән Китабка (Коръәнгә) һәм синдән әүвәл иңдерелгән Китабларга ышанырлар, һәм Ахирәтне, Кыямәтне аныкларлар булуына ышанырлар. Аллаһы Тәгалә мөттәкыйләрне (яхшыларны) шушы биш төрле сыйфат белән бәян кылган беренче иман билгайб күбрәк мөфәссирләр бәяненә күрә, гайбдән морад күз белән күренмәгән, Аллаһыга вә Аның фәрештәләре, Китаблары, пәйгамбәрләре вә Кыямәт мораддыр.
(0886) Дүртенче, бишенче сыйфатлар искә алу рәсүлуллага пәйгамбәрлек килгән вакытда мөшрикләр вә әһле китабның зур ялгышкан урынларыны әйтеб, алар ягъни тәкъва адәмләр чын иман әһелләре, алар сиңа иңдерелгән Коръәнгә һәм синдән әүвәлдә пәйгамбәрләргә иңдерелгән Китабларга иман китерер. Чын иман, тәкъвалык шушы биш нәрсәгә (хәввас хәмсә) белән беленмәгән нәрсәгә ышану, гакыл сәлим яки пәйгамбәрләр вәсыйтасы белән бергә мөмкинлегенә ышанудыр.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре Адәмне яратудан, ул Иблисне яратыб, Адәм сәбәбле үзенең тәкбирлеге аркасында Аллаһының рәхмәтендән сөрелде, мәрдуд булды (кайтарылды – А.Х.). Шул көндән башлаб та Кыямәткә кадәр адәм баласына дошман булыб:
ان الشيطان للانسان عدو مبين
Аның адәм баласына зур дошманлыгы хакында Коръәндә Аллаһы Тәгалә бик күб урында зикер кылды. Инде шушы адәм баласының зур дошманы булган шәйтан безне һәрвакыт юлдан яздырырга тырыша, һәрвакыт безнең күңелләребезгә төрле вәсвәсә, шик, шөбһәләр салыб, безне хак юлдан яздырырга, үзе кебек Аллаһы газабына дучар итәргә тырыша. Шушы галәме гайбкә иманыбыз хакында да күңелебезгә һәртөрле вәсвәсәләр сала. Хәзрәт рәсүл әкрам Кыямәт әхвалләрен бәян иткән вакытда Әби бин Халяф дигән (0887) бер мөшрик кулына бер җөргән сөяк тотыб, аны ува-ува, менә бу җөргән сөякне: кем моны яңадан әүвәлге хәленә китерер, кем бу җөргән сөякләрдән, тергезеб (торгызыб – А.Х.), кайсын оҗмахка, кайсын тәмугка кертер дигәннең соңында шушы түбәндәге аять нәзел була:
قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ ۖ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ
ди. Әүвәл мәртәбә кем соң сезне юкдан бар кылган, Аллаһы аларны яңадан торгызыб, әлбәттә, Кадир вә Галимдер.
أَوَلَيْسَ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ بِقَادِرٍ عَلَىٰ أَن يَخْلُقَ مِثْلَهُم ۚ بَلَىٰ وَهُوَ الْخَلَّاقُ الْعَلِيمُ
Җирләрне, күңелләрне, галәмне юкдан бар кылырга көче җиткән Аллаһы инде черегән сөякләрне торгызырга, әлбәттә, көче җитәр. Шуның өчен Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә

Коръәндә берничә урында шушындый аятьләр әйтә:
إِنَّ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ لَآيَاتٍ لِّلْمُؤْمِنِينَ وَفِي خَلْقِكُمْ وَمَا يَبُثُّ مِن دَابَّةٍ آيَاتٌ لِّقَوْمٍ يُوقِنُونَ
وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَمَا أَنزَلَ اللَّهُ مِنَ السَّمَاءِ مِن رِّزْقٍ فَأَحْيَا بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا وَتَصْرِيفِ الرِّيَاحِ آيَاتٌ لِّقَوْمٍ يَعْقِلُونَ
Сүрәтел Җасия, 2-5.
Ягъни: Йир вә күкләрдә иманлылар өчен Аллаһының барлыгыны белдереб торган аятьләр, галәмәтләр бардыр. Сезнең вә барча хайванларның яратылышларында да.
(0888) Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам шәригате, Коръән һичбер вакыт һичбер адәмгә көчләб иман такмый, беркемнең көчләб иманлы итәргә яки имансыз итәргә беркемнең дә хакы юк. Ислам дине, Коръән шәригате бу хакда һәркемгә зур права, зур хокук биргән. Сүрәи “Кәһеф”дә Аллаһы әйтә:
فمن شاء فليؤمن و من شاء فليكفر
Теләсә, мөэмин булсын, теләсә, кяфер булсын, теләсә ышансын, теләмәсә – юк.
Һәм “Бәкарә” сүрәсендә:
لا اكراه في الدين
Ягъни: диндә көчләү юк. Адәм баласына зур ихтыяр бирелгән, чөнки бу күңелдәге нәрсә. Һичбер кемнең күңелендә ни барын беребез дә белә алмыйбыз. Диндә көчләү юклыгына тарих шаһид. Хөләфа рашидин һәм башка хәлифәләр тарафыннан сугышыб алынган җирләрдә һәртөрле диндәге халыкларга үз динләрендә калырга рөхсәт ителде. Ислам дине һәрвакыт:
ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ ۖ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ
Күркәм булган вәгазьләр. Хикмәтле сүзләр белән Аллаһының юлына чакырырга куша.
(0889) Әмма хаклыкны эзләргә, тикшерергә һәркемнең хакы бар.
تفكر تذكر аятьләре уйларга куша. Моның соңында:
فاعتبروا يا اولى الالباب
Шуңа күрә һәркем уйларга, фикерләргә тиеш. Моның соңында һәркемгә зур ирек, ихтыяр бирелгән.
(Өстәмә язма – А.Х.):
Гариф дуст! Сезгә бирелгән дәфтәр 1968 нче елның 14нче июнендән башланган. Инде бу дәфтәр шундан соңгы булса кирәк, чөнки бу дәфтәр 1968 нче елның 5нче июльдән башлана. Номеры куелмаган.
23.10.70 Мәгълүмеңез (Имза).
Аллаһының рәхмәте сезләргә һәм балаларыгызга булсын. Диярең. Әссәләму галәйкум белән сезгә булган чын дустлыгымны аңлатам. Әхмәд Гариф, дустың.
(0890) 5 нче июльдән 26 нчы июльгә дәфтәрегезне табшырам. Мөмкин булса 26 нчы июль дәвамын бирерсез диб үтенеб калам.
Әссәләму галәйкум дия, сүземне тәмам итәм. Дога, хәерләрегезне үтенеб, Гариф бин Харис.
(0891) Шиксез ышанучылар өчен Аллаһының берлегенә дәлилләр бардыр. Киче вә көндезләрнең үзгәрешләрендә озаеб (озынаеп – А.Х.), кыскаруында, күкдән яңгыр яурдырыб, ризыклар җитешетерүдә, йилләрнең төрле тарафдан исүендә гакыл ияләре өчен Аллаһының кодрәтенә зур галәмәтләр булмакдадыр.
Менә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә яраткан мәхлукатьларына караб, уйлау, фикер итү Аллаһы каршында ничәшәр еллар нәфел намазлары, нәфел уразалары тотуга караганда саваблырак, ди. Хәзрәт рәсүл:
تفكروا في خلق الله و لا تتفكروا في ذات الله
ди. Адәм баласының күңеленә килгән начар уйларны, шик-шөбһәләрне бетерүгә сәбәб

булыб, иманның куәтләнүенә сәбәб булганлыкдан, Аллаһы хәзрәте безгә әйтә:
فاعتبروا يا اولى الالباب
فاعتبروا و يا اولى الابصار
Шуның өчен:
من كان له فكرة ففي كل شيء له عبرة
дигән сүзне искә алыб, һәрнәрсәгә уйлаб, фикерләб, гыйбрәт күзе белән карасак, һәрнәрсәдән гыйбрәт алырга мөмкин. Үзебезнең кыска гакылыбыз белән генә, әгәр дә кышның көне булыб төнлә кар яуган булса, шул кар өстендән бер кеше яки эт, мәче узыб киткән булса, күзебез белән күрмәсәк дә, ышанабыз, чөнки аның билгеләре: эзе, галәмәте бар. Шулай ук бер болынга яки су буена барыб, балыкчылардан яки печән чабучылар кылган (0892) шалашны яки землянканы күрсәк, һичшиксез ышанабыз – монда шундый адәмләр корган икән диб, күз белән күрмәсәк дә, һичшиксез ышанабыз, чөнки билгеләре, галәмәтләре бар.
Инде дөньяга күз салсак, я булмаса, күзегез белән күргән шикелле, укыб яки ишетеб беләбез. Төс-кыяфәтләре бер-берсенә башка булган хәзердә дә хисабы, саны мәгълүм булыб бетмәгән хайванат (хайваннар – А.Х.) дөньясы, кайсы җир өстендә, кайсылары су астында, кайберләре агач башларында, тау тишекләрнедә яши торган мең миллион төрле җан ияләре, ишетеб яки китаблардан укыб, гакылларны хәйранга калдыра торган мең миллион төрле үсемлек дөньясы, бирнең эчендә булган гаҗәеб төрле мәгъдәнләр, бөтен гакыл ияләрен хәйранга калдыра торган һәм андагы хисабы Аллаһыдан башкага мәгълүм булмаган чиксез галәм. Андагы планеталар, йолдыз һәм кояшлар – болар һәркайсы бер Халикның, Галим, Хәким, Мөдәббир бер Затның барлыгына зур галәмәтләр һәм билгеләр. Кечкенә генә бер хуҗалыкның да идарә итүче бер хуҗасы булмаса, ул хуҗалыкның бара алмавы һәркемгә мәгълүм. Без бөтен нәрсәне дөньядагы мисаллар белән чагышдырыб беләбез. Шул рәвешле дөньяга гыйбрәт күзе белән караб, яхшылаб уйлаб карасак, һичшиксез әйтәбез:
ربنا ما خلقت هذا باطلا
И, безнең Раббыбыз, Син боларны юкка гына, бушка гына яратмадың, бар кылмадың диб, җенабе Хакны танырга иманымызның куәтле нурына хакыйки (0893) иманга ирешүебезгә сәбәб булачак.
Моның соңында хәзрәт рәсүл әкрам әйтә:
الإيمان بالله والعمل قرينان، لا يصلح واحد منهما إلا مع صاحبه
Ягъни: иман берлән яхшы гамәлләр һичбер вакыт бер-берсендән аерылмый торган ибтәшләр, һичбери үз ибтәшендән башка була алмаслар, ди.
Чын мөэмин булган кеше бөтен чын иманлы адәм, бөтен начарлыклардан ерак булырга, бөтен яхшы, күркәм сыйфатлар белән сыйфатланучы булыб, үзен юкдан бар кылган Халикына тәгъзыйм итәргә, коллык, гыйбадәт кылырга бурычлыдыр.
Аллаһы Раббел Галәмин хәзрәте барчаларыбызны шәрр (явыз – А.Х.) шәйтандан, зәваль имандан саклаб, чын иманлы булыб яшәргә, чын иманлы булыб үләргә насыйб итсен.
(0894) 1968 нче ел, 19 нчы июль / 1388 Һиҗри, 23 нче Рәбигель ахир, җомга көн Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен мәсҗедгә килгән, җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
اعوذ بالله من الشيطان الرجيم
وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ وَعَلَّمَ آدَمَ الْأَسْمَاءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى الْمَلَائِكَةِ فَقَالَ أَنبِئُونِي بِأَسْمَاءِ هَٰؤُلَاءِ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ قَالُوا سُبْحَانَكَ لَا عِلْمَ لَنَا إِلَّا مَا عَلَّمْتَنَا ۖ إِنَّكَ أَنتَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ قَالَ يَا آدَمُ أَنبِئْهُم بِأَسْمَائِهِمْ ۖ فَلَمَّا أَنبَأَهُم بِأَسْمَائِهِمْ قَالَ أَلَمْ

أَقُل لَّكُمْ إِنِّي أَعْلَمُ غَيْبَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَأَعْلَمُ مَا تُبْدُونَ وَمَا كُنتُمْ تَكْتُمُونَ وَإِذْ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا إِلَّا إِبْلِيسَ أَبَىٰ وَاسْتَكْبَرَ وَكَانَ مِنَ الْكَافِرِينَ

Ягъни: ул шундый Аллаһы, йирдә булган нәрсәләрнең бөтенесен сезнең өчен яратды. Шул вакытны Раббың фәрештәләргә әйтде: Мин җир йөзендә Хәлифә (Хуҗа), яратмакчы булам, диде. Шул вакытда фәрештәләр әйтделәр: анда түгүче, бозыклык кылучы (0895) залимне яратмакчы буласыңмы? – диделәр. Без һәрвакыт Сиңа тәсбих, хәмде әйтәбез, гыйбадәт кылыб кына торабыз, диделәр. Шушы вакыт Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә әйтде: Мин сез белмәгән нәрсәләрне беләм, диде.

Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте Адәм (гс)гә бөтен нәрсәләрнең исемләрене өйрәтде дә моның соңында фәрештәләргә әйтде: әгәр дә сез үзегезне Адәмгә караганда артыграк диб дәгъва кыласыз икән, менә шушы нәрсәләрнең исемләрен (шундый гыйлемлекне) сөйләб бирегез алайса, ди. Шул вакыт инде фәрештәләр үзләренең кимчелекләрен белеб: и, безнең яраткан Раббымыз! Без Син белдергән гыйлемләрне генә беләбез. Шул вакыт Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Адәмгә: ул нәрсәләрнең исемләрене сөйләб күрсәт, диб белдерде. Хәзрәт Адәм ул нәрсәләрнең исемләрен сөйләб биргәч, фәрештәләр үзләренең кимчелекләрен аңладылар. Шул вакыт Аллаһы Тәгалә аларга (اني اعلم): Мин сезгә йир-күктәге серләрне һәм сезнең яшерен эшләрегезне беләм диб әйтмәдемме? – диде. Менә шул вакыт Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: Адәмгә сәҗдә кылыгыз, диде. Шул вакыт фәрештәләр һәркайсы Аллаһының әмеренә буйсыныб, итагать кылыб, Адәмгә сәҗдә кылдылар. Мәгәр Иблис тәкбирләнеб Аллаһының әмеренә буйсынмады, тәкбирләнеб сәҗдә кылмады, баш тартда. Шушы вакыт Аллаһыга (0896) итагать кылмыйча кяферләрдән булды. Менә шушы рәвешле Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Адәм баласын бөтен мәхлукдан өстен итеб, хөрмәтле итеб, бөтен мәхлукатька хуҗа булырлык, бөтен нәрсәләрдән файдалана белерлек гакыл белән хөрмәтләб, нинди генә куәтле җан ияләре, җанварлар булмасын, һәркайсын Аллаһы аларны Адәмгә буйсынучы, итагать кылучы итеб яраткан. Уйлаб карасак, нинди генә куәтле җан иясе булмасын, һәркайсы Адәмнең сүзен тыңлаб, һәркайсы Адәмгә китерәләр филләр, дөяләр, атлар, һәртөрле җырткыч җанварлар. Нинди зур, котычкыч диңгез хайванлары: исән вакыт көчләре белән үтереб, суеб, итләре, майлары, тиреләре, җоннары, сөякләре белән файдаланалар. Ул гына да түгел, тау ташларны кисәләр, җир астларына төшеб, Аллаһы нинди файдалы казылмалар, мәгъдәнләр чыгаралар. Ул гына да түгел. Океанларда йөзәләр, һаваларда очалар, бөтен табигатьне, утны, суны, җилне, яшенләрне – һәркайсына адәм баласын хәлифә итеб, хуҗа итеб, шулардан файдалана белерлек көч, куәт, гакыл, зиһен биреб, иҗтиһадлы, истигадьлы итеб яраткан.

Аллаһы Тәгалә “Тин” сүрәсендә әйтә:

لقد خلقنا الانسان في احسن تقويم

ди. Ягъни күркәм сүрәтдә, матур итеб, матди, мәгънәви көчләр, гакыл һәм һәртөрле гыйлемгә кабилиятле итеб яратыб һәм бөтен мәхлукатька, табигатькә хуҗа була алырлык итеб яратканның соңында аңар (0897) бөтен йир йөзенең хәлифәлеген табшырган. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә адәм баласын Үзенең бөтен җир шарына хуҗа итеб, шушы Аллаһы биргән бөтен нәрсәләрен адәм файдасы өчен бөтен нәрсәдән файдаланырга кушкан. Шуның өчен адәм баласына халәлдән кәсеб итүне фарыз иткән.

الكاسب حبيب الله

диб, тырыш, кәсеб итүче кешене Аллаһының дусты итеб атаган. Һәр эшләребездә тугъры, гадел булыб, һәрвакыт бөтен адәм балаларына файда итәргә боерыб

خير الناس انفعهم للناس

диб, бөтен адәм балаларына файда итәргә, ярдәм итәргә кушкан диб, рәхимле, шәфкатьле, файдалы, ярдәмле булсак, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләренең:
هل يستو الذين يعلمون و الذين لا يعلمون
дигән аятьләрен истә тотарбыз. Һәм пәйгамбәребез:
طلب العلم فريضة على كل مسلم و مسلمة
дигән сүзләрен исдә тотыб, Аллаһының матур, көчле, куәтле итеб яраткан матди көчләребезне (тәнләребезне) һәм рухани, мәгънәви көчләребез булган гакылларыбыз өстенә Аллаһының безгә фарыз иткән һәртөрле гыйлем нуры белән нурланыб, дөрестлек, гаделлек, татулык белән хәзрәт рәсүл әкрамнең:
الدنيا مزرعة الاخرة
дигән сүзен, дөнья Ахирәтнең игенлеге дигән сүзне исдә тотыб, шуның белән гамәл итсәк иде. Һәм тагын да хәзрәтнең бер мөбарәк сүзе:
ليس بخير من ترك دنياه لاخرته و لا آخرته لدنياه
Ягъни: дөньясы өчен Ахирәтен, Ахирәте өчен дөньясын куйган кеше сезнең хәерлегез (0898) түгел, бәлки икесен тигез алыб барыб, башкаларга йөк булмый, үз көнен үзе күргәнегез, дигән сүзләрен исдә тотсак, дөньябызның, динебезнең төзек булуына иҗтиһад итсәк, инша Алла, җенабе Хакның:
ان الارض يرثها عبادي الصالحون
дигән адәмләре җөмләсендән булыб, дөнья Ахирәтдә бәхетле булырбыз.
Инде Аллаһы хәзрәтнең безгә биргән матди вә мәгънәви нигъмәтләренең кадерен белмичә, көфран нигъмәт кылыб, гакылларыбызны югалта торган Аллаһы биргән күркәм сыйфатларыбызны, әгъзаләребезне һәлак итә торган азгынлык юлына кереб, нәфсебез, шәйтанларыбыз безгә хуҗа булыб, һәрбер начарлыкны эшләб, яхшы эшләрдән ерак булсак, нәсел үрчетер өчен генә яшәсәк, бу вакытда безнең башка хайваннардан һич аермабыз булмыйча, бәлки алардан да яманрак булачакбыз.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте хаклыкны, дөрестлекне уйламаган, хаклыкны күрмәгән, хаклыкны яхшылыкка өндәгәнне, вәгазь-нәсыйхәтне ишетмәгән адәмләр хакында шушындый куркыныч аятьне сөйли:
وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِّنَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ ۖ لَهُمْ قُلُوبٌ لَّا يَفْقَهُونَ بِهَا وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَّا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَّا يَسْمَعُونَ بِهَا ۚ أُولَٰئِكَ كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ ۚ
Ягъни: шундый адәмләр, аларның барачак җәһәннәм, ди. Башкалар кебек күңелләре, гакыллары булса да, уйламадылар, фәһемләмәделәр, күзләре булса да, күрмәделәр, колаклары булса да, яхшылыкка өндәгәнне ишетмәделәр. Менә болар (0899) тату тору, ашау, нәсел үрчетү – хайвандан аермалары юк. Әмма начарлык җәһатдән болар хайваннардан азгынрак, ди.
Хосусан, җәмәгать, күб кенә исерек адәмләрне күрәбез. Боларның кабахәт сыйфатлары нинди җерткыч хайванда да булачак түгел. Боларда булган кабахәт: тел куллары, көч куллары белән башкаларны рәнҗетү, нинди генә хайван булса да, үзенә, балаларына зарар тиюдән саклана. Әмма исерек теләсә, кайда нәҗес, пычрак урыннарда ауный, авызындан косыгы, гаурәтендән бәвеле агыб ята. Шушы хәлгә килгән бер хайванны да күргәнебез юк. Бит инде ахыр чикдә үз-үзенә һөҗүм итә, дөнья Ахирәтдә хур була. Аллаһы сакласын.
Аллаһы биргән тән, көч, гакыл, гыйлем нигъмәтләреннән файдаланыб, башкаларга изгелек кылырга тырышкан адәмләр хакында:
ان الذين آمنوا و عملوا الصالحات فلهم اجر غير ممنون
диб, гакыллары белән файдаланыб, Аллаһыга иман китергәннең соңында изге гамәлләр, башкаларга файдалы эшләр кылган кешеләргә хисабсыз күб әҗер вә сәваблар булачак диб,

вәгъдә кыла. Әмма үзләренең Аллаһының биргән матди, мәгънәви көчләрендән файдалана белми. Шушы көчләрен исраф итеб, Аллаһы тыйган начар юлларда булса, менә бу адәмгә дөнья Ахирәтдә хур, сәфил булыб, Аллаһының газабына дучар булачаклар, ди.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте динебезне, дөньябызна тигез алыб барыб, барчаларыбызга сәгадәт дарәйн насыйб итсен. Амин.
(0900) 1968 нче Миляди, 26 нчы июль / 1388 нче Һиҗри, Җәмадил әүвәл, беренче көне, җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Бәндәчелек бурычын үтәү, Аллаһыга гыйбадәт кылыб, азмы, күбме? Вәгазь-нәсыйхәт ишетү өчен диб гыйбадәт йортына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бүген җомга көн Җәмадил әүвәл аеның беренче көне. Өстебезгә яңа туган ай җөмләбез өчен мөбарәк булыб, илебез, җанларыбыз тыныч булыб, динебез тыйган начар эшләрдән, начар гадәтләрдән ерак булыб, Аллаһы хәзрәте разый булырлык күркәм сыйфатлар, яхшы эшләр белән үткәрергә насыйб булсын. Амин.
Узган җомгада Аллаһының кәламе (сүзләре – А.Х.) булган Коръән аяте буенча адәм баласын иң күркәм сүрәтдә яратыб, гакыл нигъмәте белән хөрмәтләб, аны җир йөзенә хуҗа, хәлифә итеб, бөтен мәхлукатка өстен итеб, җир йөзен идарә итәрлек көч-куәт, аң-белем биреб, бөтен җанлы-җансыз нәрсәләр адәмгә итагать кылыб, буйсынуы хакында сөйләгән идем.
Инде Аллаһы Тәбарәкә хәзрәте адәмне җир йөзенең хуҗасы булырлык итеб яратканның, гакыл нигъмәте белән сайлаб, аның белән генә калмаган, пәйгамбәрләр, Китаблар күндереб, ни рәвешле яшәү юлларын (0901) өйрәткән. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте һичбер нәрсәне бушка тикмәгә генә яратмаганга, инде шушы гакыл иясе, күркәм сурәтдә яратылган адәм балаларын юкдан бар кылуда Аллаһының серләре, хикмәтләре бар.
Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә:
و ماخلقت الجن و الانس الا ليعبدون
ди. Ягъни: җенләрне, адәмләрне гыйбадәт кылыр өчен яратдым, ди.
Инде шулай булгач дөньяда адәм балалары йоклаб ятыр, ашаб-эчәр өчен , кәеф-сафа кылыр өчен генә түгел, бәлки үзләрендән ничек кенә булса да бер эз калдырырга, Аллаһыны танырга, гыйбадәт, коллык кылыр өчен яратылганлар. Инде бу хакда искә алырга тиешле бер мәсъәлә бар. Аллаһыга гыйбадәт кылу, коллык кылу дибез, бу нәрсә? Без гыйбадәт дигән сүздән намаз уку, руза тоту диб кенә аңлаучыларыбыз бар. Ләкин асыл гыйбадәт кылу Аллаһыга коллык кылу, бәндәчелек вазыйфасын үтәү һичбер вакытда болар белән генә табылачак түгел. Дөрест, намаз уку, руза тоту – болар һәркайсы гыйбадәтнең зурысы, Исламның бинасы, нигезе. Шуның белән берә-бер йир йөзенә килгән бәндәнең бурычы, вазыйфасы, гыйбадәте булырга гына тукталыб калмый, болар белән генә бетми. Гыйбадәтнең кыскача гына мәгънәсе: һәрвакытда, һәр урында Аллаһы риза була торган бер эш белән мәшгуль булу, Аллаһы риза булмаган һәртөрле начарлыклардан ерак булу, менә шундый яхшы ният белән хәләлдән кәсеб итүләребез, тиешле урынларга ярдәм итүләребез, телләребезне бөтен әгъзаләребез белән башкаларны рәнҗетүдән саклану – менә болар (0902) һәркайсы Аллаһы кашында гыйбадәтдән санала. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте Коръәндә бик күб урынларда әйтә:
و بشر الذين آمنوا و عملوا الصالحات ان لهم جنت تجري من تحتها الانهار
ди. Ягъни Аллаһыга иман китергәннең соңында яхшы юлда йөреб, яхшы гамәлләр кылган

кешеләргә сөенеч бирде. Аларга Кыямәт көнендә Аллаһы тарафыннан мөкафәт ителеб акар сулары, җәннәт бакчалары бирелер, ди.
Тагын да “Бәкарә” сүрәсендә 62 нче аятьдә Аллаһы хәзрәте әйтә:
إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَالَّذِينَ هَادُوا وَالنَّصَارَىٰ وَالصَّابِئِينَ مَنْ آمَنَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَعَمِلَ صَالِحًا فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ
ди. Ягъни: Аллаһыга Ахирәт көненә иман китереб, изге гамәлләр кылган адәмләргә Рабблары каршында алар өчен әҗерләре шул: аларга ул көндә курку юк һәм узган көнләре өчен көенү, хәсрәтләнү дә булачак түгел. Ягъни алар Аллаһы газабындан котылыб, җәннәтле булачаклар, ди.
Аллаһыга иман китергәннең соңында бәндә намаз уку, руза тоту белән генә җиңелләнеб калмый икән, бәлки бу борычларны үтәгәннең соңында һәрвакыт Аллаһыны истдә тоту бәндәчелегебезнең бурычы икән. Тагын да Аллаһының сүрәи “Ниса”дә безгә әмер иткән бер аяте шуны аңлата:
فَإِذَا قَضَيْتُمُ الصَّلَاةَ فَاذْكُرُوا اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِكُمْ ۚ
Ягъни: һәркайчан намазны үтәгәннең соңында Аллаһыны зикер итегез, исегездә тотыгыз (0903), басканыгыз хәлдә, утырганыгыз хәлдә дә җанларыгызга ятканыгыз хәлдә, ди. Кыскасы, һәрвакытыбызда кай урында, нинди хәлдә булсак да, Аллаһыны исдә, хәтердә тотсак телләребез белән дә, бөтен әгъзаләребез белән дә начарлыкдан тыелуга сәбәб булачак.
Хасыйлел кәлам, без гафил булыб, Аллаһының газабындан әмин булыб, Аллаһы Гәфурун, Рәхим диеб кенә йөрсәк, без бу вакыт бик каты алданган булырбыз, чөнки мөфәссирләр (Коръәнне тәфсирләүчеләр – А.Х.) “Гәфурун, Рәхим” дигән аятьнең тәфсирендә:
اي لمن تاب و آمن و عمل صالحا
диб тәрҗемә кылганлар. Ягъни Аллаһы Тәгалә хәзрәте шундаен кешеләрне гафу итәр, ул кешеләр ихлас күңелләре белән тәүбә кылдылар, үзләренең начарлыкларына үкенделәр, иман китереб, гамәле салих кылырга тырышдылар, ди. Бер адәмнең күңелендә Аллаһыны зикер итү, Аллаһы исдә булды исә, ул адәм бөтен начарлыклардан ерак булырга тырыша, төрле юллар белән кеше рәнҗетүдән, ялган, бөһтан (яла; клевета – А.Х.), гайбәт, кеше араларын бозыштырудан фетнәгә сәбәб булган эшләрдән, һәммәсендән сакланыб, бөтен эшләрендә тугъры булырга тырыша. Менә мондый адәм, кеше күргәндә генә түгел, кеше күрмәгәндә дә бөтен начарлыкдан тыела, чөнки ул бөтен хәлемне Аллаһы хәзрәте күреб тора диб, чын күңелендән ышанган. Шушылай изге теләк белән эшләнгән бөтен дөньяви кәсебләрдә һәркайсы Аллаһы кашында гамәле салих булыб (хәтта ашау-эчүләребез, йоклауларыбыз да), йә Рабб, хәлал кәсеб итәргә, Үзеңгә гыйбадәт кылырга көч бир диб, ашау-эчүләребез, йоклауларыбыз да әҗер вә сәваблы эшләрдән булачак.
(0904) Ватанымызның төрле почмакларына, туганларыбызга, ата-аналарыбызга зиярат гыйбрәт алу, үрнәк алу теләкләребез белән һәр тарафка сәяхәт кылу, чөнки хәзрәт рәсүл әйтә:
سياحة امتي كالمجاهد فى سبيل الله
ди. Өммәтемнең сәяхәт кылуы Аллаһы юлында сугыш кылучы кеше кебек, ди. Шулай ук хәрби хезмәтдә булган һәрбер яшьләребез
حب الوطن من الامان
Ягъни: туган илебезгә мәхәббәт итеб ватаныбызда яшәүче халыкларны дошманның шәррендән, явызлыкдан саклау өчен военный хезмәтдә булулар, бөтен халыкка файда итү теләге белән колхозда, совхозда, завод-фабрикада эшләүләр, чөнки хәзрәт рәсүл әйтә:
خير الناس انفعهم للناس

ди. Нинди генә эшләрдә, нинди генә юллар белән халыкка файда итәргә тырышкан кеше сезнең иң хәерлегез, иң яхшырагыз, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте адәм балаларын яратыб, бөтен җир йөзенә хуҗа итүендә шундый сер-хөкемнәр бар икән: Аллаһыга иман китереб, намаз, руза бурычларыны үтәб, Аллаһының безгә биргән нигъмәтләрендән дөрест юллар белән үзебез файдаланыб вә башкаларны да файдаландырыб яши белсәк, бондай кешеләр хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:
ان الذين آمنوا و عملوا الصالحات اولئك هم خير البرية
Менә бу мәхлукатнең иң изгеләре, хәерләре, ди, менә бу кешеләр: җәннәт йортында мәңге калачаклар, ди.
راضي الله عنهم و راضوا عنه
Менә бу кешеләрдән Аллаһы разый булды. Болар да Аллаһының биргән нигъмәтләрендән разый булдылар, ди. (0905)
ذالك لمن خشى ربه
Менә бу мөкафәтләр, бүләкләр кемгә? Шундай кешеләр, алар һәрвакыт Аллаһыны исдә, Аллаһының газабындан курыккан кешеләргә, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать!
و ما خلقت الجن و الانس الا ليعبدون
Без эш дөньясында торуыбызны хәтердә тотыб, динебез, дөньябыз өчен тырышу исламият кушуы буенча һәркайсыбызның изге бурычы. Бәгъзе бер адәмләребез хакында дөньяга мәңге килгән кебек җөри диб әйтәбез. Бу сүзебез хәзрәт рәсүлнең мөбарәк сүзенә мөафик сүз булмый, чөнки пәйгамбәребез Хода әйтә:
اعمل لدنياك كأنك تعيش أبداً ، واعمل لآخرتك كأنك تموت غداً
Мәңге торыр кебек халәл рәвешдә дөнья ку, иртәгә үлер кебек Ахирәтең өчен хәзерлән, ди.
Дөрест юл белән дөньяда кәсеб итүләребез – һәркайсы Аллаһы кашында гыйбадәтдән санала икән. Инде Ахирәтебезне онытыб, халәлен, хәрамен тикшерми, гел дөнья артындан гына чабса, бу исламият юлы түгел. Бу адәм соңгы көндә зур үкенечкә, хәсрәткә калачак. Аллаһының биргән бөтен нигъмәтләрендән файдаланыб, дөньясын, Ахирәтен тигез алыб барырга тырышкан адәмләр чын мәгънәсе белән Аллаһының җир йөзендәге варислары булачак.
Аллаһы Раббел галәмин барчаларыбызга хата вә кимчелекләребезгә тәүбә кылыб, сәгадәт дарәйнгә ирешергә насыйб итсен. Амин йә Мөҗибес саилин.
(0906) Намаз хакында сүрәи “Ниса”да 153 аять:
إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا
Мөнафикълар хакында – сүрәи “Ниса” 145 аять:
إِنَّ الْمُنَافِقِينَ فِي الدَّرْكِ الْأَسْفَلِ مِنَ النَّارِ وَلَن تَجِدَ لَهُمْ نَصِيرًا
Сүрәи “Маида”дә хәмер хакында 91-95 нче аятьләр.
Сүрәи “Маидә” таһарәт хакында:
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قُمْتُمْ إِلَى الصَّلَاةِ فَاغْسِلُوا وُجُوهَكُمْ وَأَيْدِيَكُمْ إِلَى الْمَرَافِقِ وَامْسَحُوا بِرُءُوسِكُمْ
“Ал-Гыймран”, 152-153 аятьләр.

(0907) 1388 Һиҗри, Җәмадил әүвәл / 1968 нче ел, 2 нче августдан башлаб сөйләнгән җомга вәгазьләре.
1)

2) Мәсҗедкә керү тәртибләре.
3) Җомга гыйбадәте хакында. (Биш вакыт намазга дәлилләр Коръән аяте илә) бу дәфтәрдә.
(0908) 1388 нче Һиҗри, Җәмадил әүвәлнең 8 нче көне, җомга көн / 1968 нче ел, 2 нче август.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Җомга намазына килгән мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Җенабе Хак Үзенең пәйгамбәре аркылы безгә шушы әмер-боерыкларын белдерә:
يَا أَيُّهَا النَّاسُ اعْبُدُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ وَالَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ
Сүрәи “Бәкарә”, 25 нче аять.
И, адәм балалары! Үзегезне юкдан бар кылган Аллаһыга гыйбадәт, коллык кылыгыз. Һәм сездән әүвәлгеләрне һәм сезне юкдан бар кылган Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз, коллык кылыгыз, шаять ки Аллаһыга гыйбадәт кылыб тәкъвалык кылырсыз, Аллаһының кушкан юлына керүегезгә сәбәб булыр, ди.
Һәм узган җомгада “Зарият” сүрәсендә Аллаһының бәндәне ни өчен яратканын сөйләгән идем.
ما خلقت الجن و الانس الا ليعبدون
(56). (0909) Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте безне гыйбадәт, коллык кылу (бәндәчелегебезне белдерү, Аллаһыны олугълау) өчен яратты дигән идем.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббел галәмин безне ни өчен гыйбадәт кылырга, коллык кылырга кушкан? Изге ният, яхшы ният белән булса, безнең дөньяви эшләребез дә – һәркайсы гыйбадәтдән санала, дигән идем. Әгәр тикшереб карасак, Аллаһының һәрберебезгә кылырга кушкан әмерләре, боерыклары, нәһиләре – болар һәркайсы адәм баласының үз файдасы өчен. Бәндә Аллаһыга гыйбадәт кылсын кирәк, кылмасын, дөньяви эшләрендә Аллаһыны искә алсын, алмасын, Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенә һич кимчелек, зарар килми. Бәндәләрнең гыйбадәтенә, гамәлләренә Аллаһы мохтаҗ түгел. Бөтен гыйбадәтләр дә, әмер вә нәһиләр дә, дөньяви вә ахирәви гамәлләребез дә фәкать бәндәнең үзенә файда өчен. Безне гыйбадәт белән гамәлес салихат белән әмер кылган. Гыйбадәтләр ике төрле булыб, гыйбадәте лязимә, гыйбадәте мөтәгаддийә булыб, икегә бүленә.
Гыйбадәте лязимә – намаз уку, руза тоту, иман китерү – боларның файдасы үзебез өчен. Инде мөтәгаддийә – үзебездән үтәб башкаларга файда китерә торган гыйбадәтләр! Ата-ананы тәрбия итү, балаларны тәрбия итү, зәкят бирү, фәкыйрьләргә тиешле урынларга ярдәм итү кебек - болар гыйбадәте мөтәгаддийә булыб, Аллаһы кашында дөньяда ук җаныбыз рәхәтләнеб, күңелләребез шадланыб, үзара тынычлык, дустлык, өлфәт, мәхәббәткә сәбәб булыб, Ахирәтдә зур әҗер вә сәваблар вәгъдә кылынган.
Һәрбер гыйбадәтнең ике төрле файдасы бар: дөньяви һәм ахирәви. Һәр гыйбадәтнең заһири һәм батыйни җәһәтләре бар, ягъни тышкы күренешләре, дөньяви файдалары. Адәм баласы җан, тәндән кушылганлыкдан тышкы күренешендә файдасы. Һәрбер гыйбадәтнең, кирәк гыйбадәте лязимә, кирәк гыйбадәте мөтәгаддийә булсын, – һәркайсының ике төрле файдасы, ике төрле рәвеше бар: дөньяви һәм ахирәви файдасы. Мәсәлән, намаз укучының беренче дөньяви файдалары, иң беренче – аның пакълегенә сәбәб, киеме, тәне пакъ булды исә, сәламәтлегенә хыйфез, сыйххәткә сәбәб булачак. Икенчедән, тәнләребезне, әгъзаләрәбезне хәрәкәтләндерү булыб, бу да сәламәтлегебезгә сәбәб, чөнки Ислам галимләрендән берәү әйтә: намазның тышкы күренешендән

әгъзаләрне хәрәкәтләндерүнең файдасы – гимнастика файдаларындан да зуррак, ди.Инде болары тышкы һәм дөньяви файдалары булды. Батыйни, ахирәви файдалары: тәгъзыйм өлүһият, Аллаһыны олугъла у, тәгъзыйм кылу вә тәһзиб инсаният – инсаниятне пакъләү, бәндәчелекне үтәү вазыйфасы – һәркайсы табылыб, һәрбер гыйбадәтдә заһири, батыйни, тышкы һәм эчке гыйбадәткә бүленеб, батыйни – эчке гыйбадәт: ният һәм күңелгә бәйләнеб, моңа һич рия катнашу мөмкин түгел. Моның өчен хәзрәт рәсүл әкрам әйтә:
إِنَّ اللَّهَ لا يَنْظُرُ إِلَى صُوَرِكُمْ وَأَمْوَالِكُمْ وَلَكِنْ يَنْظُرُ إِلَى قُلُوبِكُمْ وَأَعْمَالِكُمْ
Ягъни Аллаһы Тәгалә сезнең (0911) тышкы сурәтләрегезгә, кыяфәтләрегезгә карамый, бәлки сезнең күңелләрегезгә, кылган гамәлләрегезгә карый диб ачык әйтә.
Икенче бер хәдисдә хәзрәт рәсүл әкрам әйтә:
أَلا وَإِنَّ فِي الْجَسَدِ مُضْغَةً إِذَا صَلَحَتْ صَلَحَ الْجَسَدُ كُلُّهُ, وَإِذَا فَسَدَتْ فَسَدَ الْجَسَدُ كُلُّهُ, أَلا وَهِيَ الْقَلْبُ
Ягъни: агяh булыгыз, тәндә бер ит кисәге бар, әгәр ул ит кисәге төзек, дөрест булса, адәм баласының бөтен тәне төзек булыр. Менә хәдисләрдән аңлана (аңлашыла – А.Х.), кирәк гыйбадәте лязимә, кирәк гыйбадәте мөтәгаддийә булсын, кирәк гыйбадәт булсын, кирәк дөньяви эш кенә булсын – һәркайсы батыйненә, күңеленә караб, күңеле, нияте изгелекдә, яхшылыкда булса, һәркайсы гамәле салихат җөмләсендән әҗер вә сәваблы булырга мөмкин. Әгәр гыйфләт, гафиллек сәбәбле, Аллаһы сакласын, намаз, руза кебек гыйбадәтләребездә дә әҗер вә сәвабдан мәхрум калу куркынычы бар. Рәсүл әкрам тагын да бер хәдисендә әйтә:
اخلص دينك يكفك القليل من العمل
Ягъни: гамәлләреңдә ихлас күңел белән кылсаң, аз гамәлең дә җитәр. Аз гамәл белән дә, Аллаһы кашында мәкбуль булса, зур әҗер вә сәвабларга ирешергә мөмкин икән.
Хасыйлел кәлям, адәм баласының гамәл гыйбадәт белән мөкәлләф булуыбыз, һәркайсы дөнья Ахирәттә бәхетле булуыбызга сәбәб. Аллаһы хәзрәтләре Коръәндә пәйгамбәребез хакында:
و ما ارسلنك الا رحمة للعلمين
ди. Без сине ике дөньяга рәхмәт өчен җибәрдек, ди.
(0912) Ягъни пәйгамбәребезнең күрсәткән юлы, шәригате буенча бара алсак, әмер-нәһиләрен үти алсак, дөнья Ахирәтдә бәхетле булачакбыз. Безнең гыйбадәт кылуыбыз, яхшы гамәлләр кылуыбыз, яхшы, яман булуыбыз – бар да үзебез өчен. Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте һич адәмнең гамәл гыйбадәтенә мохтаҗ түгел. Ләкин без барчаларыбыз Аллаһы рәхмәтенә вә ярдәменә мохтаҗбыз.
Мөхтәрәм җәмәгать! Үз тарафымдан әйтә торган үтенечем: сөйләнгән сүзләрне дөрест итеб аңларга насыйб булсын. Бәлки тыңлаучылар тарафындан ялгыш аңланылса, ялгыш ишетелсә, бәлки сөйләүче тарафындан хата булырга мөмкин. Шундый хәлләр була калса, күңелләребезгә урнашмаслык шик-шөбһәгә сәбәб булырдай сүзләр аңлашса, артда сөйләб йөреб, гөнаһлы булмыйк. Турыдан-туры үземә әйтегез. Мин сезнең кебек бер гади кеше, сөйләшербез, аңлашырбыз. Шундый хәлләр булды. Мин сөйләгәннең нәкъ киресенчә ишеткән кешеләр һәрвакыт булгалый. Белмим – чукраклык, белмим – хаталык, белмим – касдән юри миңа бәһтан бәла ягу өчендерме. Без һәркайсыбыз Аллаһының рәхмәтен өмед итеб, ихлас күңелдән гыйбадәт йортына җыелган мөселманмыз. Мәшәкатьләнеб кылган гыйбадәтләребезнең сәвабын, әҗерен бетерә торган бәһтан, гайбәт кебек начар гадәтләрдән Аллаһы барыбызны да ерак кылсын.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте киемләребез, тәнләребез пакъ булган кебек, күңелләребезне дә пакъ, төзек кылыб, җенабе хозурына кылыб, сәлим белән барырга насыйб итсен. Амин.

(0913) 1968 нче ел, 9 нчы август / 1388 нче Һиҗри, 15 нче Җәмадил әүвәл, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Җомга намазына җыелган мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде.
Исламның бинасы булган мөэминнәрнең Мигъраҗы аталган намаз хакында беркадәр сөйләмәкче булам дөрест итеб. Аллаһы ярдәм итсен. Күб ишеткәнбез диб, күңелгә тәкбирлек китерергә ярамый. Белгән нәрсәләребез бер булса, белмәгәнләребез меңләрчә. Ишетеб тыңлау белән генә түгел, моның белән гамәл итәргә кирәк. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәте Коръәндә “Зарият” сүрәсендә 55нче аятьтә әйтә:
و ذكر فان الذكرى تنفع المؤمنين
Пәйгамбәр хәзрәтенә әйтә: вәгазь-нәсыйхәт кыл. Вәгазь-нәсыйхәт мөэминләргә файда бирер. Анлар шул ишеткән вәгазьләрбелән файдаланырлар, ди. Ишеткән вәгазьләребез файда бирмәсә, мөэминләр җөмләсенә кермәү ихтималыбыз бар.
Узган җомгада Аллаһының безгә гыйбадәт белән боерган аятьдән укыган идем: сездән әүвәлгеләрне һәм сезне юкдан бар кылган Раббыгызга, тәрбия кылучыгызга гыйбадәт, коллык кылыгыз, дигән аятьне Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне олугълаб вә бәндәчелегебезне искә алыб, әгәр ихлас белән укылса, бөтен бозыклардан тыелуыбызга сәбәб булган зур (0914) намаз гыйбадәтен Аллаһы безгә фарыз иткән. Шуны үтәү белән безгә әмер иткән. Бу зур гыйбадәтдә Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре безгә зур сөенечләр вәгъдә кылган, шуның белән бергә бик куркынычлы вәгыйдләре дә бар. Җөмләдән берсе рәсүлулла (сгс)дән шундый бер хәдис, риваять кылына:
من حافظ عليها كانت له نورا وبرهانا ونجاة يوم القيامة ومن لم يحافظ عليها لم تكن له نورا ولا برهانا ولا نجاة ويأتي يوم القيامة مع قارون وفرعون وهامان وأبي بن خلف
Бер кеше биш вакыт намазга даимчылык (намазны укыса), аның өчен нур була. Мөселман икәнчелегенә (икәнлегенә – А.Х.), Аллаһының әмерен итагать кылучылыгына зур дәлил була. Менә бу адәмгә Кыямәт көнендә Аллаһының газабындан котылу, нәҗат булачак. Әмма инде берәү Аллаһыга, Кыямәт көненә ышаныб да намаз укымаса, аның өчен дәлил дә юк, нур да, Аллаһы сакласын, Кыямәт көнендә Аллаһының газабындан котылу да юк. Кыямәт көнендә бу кеше Аллаһының дошманлары булган Карун, Фиргәвен. Убай бин Хәләфләр белән бергә булыр, ди.
Инде бер адәм улы яшькә җитеб, пенсиягә чыкды исә, әгәр чын күңеле белән иман китерә икән, биш вакыт намазны калдырмаска тиеш.
Мөхтәрәм җәмәгать! Кяфер булу, әлгыяз билләһ, Аллаһыны инкяр кылу, потларга, тәреләргә табыну гына түгел, Аллаһының әмерләренә буйсынмау, кылырга кушканларын кылмау белән дә булырга мөмкин, (0915) чөнки Иблис (عليه اللعنة) ни өчен Аллаһының рәхмәтендән сөрелде? Ни өчен мәңге тәмугълык булды? Аллаһының әмерен, кушканын тотмау белән Иблис Аллаһыга нык ышана, җенабе Хакны күзе белән күргән кебек, чөнки ул фәрештәләрнең арасында булды, аның көферлеге Аллаһыга итагать калмавындан гыйсьяныннан булды.
Бу хакда кечкенә генә бер мисал-хикәя бар: Бер адәм Иблис белән юлдаш була. Юлда барганда тәүлек эчендә Иблис бу адәмне төрле хәйләләр, вәсвәсәләр белән биш вакыт намазын укытмый, биш намаз укытмый узган соңында Иблис мондан аерыла. Бу аның Иблис икәнен белмәгән булса кирәк. Бу адәм әйтә: йә юлдаш, бергә-бергә сәфәребез күңелле иде, юл кыска иде. Ник аерыласың? – дигәннең соңында Иблис әйтә: синең гөнаһың сәбәбле миңа нинди Аллаһының каһере ирешүе мөмкин, ди. Мин гөмерем эчендә Аллаһының әмеренә бер мәртәбә буйсынмавым хакында Аллаһының рәхмәтендән мәрдуд

булдым, сөрелдем Иблис исеме алдым. Инде син бер көндә Аллаһының әмеренә биш мәртәбә гасый булдың диб, китеб бара.
Хәзрәт рәсүл әйтә:
ان الشيطان يجري من ابن آدم مجرى الدم
Шәйтан адәм баласының эчендә, кан тамырлары буенча җөри, ди.
Шулай булгач, шәйтан безне ничек кенә булса да намазны укытмаска тырыша, ничек кенә булса да шәйтаныбызны, нәфсебезне җиңеб, намаз укырга булсак, инде ул безнең намазыбызны боздырырга, һич булмаса, сәвабын киметергә (0916) тырыша. Һәрбер гыйбадәтдәге намаз гыйбадәтендә, намаз укуда, тәгъзыйм өлүһият, Аллаһыны олугълау, тәгъзыйм кылу, тәһзиб инсаният арулау вә шөкерен нигъмәт намазыны чын күңелебез белән, бирелеб, камил, ихлас белән, хошугъ, хозугъ, дөнья шөгыльләребезне күңелләребездән чыгарыб, Аллаһы хозурына баруны гына исдә тотыб укысак, шушы намазда тәгъзыйм өлүһият, тәһдиб инсаният Аллаһының нигъмәтләренә шөкер кылу – бар да табылачак. Аллаһу әкбар, колак кагуыбыз, сәна укуыбызның мөмкин кадәр мәгънәләрен искә төшерсәк, моның соңында сүрәи “Фатихә”дә:
الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ Аллаһыга шөкранә кылу,
مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ бөтен мәхлукатнең Кыямәт көненең хуҗасы диб,
إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ
диб укыган аятьләребезнең мәгънәсен хәтерләргә тырышсак, менә шушы сүрәи “Фатихә”дә Аллаһыны олугълау, адәмчелегебезне пакъләү, Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкранә һәркайсы табыла. Әгәр намазларыбыз шушы рәвешле булса, чындан да бу намаз безне
ان الصلوة تنهى عن الفحشا و المنكر
дигән аять кәримгә мисдак булыб, безне бөтен начарлыкдан тыячак. Шундый намазыбызны Аллаһының газабындан коткарачак. Шушындый намазны Аллаһының дустларына вәгъдә кылган зур мәкафәтләргә, зур әҗер вә сәвабларга ирешдерәчәк. Аллаһы Раббел галәмин барыбызга да шушындый ихлас күңелләребез белән гыйбадәт кылуны насыйб итсен. Амин.
(0917) Инде мөхтәрәм җәмәгать! Авыр булса да, читен булса да, әйтми калу мөмкин түгел:
1. Иң беренче тиешле булган фазыйләтләрдән, намазга килдеңме, мөэзиннең (мәзиннең – А.Х.) яки башка кешеләрнең өндәгәнен көтми, алдагы булмәләргә, алдагы сафка кереб утырырга кирәк. Әгәр үзебезгә караганда галимрәк, әфзалырак адәмләр була икән, аларга урын бирергә тиеш, хөрмәт итәргә. Аларда булган артыклык хасиятләре өчен (чөнки хәзрәт рәсүлнең галимләрне гыйлемләре өчен хөрмәтләргә кушкан хәдисләр күб).
2. Имам артындан колак кагырга тырышу. Мөхтәрәм җәмәгать! Иң куркынычлы хәл, намазыбызны юкка чыгара торган – имамдан әүвәл колак кагу һәм башка рөкенләрне имамдан алда кылу. Болар һәркайсы намазны боза торган, юкка чыгара торган, күңелсез хәлләр. Бик сак булырга кирәк, һәрвакыт моны исдә тотарга тиешлебез.
Китабларда шундый сүзләр бар: намазга килеб, намаз укыб чыгуларыбыз өч төрле булыр икән.
1. Берәүләр, нәкъ пәйгамбәребез кушканча, һәрбер көнләрен игътибар кылыб, камил ихлас белән укучылар. Болар чын, дөрест намаз укучы булыб, Аллаһы кашында зур әҗер, сәвабларга ирешдерә торган дәрәҗәгә лаек булалар, Аллаһы рәхмәтенә ирешәчәкләр.
2. Намаз укыб да, үзен гайбәт, бөһтан, ялган, хөсед кебек нәрсәләрне сөйләб, намазларның сәвабын киметүче яки бөтенләй юкка чыгаручылар.

3. Намаз бөтен гамәлләрен ашыгыб, имамдан алда үтәүчеләр. Болар бөтенләй намазсыз кайтучылар, дигәндер.
(0918) Тагын да бергә искә алыб сакланырга, тиешле бер гадәт – гозерсез тамак кырудан сакланырга кирәк. Көчәнеб-көчәнеб тамак кыручыларыбыз бар. Гозер белән – бу башка нәрсә. Беренче минутлык намазыбызда, сәлам биргәнче тамак кырудан сакланырга кирәк. Тагын да бер кимчелегебез булса, бу үзебезнең каршылыгыбыздан килгән зур хатабыз. Миндән әүвәлге килгән хәзрәтләр ничә мәртәбәләр әйткәнләр: гозер сәбәбле ярамаган эшләрдә дөрестгә илән диб, ни кадәр әйтсә дә (шәригатемез рөхсәт биргән) урынларыбыз тыгыз вакытда ишарә белән сәждәсез уку да дөрест диб, шәригатебезнең безгә биргән иркенчелекләрендән файдаланмый, юк, мин үземчә укыйм, сезнең шәригатегезнең рөхсәтендә минем эшем юк, дигән кебек, үзенең артындагы адәмләрне рәнҗетә-рәнҗетә, хәтта аркылы ятыб булса да сәҗдә кылу. Менә бу эшләр һаман да бар, җәмәгать. Мәсҗедгә килдең, инде син үзеңнән бигрәк башкаларга файда итәргә тырышырга кирәк. Хәлдән килгән кадәр вәгазь-нәсыйхәтне тыңлау-тыңламау сезнең эш.
Ишеткән вәгазьләребезне дөрест итеб аңларга, аңлаган, ишеткән вәгазьләребез белән гамәл итәргә Аллаһы насыйб итсен.
Казан шәһәре мәсҗедендә Габделхәбир Ярулла тарафыннан сөйләнгән вәгазьләр.
(0919) 1968 нче ел Миляди, 23 нче августда / 1388 нче Һиҗрия, 29 нчы Җәмадиль әүвәл, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
قال رسول الله صلى الله عليه و سلم
ن تطهر في بيته، ثم مشى إلى بيت من بيوت الله، ليقضي فريضة من فرائض الله، كانت خطوتاه: إحداهما تحط خطيئة، والأخرى ترفع درجة
Мөхтәрәм мөселманлар! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа хәзрәтенең бу безгә өммәтләрен шадландырыб сөйләгән мөбарәк сүзләре намаз хакында булырга кирәк. Ягъни бер кеше өендә пакъләнеб, таһарәт алыб, Аллаһының йортындан бер йортка, ягъни мәсҗедгә барырга чыкса, аның әүвәлге атлавында, адымында гөнаһлары гафу ителенер, гөнаһлары җыелса, икенче адымында аның сәваб йөзендән әҗере бирелер, аның дәрәҗәсе күтәрелер, ди.
Тагын да пәйгамбәр Ходаның бер мөбарәк, шадлыклы, сөенечле хәбәрен, сүзен искә төшерик:
من اغبرت قدماه في سبيل الله حرمه الله على النار
ди. Ягъни: бер адәм Аллаһы юлында (нинди дә булса бер изгелек, яхшылык юлында) ике аягын тузанландырса, аллаһы Тәгалә ул бәндәгә тәмугъ утын хәрам кылыр, ягъни Үзенең газабындан ерак кылыр, ди.
Инде безгә искә алырга, хәтердә тотарга тиешле эшләрдән: (0920) яхшы ният белән намазга баруны ният кылсак, һәм тәнләребезне, киемләребезне пакъләгән кебек үк, күңелләребезне пакъләсәк, начарлыкларыбызга үкенеб, тәүбә, истигъфар кылыб, файдасыз сүзләрдән ерак булыб, белгән догаларыбызны, яки Коръән укыб, дөньяви, ахирәви теләкләребезне теләб, я булмаса, үзеңгә караганда бер өстенрәк галим очраб, гыйлем яки берәр төрле сүз өйрәнсәк, менә шушы рәвешле мәсҗед юлында булсак, инша Алла, шушы рәвешдә, мәсҗед юлында яки башкача бер изгелек юлында пәйгамбәремезнең хәдисенә мисдак (مصداق – ышаныб А.Х.) булыб, гөнаһ вә хаталарымызның гафу ителүенә, Аллаһының газабындан котылуыбызга сәбәб булыр. Инде юлыбызда берәү очраб, кирәк кем генә булмасын, юл сораса яки берәр урамны

өйрәтүне сораса, я булмаса, берәр туганның яки берәр адәм очраб, сәлам биреб, күрешеб хәл-әхвал сорашу, бер-берецә теләкләр теләшү – болар һәркайсы яхшы эшләр. Мондый хәлләр хәзрәт рәсүлнең хәдисенә хилаф сүзләр түгел, болардан зарар юк.
Инде, җәмәгать, намаз юлында һәм башка изгелек нияте белән булган юлларыбызда гайбәт, хөсед, нәмимә, ялган, бөһтан кебек сүзләргә кереб китсәк, бу вакытда инде түгел, бәлки газабланыб кылган гыйбадәтләребез дә юкка чыгу куркынычы бар, Аллаһы сакласын.
(0921) Инде мәсҗедгә кергәндә, чыкканда мөстәхыйб мәндуб фазыйләт булган күркәм, матур гадәтләрне үтәргә тырышсак, менә бу вакыт тагын да хәзрәт рәсүлнең бер мөбарәк сүзенә моафыйк рәвешдә гамәл кылган булыб, нур өстенә нур булыб укыган намазыбызның сәвабы тагын да күбрәк булачак. Бу хакда рәсүл әкрам әйтә:
احب الاعمال الى الله ادوامها
Изге гамәлләрнең Аллаһы кашында сөеклерәге – яхшы гадәтләрне, күркәм эшләрне эшләргә гадәт итү, даимчелек кылу, ди. Мәсәлән, мәсҗедгә килгәндә, киткәндә белгәнләреңне уку, мәсҗедгә кергәндә:
اللهم افتح لي ابواب رحمتك
Ягъни: дөнья Ахирәт рәхмәт ишекләреңне ачкыл диб сорау. Чыккан вакытда:
اللهم اني اسئلك من فضلك
Ягъни: И, Аллаһы! Фазылың вә рәхмәтеңне сорыйм. И, Аллаһы! Дөньяви һәм Ахирәви эшләребездә ярдәм сорау – искә алырга тиешле эшләрдән тиешлерәге. Сөннәтләреңне укыдыңмы? Әгәр дә алдагы сафда урын бар икән, һичкемнең өндәвен, әйтүен көтмәскә кирәк.
Мөхтәрәм намазга килүчеләребез! Һәркайсыларыбыз олугъ яшькә җиткән кешеләребез, һичберебезнең икенче берәвебездән артыклык юк.
ان اكرمكم عند الله اتقاكم
– Коръән аяте.
Рәсүлулладан шундый сүзләр риваять кылына: әгәр өммәтләрем алдагы сафда намаз укуның хасиятен белсәләр иде (0922), алдагы сафка керер өчен сугышырлар иде, ди. Хәбәрләрдә шул риваять кылына ки: кайчан Кыямәт көне булса, бер төркем нурлы йөзле адәмләр килерләр, ди. Бу кешеләрдән сорарлар икән: бу рәвешле нурлы булыб кубарылуыгызга ни сәбәб? – диб. Соралганның соңында болар әйтерләр: без азан тавышы ишетү белән җәмәгать намазына ашыкдык диб, икенче бер төркем халык килерләр икән. Боларның нуры башка йолдызларга караганда, айның нуры артыграк булган, тагын да нурлырак булыб килерләр икән. Болардан: нинди изге гамәлләр кылыб бу дәрәҗәгә ирешдегеэ? – диб. Соралганның соңында: без азандан әүвәл таһарәт алыр булдык. Өченче бер төркем халык тагын да нурлырак рәвешдә мәйданга килгәннең соңында болардан һәм соралганның соңында болар әйтерләр: моның сәбәбе - без азан тавышын мәсҗеддә ишетер булдык, диб. Әлбәттә бу фазыйләтләр, бу сәваблы эшләр эшдән бушаныб, пенсиягә чыгыб, намазга килергә мөмкинлек булган адәмләр хакында әйтелә. Бу гамәлләр мәндуб, мөстәхыйб кебек (نور على نور) булган сыйфатлар һәм намазга килеб дә имам белән бергә тәкбир, тәхримгә ирешү хакында зур фазыйләтләр, зур әҗер-сәваблар вәгъдә кылынган. Сәхабәләр, сәләфе салихин җәмәгать намазында имам белән тәкбир, тәхрим кылырга зур әһәмият биргәнләр. Тәкбир, тәхримгә ирешүдә Аллаһы ризалыгы өчен меңләрчә симез дөяләр чалудан да артыграк зур әҗер, сәваблар (0923) барлыгын сөйләгәнләр.
Исламның бинасы булган намаз гыйбадәтен яхшы, нык бер нигезгә утыртылган җуан (юан – А.Х.) бүрәнәдән салынган бер йортка охшатсак, түбәләре мөкәммәл булыб, эчен, тышын

обшивать итеб, буяб да җибәрелсә, бу йорт һәркем тарафындан кызыгырлык яхшы йорт булган кебек, мөселманлыгыбызның иң зур билгесе булган биш вакыт камил ригая, ихлас белән фарыз важибләрдән сөннәт, мөстәхыйб, фазыйләтләрен дә мөкәммәл рәвешдә үтәргә тырышсак, әхсанель халикин булган җенабе Хак хозурында мәкбуль булыб, гарәсат (عرصات) мәйданында Мәхшәр көнендә йөзләребез ак вә нурлы булыб, инша Алла, Аллаһының газабындан котылыб, зур мөкафәтләргә ирешүебезгә сәбәб булыр.
Кыска гына бер мисал: суга барганның соңында һәркайсыларыбызның суны, чиләкләребезне тутырыб, мөлдрәтеб алыб кайтасыбыз килә. Шуның кебек ерак урынлардан зур мәшәкатьләр белән нәфесләребез, шәйтанларыбызны җиңгеб, киләчәгебез өчен зур өмедләр, сәваблар булачагына ышаныб, кылган намаз гыйбадәтләребезне әҗер вә сәвабларын бетермичә, киметмичә, зур әҗерләргә ирешергә насыйб булсын. Шулай ук эшдән бушаныб, ялга чыккан картларыбызга да, Аллаһыны искә алыб, яшьлекдә булган хата вә кимчелекләребезгә үкенеб, тәүбә, истигъфар кылыб, гомеребезнең соңгы көнләрен гамәле гыйбадәтдә уздырырга насыйб булсын. Амин.
اهدنا الصراط المستقيم

(0924) 1968 нче Миляди, 30 август / 1388 нче Һиҗри, 6 нчы Җәмадил ахир, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһының рәхмәтен өмед итеб, Аллаһының газабындан куркыб, ихлас күңелләре белән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Мөхтәрәм җәмәгать! Сәййидель әййам булган җомга көнендә укыла торган җомга намазы, җомга гыйбадәте хакында беркадәр сөйләмәкче булам. Җенабе Хак дөрест итеб аңлатырга һәм дөрест итеб аңларга ярдәм бирсен.
Мөселманлар тарафындан укылыб килә торган җомга намазы хәзерге көнемездән 1346 ел элек, хәзрәт рәсүлнең Мәккәдән Мәдинәгә күчкәнче, Мәккәдә вакытда фарыз булган иде. Мәккә шәһәрендә мөшрикләрнең һәрвакыт борчулары, манигълары сәбәбле Мәккәдә вакыт укылмый торды. Иң әүвәл Мәдинәдә башлаб җомга намазын укучы кеше әсхабдән Әсгад бин Зурарә дигән сәхабә булды. Бу сәхабә рәсүлулла Мәдинәгә килмәсдән ул кырык кадәр мөселманлар белән җомга укыды. Тарих Исламның күрсәтүенә караганда, иң әүвәл укылган җомга шушы җомга булса кирәк. Мондан соң рәсүлулла (сгс) Мәдинәгә Һиҗрәт итеб, Мәдинәи Мөнәввәрә якынында Куна карьясендә (авылында – А.Х.) дүшәнбе, сишәнбе, чәһаршәнбе (0925), пәнҗешәнбе көнләре торыб, җомга көн Мәдинә шәһәренә килде. Һәм Сәлим бин Гауф кабиләсе эчендә Батель вади (بطن الوادى) дигән урында бәлигъ бер хөтбә сөйләб, җомга намазы укыды. Рәсүлулла тарафындан иң әүвәл укылган җомга шушыдыр. (622 нче Миляди, 12 нче Рәбигел әүвәл (24 нче сентябрь).
Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам диненең иң зур галәмәтләрендән булган
حج الفقراء ، حج المساكين
аталган Аллаһының кәляме, пәйгамбәрнең сахих хәдисләре белән ачык мәгълүм булыб, фарыз ителгән шушы җомга көнен хөрмәт итеб, аруланыб, пакъләнеб, туганларыбыз, дуст-ишләребез белән күрешеб, мөмкин зияратларга барыб, мәетләребезгә догалар кылыб гыйбрәтләнү, әгъзаләребезне ял итдереб, күңелләребезне дөнья шөгыльләрендән бушатыб, Аллаһыны искә алыб, җомга гыйбадәтенә килеб, азмы-күбме вәгазь. нәсыйхәт ишетүебез бик тиешле булган. Һәрбер мөселманның гозер булмаганда үтәргә тиешле булган изге, мөкаддәс бер бурычыдыр. Җомганың фарызлыгына:
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ

Җомга намазы кемләргә фарыз, кемләргә фарыз түгел? Фикыһ китабларында шушы рәвешле аңлатылган:
1) Ир кеше. Хатынларга фарыз түгел.
2) Балигъ булу.
3) Гакыллы булу.
4) Азад һәр кеше булу. Колларга, тоткындагыларга фарыз түгел.
5) Мөкыйм (مقيم) булу.
6) Сәламәт булу. (0926)
7) Күзләре сәламәт булу.
8) Аяклары сәламәт булу.
Менә саналган сигез төрле кешегә җомга намазы фарыз түгел. Әмма укый алалар икән, җомга укулары дөрест.
Җомга намазын укыр өчен берничә шартлары бар:
1) Мисыр Ислам шәһәре диерлек шәһәр яки авыл.
2) Хөкүмәт тарафдан яки мөфти тарафдан рөхсәтле кеше имам булмак.
3) Җәмәгать имамдан башка иң азында өч кеше булмак.
4) Һәркем кереб укырлык рөхсәтле гыйбадәтханә булмак.
5) Вакыт зоһер.
6) Хөтбәдән морад вәгазь-нәсыйхәт булмак.
Фикыһ китабларында күрсәтелгән бу алты төрле шартларның һәркайсы табылуы күб җирләрдә мөмкин түгел. Бу хакда әүвәлге вакытда да галимләр тарафындан күбтөрле сүзләр, фикерләр булган мәсҗед булмаган җирләрдә.
Рәсүлулла һәм хәлифәләр заманындан бирле дәвам итеб килгән Ислам шигарене, Ислам галәмәтене һәртөрле сүзләр сөйләнгән.
Бервакытда эшдән бушаган, мөмкинлеге булган адәмләребез җомга көнен хөрмәтләб, искә алыб, аруланыб (чистарыныб – А.Х.), гаҗизлек, йитешсезлек белән булса да, Аллаһы хозурында бәндәчелек кылыб, шушы гыйбадәтне “җомга” укуны тиеш диб сөйләүче галимләребез булган.
(0927) Аллаһы Тәгалә хәзрәте Коръәндә әйтә:
ان الصلوة تنهى عن الفحشاء و المنكر
(Ганкәбут, 45 аят). Аллаһы ризалыгы өчен чын ихласдан укылган намаз бөтен начар вә бозык эшләрдән тыяр, ди.
من ترك الجمعة من غير عذر فليتصدق بدينار، فإن لم يجد فبنصف دينار
Хәзрәт рәсүлнең бу сүзендән беленә, җомганың казасы: бер кеше гозерсез җомганы үти алмаса, бер динар садака бирсен, әгәр бер динарны табмаса, ярты динар бирсен, ди.
(0928) Намаз хакында булган вәгъдәләрне намазның фазыйләте һәм намаз калдыруның никадәр зур гөнаһ икәнен искә төшерсәк, намаз хакында никадәр сөйләнсәк дә һаман аз булачак. Намазның фарызлыгы хакында Аллаһы әйтә:
ان الصلوة كانت على المؤمنين كتابا موقوتا
(сүрәи “Ниса”, 153 аят). Намаз мөэминләргә вакытлы фарыз ителде (бурыч булды).
Һәм рәсүл әкрам (сгс)нең намаз хакында хәдисләре бик күб. Җөмләдән берсе:
الصلوة عماد الدين فمن اقامها فقد اقام الدين و من تركها فقد هدم الدين
Намаз диннең терәге, Исламның бинасы. Берәү намаз укыса, динне торгыза, ди, (торгызды). Әгәр берәү намаз укымаса, динне һәлак итде, ди.
(0929) Җомга намазын уку рәвеше: әүвәл һәрвакытда укыла торган Тәхиятель мәсҗед намазы, дүрт рәкәгать сөннәт, соңында хөтбәдән соң ике рәкәгать фарыз. Һәм фарыз

соңында дүрт рәкәгать сөннәт.
Җомга намазы хакында бик күб сораулар булырга мөмкин. Бу хакда сораулары булыб, белергә-теләргә кешеләр булса, минем янга керерләр, шунда сөйләшербез.
Җомга намазы хакында пәйгамбәр Ходадан шушындый сүзләр риваять кылына:
مَنْ تَرَكَ ثَلَاثَ جُمَعٍ تَهَاوُنًا بِهَا، طَبَعَ اللَّهُ عَلَى قَلْبِهِ
Ягъни: бер кеше, әһәмият бирмичә, йиңелгә санаб, 3 җомганы калдырса, Аллаһы Тәгалә ул адәмнең күңелен каралтыр, ди.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Олы яшькә җитеб, чәченә-сакалына чал кереб, пенсиягә чыгыб да, үзен мөселман диб, иман әһеле санаган адәмгә мондан да зур кимчелек һич булырга мөмкин түгел. Шәһәрдә торучыларыбыз, сау-сәламәт булган кешегә шәһәрнең һәртөрле урынларына транспортлар йөреб торган вакытда һичбер гозерсез атнага бер мәртәбә җомгага да килмәсә. Үлемгә ышанса да, Кыямәт көненә Аллаһы хозурына баруына иманы камил түгел диб әйтүдән башка чара калмый. Җомга көнен хөрмәт итеб, аруланыб, пакъләнеб, ару киемләр киеб, мәсҗедгә килсә, азмы-күбме вәгазь-нәсыйхәт ишетсә, дуст-ишләре, туган-кардәшләре, мөселманлар белән күрешеб, мөселманлар (0930) берлекдә гыйбадәт кылыб, дөньяви-ахирәви теләкләр дә теләб, күбчелек белән дога кылыр. Дөнья шөгыльләрен ташлаб, Аллаһы хозурына баруны искә төшереб, сәййидель әйам булган мөбарәк көндә – җомга түрләрендә генә булса да, гыйбадәт белән шөгыльләнү мөселманлыгыбызның зур билгесе булыб, Аллаһы кашында зур әҗер вә сәвабларга ирешүебезгә сәбәб булачак. Инде атнага бер генә мәртәбә дә, үзенең бәндә икәнчелеген белми, башын сәҗдәгә куймаса (гозерсез), әлбәттә, бу кешенең мөселманлыгында зур кимчелек булачак.
Риваятьләрдә җомга намазына хәзер булучылар хакында шушындый сөенечле хәбәрләр сөйләнә: Аллаһының бер төркем рәхмәт фәрештәләре җомга кичәсендә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләрендән: и Бари, җомга көнендә пакъләнеб, җомга намазына барган колларыңның хаталарын гафу ит диб, кылган гыйбадәтләрен, теләкләрен кабул ит диб, – киче вә көндезен дә Аллаһыга ялварыб дога кылалар икән.
Аллаһы тарафындан җомга көнендә ихлас күңелләре белән кылган догалары, гыйбадәтләре мәкбуль булыб, хата вә кимчелекләре гафу ителеб, күңелләрендә иман нуры булыб, җомгага килгән адәмләргә нинди зур сөенеч! Пенсиягә чыгыб, эшдән бушаныб да, һичбер гозерсез җомгага килмәгән (үзен мөселман диб санаган) картларга нинди зур үкенеч. (0931) Бәгъзе бер шундый адәмләр ишетелә, пенсиягә чыгыб да, үзләренең шул яшькә җитеб, сау-сәламәт булуына шөкранә кыласы урында, эчкелек белән мөбтәла булган кешеләргә дөнья Ахирәтдә үкенеч, кайгы, хәсрәт, шундый күңелсез юлда булган картларыбыз өчен. Һәм яшьләребезгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тәүбә, истигъфар кылыб, яхшы юлга аяк басарга насыйб итсен.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Бәгъзе бер адәмләр тиз-тиз генә җомганың сөннәтен укыб, тәсбих тартырга ашыгалар. Тәсбих тартмый калабыз диб, намазга кимчелек китерергә һич ярамый. Намазда тәсбих дә бар, тәкбир дә бар, хәмде дә бар. Тәсбих тартырга теләгән адәмгә кеше чыгыб беткәнче дә тәсбих тартырга мөмкин. Тагын да искә алырга тиеш бер хәлебез булса – ул да, мөхтәрәм җәмәгать, атнага бер килгән җомгабыздан күбрәк файда, күбрәк сәваб, киләчәгебез өчен күбрәк азык хәзерләргә тырышырга кирәк. Намаз соңында артык кысталмасак, эшкә бара торган адәмләр булыб, эшебезгә соңга калмаслык булсак, Аллаһының бер әмерен, бер боерыгын үтәсәк, нур өстенә нур булыб, Кыямәт көнендә йөзебез ак булуга сәбәб булачак.
Аллаһы Тәгалә Коръәндә “Әгъраф” сүрәсендә әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ
Ягъни: һәркайчан Аллаһының аяте укылса, бөтен эшләрегездән тукталыб, Корънне тыңлагыз, ишетегез, шает ки Аллаһының рәхмәтенә ирешерсез, ди.
Артык гозерләребез булмаса, Корън укыганны ихлас тыңлаб утырсак, Аллаһының тагын да бер боерыгын (0932), әмерен үтәгән булыб, Аллаһының рәхмәтенә ирешүебезгә сәбәб булыб, тагын да зуррак әҗер вә сәваблы булыр идек. Мин сезгә Аллаһының әмер вә боерыкларын, пәйгамбәребезнең сүзләрен хәлемдән килгән кадәр сөйләб күрсәттем, аңлаттым. Тоту, тотмау һәркемнең үз ихтыярында.
Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб, мөмкин кадәр ишеткән вәгазьләребез белән гамәл итеб, Аллаһы хозурына ак йөз белән барырга насыйб булсын.
(0934) Сүрәи "Ниса", 154:
ان الصلوة كانت على المؤمنين كتابا...
Сүрәи "Бәкара", 238:
حافظوا على الصلوات و الصلوة الوسطى ...
Сүрәи "Исра", 78:
اقم الصلوة لدلوك الشمس الى عسق الليل...
Сүрәи "Рум", 17:
فَسُبْحَانَ اللَّهِ حِينَ تُمْسُونَ وَحِينَ تُصْبِحُونَ
وَلَهُ الْحَمْدُ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَعَشِيًّا وَحِينَ تُظْهِرُونَ
Сүрәи "Һуд", 114:
و اقم الصلوة طرى النهار و زلف من الليل...
Сүрәи "Каф", 39:
فاصبر على ما يقولون و سبح بحمد ربك قبل طلوع الشمس...
Сүрәи "Та-hа", 135:
و قبل المعرب...
Биш намазның фарызлыгына Корънда дәлилләр.
(0936) 14. Сәламәтлек хакында хәдисләр – 149.
6нчы сентябрьдән сөйләнгән вәгазьләр.
Сөйләнгән вәгазьләр: 1968 нче ел, 6 нчы сентябрь; (Рамазан) 1968 нче ел, 6 нчы декабрь; (Рамазан) 1968 нче ел, 20 декабрь: Ахыр җомга.
(0937) Гайбәт, ялган сүз сөйләү, кешегә яла ябмак, ялган, гяваһ булмак вә башка олугъ гөнаһларны эшләмәк. Руза максуд булган тәһзиб, әхлак холыкларны сафлау вә яманлыкдан пакъләү кеби гүзәл сыйфатлар тәхсыйл итү булдыкдан.
Әлбәттә, югарыда әйтелгән яманлыклар рузага зарар бирер (тарикат әһелләре каршында рузалары ачылыр).
(0938) 1968 нче ел, 6 нчы сентябрь / 1388 нче Һиҗри, 13нче Җәмадил ахир, җомга көн.
Ихлас күңелләр белән җомга гыйбадәтенә җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Мөхтәрәм җәмәгать! Миңа уйламаганда гына Уфа шәһәрендәге Диния нәзарәтебезгә барырга тугъры килде. Кыска гына сәфәрдә күб кенә адәмләр белән күрешеб сәламләшергә тугъры килде.
Хосусый һәм гомуми рәвешдә казан мөселманларына күб кенә адәмләр дога укыныб, сәлам табшырдылар. Шул җөмләдән Диния нәзарәтенең рәисе мөфти Шакир хәзрәт һәм казый Камил хәзрәт казан мөселманларына саулык-сәламәтлек, тынычлык теләб, дога кылыб, сәлам табшырырга кушдылар: Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә

бәрәкатуһу... Шулай ук Уфа мөселманлары һәм һәр тарафдан килгән имам һәм мәхәллә кешеләре – һәркайсы казан мөселманларына сәлам укырга кушдылар. (Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу...). Хосусан мөфти хәзрәт казан мөселманларындан үзенә күрсәткән хөрмәт вә ихтирамларындан мәмнун вә разый булыб, кат-кат догалар кылды.
Мөхтәрәм җәмәгать! Анда баруымның сәбәбе, берничә төрле хосусый йомышларым булыб:
1) Диния нәзарәте тарафындан бирелгән мәншурәнең (рөхсәт кәгазенең) мөддәте тулганлыкдан шуны озайту (озынайту – А.Х.);
2) Әлхәмделилләһи Раббел галәмин, җенабе Хакның ярдәме, мәхәллә мөселманларының догасы (0939) беркетендә елда өч ай сау-сәламәт, тыныч кына имамәтчелек ләвәзимен үтәдек. (Кимчелекләр булгандыр, бән дә хатадан хали түгел). Һәркайсыгыз беләсез, без барыбыз да олугъ яшькә җиткән, сәламәтлекләребез уртача гына булыб, еллык ял итү хакында рөхсәт сорау иде.
Канун һәм шәригать тарафыннан рөхсәт кылынган эшкә безнең тарафдан һичбер төрле манигъ юк диб, дога кылыб, ялга китәргә рөхсәт итделәр. Мулла Сафиулла абзый ял итде, Фәйзрахман, инша Алла, шушы көнләрдә кайтыб җитәр. Инде нәүбәт миңа килде. Шушы ял итүебез яхшы ният белән булса, зур фазыйләтле, әҗерле гамәлләрдән булачак.
1. Һәрбер инсанның вазыйфасы булган тәгъзыйм өлүһият, тәһзиб инсаният (شكر النعمت).
Аллаһы биргәнләренә шөкранә кылу, шуның кадерен белү. Аллаһы Раббел галәмин безне бик төрле нигъмәтләр белән сыйлаган, Аның зур нигъмәтләрнең берсе – бөтен әгъзаләребезне төгәл, камил итеб, сәламәтлек нигъмәте белән хөрмәтләгән. Әгәр дә сау-сәламәт булсак, сәламәтлегебезне саклау, сәламәтлегебезгә кимчелек килсә, авыру булсак, шул авыруны җибәрергә, сәламәтләнергә тырышу һәрберебезнең вазыйфасы булыб, шуны тиешенчә үти белсәк, шушы шөкрен нигъмәт булачак инде. Боларның киресенчә үтәсәк, бу Аллаһының безгә биргән нигъмәтләренә көфран нигъмәт булыб, Коръән Кәримдә:
وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ
Минем нигъмәтләремә шөкранә кылсагыз, нигъмәтләрне артдырыб бирәм. Әгәр Минем нигъмәтләремә көфранә кылсагыз (0940), минем газабым бик каты булыр, ди
2. Дөньяга килүебезгә сәбәбче булган, тәрбияләб үстергән ата-аналарыбызның каберләрен зиярат, аларга догалар кылу җенабе Хакның
و بالو الدين احسانا
сүзенә мисдак булыб, Аллаһының бер әмерен үтәгән булыб, ата-аналарыбызга изгелек кылу булачак.
3. Һәркайсыбызның чит шәһәрләрдә ерак вә якын кардәшләребез, туганларыбыз бар. Шушы якын кардәшләребез белән саләт кылу, хәлләрен белү Коръән хөкеменә бина, тагын бер изге гамәл кылган булырбыз, чөнки җенабе Хак “Ниса” сүрәсендә әйтә:
وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَاناً وَذِي الْقُرْبَى وَالْيَتَامَى وَالْمَسَاكِينِ وَقُولُوا لِلنَّاسِ حُسْناً وَأَقِيمُوا الصَّلاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ ثُمَّ تَوَلَّيْتُمْ إِلَّا قَلِيلاً مِنْكُمْ وَأَنْتُمْ مُعْرِضُونَ
ди. Ата-аналарга һәм якынлык иясе булган туганларыгызга изгелек кылу белән боера, куша. Хәлләрен белү, зиярат кылу, һәркайсы гамәлес салихат җөмләсендән булачак.
4. Аллаһы Кәрим “Әл-Гыймран”да әйтә:
قَدْ خَلَتْ مِن قَبْلِكُمْ سُنَنٌ فَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ فَانظُرُوا كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الْمُكَذِّبِينَ
Сәяхәт кылыгыз, гыйбрәт алыгыз, пәйгамбәрләрне ялганга тоткан адәмләрнең соңгы ничек булды, ди. Һәм әүвәлдәге кавемләрнең хәлләре ничек булды, ди. Менә мөфәссирләр бу аятьдә җәгърафия гыйлеме өйрәнүгә ишарә бар, диләр. Һәм рәсүл әкрам:
سياحة امتي كالجهاد في سبيل الله

Минем өммәтемнең сәяхәт кылулары Аллаһы юлында сугыш кылучылар кеби, ди.
و سافروا تصحوا
Менә шушындый изге теләкләр: гыйбрәт алу, яхшылардан үрнәк алу, гыйлем артдыру, галимләр белән күрешү. Менә шушы рәвешле сәяхәт кылуларыбыз дөньяви, ахирәви эшләребезне (0941) эченә алган фазыйләтле эшләрдән булачак.
Аллаһы Раббел галәмин илләребезгә, җанларыбызга тынычлык, тәнләребезгә сәламәтлек биреб, йортларыбызда торучыларга һәм сәфәрдә йөрүчеләребезгә һәртөрле афәт вә бәла-казалардан әмин булыб, бөтен мөселманлар бер җан, бер тән булыб, шушы мәсҗедебездә күб елларга кадәр гыйбадәт кылырга насыйб булсын.
رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ
ربنا تقبل دعائنا انك السميع العليم
(0942)
7. 1968 нче ел, декабрь 6 нчы көне / 1388 нче Һиҗри, 16 нчы Рамазан, җомга.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Мөбарәк Рамазан аен хөрмәт итеб, (سمعنا و اطعنا) диб, и Аллаһы, без Синең әмерләреңне ишетдек дә буйсындык диб, ихлас белән руза тотучы мөхтәрәм мөселман кардәшләрем!
Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең сәламе вә рәхмәте вә бәрәкате барчаларыбызга насыйб булсын иде. Аллаһы Раббел галәмин кашында һәрбер гыйбадәтләребез мәкбул булыб,
سلام عليكم طبتم فادخلوها خالدين
дигән . Ягъни: җәннәт сакчылары тарафында әйтелер: сез Аллаһының әмерләренә итагать кылыб, гөнаһ керләрендән, пычракларындан пакъ булдыгыз. Инде сезнең күңелегезгә хуш булмаган, күңелсез хәлләрдән пакъ булганыгыз хәлдә Аллаһының мәңгелек нигъмәт йорты булган җәннәтгә керегез, дигән бәндәләре җөмләсендән булырга Аллаһы насыйб итсен.
Мөхтәрәм җәмәгать! Рәсүл әкрам (сгс) әйтә:
اغتنم خمسا قبل خمس شبابك قبل هرمك وصحتك قبل سقمك وغناك قبل فقرك وفراغك قبل شغلك وحياتك قبل موتك رواه الحاكم وقال صحيح على شرطهما وصححه الألباني في صحيح الترغيب والترهيب.
Рәсүлулла әкрам хәзрәте безгә биш нәрсәне биш нәрсәдән алда, ганимать белеб, кадерен белеб, вакытында файдаланыб калырга куша. Эш үткәннең соңында үкенү белән хәсрәткә калу белән файда итеб булмый. (0943) Үлем килгәнгә терек (тере – А.Х.) вакытыбызны кадерен белеб, Ахирәт тереклегенә чын күңелебез белән ышанабыз икән, шуңа хәзерлек күрергә куша. (استعد للموت قبل نزول الموت), ди. Сәламәтлегебезне авыру килүдән әүвәл, буш вакытыбызны һәртөрле мәшәкать килүдән әүвәл, яшьлегебезне картлыкдан әүвәл, байлыгыңны фәкыйрьлекдән әүвәл.
Әлхәмделилләһи сау-сәламәт, Аллаһы кашында мөбарәк булыб, зур әҗер вә сәвабларга ирешдерә торган Рамазан аеның соңгы яртысына килеб җитдек. Инде һәркайсыларыбыз төн артындан көн килүенә ничек ышансак, тереклек артындан үлем килүенә барыбыз нык ышанабыз. Инде шулай булгач, кайчан үләсебез , кайда үләсебез, ни рәвешле үләсебезне беребез дә белмибез. Киләчәк Рамазан аен әллә күрәбез, әллә юк, без генә түгел, яшьләребез дә үлеб китә. Бүгенге өстебезгә килгән Аллаһының рәхмәтенә, Аллаһының ризасына, мәңгелек сәгадәткә ирешдерә торган шушы мөбарәк көнләрдә файдаланыб калу, һәрбер мөэмин бәндәнең бурычыдыр.
Рәсүл әкрам (сгс) әйтә:
الصلوات الخمس, والجمعة إلى الجمعة, ورمضان إلى رمضان كفارات لما بنينهما إذا اجتنبت الكبائر
Ягъни: биш вакыт намаз уку, җомга намазларын уку, Рамазан рузасы. Шушы ике арада

булган вак гөнаһларның бетүенә сәбәб булыр, ди, әгәр дә олугъ гөнаһлардан саклансак.
Тагын да рәсүлулла әйтә:
مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ
(0944) Әгәр бер кеше, чын күңелендән ышаныб, Аллаһыдан зур сәваблар өмед итеб, Рамазан рузасын үтәсә, гөнаһларының кичелүенә (кичерелүенә – А.Х.) сәбәб булыр, ди.
Тагын да җенабе Хак әйтә:
الصوم لي و انا اجزى به
Руза тоткан бәндәләргә бирелгән әҗер вә сәвабларның хисабын Аллаһы Тәгалә Үзе генә белгүче, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Гәрчә мәгълүмне тәгълим, мәгруфне тәгъриф кебек булса да, Рамазан аеның хасиятләре хакында тагын да беркадәр исегезгә төшерәм. Рәсүл әкрам әйтә:
فمن صام نهاره و قام ليله اي ادى التراويح ايمانا و تصديقا كان كفارة لما مضى و خرج من ذنوبه كيوم ولدت امه
Ягъни: бер кеше Рамазан аенда көндезләрен руза тотыб, кичләрен Тәравих намазларын үтәсә, халәл ризыклар белән ифтар кылса, гөнаһлардан тәүбә кылса, анадан яңа туган сабый бала кеби гөнаһларындан пакъләнер, ди.
Тагын да Аллаһының нигъмәт йорты булган җәннәт, халь теле белән әйтер икән: йә Рабб, минем нигъмәтләремне дүрт төрле адәмгә насыйб кыл, шуларны минем нигъмәтләрем белән хөрмәтлә диб әйтер икән:
1) ихлас күңелләре белән Коръән укыб, Коръән хөкемләре белән гамәл итүчегә;
2) телен тиешсез сүзләрдән, начар гадәтләрдән телен саклаучы адәмләргә (حافظ اللسان);
3) (مطعم الخعان) ачларны туйдыручылар, хосусан Рамазан аенда руза тотучыларны ифтар кылдыручылар, ди . Шушы дүрт төрле сыйныфны җәннәт берлә хөрмәтләб, шуларга гашыйкмы диб әйтер, ди.
(0945) Тагын да ифтар мәҗлесләре хакында хәзрәт рәсүл әйтә:
من فطر صائما او جهز عازيا فله مثله (مثل) اجره
Бер кеше бер руза кешене ифтар кылдырса, яисә Аллаһы юлында сугыш кылучыны җиһазландырса: кием-салым беләнме корал беләнме, менә шушы ифтар кылдыручыга фи сәбилилләһ булган адәмгә, ярдәм итүчегә, - шуларга булган кадер, сәваб булыр, ди. Ифтар мәҗлесләрендә руза тотучыларыбыз ни кадәр күбрәк булса, димәк, мәҗлес уздыручыга сәвабы тагын да күбрәк булачак икән.
روى عن النبى صلصم قال:
إذا كان يوم القيامة يجيءُ قوم لهم أجنحة كأجنحة الطير فيطيرون بها على حيطان الجنة , فيقول لهم خازن الجنة من أنتم؟ فيقولون نحن من أمة محمد عليه الصلاة والسلام فيقول هل رأيتم الحساب ؟ فيقولون لا , ثمَّ يقولُ ثانيا هل رأيتم الصراط؟ فيقولون لا, ثمّ يقول بم وجدتم هذه الدرجات ؟ فيقولون عبدنا الله سرًّا في دار الدنيا وأدخلنا الجنة سرًّا في الآخرة
Ягъни: рәсүл әкрам хәзрәтләрендән шул рәвешле риваять кылына: Кыямәт көнендә бертөрле кавем килер. Җәннәт эчендә кошлар кебек сәйр вә тамаша кылыб очыб йөрерләр. Җәннәт сакчылары алардан сорарлар: сез хисабда, мизанда булдыгызмы? – диб, – Һәм сиратда булдыгызмы? – диб. Болар җаваб бирерләр: без хисабны, сиратны күрмәдек, диб. Нинди гамәлләр сәбәбле бу дәрәҗәне табтыгыз? – диб. Без дөньяда вакытда Аллаһыга сер булган, яшерен гыйбадәт кылдык, чөнки руза гыйбадәте күзгә күренми торган яшерен гыйбадәт. Шуның өчен Аллаһы безне яшерен рәвешдә хисабсыз, сөәлсез (сораучыз – А.Х.) җәннәткә кертде диб әйтерләр, ди. (0946) Алабызмы, юкмы? Аллаһыдан башка берәүгә дә мәгълүм түгел.
Хәзерге көнебездә, хәзерге сәгатебездә файдаланыб калу, киләчәгебездә файдалы эшләр кылырга тырышу һәр гакыл иясенең беренче вазыйфасы булырга тиеш. Барыбыз да көн артындан төн булачагына нык ышанган кебек, терелек соңында үлем киләсенә барыбыз

ышанабыз.
كل آت قريب. ان الساعة لا تية لا ريب فيها و لكن اكثر الناس لا يؤمنون.
Шулай ук, һичшиксез, Кыямәт көнендә Аллаһы хозурына җыелачакбыз. Шуның өчен пәйгамбәребез әйтә: (استعيد) (әзерләнегез – А.Х.).
Рәсүлебезнең бер мөбарәк хәдисе...
Мөхтәрәм җәмәгать! Бигрәк дә Рамазан Аллаһы каршында мең айдан изгерәк. Хисабланган, Кадер кичәсе булган Рамазан шәрифнең 3нче унына аяк басабыз. Хәзрәт рәсүл әкрам вә әсхабе кирам Рамазанның соңгы унында гыйбадәтләрен, яхшылыкларын тагын да артдыра төшкәннәр. Инде без дә бүгенге көндә исәнлегебезне, тынычлыгыбызны ганимәт белеб, начар гадәтләребезне ташлаб, сәвабларны мөмкин кадәр күбрәк алырга тырышу һәрбер мөэмин камилнең бурычыдыр.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга мөбарәк айда вәгъдә кылынган хисабсыз әҗер-сәвабларга ирешергә насыйб итсен.
(0947) 1969 нчы Милядия, 28 нче ноябрь / 1389 Һиҗри, 18 нче Рамазан, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ерак вә якын җирләрдән мәсҗедгә мәхәббәт итеб пәйгамбәр Мөхәммәд (гм)гә, чын күңелдән өммәт булуны теләб, ихлас күңел белән руза тотыб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Кылган гыйбадәт вә изгелекләребезгә кат-кат әҗер вә сәваблар вәгъдә кылынган, мөбарәк Рамазан аенда кылган һәртөрле гыйбадәтләребез җенабе Раббел галәмин хозурында мәкбуль булыб, Хисаб көнендә, Җәза көнендә сәвабе җәзил (күп – А.Х.), вә әҗре газыйм насыйб итсен. Рамазан аебыз вә җомга көнебез мөбарәк булыб, киләчәкдә дә мөбарәк айларны вә мөбарәк көнләрне шадлык белән күрергә насыйб вә мөйәссәр кылсын. Амин.
Мөхтәрәм җәмәгать! Һәркайсыларыбызга мәгълүм, заман, вакыт өчкә бүленә: ( زمان ماضي، زمان حاضر، زمان مستقبل). Үткән заманыбыз, хәзерге заманыбыз һәм киләчәк заманыбыз. Никадәр үткән заманыбыз өчен, кайтарыр өчен никадәр тырышсак да,миллионлар белән мал сарыф итсәк дә, һичкемгә аны кайтару мөмкин түгел. Үткән – беткән. Киләчәк заман шулай ук безнең кулыбызда түгел. Белмибез, күрә ...(ахыры юк – А.Х.)
(0948) Инде мөхтәрәм җәмәгать! Руза гыйбадәтендән иң зур максад нәфескә хуҗа булыб, аны яхшы гадәтләргә күнектерү, начар гадәтләрдән, шәригать тарафындан тыелган, инсаният галәменә зарарлы булыб табылган, мәкруһ-хәрам эшләрдән саклану, рухыбызны, күңелебезне тәрбия кылудан гыйбарәт.
Хәзрәт рәсүлнең бу хакда шундый сүзләре бар:
رب قائم حظه من قيامه السهر و رب صائم حظه من صيامه الجوع و العطش
Ягъни: шундалаен төнләрен калдырыб гыйбадәт кылучылар бар. Аларның гыйбадәт кылулары бары йокы калдырулары гына, ди. Һәм шундаен руза тотучылар бар, аларның рузасы ач торудан гына гыйбарәт, ди. Ягъни руза тотыб да, телләребезне, дөньябызга, Ахирәтебезгә файдасы булмаган. Сүзләрдән сакларга тырышу, гайбәт, ялган, сүз йөртү, яла ягу, бөһтан – болар башка вакытларда хәрам булган начар сыйфатлар. Менә болар бигрәк дә руза вакыт кылган гамәлләребезне юкка чыгара торган, әлбәттә, тыелырга тиешле, лязим булган эш. Ләкин, җәмәгать, кызганычка каршы, мәсҗедебездә шундый гадәтләр күренә. Мәсҗед әүвәлге заманындагы кебек, тәмәке тартыб, кеше гаебен тикшереб, кешедән көлеб утыра торган каравыл урыны түгел. Мәсҗед – гыйбадәт йорты. Мәсҗедебезнең идарәханәсендә дә кычкырыб көлү, кирәкмәгән сүзләр сөйләнергә тиеш түгел. Хәтта мондый начар гадәтләр мәсҗеднең әхатәсендә (ара-тирәдә – А.Х.), ишек алдында да булырга тиеш түгел. Бу эшләр һәркайсы мәсҗеднең кадерен-хөрмәтен

белмәгәнлекдән килеб чыккан начар гадәтләр. Мондый эшләр һичбер вакытда булырга тиеш түгел.
(0949) Инде Ислам дине бөтен гали, күркәм сыйфатларга чакыручы, өндәүче бер дин булганлыкдан, үзләрен шушы юлда диб белгән адәмләр һәрбер начар, күңелсез гадәтләрдән ерак булырга тиеш.
Рәсүл әкрам хәзрәте әйтә:
ان المؤمن ليدرك بحسن الخلق درجة القائم الصائم
Күркәм холкы сәбәбле мөэмин көндезләрен руза тотыб, төнләрен намаз укыб үткәргән кебек булыб, шулар табкан, шулар ирешкән дәрәҗәгә, сәвабларга ирешер, ди.
قل الخير فالا فسكت
Матур булган, хәерле сүзләрне сөйлә, я булмаса, тик тор. Дөньяңга Ахирәтеңгә файдасыз, әдәбсез сүзләрне сөйләгәнче тик торуың хәерлерәк, ди.
Инде бер адәм синең ачуыңны китерердәй сүз әйтсә дә, син үзеңә-үзең әйт: мин рузада, синең белән сүз көрәшдереб рузама зарар китерер, рузамның сәвабын киметәм диб әйт, ди.
Җенабе Раббел галәмин барчаларыбызга мөбарәк айның хөрмәтен белеб, киләчәгебез өчен зур өлеш алыб, кылган гамәлләребезнең сәвабын киметә торган, җилгә очыра торган начар гадәтләрдән ерак булыб, пәйгамбәребез тарафыннан хәбәр бирелгән зур әҗер вә сәвабларга ирешергә насыйб булсын. Амин.
(0950) 1968 нче ел, 20 нче декабрь / 1388 нче Һиҗри, 30 нчы Рамазан, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ихлас күңел белән руза тотыб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Рамазан аеның ахыр җомгасы барчаларыбызга мөбарәк булсын!
Мөхтәрәм җәмәгать! Мөбарәк Рамазан ае үтде. Ул ай Шәһре рәхмәт диб аталган иде. Шәһре шәфкать, Шәһрель ухуввәт, Шәхрель имтихан, Шәһрет тәрбия диб аталган иде. Шәһрель иҗтимагъ, Шәһрель иттифак диб аталган иде. Ул әүвәл Аллаһының рәхмәте, уртасы, Аллаһының мәгъфирәте, ахыры утдан азад була торган ай диб аталган иде. Гыйбадәт ае, Имтихан ае, Тәрбия ае дигән идек. Чындан да гыйбадәт, Сынау ае, Тәрбия ае икәнен мәсҗедләребездә күзләребез белән күрдек. Мәсҗедебез гыйбадәт кылучылар белән тулыб торды. Чын мөселман адәмләр белән начар юлда булган адәмләр – һәркайсы сыналды, аерылды. Кардәшлек, дустлык, бердәмлек ае дигән идек. Бу айда барчаларыбыз бертуган кебек, чын туганларча, дустларча мәсҗедкә җыелыб, (0951) күмәк рәвешдә Тәравих намазлары укыдык. Бөтен мөселманлар бердәй булыб, ихлас күңел белән дөньябыз, Ахирәтебез төзек булсын диб, җәмәгать белән догалар кылдык. Шушы рәвешле күб җәмәгать белән Тәравих укуларыбыз, меңләрчә мөселманлар бергә җыелыб догалар кылуыбыз, менә бу әйткәнләребезнең шаһидлары.
Әлхәмделилләһи Раббел галәмин, шушы мөбарәк айны зур изгелекләр белән динебез кушканча, пәйгамбәребез кушканча үтәдек. Шушы кылган гыйбадәтләребезнең чындан да чын күңелдән булганмы? Чындан да зур сәвабларга ирешдерә торган руза гыйбадәтебездән күңелләребезне, йөрәкләребезне пакъли алдыкмы? Нәфесләребезгә чындан да хуҗа була алырга гадәтләндекме?
Шактый гына вәгазь-нәсыйхәтләр ишетдек. Коръән Кәримдә Аллаһының әйткәне:
و ذكر فان الذكرى تنفع المؤمنين
Ягъни: вәгазь-нәсыйхәт кыл. Вәгазь-нәсыйхәт мөэминләргә файда бирер. Алар вәгазь-нәсыйхәтне тотарлар дигән адәмләр җөмләсенә керә алырбызмы? Һәм “Ганкәбут”

сүрәсендә 45 аятдә Аллаһы Кәримнең:
ان الصلوة تنهى عن الفحشاء و المنكر
дигән сүзенә мөафыйк булыб, укыган намазларыбыз безне бозыклык, начар гадәтләрдән тыямы?
Инде Рамазан чыкканның соңында азмы-күбме ишеткән вәгазьләребез файда биреб, шуларны исдә тотыб, начар, күңелсез гадәтләребезне ташлаб, форсатыбыз булган сау-(0952)сәламәт булганларыбыз җәмәгать намазына дәвам итсәк, яки өйләребездә укысак
طاعة بعد الطاعة دليل الرضوان
Гыйбадәт соңында гыйбадәт – Аллаһының ризалыгына (гыйбадәтләрнең кабуллыгына) сәбәб, дигәнләр. Шушы сүзгә бина, һичшиксез, әйтә алабыз: тоткан руза гыйбадәтләребез, намаз гыйбадәтләребез Аллаһы кашында мәкбуль ителсен, һәм зарилык белән кылган тәүбәләребезнең, догаларыбызның кабуллыгына ишарә булачак. Рамазан аенда руза тотыб, намазлар укыб, Рамазан чыгу белән, начар, бозык, Аллаһы тыйган гөнаһлар эшләргә кереб китсәк, менә бу вакыт:
معصية بعد الطاعة دليل الخذلان
Ягъни: күб яхшылыклар кылыб, тәүбә-истигъфар кылыб, гөнаһдан арынганның соңында яңадан гөнаһ булган, динебез тарафындан тыелган начар эшләргә ябышу – дөнья Ахирәтдә хурлыкка төшүнең галәмәте, дигәнләр.
Чындан да мунча кереб, тәнләребезне кердән пакъләб, сафлаб, чиста киемләр кигән адәмнең пычракка кереб батуы нинди күңелләргә авыр булган, күңелсез хәл булса, инде ихлас күңелләребез гыйбадәт кылыб, рузалар тотыб та, яңадан шундый гөнаһ эшләргә кайтсак, Аллаһы сакласын.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең “Игъраф” сүрәсендә 179нчы аятендә зикер ителгән, зур үкенечгә калган адәмләр җөмләсендән булуыбыз ихтимал:
وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِنَ الْجِنِّ وَالإِنْسِ لَهُمْ قُلُوبٌ لا يَفْقَهُونَ بِهَا وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لا يَسْمَعُونَ بِهَا أُولَئِكَ كَالأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ أُولَئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ
ди. (0953) Тәхкыйк, шундый адәмләрдән, җенләрдән җәһәннәмгә керерләр. Алар күңелләре, калебләре (йөрәкләре – А.Х.) белән Хакны белмәсләр, белергә тырышмыслыр, күзләре булса да, Хакны күрмәсләр, игътибар итмәсләр, колаклары булса да, Хакны ишетмәсләр, ягъни вәгазь-нәсыйхәтне ишетмәсләр, бу сыйфатдагы адәмләр. Хәйванлар бәлки алардан күб азгынрак, чөнки хәйванларда үзләренә зарарлы булган нәрсәләрдән сакланыр өчен күңелләре, күзләре, колакларын сарыф итеб, үзләренә зарарлы нәрсәләрдән саклpoints.
Аллаһы Раббел галәмин барчаларыбызны мондый хәлләргә калудан сакласын. Дога кылыйк:
اللهم أرنا الحق حقا وارزقنا اتباعه ، وأرنا الباطل باطلا وارزقنا اجتنابه ، ولا تجعله ملتبسا علينا فنضل ، واجعلنا للمتقين إماما
И Аллаһы, барчаларыбызга хаклыкны күрергә, хак диб белеб, хаклыкка иярергә, хак юлга гомер итәргә насыйб итсен. Батыйль, бозык юлны батыйль диб белергә, андан сакланырга насыйб итсен иде.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мөбарәк гаед Фитыр көнен шадлык белән күрергә. Тынычлык, татулык нигезендә матур итеб каршы алыб, матур итеб үткәрергә насыйб булсын.
Җәмәгать! Гаед намазында тыгызлык булыр, эссе булыр. Пәйгамбәребезнең
احب للناس ما تحب لنفسك
дигән сүзен исдә тотыб, үзебезгә аулак килсә дә, үзебездән башкаларга авырлык китермәскә тырышыйк. Бик кыска вакыт уңайсызлыкка түзсәк, Аллаһы Раббел галәмин

хәзрәте безне Кыямәт көнендә (0954) булачак авырлыклардан халас (коткарыр – А.Х.), нәҗат бирер.
Җенабе Хак Рамазан шәриф аен матур итеб гамәле гыйбадәт, биш вакытка җөреб үткәргән кебек, алдагы көнләребездә дә биш вакыт намазларыбызны җәмәгать белән үтәргә насыйб булса иде. Кылган догаларыбыз кабул булыб, барчаларыбыз сәгадәт дарәйнгә ирешү насыйб вә мөйәссәр булсын.
(0955) 1968 нче Миляди, 27 нче декабрьдә / 1388 нче ел Һижри, 7нче Шәввал, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Өстебезгә туган Шәввал ае һәм Шәввал аеның 1 нче җомгасы мөбарәк булыб, алдагы көнебездә дә барчаларыбызга күб җомгаларны ил, җан тынычлыгы һәм шадлык белән күрергә насыйб булса иде!
Мөхтәрәм мөселманлар! Шәригате мөхәммәдия безне һәрбер начар гадәтләрдән сакланыб. Үзара дошманлыкка, рәнҗетүшегә сәбәб булган начар гадәтләрне безгә һәркайсын хәрам иткән, һәркайсыларыбызның ишеткән вакытда күңелләребезне рәнҗетә торган бер начар гадәт булса, ул да булса бөһтан, ифтира, ягъни бер адәмнең бөтенләй ул эшдән хәбәрсез, күңеленә дә килмәгән бер эшне, ул адәмгә сылтау, бәла ягу. Менә бу Ислам шәригате каршында хәрам булган бер начар гадәт. Чын мөселман адәм асылын, төбен, чынлыгын белмичә, һичбер адәмгә бер гәебне, начарлыкны иснад (ягъни ул шулай, ул болай) тәгаен гәеб анда диб, бөһтан, яла ягудан, әлбәттә, сакланырга тиеш. Бөһтан дигән начар сыйфат Аллаһының каты газабына дучар итә торган мәшәкать белән ирешкән, яхшы гамәлләребезнең әҗер-сәвабларын бетерә торган, (0956) олугъ булган гөнаһдыр.
Җенабе Хак Коръән Кәримдә “Нур” сүрәсендә 15-16 нчы аятләрдә әйтә:
وَتَحْسَبُونَهُ هَيِّنًا وَهُوَ عِندَ اللَّهِ عَظِيمٌ وَلَوْلَا إِذْ سَمِعْتُمُوهُ قُلْتُم مَّا يَكُونُ لَنَا أَن نَّتَكَلَّمَ بِهَٰذَا سُبْحَانَكَ هَٰذَا بُهْتَانٌ عَظِيمٌ
Ягъни: сез ул бөһтанны җиңел эшкә санарсыз. Хәлбуки ул бөһтан яла ягу, гөнаһсыз адәмләрне рәнҗетү. Аллаһы кашында гөнаһ вә үкенечкә сәбәб булган, Аллаһының газабына сәбәб булган зур эшдер, ди.
Шушындый бер бөһтан булган бер хәбәрне, сүзне сөйләүчеләрне ишеткән вакытда да
سبحانك هذا بهتان عظيم
диб әйтергә кирәк иде диб, Коръән аяте тәнбиһ кыла.
Бу аятьнең сәбәбе, нөзүле – хәзрәт хакында Гайшә булса да хөкме гамь (барчабызга) тагын да Аллаһы Тәгалә Коръәндә “Әхзаб” сүрәсендә 58нче аятьдә әйтә:
وَالَّذِينَ يُؤْذُونَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ بِغَيْرِ مَا اكْتَسَبُوا فَقَدِ احْتَمَلُوا بُهْتَانًا وَإِثْمًا مُّبِينًا
Ягъни: шундалаен адәмләр мөэмин ирләрне мөэминә хатынларны кылмаган эшләрен (гаебләрен) кылды диб, бөһтан ифтиракладылар. Ул кешеләр ялган бәла ягу белән ифтира, бөһтан кылу үзләренә зур гөнаһ йөкләделәр, алдылар. Бу аятьнең сәбәбе нөзүле – хәзрәт Галине рәнҗеткән мөнафыйклар хакында иңгән, диләр. Тагын да Аллаһы Тәгалә хәзрәте безгә хыйтаб кылыб:
يا ايها الذين آمنوا اجتنبوا كثيرامن الظن ان بعض الظن اثم
И, иман китергән бәндәләр! Күб гөманнан сакланыгыз, гөманның башкалар хакында начар уйлау – зур гөнаһ булган эш. Бөһтан, ифтира – башкалар хакында яла ягу нахак бәла тагу – безнең динемез тарафындан хәрам булган эш, чөнки бу эшләр кешене хаксызга рәнҗетү, (0957) нахак сүзнең күңелләргә бик авыр тыелыб, рәнҗетелгән адәмгә зур җәбер-золым булачак. Ислам дине адәмләрне кул белән дә, тел белән дә, нинди генә юллар белән булса да рәнҗетүдән каты тыйган, сакланырга кушкан. Бондый эшләрнең ахыры үкенечкә

калуга сәбәб булган, зур гөнаһ булыб, Аллаһының газабына дучар булуга сәбәб булуын безгә ачык белдергән.
Бөһтан сәбәбле Карунны дөньяда ук җир йотыб, Аллаһының газабына ирешде. Коръәндә “Кыйссас” сүрәсендә җенабе Хак әйтә:
فخسفنا به و بداره الارض
Ягъни: Без Карунны, йортыны вә малларыны йирдән йоттырдык.
Бөһтан сәбәбле дөньяда ук [Карун] газабына дучар булды. Карун Муса пәйгамбәрнең атасы белән бертуганның улы була. Зур дәүләткә хуҗа була. Үзенең дәүләте белән горурланыб, тәкәбберләнеб, Муса пәйгамбәрне һәртөрле рәнҗетә. Муса пәйгамбәр туганлык хакда хаклаб, моңа сабыр итә. Шул кадәр кабәхатьлеккә бара ки, бер зиначы, корсаклы хатынны тавыб, күб акча бирергә вәгъдә кылыб, Муса пәйгамбәргә бәла ягыб (бөһтан кылыб), Муса минем белән зина кылды, диб әйтергә вәгъдә ала. Бер бәйрәм көнендә Муса пәйгамбәр халыкны җыеб, шәригать хөкемләрен халыкка өйрәткән вакытда: әгәр бер адәм кеше малын урласа, кулы киселер, зина кылса, рәҗәм кылыныр. Шушындый зур гөнаһлары гадел мөтәһидләр белән ачык беленсә, бу адәмгә шәригать хөкеме шулай булачак, диб сөйләгән вакытда Карун аягүрә басыб: йә Муса, әгәр шушы гөнаһларны син эшләсәң дә, шулай эшләргәме? – диб сорый. Шул вакыт хәзрәт Муса: Аллаһының хөкеме бөтен кешегә бертөсле. Мин эшләсәм дә, (0958) хөкем шулай булачак, дигәннең соңында Карун, әлгыйаз билләһи, Муса пәйгамбәргә: менә синең хакыңда фәлән хатын белән зина кылган, диб әйтәләр. Алайса сине таш белән атыб үтерергә кирәк, диб Аллаһының зур пәйгамбәренә бөһтан, ифтира кыла. Шул вакыт Муса пәйгамбәр хатынны чакырта. Хатын: Карунның зур акча бирергә вәгъдә кылыб, Аллаһының пәйгамбәре шушындый начарлыкны кылды диб әйтергә сүз биреб икърар кыла. Хаклык ачык, мәгълүм була. Муса пәйгамбәр: үзенең ибне гамми (абыемның улы – А.Х.) тарафындан шушы кадәр бөһтан, ифтира (яла ягылуга) ифрат дәрәҗәдә күңеле белән рәнҗеб: йә Рабб, бу залимнең ширендән (явызлыгыннан – А.Х.) коткар, диб Аллаһыга шикаять кылганның соңында Аллаһы тарафындан хыйтаб кылына: йә Муса, җирне сиңа мәсхәрә кылдым. Йирне синең ихтыярыңга куйдым, диде. Шул вакыт Муса пәйгамбәр: и җир, Карунны йот, диде. Тезләренә кадәр батды, икенче дәфга – билләренә кадәр батды, өченче мәртәбә – дөшенми мәртәбәләрендә бөтенләй җиргә батды. Шушы вакыт бәгъзе мөнафыйклар: Муса пәйгамбәр Карунның хәзинәләренә кызыгыб, шушы рәвешле кылды, диюләренә каршы – [Муса] Карунның малын, хәзинәсен, йортларын юк булуын теләде. Бөтен сарайларын, амбарларын җир йотды:
فخسفنا به بداره الارض
Үзе белән бергә йортларын да йиргә гарик итде.
Бөһтан яла ягу гөнаһ кәбаирдән саналыб, бу гөнаһның тәүбәсенең кабуллыгы да берничә шартка бәйләнгән:
1. Мин фәлән адәм хакында нахак бәла, бөһтан кылган идем, менә ул сүз дөрест сүз түгел, диб башкаларга белдерү.
2. Бөһтан кылынган кешедән гафу үтенү.
3. Бөһтан ителгән адәмгә истигъфар идеб, Аллаһы, бу кешедән гөнаһлар гафу ит. Мин аны хаксызга рәнҗетдем, диб.
Соңыннан ихлас күңел белән бу эшенә (0959) тәүбә кылыб, мондый начар гадәтне ташлаб, бу эшендән катгый рәвешдә тыелу. Безнең арабызда шушындый начар гадәтләр күб. Үзебез дә булган начар гадәтләрне күрмибез, башкаларыбызның начарлыгын күрәбез. Ул гына да түгел, булмаган эшләр белән бөһтан, яла ягу кебек начар гадәтләрне кылудан да

тайпынмыйбыз. Әгәр дә без рәсүл әкрам хәзрәтенең:
فطوبى لمن شغله عيبه عن عيوب الناس
Ягъни: нинди зур сөенеч шул кешегә, үз гаебен тикшереб, башкаларның гаебен күрә алмады, үз-үзен төзәтергә тырышды, дигән сүзен исдә тотсак, мондый начар гадәтләрдән ерак булырбыз.
Җенабе Хак барчаларыбызны дөньяда вакытда дустлык-татулыкны җибәреб, дошманлыкка, фетнәгә сәбәб булган мондый начар гадәтләрдән ерак булыб, Кыямәт көнендә шушындый начар гадәтләребез сәбәбле рисвай галим булудан барчаларны сакласын иде.
1969 нчы ел, 3нче гыйнвар / 1388нче Һиҗри, 14нче Шәввал, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Ерак вә якын йирләрдән пакь кием, саф күңел белән җенабе Халик вә Раббел галәмин хәзрәтенең ризалыгын истәб, җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Дөнья Ахирәт сәламәтлек, (0960) дөнья Ахирәт Аллаһының рәхмәте вә бәракәте барчаларыбызга насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Сау-сәламәт булыб, Яңа елны күргәнләребезгә, барчаларыбызга Яңа елыбыз мөбарәк булсын, илләребез, җанларыбыз тыныч, тәнләребез сәламәт булыб, җөмләбезгә шадлыклы, мәхәббәтле ел булсын. Барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять биреб сыйрате мөстәкыйм үзрә яшәб, гомерләребез түгәрәк, әҗәл вәгъдәләребез ирешсә, ахыр сулуларыбызда иманыбызны юлдаш кылыб, сәгадәт әбадиягә (мәңгелек бәхеткә – А.Х.) ирешергә насыйб булсын. Йә, Мөҗибед дәгъват! Йә, Мөҗибес са’илин!
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сүрәи “Ниса”да, 13-14 аятьләрдә безгә караб әйтә:
تِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ ۚ وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ يُدْخِلْهُ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا ۚ وَذَٰلِكَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَيَتَعَدَّ حُدُودَهُ يُدْخِلْهُ نَارًا خَالِدًا فِيهَا وَلَهُ عَذَابٌ مُّهِينٌ
Ягъни: бер кеше Аллаһыга итагать кылса (буйсынса) һәм пәйгамбәргә итагать кылса, Аллаһы Раббел галәмин ул адәмне Үзенең мөэмин колларына вәгъдә кылган нигъмәт, шадлык йорты булган җәннәт бакчаларына кертер. Әгәр бер адәм шушындый мәңгелек, чиксез булган Аллаһының нигъмәт, шадлык йортына ирешдеме, инде бу адәм зур бәхеткә, зур теләгенә ирешде. Әгәр бер адәм Аллаһыга һәм Аның рәсүленә итагать кылмый, каршылык кылыб, чикдән үтсә, менә ул адәмне тәмугъка кертер.
نعوذ بالله من ذلك الحال
Ул тәмугъ әһелләренә хурлыклы, рәнҗеткүче, каты газаблар булгучыдыр.
Инде бу аятьдән аңлашылганча, Аллаһыга итагать кылу кебек, пәйгамбәренә дә (0961) итагать кылу бөтен мөэмин, мөселманга фарыз бурыч була.
Аллаһыга итагать кылу, пәйгамбәргә итагать кылу ничек була? Аллаһының әмер-боерыкларын үтәү, тыйган эшләрендән тыелу Аллаһыга итагать кылу булачак. Инде пәйгамбәргә итагать кылу, буйсыну, пәйгамбәребезнең сүзләрен искә алыб, аның әйткәнләрен үтәргә тырышу. Менә шушы вакытда гына без Аллаһыга итагать кылган булабыз һәм пәйгамбәргә итагать кылган булабыз. Шушы мөбарәк пәйгамбәребезнең әйткән сүзләрен исдә тотыб, хәтердә тотыб, пәйгамбәр кушкан яхшы гадәтләр белән гадәтләнергә тырышу, пәйгамбәр тыйган начар гадәтләрне ташлау, пәйгамбәрнең кушканны гамәл итү, аңа итагать кылу. Пәйгамбәргә итагать кылу Аллаһыга итагать кылу булачак. Җенабе Хак сүрәи “Ниса”да 85нче аятьдә әйтә:
من يطع الرسول فقد اطاع الله

ди. Бер адәм пәйгамбәргә итагать кылса, аның сүзләре белән гамәл итәргә тырышса, тәхкыйк, ул адәм Аллаһыга итагать кыла, буйсына, ди. Пәйгамбәребезнең беркадәр мөбарәк сүзләрен әйтеб узам. Мөбарәк сүзләрне исдә тотыб, шулар белән вәгазьләнеб, дөнья Ахирәтдә Аллаһының рәхмәтенә ирешергә сәбәб булсын.
قال رسول الله صلعم: من اعبرت قدماه في سبيل الله حرمه الله على النار
Бер кеше Аллаһы юлында ике аягын тузанландырса, җенабе Раббел галәмин ут газабын хәрам кылыр (тәмугъдан коткарыр).
Безгә искә алырга тиешле эшләр, безнең мәсҗедгә җомга килүләребез – һәркайсы Аллаһы юлында аякларыбызны тузанландыру. Инде пәйгамбәребезнең шушы сөенечле хәбәре шул вакытда җиренә җиткерергә тиешенчә үткән булырбыз. Тәнләребез, киемләребез пакъ булган шикелле, күңелләребезне бозык, начар ниятләрдән, телләребезне (0962) бөһтан, гайбәтләрдән саклаб, файдасыз сүзләрдән сакланыб, шушы рәвешдә булса, юлда җөрүләребез дә Аллаһы кашында гыйбадәтдән саналачак, чөнки рәсүлулла икенче бер хәдисендә әйтә: берәү пакъләнеб, яхшы ният белән мәсҗед юлында булса, әүвәлге адымында Аллаһы Тәбарәкә аның хаталарын гафу кылыр. Икенче адымында аңа изгелекләр, сәваблар язылыр, ди.
Шушы рәвешле әдәб белән күңелебездән белгәнләребезне укыб, я булмаса, ана телебез белән: йә Раббым, гөнаһларымны ярлыка, дөнья Ахирәтдә рәхмәт ишекләреңне, рәхмәт хәзинәләреңне ачкыл. Мәсҗедгә керсәк, берәүгә уңгайсызлык, күңелен рәнҗетерлек эшләрдән сакланыб, берәүне дә этми-төртми, пәйгамбәребезнең:
ارحموا ترحموا و اغفروا يغفر لكم
Ягъни: рәхимле, шәфкатьле булыгыз, Аллаһының рәхмәтенә ирешерсез. Башкаларның кимчелекләрен гафу итегез, үзегезнең кимчелекләрегез гафу кылынмыш булыр, дигән.
انما يرحم الله من عباده الرحماء
Ягъни: Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Рәхимле. Колларына гына рәхим, шәфкать кылачак, дигән сүзләрен исдә тотыб, шулай ук мөбарәк пәйгамбәрнең алтындан кыйммәтле сүзләре:
أَلا أُخْبِرُكُمْ بِأَيْسَرِ الْعِبَادَةِ وَأَهْوَنِهَا عَلَى الْبَدَنِ ؟ الصَّمْتُ وَحُسْنُ الْخُلُقِ
Ягъни: Мин сезгә гыйбадәтләрнең иң җиңеле, тәнгә дә авырлыгы булмаган гыйбадәтләрдән хәбәр бирмәм, ди. Ул да булса, телеңне кирәкмәгән, файдасыз сүзләрдән тыеб, тик тору, күркәм холыклы булу, Кыйблага каршы утырыб, башкаларга ничек кенә булса да уңайсызлык кылудан сакланыб, – мәсҗеддә тик утыруларыбыздан Аллаһы каршында гыйбадәтдән санала икән.
(0963) Җенабе Хак “Муҗадәлә” сүрәсендә әйтә:
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قِيلَ لَكُمْ تَفَسَّحُوا فِي الْمَجَالِسِ فَافْسَحُوا يَفْسَحِ اللَّهُ لَكُمْ ۖ وَإِذَا قِيلَ انشُزُوا فَانشُزُوا يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ
Бу аять безгә генә караб әйтелгән кебек. Ягъни Аллаһыга иман китергән, Аллаһының сүзенә ышанган адәмләр һәркайчан, сезгә әйтелсә: иркенәегез, киңәегез, башкаларга киңлек кылыгыз. Мәҗлесләрдә, халык күб җыелган урынларда башкаларга киңлек кылыгыз, урын бирегез. Инде, әмеренә итагать кылсагыз, (يفسح الله لكم) Аллаһы сезгә дә ризыкларыгызда, урынларыгызда, дөньяда да иркенлек кылыр һәм Ахирәтдә дә:
وإذا قيل انشزوا فانشزوا يرفع الله الذين آمنوا منكم والذين أوتوا العلم درجات والله بما تعملون خبير يا أيها الذين آمنوا إذا ناجيتم الرسول فقدموا بين يدي نجواكم صدقة ذلك خير لكم وأطهر فإن لم تجدوا فإن الله غفور رحيم
Ягъни: килүчеләргә урын бирегез, күтәрелегез диб әйтелсә, сез күтәрелегез, урын бирегез. Менә шушы рәвешле башкаларга изгелек кылуларыгыз сәбәбле Аллаһы сезнең дәрәҗәләрегезне күтәрер, исемләрегезне яхшылык белән зикер кылынырга сәбәб булыр

һәм Кыямәт көнендә дәрәҗәләрегез күтәрелергә сәбәб булыр, ди. Мәсҗеддә башкаларга урын бирүләребез, үзебезгә уңгайсыз, читен булса да, башкаларга иркенлек кылырга тырышуларыбыз нинди зур, сәваблы хәлләрдән икән.
Мөхтәрәм җәмәгать! Мәсҗедебезгә килгәндә, киткәндә һәм башка вакытларда, һәм мәсҗед эчендә дә, кергәндә, чыкканда да Аллаһының әмерләрен, пәйгамбәремезнең сүзләрен исдә тотыб, шулар белән гамәл итәргә тырышсак, Аллаһыга итагать, пәйгамбәргә итагать кылган булыб, Аллаһы тарафындан вәгъдә кылынган, пәйгамбәр тарафындан сөенеч бирелгән бөек мөкафәтләргә һәм мәңгелек сәгадәткә, теләкләребезгә ирешү булыр.
(0964) Инде мәсҗедгә килү-китүләребез дә, әллә кемләргә начарлык теләү, телләребездә гайбәт, бөһтан булса, мәсҗедгә кергәндә, чыкканда башкаларны этеб-төртеб, телләребез белән бер-беребезгә әдәбсез сүзләр сөйләү белән торыб да, мәсҗеддә мөселманларның яхшы киемләрен, я булмаса, яхшы аяк киемләрен киеб, алар урынына начар аяк киемләрне калдырсак, мәсҗеддән чыгу белән мулла-мөәзинне вә башкаларны гайбәт-бөһтан кылыб, нинди генә юллар белән булса да башкаларны рәнҗетсәк, бу эшләребез Аллаһыга, Аллаһының пәйгамбәренә гасый булу, каршылык булу булыб, Кыямәт көнендә зур үкенечкә калуыбызга сәбәб булачак. Чөнки пәйгамбәр Хода ачык рәвешдә әйтә:
ايها الناس اتقوا الله فوالله لا يظلم مؤمن مؤمنا الا انتقم الله منه يوم القيامة
Ягъни: И, адәмләр! Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз, начар эшләрдән сакланыгыз. Аллаһы берлә ант итеб (فوالله) диб әйтә мөэмин булган кеше, икенче – рәнҗетмәс, җәбер-золым кылмас. Иллә мәгәр ничек кенә булса җәбер-золым кылыб рәнҗетсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ул адәмдән үч алачак.
Бу бик зур сүз Аллаһының пәйгамбәре юк-бар гына, аз гына эшләргә ант итми ифрат дәрәҗәдән сакланырга тиешле. Мөэмин адәм пәйгамбәрнең шушы хәдисләрен ишетә торыб мондый эшләрне кылмас. Тагын да пәйгамбәр Хода әйтә:
ليس منا من غش مسلما او ضره او ماكره
Ягъни: алдаучылар, башкалаларга ничек кенә зарар итүчеләр, күңелләренә авыр тыелган эшләр белән башкаларны рәнҗетүчеләр – минем өммәтемнән түгел, ди.
Мондый эшләрдән саклансак, безнең дөньяда ук тату, тыныч, рәхәт яшәвебезгә сәбәб булган яхшы хәлләр.
(0965) Адәм баласы хатадан хали (ирекле – А.Х.) түгел, кимчелексез – бер Аллаһы. Һәркайсыларыбызда зур кимчелекләр булырга мөмкин. Чын мөселман булыйк, пәйгамбәргә чын өммәт булуны теләсәк, пәйгамбәр кушканча, әсхабе кирам юлын тотыйк. Алар ничек булганлар? Берәү дә, начар гадәтне күрсәләр, артындан сөйләб йөрмәгәнләр. Кеше юк вакытда гына аның турында начар сүз әйтмәгәннәр кеше алдында йөзен кызартмый гына. И, кардәш! Синдә шундый күңелсез гадәт бар, син ул гадәтеңне ташла, диб әйтә торган булганлар.
Инде мөхтәрәм җәмәгать! Хәлемдән килгән кадәр Коръән аятьләре белән пәйгамбәремезнең мөбарәк сүзләрен әйтеб исегезгә төшердем.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте барчаларыбызга тәуфыйк, һидаять бирсен. Җенабе Хакка итагать кылыб, пәйгамбәренә итагать кылыб, аның сүзләре белән гамәл итеб, Аллаһыга, пәйгамбәргә итагать кылган бәндәләренә вәгъдә кылынган әҗер вә сәвабларга ирешергә насыйб булсын.
(0966)
15. 1968нче Миляди. Вәгазь башлана 11нче октябрьдән.
Мигъраҗ хакында бар.

(0967) 1388нче Һиҗрия, 19нчы Рәҗәб, җомга көн
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим.
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәтенең рәхмәтен өмед итеб, ихлас күңелләре белән гыйбадәт кылыр өчен җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Аллаһы Раббел галәмин хәзрәте тарафыннан барчаларыбызга дөнья Ахирәт сәламәтлек, дөнья Ахирәт Аллаһының рәхмәте, дөнья Ахирәт хәер вә бәракәт насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһының ярдәме, сез, мөселман кардәшләремнең догасы сәясендә ерак елларга сәяхәт кылыб (сәфәр кылыб), кан кардәшләрем, мөселман кардәшләрем, шул җөмләсендән күб кенә якташларыбыз белән күб кенә галимләр белән күрешеб, утырышыб, сау-сәламәт әйләнеб кайтдым. Күб кенә дин галимләре белән күрешеб, утырышыб, сау-сәламәт әйләнеб кайтдым. Күб кенә дин галимләре, фән галимләре вә башка мәшһүр, күренекле адәмләр җитешдергән Татарстан үзәге – тарихи Казан шәһәрендән килүем мөнасәбәте илә, гәрчә мин андый ихтирамга лаек адәм булмасам да, (0969) зур ихтирам итеб, зур кунак итделәр. Аллаһы разый булсын һәр күрешкән адәмләргә һәм мәҗлесләрдә һәркайсыларына. Казан мөселманлары исемендән сәламләрегезне табшырдым. Ангрен (Аһәңгәран шәһәре, Үзбәкестанда урнашкан – А.Х.) шәһәрендә үзбәк, таҗик, казак (казах – А.Х.) халыклары катнаш сөннәт туйларында һәм мәет озату мәҗлесләрендә булырга тугъры килде. Һәрбер булган җиремдә утырышкан мөселман кардәшләребез әһле гыйлем дә – һәркайсы сау-сәламәт илегезгә кайтыб, Казан шәһәрендә яшәүче кардәшләребезгә хөлус калебдән (чын йөрәктән – А.Х.) дога вә сәлам табшырырга кушдылар. Өстемә әманәт итеб алган шушы мөселман кардәшләребезнең сәламен табшырам. Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу!
Әгүзу билләһи минәш шәйтанир рәҗим.
Җенабе Раббел галәмин Коръәндә “Тәхрим” сүрәсендә 8нче аятьдә әйтә:
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا عَسَىٰ رَبُّكُمْ أَن يُكَفِّرَ عَنكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ وَيُدْخِلَكُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ يَوْمَ لَا يُخْزِي اللَّهُ النَّبِيَّ وَالَّذِينَ آمَنُوا مَعَهُ ۖ
И, Аллаһыга иман китергән, ышанган бәндәләр! Аллаһыга чын тәүбә белән (чын үкенү белән) тәүбә кылыгыз, чын үкенү белән үкенеб, Раббыңызга кайтсагыз, җенабе Хак гөнаһларыгызны бетереб (гафу итеб), агар сулары булган оҗмах бакчаларына кертүе өмедле. Ул көндә, ягъни Кыямәт көнендә пәйгамбәргә ияреб иман китергән бәндәләр хур кылмас (0970), үкенечкә калдырмас, ди.
Коръәндә “әл-Гыймран” сүрәсендә, 135нче аятендә җенабе Хак әйтә:
وَالَّذِينَ إِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً أَوْ ظَلَمُوا أَنفُسَهُمْ ذَكَرُوا اللَّهَ فَاسْتَغْفَرُوا لِذُنُوبِهِمْ وَمَن يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا اللَّهُ وَلَمْ يُصِرُّوا عَلَىٰ مَا فَعَلُوا وَهُمْ يَعْلَمُونَ
Ягъни: шундалаен адәмләр гөнаһ булган бер эшне эшләгәннең соңында чын күңелләре белән үкенеб, тәүбә кылыб Аллаһыга кайтдылар да икенче мәртәбә шушы начар, гөнаһ булган эшне кайтдан (кабат – А.Х.) эшләмәделәр.
136нчы аятьдә шушы кешеләр хакында җенабе Раббел галәмин шушы рәвешле бушәрәт (шатлыклы хәбәр – А.Х.) бирә:
أُولَٰئِكَ جَزَاؤُهُم مَّغْفِرَةٌ مِّن رَّبِّهِمْ وَجَنَّاتٌ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا ۚ وَنِعْمَ أَجْرُ الْعَامِلِينَ
Ягъни: шушы рәвешле хата вә гөнаһларына тәүбә кылыб, үкенеб Аллаһыга кайткан бәндәләрнең җәзалары, мөкафәтләре гафу ителер. Аллаһы тарафыннан гөнаһлары гафу кылыныб, җәннәт бакчаларында мәңге калучылар, ди.
Шушы аятьләрдән аңлашыла ки, һәрбер мөэмин, мөселман булган адәмгә һәрбер хата, касдән онытыб кылынган гөнаһларыбызга чын күңелдән үкенеб, тәүбә кылу, икенче

эшләмәү барыбызга фарыз була. Иң яхшысы:
فرض على الناس ان يتوبوا و لكن ترك الذنوب اوجب
Гөнаһдан үкенеб тәүбә итү – фарыз, әмма гөнаһ булган эшләрдән саклану, ерак булу – монысы фарызрак була.
Инде, җәмәгать, форсат кулда вакыт шартларын җиренә җиткереб тәүбә кылуда. Югарыда укылган аятьләр буенча вәгъдә кылынган зур сөенечләр бар.
Гөнаһ эшләр төрлечә була:
1. Аллаһы берлән ике арада булган гөнаһлар, ягъни: фарыз важибләребезне үтәмәү, хәрам ризыклар ашау, хәрам нәрсәләр эчү, үз-үзен үтерү, башкаларны начарлыкка өндәү. Менә бу эшләр Аллаһы берлә ике арада булган хәрам. Хәрам гайре золми (ظلمى) булыб, мондый гөнаһларга [кеше] чын күңелендән үкенеб тәүбә кылса, инша Алла, ихласдан булса, Аллаһы гафу итәр. Фарыз важибләрне каза кылырга онытмаска кирәк.
2. Инде хәрам золми булган гөнаһлар бар. Менә бу гөнаһланың мисаллары: көч-куәт беләнме, теләк беләнме, ничек кенә булса да башкаларны рәнҗетү. Менә мондый гөнаһларга никадәр генә тәүбә кылсак да, шушы җәбер-золым итеб рәнҗеткән адәмләрне бәхилләтмичә тәүбәләре, никадәр ихлас белән әйтелмәсен, гөнаһлары гафу ителмәячәкдер. Иң куркынычлы гөнаһ менә шушы – золми булган гөнаһлар. Шәйтан коткысы белән бер-беребезне рәнҗеткән булсак, кирәк малларына җәһатендән, кирәк – телләребез белән бөһтан, гайбәт, нахак сүзләр белән рәнҗеткән булсак, тиздән ул кешеләр белән бәхилләшү, ризалашу кирәк. Инде берәү рәнҗетелгән адәмдән үзенең начарлыгына үкенеб, бәхиллек сорый икән, чын мөселманлык шул гафу итү, риза булу. Бу хакда җенабе әйтә:
الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ ۗ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ
Ягъни: чын тәкъва адәмләр ачу килгәндә ачуларын (0972) йотарлар, ягъни никадәр ачулары килсә дә, Аллаһыдан куркыб, ачулары белән эш итмәсләр. Шулый ук ул кешеләр башкаларны гафу итәрләр, ди. Менә мөттәкыйләр (тәкъва адәмләр) шулар, ди.
Дәхи пәйгамбәр Хода әйтә:
ان الله عفو يحب العفو
Ягъни: Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Гафу итүче, бәндәләренең дә бер-берсен гафу итүләрен сөя, ди.
3. Гөнаһлары адәмләрнең башка мәхлүкъләр (хәйванлар) белән ике арада булган гөнаһлар. Башка гөнаһсыз хәйванларны рәнҗетүдән, аларның хакларына керүдән, җәбер-золым итүдән сакланырга кирәк. Колхозларда, совхозларда хәйван караучылар, кошлар караучылар, шушындый эшдә булган адәмләр хәйванларның ризыкларына хыянәт кылудан, аларны рәнҗетүдән бигрәк дә башларына сугудан бик сакланырга кирәк. Вакытында ашатыб-эчертеб, астларын тазарту – менә болар аларның хакларын ригаять кылу була. Әгәр, киресенчә, тәрбиясенә кимчелек кылса, ризыкларына хыянәт кылса, бу да куркынычлы хәлләрдән. Инде йортларда эт асраучыларыбыз, мәче асраучыларыбызда да һәркайсын хакын ригять кылырга тиешбез аның. Хәзрәт рәсүлнең сәхих хәдисләрендән: бер гөнаһ иясе бер хатынның сусаган эткә шәфкать кылыб сораруы аркасында хәрам гайре золми булган гөнаһысы ярлыканыб җәннәттә булуы; бер хатынның мәче бәйләб ашатмый асравы хакында тәмугълык булуы – менә бу эшләр һәркайсы гөнаһсых хәйванлар хакында зур игътибарлы булуны (0973) искә төшерә торган гыйбрәтле хәлләр.
Хәрам золми булган гөнаһлар хакында дөньяда бәхилләшмичә, ризалашмаенча, Ахирәткә, Кыямәт көненә калса, ул көндә хәлләрнең бик мөшкел булачагы һичшиксез ачык мәгълүм, чөнки сәйидель әнбия, хатимен нәбийин булган пәйгамбәребез (сгс)нең (حجة الوداع) да

сөйләнгән хөтбәсендән ачык мәгълүм: мөбарәк пәйгамбәр актык хаҗендә җыелган җәмәгатькә караб: кем дә кемнең минем өстемдә хакы булса, әйтсен, хакын үтәрмен. Кем дә кемгә, беренчедән, мин кулым беләнме, телем беләнме җәбер кылган булсам, менә тәнем әгъзаләрем миндән кыйсас (кисеп – А.Х.) таләб итсен, Кыямәткә калмасын, диб, пәйгамбәр булса да, Кыямәтнең хәлендән шушы кадәр курыкды. Инде пәйгамбәрләрнең хуҗасы, Аллаһының дусты, хәбибе кеше хакының Кыямәтдә шундый куркынычлы хәлгә калудан курыкса, инде безгә ни калды?
Бәндәчелек белән ир хатынын, хатын ирен, күршеләребезне, башка адәмләр белән үбкәләшкән, бәйләнешкән, хәтер калдырышкан булсак, вакыт үтмәс борын, бәхилләшеб тәүбә кылыйк. Бүгенге эшне иртәгә калдыру ирлек түгел. Үлемнең уйламаган-көтмәгән вакытда килеб җитүен һәрвакыт исдә тотарга кирәк. Хәзрәт рәсүл әйтә:
اني لا توب الى الله في اليوم مائة مرة
Ягъни: мин Аллаһыга һәр көндә йөз мәртәбә тәүбә кылам, ди.
Инде чагыштырыб карыйк: гөнаһларыбыз башда кеше хакларындан, кеше рәнҗетүләрдән һич курыкмый, (0974) гайбәт, бөһтан, хөсед кебекләрне гөнаһ диб дә белмибез.
حاسبوا انفسكم قبل ان تحاسبوا
ди. Инде кеше хәлләренә килгәнче, күз йомыб, үзебезнең гаебләребезне, хаталарыбызны эзләб тикшерсәк, үзебезне-үзебез яхшылыкларыбыз белән яманлыкларыбызны чагыштырыб карасак, киләчәгебез өчен зур файда булыр. Рәсүл әкрам әйтә:
هلك المسوفون
Ягъни: үзләренең начарлыкларына тәүбә итмәенчә кичекдерүчеләр: юк, әле үлем хәбәре килмәгән, кайчан да киләчәкдә бер тәүбә кылырмын әле, диб уйлаучылар – менә болар һәлак булучылар, ди.
Мөхтәрәм җәмәгать! Шушы үзебезнең начарлыкларыбызны искә алыб үкенү (тәүбә кылу) дөнья Ахирәтебезнең төзек булуына сәбәб була. Әгәр бер адәм чын күңеле белән Аллаһы хозурына барыб, бөтен эшләребездә хисаб бирәсе бар диб ышанса, ул адәм бөтен начарлыкдан саклана, бөтен кешегә яхшылык итәргә тырыша, кирәк күргәндә, күрмәгәндә дә, кеше хакдан курка, кеше нәрсәсен урламый, алдамый, хыянәт кылмый, бөтен эшләгән эшләрендә, кирәк – хөкүмәт эшләрендә дә, һәрвакыт мәрхәмәт алырга тырыша. Чын иман, чын динле булган кеше һәрвакыт “хәйрен нас” булырга тырыша. Бу хакда сүз күб булачак, хәзергә шуның белән тәмам итдем.
Аллаһы Раббел галәмин барчаларыбызга тәүбәи нөсух (توبة النصوح) кылырга, бер-беребез белән тату, тыныч, дуст яшәб, Аллаһының Кыямәт көнендә Аллаһының дустлары, сөйгән бәндәләре белән бергә булырга насыйб итсен. Амин.
(0975) Шушы пәйгамбәребезнең Аллаһы тарафындан безгә ингам кылынган әмер-боерыкларын үтәб, тыйганларындан тыелсак, иншәәр Рәхман, җенабе Хакның сүрәи “Ниса”да, 49нчы аятьдә:
وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَالرَّسُولَ فَأُولَٰئِكَ مَعَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِم مِّنَ النَّبِيِّينَ وَالصِّدِّيقِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصَّالِحِينَ ۚ وَحَسُنَ أُولَٰئِكَ رَفِيقًا
Ягъни: Аллаһыга, пәйгамбәргә итагать кушканлары белән гамәл иткән бәндәләр, Аллаһының ингам кылган пәйгамбәрләре садыйклары, шәһидләре салих бәндәләр белән бергә булырлар. Менә бу адәмләр белән бергә булу нинди күркәм булган, нинди зур мәксудка ирешү. Җенабе Хак барыбызга да шушы дәрәҗәләргә ирешүне насыйб итсен.
(0976) Мөхтәрәм җәмәгать! Әфзалель әнбия, сәйидель әнбия булган Мигъраҗ сәбәбле, әгъла галийин булган мөкаддәс урынларыны күрү белән мөшәррәф булган шушы мөбарәк пәйгамбәремезгә чын-чындан мәхәббәт итеб, чын өмед булуны теләсәк, Кыямәт көнендә аның шифагәтенә ирешеб, җәннәтель әгъладә ул мөбарәкнең мәҗлесе белән мөшәррәф

булуны теләсәк, җенабе Хакның:
و ما آتيكم الرسول فخذوه و ما نهيكم عنه فانتهوا
Сүрәи “Хәшәр”, 7.
Әмерен исдә тотыб, шуның белән гамәл кылсак, ягъни пәйгамбәр рәсүл сезгә Аллаһы тарафындан ни китерсә, аны тотыгыз, алыгыз, ни, нәрсәдән, нәрсәне тыйса, тыелыгыз, дигән мәгънәдә.
(0977) 1968нче ел, 18нче октябрь / 1388нче Һиҗри, 26нчы Рәҗәб, җомга көн.
Бисмилләһир Рәхманир Рәхим. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатуһу! Барчаларыбызга җенабе Хакның сәламе вә рәхмәте вә бәракәте насыйб булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Бүгенге көнебезнең киче, бүген кич пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгс)гә вакыйгъ булган тарихи вә мөбарәк киче булган Исра вә Мигъраҗ кичәсе булачак. Бу кичә шундан гыйбарәт: рәсүл (гс)нең бик аз гына вакыт эчендә Мәккә мөкәррәмә шәһәрендәге мәсҗед Хәрамдән Шам виләятендәге Иерусалим шәһәрендә мәсҗед Акса (Бәйтель мөкаддәс)кә барыб, андан Аллаһының теләгән урынларын, рухани гамәлләрне күрү – менә шушы кичәгә Исра вә Мигъраҗ кичәсе диб атала.
Рәсүл (сгс)нең мәсҗед Хәрамдан мәсҗед Аксага баруы Коръән аятьләре белән сабит.
“Бәни Исраил” сүрәсенең башында (“Исра” сүрәсе диб атала):
استعيذ بالله
سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ
Ягъни: шундалаен Аллаһыны тәкъдис кыламын, пакълимен, Үзенең колы – пәйгамбәре Мөхәммәд (гс)не кичләрдән булган бер кичәдә сәйр кылдырды, гиздерде Мәккә мөкәррәмә шәһәрендән мәсҗеде Аксага, ягъни шундаен мәсҗед Акса, (0978) Бәйте мөкаддәс, ул мәсҗед Аксаның тирәсене дөнья Ахирәт бәракәтләре белән мөбарәк кылдык. Хәзрәт Муса (гс) заманындан бирле бөтен пәйгамбәрләрнең вәсый килгән һәм гыйбадәт кылган урынлары итеб кылдык. Һәм аның тирәсендәге акгучы сулар, файдалы йимешләр, һәртөрле үсемлекләр үсә торган, дөнья тормышы эчендә бәракәтле, файдалы урын кылдык, ди. (لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا) Җир йөзендәге галәмәтләребез, билгеләребезне күрсәтмәк өчен сәйр кылдырдык. (إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ) Ул – Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд (сг)нең сөйләгән сүзләрене Белгүче, Ишетүчедер. Һәм Ул Мөхәммәд (гс)гә гали булган, бөек дәрәҗәләрне Бирүчедер. Пәйгамбәрләрнең булган урынларын күрсәтдек, ди. Менә шушы хәзрәт рәсүлнең мәсҗед Хәрамдан Бәйтель мөкаддәскә баруы Мәккәдән Мәдинәгә күчүендән Рәҗәб аеның 27нче кичәсендә вакыйг булган.
Бәйте килеб, бөтен пәйгамбәрләрнең җанлары белән күрешеб, аларга имам булыб намаз укулары риваять кылына. Пәйгамбәремезнең Мәккәдән Бәйтель мөкаддәскә баруына ышану, иман итү тиеш дигәнләр, ышанмау – көфре, хәуфе бар, дигәнләр. Әмма Бәйтель мөкаддәсдән рухани галәмгә сәдрәтель мөнтәһа (سدرة المنتهى) вә бәйт мәгъмүр, хәуз Кәүсәр вә нәһрер Рәхма кебек урынларны күрүенә ышанмасак, заляләт әһелендән булырлар, дигәнләр, фасик булырлар, дигәнләр. Ул рәсүл әкрам хәзрәте шушы гали мәкамләргә ирешкәннең соңында
التحيات الله و الصلوة و الطيبات
Диб, Аллаһыга сәна иткәннең соңында җенабе Хакның тарафындан:
السلام عليك ايها النبى و رحمة الله و بركاته
диб хыйтаб кылынганның (0979) соңында ул мөбарәк, мөхтәрәм пәйгамбәр бер гасый өммәтләрен исенә төшереб, шушы вакытда:

السلام علينا و على عباد الله الصالحين
Ягъни: Аллаһының сәламе, бәракәте безгә һәм өммәтләрмә, Аллаһы Салих, тугъры юлда булган бәндәләренә булсын.
Мөхтәрәм җәмәгать! Гасырыбызның мәшһүр шагыйрьләрендән бер шагыйребезнең Мигъраҗ хакында әйткән сүзләрен искә алыб, узсак, инша Алла, файдадан хали булмас.
Ярты төн булган чагында Мәккә ялтыраб,
Нур тоташды йиргә, күкдән иңде нурдан бер прак.
Булды саф-саф, кылдылар сәҗдә мәләикләр бары,
Җәмге улыб, һәрбер бәни – Муса вә Гайсә җанлары.
Булды заһир, белми диләр, җир йөзе мәнкерләре,
Монда гыйбдият, гыйбадәтнең Илаһи серләре.
Үтмәде керфек кагыб да, күз ачыб җомган заман,
Мәккәгә иңде түшәге җыб-җылы ирди һаман.
Ни саташмак, ни гөман, ни төш иде,
Бер Илаһи вакыйга, Мигъраҗ вә серле эш иде.